ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

4.2008



# Яз. Шигърият. Тукай.



*Казан*



*Кырлай*

# Казан утлары
# Qazan utları

*2008*

# 4

(1026)

*Гамәлгә куючы:*
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Зиннур МАНСУРОВ. Табу дәрте ерак алып китә. *Шигырьләр.* ..... 5
Равил ВӘЛИ. Канатлы татар. *Роман.* ..... 12
Халисә МӨДӘРРИСОВА. Күңелемә яуган карлар. *Шигырьләр.* ..... 50
Марат ӘМИРХАНОВ. Үрбәт ханәкә гыйшкы. *Роман.* ..... 54
Марис НӘЗИРОВ. Кош юлыннан китеп барам. *Шигырьләр.* ..... 74
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Китмә!!! *Хикәя.* ..... 78
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Теләк. *Хикәя.* ..... 87

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Эльвира ҺАДИЕВА. Һәм мәңгелек тәме — гадилектә... *Шигырьләр.* ..... 95
Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА. Булыр. *Шигырьләр.* ..... 97

Хәрәкәттә — бәрәкәт. *«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил ФӘЙЗУЛЛИНның «Идел-Пресс» басмаханәсе генераль директоры Ислам ӘХМӘТҖАНОВ белән әңгәмәсе..* ..... 99

Татарстан язучыларының XVI корылтаен каршылап. ..... 105

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рәшит ФӘТХЕРАХМАНОВ. Милләт темасына этюдлар. ..... 110

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәридә ХӘСӘНОВА. Шигърияттә Сәйдәш яши. ..... 120

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Энҗе бөртекләрен тезгән ул... ..... 130

**ХӘТЕР**

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Гомернең бер елы. *Көндәлек сәхифәләреннән* ..... 134

**ТАРИХ**

Надир ДӘҮЛӘТ. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды? ..... 147

**СӘНГАТЬ**

Рәшит ЯГЪФӘРОВ. Татар халкының тамаша сәнгате. ..... 158

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 163
"Татар энциклопедиясе" битләреннән. ..... 168

**АК ҖИЛКӘН**

Рәйсә ЮСУПОВА. Тэтчер маҗаралары. ..... 173
Эльзира ГАБДЕЛКАЮМОВА. Сөюдә без — тигез. ..... 178
Илшат СӘЙФУЛЛИН. Шаян хикәяләр. ..... 179

"Казан утлары" архивыннан. ..... 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 187

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": романы Р. Вали "Крылатый татарин" (окончание) и М. АМИРХАНОВА "Любовь Урбат-ханакэ" (начало); рассказы Р. ГАБДУЛХАКОВОЙ "Не покидай!", Г. БАЙРАМОВОЙ "Желание"; стихи З. МАНСУРОВА, Х. МУДАРРИСОВОЙ, М. НАЗИРОВА.
"Творчество молодых": стихи Э. ХАДИЕВОЙ, Л. ФАТХУТДИНОВОЙ.
Беседа главного редактора журнала "Казан утлары" Р. ФАЙЗУЛЛИНА с генеральным директором ОАО ПИК "Идел-Пресс" И. АХМЕТЗЯНОВЫМ.
"Навстречу XVI съезду писателей Татарстана": на вопросы анкеты отвечают писатели М. МАЛИКОВА, Г. МУРАТ, Л. ЛЕРОН, Р. РАХМАН, Ю. САФИУЛЛИН.
"Публицистика": Р. ФАТХРАХМАНОВ. "Этюды на национальную тему".
"Литературная критика": статья Ф. ХАСАНОВОЙ "Образ Сайдаша в современной татарской поэзии".
"Книжное обозрение": рецензия Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ на книгу С. Гараевой "Звездные дожди".
"Память": А. ГИЛЯЗОВ. Странички из дневника (окончание).
"История": Н. ДАВЛЕТ. "Татары и башкиры на Дальнем Востоке".
"Искусство": статья Р. ЯГАФАРОВА "Театрально-зрелищное искусство татарского народа".
"Наука": Ф. ГАРИПОВА. "История наших деревень" (продолжение).
Страницы из "Татарской энциклопедии".
"Белый парус": Р. ЮСУПОВА. "Приключения Тэтчера" (продолжение); стихи Э. ГАБДУЛКАЮМОВОЙ; юмористические рассказы И. САЙФУЛЛИНА.
Дневник общественно-культурной жизни.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novels by R. VALI «Winged Tatar» (ending) and M. AMIRHANOV «Love of Urbat-hanaka» (begining);
stories by R. GABDULHAKOVA «Don't leave!», G. BAYRAMOVA «Desire»; poems by Z. MANSUROV, H. MUDARRISOVA, M. NAZIROV.
«Youth creativity»: poems by E. HADIEVA, L. FATHUTDINOVA.
Interview of main editor of magazine «Kazan utlary» R. FAYZULLIN with general director LTD «Idel-Press» I. AHMETZYANOV.
«Towards 16th convention of Tartarstan writers «: writers answer to questionnaire, M. MALIKOVA, G. MURAT, L. LERON, R. RAHMAN, YU. SAFIULLIN.
«Publicism»: R. FATHRAHMANOV. «Etudes to national subjects».
«Literary critiques»: article by F. HASANOVA «Image of Saydash in conte, porary Tatar poetry».
«Book review»: review by E. SHARIFULLINA on book of S. Garaeva «Starry rains».
«Memory»: A. GILYAZOV.
Pages from diary book (ending); N. DAVLET.
«Tatars and Bashkirs on Far East».
«Art»: article by R. YAGAFAROV «Theatrical-entertainment art of Tatar people».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from «Tatar encyclopedia».
«White sail»: R. YUSUPOVA. «Thetcher's adventures « (continuation);
poems by E. GABDULKAYUMOVA; humorous tales by I. SAYFULLIN.
Diary of social-cultural life.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.03.2008 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т–326 Тираж 5182.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.



Зиннур
Мансуров

# ТАБУ ДӘРТЕ ЕРАК АЛЫП КИТӘ...

## Моңсу өннәр

**Гомер буе килеп торган өннәр
бер иркәләп җанны, бер телгән.
Тагын тавыш: гади генә түгел—
сихри тынлык белән өртелгән.**

**Тәшвиш тулы кальбем аша тойдым:
әнкәемнең гүре ишелде!
Минем өчен бу хәл бөтен җирнең
тетрәп алуына иш иде...**

**Үзәнлеккә төштем, үз-үземә
әйтә-әйтә: "Тып-тын урын тап!"
Әсәрләнеп куйдым—әлмисакның
кайтавазы үлде ухылдап...**

**Чү, ят мәкам! Колак чың-чың итте,
телгә чәчрәп чыкты... көл тәме.
Иңемдәге көндәш фәрештәләр
әллә чынлап сүзгә килгәнме?!**

**Моңсу өннәр килеп торган саен
арта гына бара гамьнәрем.
Сизенәмен газиз аһ-зарларны
тыңлый алуымда ямь барын.**

## Сөембикә манарасы

**Бәгъзе затлар, авып китә калса, диеп,
юкка алдан төрле-төрле уй корган,—
манараның нигезенә, мәрмәрташтай,
кан-яшь, моң-зар дуен булып утырган.**

Зиннур МАНСУРОВ (1949)—*шагыйрь, публицист; "Кул бирәм", "Күңел сәфәре", "Җәрәхәтле йөрәк җылырак", "Күңелдә фидаи яшәсә" һ. б. китаплар авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

**Көләч йөзле ясинчылар нигә һаман,**
**авышкан, дип кычкырыша бар көчкә?**
**Сөембикә манарасы тоташкандыр**
**фәрештәләр йөри торган баскычка.**

**...Алла белсен, әллә юри, әллә чынлап**
**тама анда инде тагын кем яше?**
**Юк, манара төп-төз килеш басып тора,**
**кыегаеп киткән бары дөньясы.**

## Үкенечле җәй күзләре

**Йөрәк тетри. Хәзер төрле яклап**
**ябырылыр миңа йөз кинә.**
**Нигә инде, аучы сүзен тыңлап,**
**мин тиеннең аттым... күзенә?**

**Моң-зар тулы тоташ көзләр генә**
**кабатланыр шушы җәйдән соң...**
**Җәза көтә мине. Күктә яшен**
**тарта, әнә, утлы җәясен.**

**Үзем генә беләм: тәүбә сүзен**
**күңелемә ничә кат яздым,—**
**малай чагым карап торган күзне**
**нигә кургаш белән капладым?**

**"Затлы тире—артык җөйләр ясап,**
**боза күрмә",—диде сунарчы.**
**Нәкъ шул мәлдә кальбем өтеп алды**
**тиен күзләренең соң яше.**

**Кемдер җанын йорткән затка аттым—**
**әллә болар барсы төш микән?**
**Гомер буе күзгә тулган дөнья**
**агып ятар канлы тишектән...**

**Әллә нинди гайре фасыл килде**
**минем өчен шушы җәйдән соң.**
**Аяк тартмас көнне ауга барып,**
**нигә тоттым Нәмруд* җәясен?..**

## Сөлекче

**Бакый йортта, рухың борчып, йокың бүлгән**
**кемнәр булсын—янә-дәхи без инде.**
**Киңәш бирче, Бану апа, төшкә иңеп—**
**кешеләрнең каны тәмам бозылды.**

**Озак еллар сулык-сулык әрнеп торыр**
**яраларга шайтан үзе төкергән.**
**Иләт җанын сөлек салып имләр идең—**
**арабызга чиге ерак төн кергән.**

---

* Нәмруд—Борынгы Бабилның гарше әгъләгә ук атып кизәнгән хөкемдары.

Әле һаман тыныч түгел газиз халкың,
сызлый күңле, сызлый канын агулап,—
ләйсән яңгыр җебе буйлап күккә ашкан
суалчаның кулларыңа ал юллап!..

Ялгыз өйдә гомер кичеп яткан чакта,
терек суда дәва гына үрчетеп,
китеп бардың, Акъәбием, гавам канын
эчеп туймас хакимлеккә үч итеп.

Синең хакта хәтта бераз уйлап тору
зәһәр сеңгән тамырларны ныгыта...
Мәхлукларың хисап кылмас Аллаһыга,
канга сусар адәм затын ни кирәк?

Борчу өчен кичер инде, Бану апа—
димәк, сиңа җиткерәсе уй булган.
...Мыжгып торган сөлек тулы бәллүр савыт
күңелемә... шәмаилдәй уелган...

## Шундый инде Идел-йорт...

**(Шәүкәт Гаделшага)**

*"Минем сибирияле бер*
*татар дип әйтүем сезне*
*чит күрүдән түгел..."*
Габдулла Тукай

Минем өчен талип чактан бирле
сораулардан торган сер идең.
Ничек шулай яшәп калдың монда—
әллә... Себереңнән сөрелдең?

Сине бездә кем соң каршы алды:
"Чит җир түгел,—диеп,—үз җирең!.."
Ятим җаның һәрдәм татый булыр
һиҗрәт кылуларның әҗерен.

Андый хәлдә, аңлыйм, кальбең аша
суырылып күпме көч чыга!
Җиңел түгел монда синең кебек
җир-су телен белгән кешегә...

Күчемеңме кушты күченергә,
тартып китердеме Идел-йорт?!
Бәгыреңне инде ахыргача
әрнүләргә, кардәш, иркен тот.

Илдә үзен үксез бала итеп
тойганнарга, Тәңре, тәкать бир!
Безнең кавем хәзер бүтән инде:
үч-кинәле, көнчел, тәкәббер...

Үзгәртелгән ыру үзәгендә
утырадыр төсле башка мин.
Сизәсеңме сызлар сөяләңә
елан аягының басканын?

Шаман мисле әфсен укып җибәр,
артык садә булу тәү хатаң...
Иксез-чиксез дала кайтавазы
татар күңлен ничек тарайткан?!

Берәмтекләп саный варисларын
чорлар кичеп килгән барымта,—
синең башка гына ява сыман
безнең өммәттәге бар нөктә...

Кемдер чалдон итеп саный бирсен,
ә миңа син күптән үз инде.
Әмма кара-каршы килгән мәлдә
кайчак җайсыз сизәм үземне.

Юк, дуслыкның асыл җепләренә
кунмагандыр әле кер-тузан,—
куркам
синең рия йокмас йөздә
ямьсез якларымны күрүдән...

Сабырлыклар сора Себереңнән—
менә шундый инде Идел-йорт.
Бәгыреңне насыйп әрнүләргә
ахыргача, шагыйрь, иркен тот.

## Кан өне

(Ыру бәете)

Нәсел күрке булып үскән угыл иде асылда,
япь-яшь башын ашадылар канга туймас ач елда.

Кара хәбәр елан кебек чагып алды бәгырьне;
ана яше тамган чакта тулгак тотты бар Җирне,—

"Шулай, балам: һәммә ямьнәр үзәгендә гамь икән,
тамырыңда агып ятса нәзер-хәбәр гаиптән..."

Токым канын көчәйтергә ул никадәр теләде!—
Калым хакын шаһ-атага гомерләтә түләде.

Үксез яры күрде микән башка сыймас бу төшне:
канын, бахыр, сөргендәге... черки белән бүлеште.

Ата-баба әманәте тибеп торса йөрәктә,
мәгънәсезгә шаһит китү үкенечле бигрәк тә.

Көне җиткәч, хисап тотар хәтта золым кануны.
Ә җир-күктә бәргәләнә тынгы тапмас кан өне...

## Акыл вакыты

О, иртәнге сихри сәгать,
җирнең моңга талуы!
Баштанаяк өтеп ала
томан катыш таң суы.
Баш шундый саф!.. Шаулап килер
тагын исәп ташуы.

Уйлап ният кылыр өчен
җайлы вакыт иллә дә:
фәрештәләр, киңәш биреп,
пышылдаша иңнәрдә;
аң-зиһенне үткерлидер
салмак искән җилләр дә...

Хәтта мәгънә чыгарасың
сүнеп бетмәс төштән син.
"Амин" күбрәк иңә иртән—
уйлар уйга тоташсын!
...Иблис көлеп куя кебек:
"Татар акылы төштән соң.
Татар акылы төштән соң..."

## Битарафлык

*Кеше яхшылыкның яхшылык икәнлеген белгәч, Җирдә яманлык та барлыкка килгән.*

Борынгы кытай гыйбарәсе

Шуның кадәр хәттин ашып киткән вәкарь
булса булыр икән Аллаһ кулында!..
Нигә сиңа үсенергә форсат бирим—
селкенмидер күңелнең бер кылы да.

Дегетеңне хәтта гамәл дәфтәремә
сөртер сымак кылансаң да ис китми.
Карындагы бала кебек күренәмдер—
нахак сүзне колакларым ишетми.

Тамырларың буйлап аккан шайтанлыкны
күрә торып дәртләндермәм бит инде.
Сиңа тансык "чәбә" сүзен әйтми генә,
үтең белән көн дә юам... битемне.

## Ихтыяр

Күзгә алсу томан бөркеп тора
яшьлектәге тоташ җыр-уен.
Искә төшә сине ихлас белән
фәрештәгә тиңләп йөрүем.

Гарше затны шулай җирдә итеп
күргән өчен Аллаһ кичерсен...
Фәрештәләр белән охшашлыгың
бар икән бит—күкләр көч бирсен.

**Ихтималлап куям: ихтыярдан**
**син дә, ахры, мәхрүм калгансың.**
**Азман чорда ничек ак-пакь килеш**
**яшәп була мондый хәлдән соң?!**

**Акыл гына каршы тора алмый**
**җитмеш җәтмә корган әгъвага.**
**Сөендерми кояш чыгулары,**
**көчең суыргандай ай бага.**

**Гомер иткән нигез тетрәп куя,**
**җитмәгәнгә асыл бер ниргә...**
**Ихтыярсыз кылган гамәлләрнең**
**барсы өчен җавап бирергә.**

**Хәерлегә булсын—үз-үземне**
**кисәтәмен: тирән кермә син,—**
**аңа хаслап "амин" әйткән чакта**
**фәрештәнең**
**теле көрмәкләнә күрмәсен.**

## Кирәкмәгән очрашу

*Н. абый авызыннан*

**Әллә кайчан сөеп йөргән җанкай**
**беркөн хәбәр салгач аһ иттем.**
**Аулак өйгә чапкан егет кебек,**
**очрашуга шундый ашыктым!**

**Мәрхәмәтсез тәүге мәхәббәттән**
**кичердемме әллә аз җәфа?!**
**Тизли төшкәч, йөрәк кагып куйды—**
**арттан куды төсле аждаһа...**

**Кара-каршы килеп күрешкәндә**
**сыннарыбыз алга йөгенде.**
**Шундук тойдым: мине ничә еллар**
**тартып торыр ишем юк инде.**

**Шулай озак дәшми гомер иткәч,**
**үзен ачып, нигә сүз әйтте?**
**Челпәрәмә килде сөйләшкәндә**
**күңелдәге асыл сурәте...**

**Теләмичә тасма телләнәбез,**
**кайный бәгырьдәге бар ачы.**
**Камыр ташый, диеп, җәһәт кенә**
**хәтердән дә китеп барсачы!..**

**Ерактагы сөю каршысына**
**бардым юкса озын тау ярып.**
**Үчектергеч мондый очрашуны**
**Тәкъдирчемме язган шаярып?!.**

## Аклану

**Теге чакта булган иде бугай
җәһәт белдерәсе ниятең.
Ишетмичә калдым пышылдауны—
күкләр күкрәгәндә ни әйттең?**

**Игътибарсыз идем өннәремдә,
инде сизгер хәтта төшкә мин.
...Янә күрми калдым йөзең буйлап
күз яшьләре агып төшкәнен.**

**Ләйсән явып торган матур көндә
нигә эле, нигә еладың?—
Язын тәүге яшен алып килгән
яңгырлардан сорыйм ел да мин.**

**Гомер буе җавап эзләп сызлый—
фани тәнем түгел, бу җандыр.
Белми калдым, димәк, ерак күкнең
ихтыяры шундый булгандыр.**

## Югалту

**Бергә тапкан инде байтак булды,
насыйп өчен шактый куандык.
Алда гомер аз-маз бардыр әле—
ачылмыйча калды күп сандык.**

**Табу дәрте ерак алып китә—
шушы юлдан ничә ел кайттык.
Тәүге мая кулга кергән чактук
нәрсәнедер саксыз югалттык.**

## Сиздерү

**Миңа гомер өстәп торган һәрбер елны
башлап кына китмәк булам ак биттән,—
төштән очып өңгә кайтып кергән төсле,
иске эзгә төшә барсы актыктан.**

**Өр-яңадан кормак булсам тормышымны,
дертләп куям әллә нинди ят өннән,—
яшен сызып үткән кебек, тәкъдир сүзе
саркып чыга күкнең теге ягыннан...**

Равил
Вәли

# КАНАТЛЫ ТАТАР

РОМАН

## 31

Марго Фонтейн үз остазын башта аңлап җиткермәде.

Рудольф Нуриев белән аны әүвәл нигә нәкъ менә «Жизель» балетында биетеп карау кирәк булды икән? Бу балетны Маргоның бии башлавына инде биш былтыр гына түгел—хәтта ки чирек гасыр! Ул чакта әле аның бүгенге сәхнә пары Рудольф өстәл астында мүкәләп йөрү генә түгел, бу якты дөньяга тумаган да булган!

Әйе, «Жизель»дә Марго егерме биш ел биеде. Ләкин, турысын әйтергә кирәк, бу әсәрдәге төп рольне башкарып, ни тамашачылар йөрәгендә тиешле уңыш казана, ни үз җанында рухи канәгатьләнү таба алмады. Эш нәрсәдә, сәбәп нидә иде соң? Менә монысын исә шушы көнгәчә Марго үзе дә аңлап җиткерә алмады.

Ә британ балетын кырык еллап әйдәгән Нинетт де Валуа һәммәсен дә алдан күреп, алдан сизеп йөргән иде, әлбәттә. Тик үз карамагында Фонтейн янәшәсенә бастырып биетерлек Рудольф Нуриевтай башкаручы булмагач, дөнья балетының уртак кимчелегенә әйләнгән әлеге чирне дәваларга керешә алмады.

Һәм менә балет сәнгатенең иң затлы җәүһәрләреннән саналган әсәрне яңача куелышта сәхнәгә менгерер вакыт, ниһаять, җитте кебек, шөкер.

Нинетт де Валуа «Жизель» балетына моңарчы Рудольф Нуриев керткән яңалыклар белән тулысынча килеште. Ә бу яңалыкларның иң җитдие, иң мөһиме—принц Альберт белән аның тарафыннан алданган гади авыл кызы Жизель арасындагы мөнәсәбәтләрне ничек тасвирлап күрсәтү мәсьәләсенә кайтып кала иде. СССР театрларында тигезсез бу мәхәббәт бары тик сыйнфый караштан, ягъни байлык яки ярлылык ягыннан гына сурәтләнеп килде. Ә менә Рудольф Нуриев, балет сәнгате тарихында беренче мәртәбә буларак, әсәрдәге төп геройларның берсе Альбертны әрсез һәм оятсыз принц түгел, ә яшьлек җилбәзәклегенә бирелеп кенә кызны алдаган, үз ялгышы өчен бик үкенүче яшүсмер зат итеп күрсәтә алган. Аерма бар һәм бик зур! Әлеге аерма әсәрнең тамашачыга тәэсир һәм тәрбияви көчен бермә-бер арттырып җибәрә.

Нинетт де Валуа, тәҗрибәле балетмейстер буларак, «Жизель» балетының

*Ахыры. Башы 2, 3 саннарда.*

Рудольф Нуриев тәкъдим иткән яна вариантын кочак җәеп кабул итте. Ә инде дирижер Джон Ланчбери белән хореограф Фредерик Аштонны әйткән дә юк—алар тыштан гына артык усал, артык җитди тоелган, ләкин үтә нечкә хисле татар егетенен Лондон сәхнәсендә биеп күрсәткәннәреннән күкнен җиденче катында иде.

«Жизель» балетына Рудольф Нуриев керткән искиткеч уңышлы яналыклар өчен иң күп сөенгән кеше, әлбәттә, Марго Фонтейн булды. Репетицияләр вакытында яна пары тарафыннан әйтелгән кайбер тәнкыйть фикерләрен, күпме еллар бии-бии бөртекләп тупланган абруен бер читкә куеп торып, ул тыныч кына кабул итә белде.

Үз шәкертенен мондый сабырлыгын күреп, Нинетт де Валуа аңа эчтән генә рәхмәт укыды. Ә Рудольф, Маргонын капма-каршысы буларак, артык тиз кызып китүчән һәм кайнар холыклы иде. Мондый холыклы биючене тезгендә тотарга нәкъ менә Марго сабырлыгы кирәк тә! Алар икесе—нәкъ чиләгенә күрә капкачы! Сәхнәдәге парлашып биячәк гомерләре дә, Ходай кушып, озын-озак дәвам итәргә охшаган.

Өмет тулы репетицияләр, тир тулы күнегүләр артта калып, менә күптән көтелгән көн дә килеп җитте. Ковент-Гарден театрына «Жизель» балетынын яна куелышын карарга килгән тамашачылар арасында Бөек Британиянен әнкә-королевасы Елизавета да бар иде.

Сәхнәдә иң еш барган спектакльнен төп герое принц Альбертны бер үк төрле буяуларда күрергә Лондон тамашачысы инде күптән күнегеп беткән иде: ул—таза-чибәр, ул—кыю-батыр, ул—дәртле-егәрле... Ләкин монарчы бу рольне башкаручыларнын берсе генә дә Альбертнын алдаулы сөюдән туган рухи газаплануларын, үкенүле кичерешләрен күрсәтеп бирә алмады. Дөресрәге, теләмәде.

Ә Рудольф Нуриев очына-очына биегән Альберт нечкә хисле йөрәге һәм үкенүле тойгыларга бирелергә сәләтле вөҗданы булган бөтенләй яна, бөтенләй бүтән төрле принц иде. Әйтерсен, бу образны күпме еллар кысып, буып торган, аңа киң һәм иркен сәнгать мәйданында иркенләп, бар көченә алдырырга ирек бирмәгән рухи тышавыннан азат иттеләр!

Марго Фонтейннын биюен дә танырлык түгел иде. Альберт-Рудольфнын зур итеп ачылган төпсез яшькелт күзләреннән бертуктаусыз агылучы кайнар хис ялкыны шундук Жизельнен төгәл-нәфис, наз тулы хәрәкәтләренә көчә бара иде. Әнә ул күзгә күренмәс дәрәҗәдәге вак-вак адымнарыннан чигү чиккәндәй, үзен мәрхәмәтсез алдаган егете тирәсеннән бер кат биеп узды. Юк, биеп узмады—әйтерсен, әнә шул вак адымнары кебек тезеп-тезеп, сәхнәгә ул ачы һәм әрнүле күз яшьләрен тамызды!

Ә Жизель кабере читендә Альбертнын бөтерчек кебек әйләнеп өскә томырылуы һәм һавада эленеп торганда, аккош канат кагынгандай, аяк балтырлары белән бер-берсенә җинелчә генә кагып-кагып алулары! Тамашачы бәгыренен иң нечкә төшләренә килеп тия торган әлеге хәрәкәтләр—Марго Фонтейннын күз яшьләре кебек тамган вак адымнары белән Рудольф Нуриев башкаруындагы антраша-силәр әйтерсен лә бер йөрәктән ургылучы бер үк хисләр ташкынынннан яралган һәм бу гүзәл хәрәкәтләрне тиз генә онытырлык түгел иде!

Балет сәхнәсе белән инде бөтенләй хушлашырга җыенып йөри башлаган Марго Фонтейн бу кичне үзен яңадан тугандай хис итте. Юк икән, болай булгач, анын иҗат, димәк, гомер көзе дә шактый кичегеп киләчәк икән бит әле!

Лондон сәхнәсендә яна туган бию парын хуплап, бу кичтә аларны сәхнә алдына барлыгы егерме дүрт мәртәбә чакырып чыгардылар. Һәр чыгуларында, «Жизель» балетына керткән үтә мөһим яналыклары өчен рәхмәт билгесе

булып, үзләренә кочак-кочак чәчәк бәйләмнәре яуды.

Ә азакта бөтен тамашачылар йөрәгенә тагын бер рәхәт тетрәнү өстәгән мондый хәл булып алды. Королева әби Елизаветаның үзеннән дип, менә Жизель ролен бу кичне моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә гаять оста, галәмәт рухланып биегән Марго Фонтейнга берсе-берсе чынаяк тәлинкәсе кадәрле кып-кызыл роза чәчәкләре бәйләмен китереп бирделәр. Уттай янган шул чәчәкләрнең берничәсен ул ефәк тасмалы бәйләмнән суырып алды да, нәзакәтле кул хәрәкәтләре белән янәшәсендәге Рудольфка сузды:

—Ал, Руди—болары сиңа! Язмышыма соңлабрак булса да килеп керүең өчен чиксез рәхмәтлемен үзеңә!

—Мин дә...—дип пышылдады Рудольф һәм, бер аягы белән тезләнеп, Фонтейнның кайнар-йомшак кулларын шашып-шашып үбә башлады.

—Син бүген бәхетлеме, Руди?

Рудольфның әле генә яшьлек дәрте бөркелгән күзләре бу юлы Маргога бик моңсу карады:

—Сиңа бит яхшы мәгълүм, Марго—минем әле моңарчы беркайчан да үземне бәхетле итеп тойганым булмады.

—Ә менә бүген? Хәзерге мизгелдә?

Марго бүләк иткән чәчәкләрне Рудольф сүзсез генә күкрәгенә кысты. Ләкин Фонтейн барысын да аңлады. Чөнки чәчәкләр сөйли белә: кызыл розалар—ошату һәм ярату билгесе!

Ике биюченең, алдан сөйләшеп куйгандай, үзара хөрмәт белдерешүе шулхәтле табигый килеп чыкты ки, яңа туган сәхнә парының озак, әле бик озак дәвам итәчәк данлы киләчәгенең чын күңелдән хуплап, көчле кул чабулар ишетелде. Меңләгән тамашачыларның бердәм теләген үтәп, алар мондый хәрәкәтләрне алдагы көннәрдә дә еш кабатларга мәҗбүр булдылар. Тик горур холыклы Марго Фонтейн аларга аз гына үзгәреш кертте: Рудольф Нуриев аның яшәгән еллары һәм бөртекләп тупланган осталыгы алдында баш ия икән дип уйламасыннар өчен, үзе дә чәчәкләрне яшь биючегә тезләнеп бүләк итә башлады.

## 32

Бөек Британия королевасы Елизаветага «Жизель» балетының яңача куелышы шулхәтле ошаган иде ки, ул аны өч көн рәттән карады. Аннан күреп—принцесса Маргарет һәм бүтән ледилар да!

Өч көн рәттән, очсыз-кырыйсыз чиратлар аша үтеп, Лондон тамашачылары Король балеты театрына агылды. Өч көн рәттән алар телендә Марго да Рудольф, Рудольф та Марго гына булды.

Тышкы дәүләти эшләрендә ашыгыч мәшәкатьләр чыгу сәбәпле, Панаманың Бөек Британиядәге тулы вәкаләтле илчесе Роберто Ариас атаклы «Жизель» балетының үз хатыны катнашындагы яңача куелышы премьерасына бара алмыйча калган иде. Ләкин үзенең күптәнге гадәтенә барыбер тугры калды: тотты да әлеге спектакльдә катнашучыларны дингез сәяхәтенә чакырды.

Ял көне иде. Шуңа күрә ирле-хатынлы Ариас-Фонтейннар оештырган мондый круизларга күптән күнегеп беткән Король балеты артистлары кыстатып тормадылар: оҗмахка төртеп кертмиләр дип, «Кристина» исемле бик матур яхта килеп туктаган дебаркадерга бер-бер артлы агылдылар. Чегәндәй каратут йөзенә юмарт елмаю кундырып, аларны култыксалы басма каршында Роберто Ариас үзе каршы алды.

Менә дебаркадердан сузылган басмада чираттагы пар—болгар кызы Сания Арова белән татар егете Рудольф Нуриев күренде. Совет киртәләре аша ярсу аттай дулап кача алган бу мөселман биючесенә Роберто Ариасның

ихтирамы башта бик зурдан иде. Ләкин олы сәхнәдән инде бөтенләй төшәргә ниятләп йөргән кырык ике яшьлек хатыны Марго Фонтейн, кем әйтмешли, әле борын асты да кибеп житмәгән шушы япь-яшь жилкенчәк белән «Жизель» балетында биеп, көтелмәгән һәм монарчы күрелмәгән уныш казангач, хәлләр кинәт кирегә үзгәреп китте. Әйе, куянныкыдай жөйле һәм калын-сусыл иренле авызын ачкач әлегә арык үпкәсе генә шайләнсә дә, егет ярыйсы ук горур күренә иде! Ә Ариаслар исә, дөнья кендеген үзләре тотып яшәгәч, горур кешеләрне янәшәләренә якын да жибәрмәделәр. Әйе, монысы шулаен шулай... Аннары, йә кем... бөтен дөньясына билгеле кайсы балеринаның хәләл ире инде үз хатынының яшьлек дәрте ташып торган икенче бер ир кисәге белән кочаклаша-кочаклаша биюенә көнләшмичә кала алыр икән? «Жизель» балетының янача куелышын үзе карый алмаса да, Рудольф Нуриевка Марго Фонтейнның нинди кызыл, нинди уттай янып торган розалар бүләк итүен аңа бит килеп әйттеләр, житкерделәр инде. Ә кызыл розаларның чын сөю билгесе икәнлеге күптәннән һәм күпләргә билгеле! Юк, тыштан гына беркатлы күренгән бу татар егете белән талканны коры тотарга кирәк: йомшак жәеп, катыга утырта—ягъни мәсәлән, инде пеләшләнеп килгән баш түбәнә ике жәпле мөгез куя күрмәсен!

Хәер, мөгез дигәннән...

Бик тә нечкә, бик тә нәзакәтле бу мәсьәләдә Роберто Ариас үзе дә бигүк төшеп калганнардан түгел иде. Аның инде сәхнә өчен зерә дә чибәр, ләкин гаять түзем һәм сабыр холыклы итеп яратылган Маргосының әле бер сызык та кунарга өлгермәгән матур маңгаена дистәләп кенә түгел, ә йөзләп мөгез утыртканы булды бугай. Бу турыда бөтен Лондон, бөтен Панама белә. Тик, нишләсен, түзә шактый олыгаеп—инде дүртенче дистәсен тутырып килгәндә генә беренче мәртәбә кияүгә чыга алган Марго апагыз! Дөрес, яшь чагында аның кулын сораучылар күп булган диләр. Әмма кечкенәдән балет сәхнәсенә үлепләр гашыйк кызны үзенә карата алырлык ир-егет табылмаган. Иренең нәсел үгезе кебек үзенә һәрдаим, жае чыккан саен хыянәт кылып яшәвен Марго яхшы белә. Ләкин алар икесе дә үз язмышлары—берсенең еш кына ужымга чыгып керүе, башкасының дәрәжәле һәм бай илче хатыны булып гомер кичерүенә күптән күнегеп беткәннәр иде инде.

Тукта, чү!

Әгәр кырыс язмыш әле бер аягы сәхнәдә, икенчесе исә бишектә килеш үк бар дөнья игътибарын жәлеп итә алган бу егетне аларның чын мәхәббәтсез, ләкин инде шактый ипле арасына сугылачак чөй сыйфатында жибәргән булса? Ягъни мәсәлән, кырык яшенә житеп тә әле чын сөю, чын ярату хисләрен кичереп карамаган Маргоны алай-болай үзенә гашыйк итеп куйса яисә аңа үзе гыйшык тота башласа? Булмас димә—дөнья бу! Аеруча сәнгать диган, балет сәхнәсе диган иректе мәхәббәт диңгезендә парлап йөзүчеләр арасында?!

Үз хатынын көнләштергән ир үзе дә көнчелек утында интегүчән була икән!

Култыксалы басма аша узган чираттагы кунаклар үзе каршына килеп туктагач, хужа кеше борчулы һәм көнчел уйларыннан, ниһаять, айнып китте:

—О-о, хуш киләсез! Әйдәгез, әйдә—яхтам түренә үтегез!—диде ул, ярыйсы ук салкын йөзенә ясалма елмаю билгеләре кундырырга тырышып.

Роберто Ариас янәшәсенә килеп баскан ап-ак джинси чалбарлы Марго Фонтейн ирен яңа кунаклар белән таныштыруны кирәк тапты:

—Руди...

—О-о, мистер Нуриев!.. Без инде күптән таныш—күрешеп тормасак та буладыр кебек...

Рудольф күрешер өчен сузган кулын, утка пешкәндәй, ялт кына кире тартып алды:

—Күрешмик соң алайса.

Горурлыгына көч килүдән, Рудольфның йөзе чөгендер төсле кызарып чыкты. Ачуың чыкмаслык та түгел: бер дигән хатыны өстеннән йөрүе бөтен ил теленә керүе җитмәгән, өстәвенә, бүтәннәрне түбәнсетеп, мыскыл итеп маташа! Юк, әҗәткә каршы йомыш дигәндәй, ачуын кайтарачак әле Рудольф бу гарьләнүләрнең, бик тиз кайтарачак!

Һәм Роберто Ариасның кәпрәюле тәкәбберлеген чеметтереп үтәрлек андый беренче җай тиздән табылды да.

—Ә бу туташны кем дип белик?—диде хуҗа кеше, май урлап ашаган мәченекедәй ялт-йолт карашын Дунай яклары кызына юнәлтеп.

—Сания... Сания Арова.

Монарчы үзенә таныш булмаган сәер исемне ишеткәч, гаҗәпләнүдән, Роберто Ариасның чабата кашлары тар маңгае өстендә бергә килеп кушылды:

—Сания??? Ә нигә, әйтик, Соня түгел?

Кан-кардәшен яклап, бу юлы инде Рудольф сүзгә кушылды:

—Мистер Ариас! Сания бик матур исем, минемчә. Үзе татарча, нәкъ үзебезчә! Шулай бит, Сания?! Безнең халыкта мондый исемле хәтта бер шаян җыр да бар.

—Җырлап күрсәт!

—Юк, мистер Ариас, минем ул җырны көйләп түгел, ә биеп күрсәтәсем бик килә.

—Күрик соң, алайса.

—Юк. Хәзер үк түгел—бераз соңрак!

—Килешәм...

Чеметтереп төрттерү, авырттырып бәхәс уяту дигәндә, Роберто Ариас үзе дә кимен куймый иде:

—Сания татарның бик матур исеме булгач, нигә соң әти-әниләрең сиңа да шундыйракны кушмаганнар?—диде ул, кинаяле иттереп.

—Нindirәкне?

—Һәрхәлдә, Адольф та Рудольф түгел инде... Чын татарчаны?

—Ә-ә... Гитлерның адашы булуым күздә тотыламы?

—Менә-менә...

—Эш бит менә нәрсәдә, мистер Ариас... Сугыш алды елларында, Советлар Союзы белән дуслык килешүләре төзеп бетергән Гитлер Германиясенә хөрмәт йөзеннән, яна туган сабыйларга немец исемнәре кушу кин таралган: Ганс, Фердинанд, Карл, Рудольф... Күпләрнең тешенә тия торган минем исемем дә әнә шул шаукым нәтиҗәседер.

—Аңлашыла...

Кыска вакытлы круизга чыгучылар җыелып бетеп, ул арада кадерле кунакларны «Кристина» яхтасы ресторанына чакыра башладылар. Ак эскәтертле өстәлләр затлы ризык-нигъмәтләр, тәмле сый-эчемлекләрдән сыгылып тора иде. Рудольф Нуриев та кан-кардәше Сания Арова янәшәсендәге үз урынына килеп утырды. Ләкин тиз генә тынычлана алмады. Чөнки кайберәүләр кебек, ул бер яңагына суксалар, икенчесен куеп торучылардан түгел иде. Аны авыр балачагыннан бирле озата килгән кырыс язмышы шулай тәрбияләде.

Азгын «нәсел айгыры» Роберто Ариастан аның гүзәл, түзем хатыны Маргоның һәм үзенең дә ачуын кайтарыр җай тиздән чыкты. Биләгенә ак сөлге салган официант, кулын изәп, мәҗлеснең иң кызган төшендә

Рудольфны бер читкә чакырып алды:

—Мистер Нуриев, сезне капитан каютасындагы телефонга чакыралар.

—Кем?

Симез йөзле официант ак сөлгесе белән кин маңгаендагы тир тамчыларын сөртеп куйды:

—Гафу итегез,менә анысын әйтмәделәр инде...

Рудольф жил-жил адымнар белән тиздән әйләнеп тә килде:

—Мине түгел, телефонга сезне чакыралар икән бит, мистер Ариас!—диде ул, хужа кешенен йонлач колагына иелеп.

—Мине?!—диде Роберто Ариас, утырган жиреннән сикереп торып.—Ә нигә?

Кемгәдәр, нигәдер ачуы килгән чакларында Рудольфнын кинаяле иреннәреннән тапкыр сүзләр ниндидер тирән, аскы мәгънәгә ия булып, зирәк мәкаль-әйтемнәргә охшап тама башлый иде. Бу юлы да шулай килеп чыкты:

—Нигәме?.. Чөнки мин әлегә мистер Фонтейн түгел!

Мистер Фонтейн дигәч, житмәсә, бөтен кунаклар да ишетерлек итеп юри кычкырып әйтелгәч, миссис Маргонын булачак ире кебек килеп чыкты бит инде бу! Анлады Роберто Ариас кем бакчасына таш ыргытылганны. Анлады һәм, әлегә ни дип жавап кайтарырга белмичә, нечкә иреннәрен чәйни-чәйни, телефонлы каютага юнәлергә мәжбүр булды.

## 33

«Рудольф Фонтейн» мәсьәләсендә миссис Маргоны унайсыз хәлгә куеп, таякны артык бөгеп жибәрүен анлады Нуриев. Ләкин үзе ыргыткан жимне Роберто Ариаснын тавыш-тынсыз гына йотып жибәрәчәген сизенә иде ул. Чөнки, кемнәндер көнләшүгә килгәндә, хатынына бик еш хыянәт иткәнлектән, үз койрыгы бозга каткан!

Ул, ахыр чиктә, нәкъ әнә шулай булып чыкты да. Ләкин ике арадагы рухи бәйге бетмәгән иде әле.

Елга булып агылган затлы сый-шәрабларнын шайтани тәэсир көче тән буыннарын кыздырып жибәргәч, гадәттәгечә, бию ярышлары башланып китте. Балет сәхнәсендә инде күптән танылып һәм азу ярып өлгергән артистлар үз халыкларынын милли биюләрен башкару буенча көч сынаштылар. Дингез куенында чайкалган «Кристина» яхтасынын хужабикәсе Марго Фонтейн башта ярсу дәртле бразилия, аннары британ биюен башкарды. Дунай болгарлары кызы Сания Арова исә ярым төрки, ярым христиан моннары катышкан салмак ритмнарга тирбәлде.

Чират үзенә житкәч, Рудольф озак баш ватмады—тотты да балачактан үзенә яхшы таныш булган «Әпипә» көенә биеп китте. Кулларын чәбәкли-чәбәкли, үзе жырлады, үзе биеде:

Бас, кызым Әпипә,
Син басмасаң, мин басам:
Синең баскан эзләреңә
Мин дә китереп басам.

Бер үк куплетта уртак тамырлы «бас», «басмасаң», «басам», «баскан», «басам» сүзләренең биш мәртәбә кабатланып килүе белән грузиннарнын «ас-са!» дип аяк бармаклары очында очып-очып йөрүен хәтерләткән бу биюнең сүзләре дә, көе дә бик дәртле иде. Атаклы Король балеты артистларынын моңарчы үзләренә бөтенләй таныш булмаган татар биюен тын да алмыйча күзәтүләрен күргәч, Рудольф тагын да рухланып-илһамланып тыпырдавын дәвам итте:

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була.
Биегән кеше бай булганда—
Карт алаша тай була!

Гыйбрәтле үткән тарихында күпме авыр фаҗигаләргә юлыгып та күнел көрлеген югалтмыйча, җор телле шаян холкын саклап кала алган татар кешесе турындагы бу җырлы бию барлык артистларга да бик ошады. Менә сиңа дала атына атланган кыргый татар! Менә сиңа кайчандыр Париж хәтле Парижларны тетрәткән явыз татар! Үз халкының шук-шаян холкын шулай бер-ике биюдә күрсәтеп бирә алгач, ничек итеп инде андый милләт һәм аның искиткеч талантлы биюче улы алдында башыңны имисен?! Панама президентының кечкенәдән балет артистлары белән аралашып үскән улы булгач, Роберто Ариас бию сәнгатенең серләрен ярыйсы нечкәләтеп аңлый иде. Көйләре генә түгел, исемнәре дә гаҗәеп серле, гүзәл булган татар биюләрен ул да бик ошатты. Тик менә татарча ипи-тозлык та белмәгәч, үкенеч ки, сүзләрен генә аңлап җиткерә алмады.

Әле бая гына арба күчәре башларының берничә мәртәбә әләгешеп алулары турында уйламаска тырышып, менә Роберто Ариас яңа биеп туктаган яшь көндәше каршына килеп басты:

—Ул гаҗәеп гүзәл биюләрнең сүзләрендә ни турында әйтелә, мистер Нуриев?

Татарның иң дәртле, иң шаян биюләрен ничек ошатуын күргәч, Рудольф шактый тәкәббер бу түрә кешегә карата үпкә-сапкаларын шунда ук онытты:

—Тәрҗемә итимме?—диде ул, инглизчәләп.

—Әлбәттә, мистер Нуриев!

—Яхшы... Бу соңгы тыпырдауда биегән кешенең бик бай булачагы турында әйтелә.

Роберто Ариас әлеге фикер белән килешергә теләмәде:

—Юк! Биеп кенә баеп булса икән лә ул!

—Сабыр, мистер Ариас—әлеге көйдә дә биючененң карт алаша тайга әйләнгәч кенә байый алачагы хакында әйтелгән. Һәм бик ышандырырлык, образлы итеп әйтелгән!

Һәр дуңгыз әүвәл үз бозыклыгы турында уйлар дигәндәй, уҗымга чыгып керү хәлләре белән бәйләнгән «карт алаша» тәрҗемәсе колагына чалынгач, Роберто Ариасның болай да усал-кырыс йөзендәге төртеп тишкәндәй кечкенә күзләреннән зәһәр очкыннар чәчрәп куйды. Ләкин ул үзен тиз кулга алды:

—Дөрес, мистер Нуриев: бу дөньяда биеп түгел, ә бары тик бизнес аша гына баеп була!

—Бәлки...

—Хәер, үтә шәп биегән очракта акчаны безнең дә җәлләп торган юк инде, анысы. Хәзер сез моны үз күзләрегез белән күрә алырсыз.

Илче Ариас, бармак очы белән изәп, үзе янына музыкантлар төркеме башлыгын чакырды:

—Ә хәзер Америка халыкларыннан берәрсенең утлы-давыллы биюю көен уйнарсыз.

—Бик теләп, мистер Ариас! Тик кайсысын икән?

—Әйтик, мексикан биюен.

—Димәк, «Кукарача»ны?

—Менә-менә...

—Ә кем бии, мистер Ариас?

—Нуриев, билгеле! Бу биюне мин нәкъ менә ул башкарырга тиеш дип саныйм.

«Тиеш саныйм...»

Кем көймәсенә утырсаң, шуның жырын жырларсың дисәләр дә, тәкәббер илченең әмер төсендә әйтелгән масаюлы сүзләренә алай бер дә буйсынасы килеп тормый иде әле Рудольфның. Ләкин сәфәрдә катнашучыларның һәммәсе дә шушыны ук үтенеп сорагач, ризалашмый чарасы калмады.

Мөгаен, Рудольфка таныш түгел бию көен тәкъдим итеп, Ариас горур Нуриевның унайсыз хәлдә калуын көткәндер. Ләкин бик бәләкәй чакларыннан ук сәхнәдә кайнашканлыктан, дөнья халыкларының биюләре мәсьәләсендә дә Рудольфның белмәгәне юк иде. Ленинград хореография училищесында уку елларында да ул Кубадан килгән сабакташ дусты Мения Мартинестан байтак кына американ биюләрен өйрәнде.

Йөрәкләр тибешен кызулатып, менә ярсу агышлы «Кукарача» көе яңгырый башлады. Табигатьтән бирелгән үзенә генә хас кыяфәт-кыланышлары, тигез аяк хәрәкәтләре, аеруча магнитлы күз карашлары белән Рудольф Король балеты биючеләрен үз ихтыярына бик тиз бөтереп алды. Туктаусыз кул чаба-чаба, аны кат-кат биеттеләр.

Мистер Ариас бию мәсьәләсендә Рудольф Нуриевны һичкайчан кызарта алмаячагын, ниһаять,аңлады. Ләкин аның соңгы һәм бик көчле тагын бер чарасы калган иде әле. Ул—акча! Ә акча каршында монарчы әле беркемнең дә баш ими кала алганы юк. Үҗәт татар, ярсу татар, горур татар дигән даны булса да, Рудольф та баш ияр, ул да табынмый кала алмас кодрәтле көчкә!

Куен кесәсеннән төргәк-төргәк яшел акчалар чыгарды да, Нуриевның биюдән тукталмавын, «Жизель» балетындагы принц Альберт кебек, әйтерсең лә, үлгәнче биюен таләп итеп, Роберт Ариас аларны берәм-берәм идәнгә ыргыткалый башлады. Ул көзге агач яфракларыдай коелган әлеге кәгазь долларларны Рудольф иелеп ала барыр һәм, биюенә шулай зыян китереп, Король балетындагы хезмәттәшләре алдында хурлыкка калыр дип уйлаган иде булса кирәк.

Тик мистер Ариас уйлаганның нәкъ киресе килеп чыкты. Аның кулыннан ычкынган акчалар идәнгә бер-бер артлы очып төшә торды, алар очып төшкән саен, тамаша алкышлагандай, яхта хуҗасы кулын-кулга сугып куйды:

—Бие, бие, Хәйбулла—биегән кеше бай була!

Ә кинәт килеп туган мондый кыен минутларда һич югалып калмый торган тапкыр һәм горур Рудольф нишләде дисезме? Тотты да аяк астында бөтерелеп кыштыр-кыштыр килгән яшел акчаларны таптый-таптый, биюен дәвам иттерде. Инде музыкантлар да арып-тынып калды. Ә ул биеде дә һаман биеде!

Юк, биемәде—мистер Ариас тәкъдим иткән тамашаның азагында Рудольф Нуриев инде яшел меңлекләрне очлы туфлиләре белән тибеп-тибеп очыра ук башлады. Җил алып менеп китеп, палуба өстендәге зәңгәр күктә тирбәлешкән әлеге акчалар теплоходлар артыннан йөрәкләргә тиючән сагышлы тавышлар белән ачыргаланып кычкыра-кычкыра очарга яраткан моңсу акчарлакларны хәтерләтә иде.

### 34

Балет сәнгатендә монарчы күрелмәгән ярсу дәртле биюләре белән Рудольф Нуриев башта Париж, аннары Лондон тамашачылары күңелен бик тиз яулап алды. Аның көнбатыш сәхнәсендә нәфис-нәзакәтле Марго Фонтейн белән парлашып бии башлавын кайбер сәнгать белгечләре савыт-саба кибетенә көтмәгәндә килеп кергән сөзгәк үгез белән тиңләделәр.

Савыт-саба кибетендәге «сөзгәк үгез»нең, ниһаять, Америка тамашачылары алдында чыгыш ясый башлар көннәре дә килеп җитте.

Алар биеп туктауга, әйтерсең, көчле күк күкрәде!

Моңарчы тын да алмыйча утырган галәмәт зур тамаша залы ярсу алкышлардан кинәт тетрәнеп китте. Озын-озак алкышларның таләпчән чакыру авазларына буйсынып, композитор Адольф Аданның «Жизель» балетындагы төп рольләрдә биегән инглиз кызы Марго Фонтейн белән татар егете Рудольф Нуриев Нью-Йорктагы атаклы «Метрополитен-Опера» сәхнәсе уртасына җәмгысы... кырык ике мәртәбә (!) чыгып басарга һәм, рәхмәт белдереп, башларын иярга мәҗбүр булдылар. Шулкадәр көчле һәм тоташ алкышлардан тамашачыларның кулларына хәтта сөялләр чыгып бетте диярлек.

Ә сәхнәгә, меңләгән кешеләрнең соклану билгесе булып, аллы-гөлле чәчәкләр яуды, чәчәкләр яуды...

Бу тамашаны караучылар арасында, Нью-Йоркның бик күпләгән мөхтәрәм шәхесләре белән беррәттән, АКШ президенты хатыны Жаклин Кеннеди да бар иде. Тамырларында кайнар ирланд каны аккан әлеге леди кечкенәдән бию сәнгатенә гашыйк булып үскән, алай гына да түгел, Нью-Йорктагы балет студиясенә йөреп, үзе дә кайбер осталык серләрен үзләштереп өлгергән иде. Шуңадырмы, бөтен Америка тамашачыларын аякка бастырган ниндидер татар егетенең моңарчы күрелмәгән ярсу хис белән искиткеч дәртле һәм ашкынулы биюе аңа шулхәтле тәэсир итте ки, спектакль тәмамлануга, олы башын кече итеп, илнең ал розалар бәйләме тоткан беренче ледие сәхнә артына кереп китте. Балет сәнгатен сөючеләр күңеленә шулкадәр тылсымлы тәэсир итү көченә ия булган яшь биючене якыннан күрәсе һәм, чын күңеленнән котлап, гаҗәеп сыгылмалы һәм көчле кулларыннан бер кысасы килгән иде аның.

Балет күгендә яңа калыккан яшь һәм якты йолдыз турында ул иң беренче мәртәбә үз сеңлесе Ли Радзивиллдан ишеткән иде. АКШ президенты хатынының бертуганын сихри биюе белән күз ачып йомганчы үзенә гашыйк иттерә алган бу татар егетен менә шуңа күрә леди Кеннединың да бик күрәсе килгән иде. Ә сеңлесе Линең беренче ире Стас Радзивилл белән уртак тормышлары барып чыкмаган, шуңа күрәме, бөтен балет күген яктырткан үзе яшь, үзе әле өйләнергә дә өлгермәгән яңа йолдызга аның өметләре шактый зурдан иде бугай.

Тик бу кичне илнең беренче ледиена әле кайчан гына КГБ киртәләре аша азатлык, хөрлек тарафларына легендар сикереш ясап, бөтен дөньясын шаккатырган татар егете белән якыннан танышып китәргә язмаган булып чыкты. Юлына һаман да шул сәхнә эшкуары Сол Юрок аркылы төште!

Россиядән 1906 елда ук күчеп килеп, бүтән илләр һәм аеруча рус сәнгатенең Америкадагы рәсми булмаган илчесе сыйфатында хезмәт итә башлаган, дирижер таякчыгы хәтле генә тәбәнәк гәүдәсе белән терекөмештәй тегеләй дә болай тәгәрәп йөргән бу яһүд агаеның Америка кыйтгасында кермәгән ишеге, чыкмаган тишеге юк иде. Жирле халык, аеруча театр, опера һәм балет сәнгатен сөючеләр, барыннан да бигрәк аны чынаяк тәлинкәсе кадәрле кара кысалы күзлеге һәм көмеш тоткалы кул таягы аша ерактан ук танып алалар. Танып та алалар һәм, хөрмәт хисләрен белдереп, янәшәсеннән башларын ия-ия үтәләр.

Имәслек тә түгел шул!

Рус сәнгатенең мәшһүр биюче Анна Павлова, атаклы җырчы Федор Шаляпин кебек һәм башка бик күп йолдызлары, нәкъ менә Сол Юрокның җылы куллары аша «үтеп», беренче мәртәбә Америка тамашачыларына барып ирешкән. СССРның Урал тарафларыннан калкып, башта Париж, Лондон, инде менә хәзер Нью-Йорк сәхнәләрендә ут уйнаткан Рудольф Нуриев исемле канатлы өермә турында кайгыртуга да ул зур өлеш кертте.

Ә бу яңа йолдызның чыгышларын, бүтән биючеләрдән аермалы буларак,

тамашачы тыныч кына карый алмый. Анын һәр хәрәкәтеннән ирлек дәрте, сөю-мәхәббәт ялкыны бөркелгән утлы-ашкынулы биюе, нишләптер, хатын-кыз тамашачыларга аеруча көчле тәэсир итә. Күзгә күренми торган үткәргеч чыбыклар аша гүя ул алар бәгыренә үз йөрәгеннән кайнап чыккан гыйшык уты җибәрә! Әлеге ток, бертуктаусыз назлый-назлый, акрынлап чибәр туташларны шашу-шашындыру халәтенә китереп житкерә. Менә ни өчен андый ханымнар, кулларына чәчәк бәйләмнәре тотып, тамаша бетүгә үзләрен әсир иткән биюченең бизәнү-ясану бүлмәсенә таба ашкыналар.

Баштарак шактый уздырды андый гашыйкларны Сол Юрок яшь йолдыз бүлмәсенә. Ләкин һәммә нәрсәнең чамасы бар. Спектакльдән соң Нуриевның иркенләп сулыш ала-ала бераз бушанырга да мөмкинлеге булмау сәбәпле, үзенә әйтеп тормыйча гына, тиздән Сол Юрок аның бүлмәсен тышкы яктан бөтенләй бикләп куя башлады. Ун-унбиш минутка гына! Иң күбе—ярты сәгатькә!

Чарасызга күрә, бүген дә шулай эшләгән иде.

Күпме генә әрсез-кыю димәсеннәр, ал розалар бәйләме тотып бикле ишек төбенә килеп баскан АКШ хәтле АКШ президенты хатынын күргәч, Сол Юрокның да коты ботына төште. Артык каушап китү сәбәпле, ул буй-буй сызыклы соргылт костюмының һәрчак түш кесәсендә йөри торган тиешле ачкычын таба алмый интекте. Шулай да бер кесәсеннән икенчесенә күчкән арада, үзен кулга алып, илнең беренче ледиен жентекле күздән кичерергә өлгерде: биек үкчәле ак туфли кигән төз аяклар, Нуриевныкыдай артык озын да, тәбәнәк тә булмаган урта буйлы гәүдә, нәфис инбашларына дулкын-дулкын ишелеп төшкән калын-кара чәч, карлыгач канатыдай сызылып киткән нечкә кашлары астыннан төбәлгән эчкерсез-жылы караш... Өстәвенә, үзе сөйкемле, үзе яшь!

Әйе, хатын-кыз чибәрлеге ягыннан караганда, АКШның беренче ледиена һич тә тел-теш тидерерлек түгел иде. Ләкин Жаклин Кеннединың Сол Юрокка иң ошаган сыйфаты—аның үлепләр балет яратуы!

Хәер, леди Кеннедидән күреп һәм аннан калышмаска теләпме, СССР лидеры Никита Хрущевның күптән тулып ташыган гәүдәле хатыны Нина Петровна да балет сәнгатен шашыплар ярата булып чыкты. Ләкин моның һәвәскәрләр дәрәжәсендәге беркатлы ярату, Куба утравында әле күптән түгел генә булып алган хәрби-сәяси каршылыкны аздан гына коточкыч атом зилзиләсенә әйләндерми калган куркыныч «ярыш»ны бию сәнгате өлкәсенә дә тартып кертү нәтижәсе икәнлеге әллә кайдан күренеп тора иде.

Хатыннары яраткач, аларның кодрәтле икенче яртылары да соңгы елларда аеруча жанланып, аеруча модага кереп киткән балет сәнгатен ошатырга тиеш булып чыга бит инде! Чөнки муен кай тарафка борылса, баш та шул якка әйләнүчән ич! Дөнья лидерларының менә шушы сыйфатыннан бераз файдаланып калып булмасмы? Балет сәнгатенең киләчәге, аеруча аның Рудольф Нуриев кебек дөрләп кабынган яңа йолдызлары хакына! Әлбәттә, үз кесәнне калынайту хакында да онытып бетермичә...

Сәхнә продюсеры Сол Юрокның гамәли юнәлештәге әрсез уйларын Жаклин Кеннединың гафу үтенгәндәй тыйнак-ягымлы тавышы бүлдерде:

—Димәк, мистер Нуриевны бүген күрергә язмаган икән, алайса...

—Хәзер, хөрмәтле леди, хәзер...—диде Сол Юрок, кесәләрен әле һаман капшавын дәвам итеп.—Шунда ул мистер Нуриев, шунда... Бөтен тамаша залын һуштан яздырган чыгышыннан соң, исенә-акылына килеп утыра...

—Утырсын, алай булгач... Без әле очрашырбыз—комачауламыйк үзенә!—диде леди Кеннеди, ал розалар бәйләмен Сол Юрокка сузып.—Ә бу чәчәкләрне, чиксез рәхмәтем һәм тирән хөрмәтем билгесе итеп, мистер

Нуриевка тапшырырсыз. Хушыгыз!

—Хушыгыз, хөрмәтле леди!—диде Сол Юрок, гаепле кешенекедәй калтыраулы тавыш белән.

Калтырарсың да шул!

АКШ президентының хатыны, ниһаять, китте. Тик кулны инде пешерә үк башлаган ал розаларын тиешле иясенә тапшыруны нәкъ менә ана йөкләп, каушап-югалып калу кебек галәмәтләрне һичкайчан белмәс атаклы сәхнә эшлеклесен бик авыр хәлдә калдырып китте! Хәзер аңа бу чәчәкләр бәйләме белән нишләргә? Әгәр тиешле кешесенә кертеп бирсәң, ник үз аяклары белән атлап килгән президент хәтле президент хатыны юлына аркылы төштең дип, ярсу канлы Нуриев анын җелегенә үтәчәк! Әгәр бирми генә калдырсаң, мәрхәмәткә шулай ук өмет баглап булмый: кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә бит! «Әллә инде алдаша ук башладыңмы, «Нью-Йорк Юрогы?» дип (ачуы килгән чакларында Нуриев аңа гел әнә шулай сүз уйнатып дәшәргә ярата!), хәтта иманыңны тетеп ташларга да бик мөмкин. Ул сиңа кин күңелле опера җырчысы Федор Шаляпин яки нечкә-нәзберек күңелле бию остасы Вацлав Нижинский гына түгел! Кыскасы, кайнар татар, ярсу канлы Чыңгыз хан оныгы!

Президент хатыны киткәч, кирәкле ачкыч тиз табылды табылуын. Аны йозактагы тишек оясына кертеп бер борды да, ни булса—шул булыр дип, Сол Юрок бүлмә эченә атылды. Анын кулындагы чәчәкләрне күргәч, уйларыннан бүленеп һәм соклануын белдереп, Рудольф Нуриев әйтеп куйды:

—О-о!.. Ал розалар—ярату билгесе! Йә, кемне гашыйк иттек әле, мистер Юрок?

—Мин түгел, син гашыйк иткәнсең, мистер Нуриев, син!!

—Мин?.. Ә кемне?

—Президент хатынын!

Көтелмәгән бу сүзләрне ишеткәч, Рудольф утырган җиреннән үрлекырлы сикереп торды:

—Кемне, кемне?!

—Илнең беренче ледие Жаклин Кеннедины! Менә бу чәчәкләрне, чиксез рәхмәте һәм тирән хөрмәтенең билгесе итеп, сиңа ул тапшырырга кушты.

—Ә нигә үзе тапшырмады?

—Аны күреп каушаудан, һәрчак түш кесәмдә йөргән ачкычымны таба алмый интектем. Чөнки, гөнаһыма күрә, синең бүлмә ишеген тышкы яктан бикләп куйган идем.

—Ә ул ишекне ниемә дип бикләден?

—Синең тынычлыкны саклап инде, мистер Нуриев! Кермәсеннәр, йөрмәсеннәр чәчәк тоткан ханымнар—спектакльдән соң бераз ял итеп, бушанып алсын дидем.

—Рәхмәт инде кайгыртуыңа...—дигән булды Рудольф һәм бераздан кырыс тавыш белән өстәде.—Йә, әйт: президент хәтле президент хатынын кире борып җибәргәч, кем булып чыгасың инде син, мистер Юрок?

Сол Юрок ни дип җавап бирергә дә белмәде. Ә Нуриев исә, җай чыгудан файдаланып, үтергеч юморын эшкә җикте:

—Нью-Йорк Юрогы түгел, ә Нью-Йорк сарыгы син болай булгач, мистер Юрок!

Сол Юрок поляк Вацлав Нижинский, данияле Эрик Брун кебек моңарчы балкыган балет йолдызларының һәммәсеннән дә яктырак яна башлаган татар биючесе Рудольф Нуриевның усал телле мондый шаяртуларына күптән күнегеп беткән иде инде. Шуңа күрә чираттагы сүз уйнатуга ул артык үпкәләмәде...

Шаяртсын, теләгәнчә теш агартсын теленә шайтан төкергән Нуриев—

аннан гына укасы коелмаячак бит Сол Юрокның! Иң мөһиме, Лондон балетының Америка кыйтгасындагы Рудольф Нуриев катнашкан гастрольләре генә зур уңыш белән узсын!

## 35

Жаклин Кеннединың сәхнә артына ярты юлда бүленгән «визит»ы тиздән онытылды. Ә менә ул «Без әле очрашырбыз» дип теге көнне әйткән сүзен истә тоткан булып чыкты.

Берничә көн үтүгә үк, Нью-Йорк аэропортына ил президенты Джон Кеннединың АКШ башкаласы Вашингтоннан үзе җибәрттергән шәхси очкычы төшеп утырды. Әлеге очкыч экипажына Лондон балетының якты йолдызлары Марго Фонтейн һәм Рудольф Нуриев белән аларның хореографы Фредерик Аштонны зур хөрмәт белән АКШ президентының Ак йорттагы кабул итү бүлмәсенә алып кайту бурычы куелган иде.

Килеп җиттеләр мәртәбәле кунаклар Ак йортка, барып керделәр АКШ президентының «оваль кабинет» дип аталган атаклы бүлмәсенә, утырдылар, син күр дә мин күр дигәндәй, тирән эчле йомшак-затлы кәнәфиләргә!

Дөрес, бу минутларда Джон Кеннеди бүлмәдә үзе юк иде. Шунда ук Жаклин Кеннеди, ирен чакырып керергә дип, каядыр чыгып китте. Алар балет сәхнәсе кебек киң-иркен өстәлле зур бүлмәдә өчесе генә калдылар.

АКШ президентының затлы күн белән тышланган тәхет кәнәфие буш иде.

Шулчак шаккатыргыч бер хәл булып алды.

СССРдагы тышаулы язмышыннан бөтен тезген-дилбегәләрен өзеп кача алган татар биючесе Рудольф Нуриевның һич уйламаганда көтелмәгән адымнар ясау сәләте монарчы да күпләргә һәм күптәннән мәгълүм иде. Бу юлы да шулай булды. Джон Кеннеди үз бүлмәсендә юклыктан файдаланып, нигә әле аның серле-ымсындыргыч һәм үтә дә биек кәнәфиенә утырып карамаска?! Бар җиһанны дер калтыратып торган АКШ президенты кәнәфие бит ул! Рудольф Нуриев кебек бер татарга мондый мөмкинлек тагын кайчан тәтеячәк? Ычкындырма сирәк очрый торган алтын мизгелне, егетем!

Һәм, дөрестән дә, тагын бер мизгелдән ул АКШ президенты кәнәфиендә утыра иде инде. Килеп утырган шәпкә, бу гаҗәеп хәлгә үзе дә ышанып бетәсе килмичә, баштa әлеге кәнәфидә тегеләй дә болай әйләнгәләп карады. Шәп әйләнә тәхет кәнәфие! Аннары, телефон трубкаларын алып тормыйча гына, тегенди дә мондый затлы тугралар ясалган ул хәтәр аппаратларны куллары белән капшап-капшап куйды. Их, менә шушы кәнәфидән торып кына СССРда калган газиз анаң яки апаларына чылтырата алсаң икән ул! Юк, монысы инде—бөтенләй буй җитмәслек хыял!

Ул аңына килеп өлгергән арада менә ишектә Жаклин Кеннеди һәм аның ире үзе күренде. Аларны күрүгә, май урлап ашаганда тотылган мәчедәй, Рудольф тирән эчле кәнәфигә сеңде. Ләкин тиктормас малайлар шуклыгы белән ясалган хатаны төзәтергә соң иде инде.

АКШ президенты кәнәфиендә—татар баласы!

Мондый гайре табигый хәлне күргәч, кадерле кунагының балаларча шуклыгы өчен ире алдында уңайсызланып булса кирәк, Жаклин Кеннединың һәрвакыт ачык чырайлы йөзе кинәт шомланып-караңгыланып китте. Ләкин ул үзен тиз кулга алды.

Ә менә президент Кеннединың ник бер чәч бөртеге селкенеп карасын! Киресенчә, үз кәнәфиендә бөтен татарның, бөтен СССРның, бөтен Ауропаның гына түгел, ә Җир шары дип аталган барча җиһанның булачак бөек биючесе утыруны күргәч, ул мыек астыннан гына елмаеп куйды. Һәм, күрешер өчен ике кулын мөселманнарча алга сузып, мәртәбәле

кунагына таба атлады:

—Йә, ничек президент кәнәфие? Биекме, йомшакмы?..

—Гафу итегез, президент әфәнде!

—Юк, юк... Чит кәнәфигә утырып каравыгызга һич кенә дә уңайсызлана күрмәгез, мистер Нуриев! Ике ил, капма-каршы сәясәтле ике җәмгыять, ике дөнья арасына сузылган биек киртәле чикләр аша легендар төстә сикереп үтә алуыгыз өчен, һичшиксез, тагын да дәрәҗәлерәк кәнәфиләрдә утырырга лаек сез! Ә инде балет сәнгатендә соңгы елларны сез ирешкәннәр турында әйтеп тә торасы юк. Аларын тулаем киләчәк кенә бәяли алыр. Ә безнең бүгенге бәягә, бүгенге рәхмәтебезгә килгәндә...

Шулчак бүлмә түрендәге ишекне тавышсыз гына ачып, ике чибәр туташ килеп чыкты. Аларның берсе нечкә билле бәллүр кәсәләр тезелгән поднос, икенчесе исә... көмеш рельсле уенчык поезд тоткан иде. Аның бер-бер артлы тезелешкән вагоннары гына түгел, хәтта яшел, сары, кызыл күзле семафорларына хәтле бар! Әлеге гаҗәеп таныш һәм кечкенәдән җанга якын уенчыкны күргәч, чабышка ыргылган Сабантуй аты кебек, Рудольф Нуриевның борын тишекләре киерелеп килде. Юк, эш көмеш рельсле, көмеш көпчәкле бүләкнең үтә затлы, үтә кыйммәтле булуында гына түгел—президент хәтле АКШ президентының татар биючесе тормышын ярыйсы ук яхшы һәм алдан белеп торуында иде.

Затлы бүләкне булачак иясенең бер күрүдә ошатуы Джон Кеннеди күңеленә дә сары май булып ятты:

—Мистер Нуриев!—диде ул, шампан шәрабе салынган бәллүр чәркәне кулына алып.—Франциядәге беренче гастролегез вакытында сатып алынган уенчык поездыгызның ул чакта сездән башка гына ни өчен Лондонга китеп бару сәбәпләре безгә яхшы билгеле. Язмыш сезгә киләчәктә хәвефсез сәфәрләр, бәләкәй вакытыгыздан ук бик тә таныш булган шушы житез поезд кебек, гел алга, гел изге максатларга ыргылып яшәүләрне насыйп итсен!

Тамаша залына рәхмәт белдергән балет биючесе кебек бер тезенә чүгеп һәм тынлаусыз чәчле башын биленә хәтле иеп, Рудольф Нуриев та тиешле җавабын матур гына әйтеп бирә белде:

—Хөрмәтле президент! Хөрмәтле леди һәм джентельменнар! Рәхмәт мина хәерле сәфәрләр теләгән затлы бүләгегез өчен! Ләкин иң зур рәхмәтем бу бүләкнең чын көмештән ясалган рельсле һәм тәгәрмәчле, үтә затлы һәм кыйммәтле булганы өчен генә түгел. Ә бию дигән биек сәнгать күгендә канатларны тулы көченә җилпеп оча алу хакына туган иленнән аерылуга дучар ителгән бер татар баласын рухи сыендырып, рухи яклый алганыгыз өчен!

Тиздән шөһрәтле биючеләр хөрмәтенә җыелган кабул итү мәҗлесенең күңел ачу өлеше башланып китте. Кешеләр белән гаять тиз һәм җинел аралашучан Рудольф, көтелмәгәндә килеп туган мөмкинлектән файдаланып (Ычкындырма тарихи мизгелне, Нуриев!), бу мәҗлес барышында илнең беренче ледиен биергә чакырырга һәм аның белән якыннанрак танышырга да өлгерде. Аларның шушы танышлыктан башланып киткән чын дуслыгы аннары утыз ел буе—«бию падишаһы» вафат булганчы дәвам итте. Әле алай гынамы, Жаклин Кеннединың ярсу канлы татар биючесенә үлепләр гашыйк булган бертуган сеңлесе Ли Радзивилл аша атаклы токым вәкилләре белән хәтта туганлашып, ягъни мәсәлән, АКШ президенты баҗасына да әйләнеп бетте кебек!

Ак йортта көндезге икеләрдә башланган кабул итү мәҗлесе кичке алтыларга хәтле дәвам итте. Аннары АКШ президентының шул ук шәхси очкычы кадерле кунакларны гастрольләр барган Нью-Йорк каласына кире кайтарып та куйды.

## 36

Лондондагы мәгълүм «Обсервер» гәҗитендә яшь биюченең тиздән нәшер ителәчәк автобиографик китабыннан өзекләр басыла башлады. Аларның «Минем хөр иреккә сикерүем» дип аталган беренче өлеше шунда ук укучылар күңелен яулап та өлгерде. Бу санны гәҗит-журнал киоскларыннан бик тиз—чират тора-тора алып бетерделәр. Алдагы көннәрне исә әлеге киосклар ачылганчы ук—иртә таңнан алар каршында озын-озак чиратлар барлыкка килә торган булды.

Халыкны аеруча гаҗәпләндергәне шул иде: галәмәт абруйлы «Обсервер» басмасының монарчы беркайчан Рудольф Нуриев кебек нибары егерме дүрт яшен тутырган, кем әйтмешли, әле борын асты да кибеп өлгермәгән яшь кешеләр турында болай зур һәм саллы итеп язып чыкканы юк иде. Ә бу юлы-ы! Берничә тоташ битне биләп торган текстны инде әйтәсе дә юк! Шуларга өстәп, тагын өстәл кадәрле дүрт фото бирелгән!

Бу истәлекләр француз журналистларының кайчандыр Нуриев белән үткәргән әңгәмәләренә таянып язылган иде. Аларны Рудольф Лондонга килгәч Марго Фонтейн, Нинетт де Валуалар аша качкын татар биючесе белән танышкан һәм киләчәктә аның якын киңәшчесе вә биографы булып китәчәк Найджел Гослинг бергә җыйган, аннары иҗади эшкәртеп һәм тагын да камилләштереп, үзе эшли торган «Обсервер»га тәкъдим иткән иде.

«Обсервер» басмасында Рудольф Нуриевның саннан санга бирелә барган истәлекләре Парижлагы Ле Бурже аэропортында легендар сикерүе әле кайчан гына бар дөньяны шаулаткан татар егетенә бөтен Лондон, хәтта бөтен ил игътибарын тагын җәлеп итте. Тиздән әлеге истәлекләр «Опера Мунди» нәшриятында аерым җыентык булып басылып чыкты. Китап кибетләре шүрлекләренә менүгә, аны ай күрде дә кояш алды! Шулай итеп, япь-яшь биюче ниләр кичереп өлгерсен соң әле дип тормадылар, чиратлашып, кулдан-кулга йөртеп укый-укый, Рудольф Нуриевның «Минем автобиографиям» дип аталган җыентыгын ул көннәрдә укучыларның иң кайнар мәхәббәтен яулаган китабына әверелдерделәр.

Хыянәтче биюченең көнбатышта ничек шулай бик тиз абруй казануын күреп эчләре пошкан совет җитәкчелеге дә, бу хәлләрне күрмәмеш-белмәмешкә салынудан туктап, ниһаять, тешен күрсәтә башларга ният итте. Иң әүвәл Лондондагы совет илчелеге Нуриевны Король балеты сәхнәсенә аяк бастырмау таләбен куйды. Британлылар бу таләпкә һаман колак салмагач, үч итеп, гамәли чараларга кереште.

Лондондагы «Ковент-Гарден» сәхнәсендә Мәскәүнең Зур театрыннан атаклы Майя Плисецкая белән Николай Фадеичев концертлары күрсәтелергә тиеш иде. Тоттылар да, күренекле биючеләрне бу гастрольгә барудан тыеп, британ тамашачыларын совет артистлары чыгышын караудан мәхрүм иттеләр. Риза түгелсез икән—дәгъваларыгызны әнә хыянәтче биючегә үз сәхнәсендә яшел юл ачкан Король театры җитәкчеләренә белдерегез!

Шушы ук театрда Петр Ильич Чайковскийның «Аккош күле» балетын куярга алынган хореограф Роберт Хелпманга бу әсәрне сәхнәләштерүдә бай тәҗрибә тупланган Ленинград, Мәскәү шәһәрләренә барырга һәм әлеге тәҗрибәне өйрәнеп кайтырга кирәк булды. Ләкин Лондондагы совет илчелегендә аның теләгенә аркылы төштеләр.

—Ни өчен?—дип бәргәләнде Хелпман, берни төшенмичә.—Минем бит билетлар да кесәдә иде инде.

Аны исә кырт кистеләр:

—Башта билет түгел, виза алырга кирәк!

—Берни аңламыйм...

—Аңламагач, сорагыз соң, мистер Хелпман!—дип киңәш бирделәр аңа.

—Кемнән?

—Король театрының прима-биючесенә әйләнеп барган хыянәтче Нуриевтан!

—Ә-ә... Анлашылды, болай булгач! Канга—кан, үчкә—үч, димәк?

—Шулайрак, мистер Хелпман!

—Ә бу нәрсә бирер соң, хөрмәтле иптәшләр? Куба һәм Берлин кризислары гына житми мәллә? Инде сәхнәдәгеләре дә кирәк микәнни?

—Сезгә виза бирелмәү—әле баласы гына. Анасын исә, бераз алдарак күрерсез, мистер Хелпман!—дип теш ялтыраттылар совет илчелегендә.

«Анасы» дигәннәре Мәскәүдәге Зур театрнын Лондон каласына алдан килешенгән гастроль белән бармый калуы булып чыкты. Шушы ук сәбәп аркасында Ленинградтагы Киров театрының күренекле балетмейстеры Асаф Мессерер да Король балеты биючеләренә осталык дәресләрен бирү өчен килә алмады.

Тимер читлеккә охшап калган совет империясе үзенең әлеге читлекне тарсынып хөр ирекккә сикергән бер баласына каршы кылынган гамәлләрен гел арттыра, гел аяусызландыра барды. Болары—туган илдән читтә, күптән инде череп бетәргә тиеш булган капитализм илләрендә.

Ә СССРнын үзенә килгәндә, качкын Нуриевның тынлаусыз чәчле башы өстенә үткен кылыч элеп, аны гел куркытып, өркетеп торунын тагын да дәһшәтле чарасын эзләп таптылар. Юк, көнбатыш илләр демократиясе алдында үз дәрәҗәләрен төшермәү өчен, бу юлы да Рудольф Нуриевның авыру әнисен һәи бүтән туганнарын физик җәберләү юлына басмадылар. Ә рухи эзәрлекләүләр һаман дәвам итте.

1962 елның 1 апреле, гадәттәгечә, көлке һәм алдау көне буларак билгеләп үтелде. Ләкин Ленинград балеты житәкчеләренә бу көнне көләргә түгел, ә үкереп-үкереп елый башларга язган булып чыкты. Дәүләт сәясәтен яктыртучы рәсми басмалардан саналган кодрәтле һәм зур абруйлы «Известия» гәжитендә СССР халык артистлары Константин Сергеев һәм анын хатыны Наталья Дудинскаяның Киров театрындагы эшчәнлеген кискен тәнкыйтьләгән ачык хат басылган иде. Аларны үзләренә алмашка килгән яна буын биючеләренең осталыкларын тиешле дәрәҗәгә күтәрергә теләмәүдә гаепләгәннәр. Дөрес, хатта Нуриев исеме телгә алынмаган алынуын. Ләкин яшь балериннар Никита Долгушин белән Костя Брудновның Ленинградтан ни өчен Новосибирск театрына күчеп китү сәбәпләре аңлыйсы килгән кешегә бик ачык итеп язылган иде: әлбәттә, аларга юл, үрнәк күрсәтүче Рудольф булган!

Театр житәкчелеген гаепләү хатына Ленинград балетынын Алла Осипенко, Ирина Колпакова, Нинель Кургапкина, Алла Шелест, Ольга Моисеева, Нинель Петрова кебек киң танылган биючеләре кул куйган. Өстән кушып яздырган мондый күмәк хатлардан бик тиз көек исе килә башлый. Чөнки гыйбрәтле мисаллары күз алдында: Бухарин, Каменев, Зиновьев һәм башка бик күп, бик күпләгән «халык дошманнары»н да әүвәл «Правда»ише үзәк басмаларда бөтен ил, бөтен халык тарафыннан әйбәт кенә пешекләп алганнар, аннары Лубянка төрмәсенең караңгы подвалларына алып төшеп атканнар!

Киров театры кешеләренең дә эчләренә тирән шом кереп тулды: «Известия» гәжитендәге күмәк тәнкыйть мәкаләсе дә тиздән кубачак дәһшәтле давылның алхәбәре түгелме? Аяныч лы дәвамы һәм азагы исә кайчан булыр?

Чынлап та, иртәгесен үк Ленинград шәһәр судында Киров театрынын яшь биючесе Рудольф Нуриевнын чит илдә калуы һәм бу җинаятькә китергән

хөкем эше карала башлады. КГБ тарафыннан күптән әзерләнеп, кем нинәрсә сөйләячәгенә хәтле алдан билгеләнеп куелган бу суд утырышы формаль төстә генә узар һәм бик тиз тәмамланып та куяр дип уйлаганнар иде дә, хәлләр һич көтмәгәндә катлауланып китте. Рудольфның хезмәттәшләре, борын буенча акча җыеп, бик кыю һәм акыллы бер адвокат хатынны яллаганнар иде. Эшне КГБ хәтле КГБга каршы сүз әйтергә базган әнә шул адвокат бозды.

«Известия» гәҗитендә басылган күмәк хатны суд утырышында ул башта кычкырып укып чыкты. Аннары, Нуриевны яклый-яклый, ялкынланып сөйли башлады:

—Киров театрында еллар буе дәвам иткән кимчелекләр инде һәркемгә ачык. Кара эт гаебе—ак эткә дигәндәй, ни өчен әле ул кимчелекләр авырлыгы бер Нуриев җилкәсенә генә төшәргә тиеш? Театрда тәрбия эше тиешенчә алып барылмаган. Директорның бу эш өчен җаваплы урынбасары, КГБ капитаны Владимир Стрижевский үз вазифасын үтәүгә бармак аша караган. Шуның өчен, хезмәт кенәгәсенә язып, ана кискен кисәтү бирелгән дә. Бу—күпне сөйләүче бик мөһим дәлил! Театрда яшьләргә юньләп юл бирелмәү, берсе өстеннән икенчесен донослар язарга мәҗбүрләп, аларны гел куркытып, өркетеп торулар Нуриевны нәкъ менә чит илдә калуга этәргәндер дә. Чөнки Парижда чакта бүлмәдәше Юрий Соловьев, миннән төнлә массаж ясауны таләп итте дип КГБга әләкләгәч, әгәр туган иленә кайтса, ул үзенә кимендә җиде еллык төрмә янавын яхшы аңлаган. Шулай итеп, күренә ки, аның инде бүтән чигенер юлы калмаган булган...

Ә бит, хезмәттәшләренең әйтүенчә, чит ил гастрольләренә киткән чакта Нуриев бу җинаятьчел адымын ясарга һич тә уйламаган булган. Хөрмәтле судья! Сез моның нәкъ менә шулай икәнлеген шаһитлардан сораштырып үзегез белә аласыз. Мин моны үтенеп сорыйм һәм хәтта ки таләп итәм!

Суд утырышында катнашучы шаһитларның һәммәсе, адвокат әйткәннәрне раслап, саллы дәлилләр китерделәр. КГБ кубызына биегән Соловьев кына бөтәнчә уйлый булып чыкты. Ул, авырып китүен сәбәп итеп, суд утырышына килеп тә тормаган, Нуриев турындагы үз фикерләрен хатка гына язып җибәргән иде.

Адвокат хатынның нигезле дәлилләре үз тәэсирен ясамый калмады. Дәүләт гаепләүчесе Нуриевны җәзаның иң катысына—үлем хөкеменә тартуны таләп итеп караган иде. Болай булганда Рудольфның эшләре бик хөртиләнәчәк—егерменче елларда читтән торып үлем карары чыгарылган Лев Троцкийны Сталин чекистлары хәтта ерак Мексикада эзләп табып башына җиткәннәре кебек, Нуриевны да озын куллы КГБ җанкыярлары бу якты дөньядан бик җиңел юк итәргә яки хәтта Мәскәүгә урлап китәргә дә мөмкиннәр иде. Әнә шуларны да җентекләп уйлагач, җитди дәлилләргә каршы барырга теләмәгән халык судьясы һәм утырышчылары Рудольфны читтән торып җиде елга иреге ннән мәхрүм итү турында рәсми карар чыгардылар. Нуриевны каралтуда үз шымчыларының да өлеше зур булгач, эшне зурга җибәрмәс өчен, КГБ җитәкчелегенә дә әлеге карар белән тешен кысып булса да килешергә туры килде.[1]

Ә бит, киләчәк вакыйгалар күрсәткәнчә, совет чекистларына ул чакта килешергә кирәк булмаган, ах, ничекләр кирәк булмаган ошбу хөкем карары белән! Чөнки бу килешү нәтиҗәсендә КГБның кулы отыры кыскара, ә Нуриевның эшләре, киресенчә, үргә тәгәри генә төште. Гаҗәеп хәл: күбрәк аяк чалган саен, аның дан-дәрәҗәсе гел арта гына бара иде!

[1] Әлеге хөкем карары 35 ел буе үз көчендә кала бирде. Рудольф Нуриев үлеп 4 ел узгач, ягъни 1997 елда гына ул, ниһаять, Россия Югары суды карары нигезендә юкка чыгарылды. Шулай итеп, дөньякүләм мәшһүрлек казанган татар биючесенең Ватан алдындагы керсез исеме тәмам акланды.

Житмеш җиде колаклы КГБ барысын да яхшы белеп тора: АКШ президенты Джон Кеннеди һәм аның балет сәнгатен үлепләр яраткан гүзәл хатыны Жаклин Кеннеди белән дуслашып алгач, аеруча президент балдызы Ли Радзивилл белән якынаеп, хәтта президент хәтле президент баҗасына әверелгәч, Рудольф Нуриевка совет чекистларының хәзер бөтенләй тешләре үтми башлады.

АКШ президенты Джон Кеннедины озакламый үз илендә мәргән мылтыгыннан атып үтерделәр. Аннары—шушы ук постка дәгъва кылган энесе Роберт Кеннедины... АКШның яңа президенты итеп Линдон Джонсон сайланды. Аны тәкъдир итү кичәсендә Рудольф Нуриевнын урыны шулай ук түрдә булды. Әле алай гынамы, мәртәбәле бу кичә сәхнәсендә «Корсар» балетыннан зур гына өзекне искиткеч оста биеп, ул яңа президент һәм аның хатынының да тирән хөрмәтен яулады.

Юк, чит ил шартларында канатларын тулы көчкә җәеп, капитализмча яшәү өстенлекләрен көннән-көн күбрәк раслый барган Нуриевка каршы көрәшнең тагын да нечкәрәк, тагын да мәкерлерәк ысулларын кулланып карарга кирәк иде.

Тукта!

Ленинградтагы халык судьясының артык гаделлеге, Нуриев дуслары яллаган адвокатның исә артык чаялыгы сәбәпле, бу биючене читтән торып үлем җәзасына тарту теләге барып чыкмады. Бәс, шулай икән, моңа өстәп, КГБның озын кулы да кыскара төшкән икән, димәк аңа каршы ЦРУ[1] яки ФБР[2]ның үзен өстереп карарга кирәк! Әйтик, бик ышанычлы кешеләреннән бу усал оешмалар колагына: «Нуриев—КГБ шымчысы!» дигән коточкыч хәбәрне ирештерсән? Әгәр барып чыкса, монын бит биюче өчен гаять күңелсез нәтиҗәләргә китерүе мөмкин!

## 37

Әйе, читтән торып булса да Нуриевны җиде елга гына ирегеннән мәхрүм итү хөкеме белән килешеп, КГБ үз эшен шактый катлауландырды. Халыкара кануннарны бозмыйча гына хәзер чит илләрдә аны физик яктан юк итү бөтенләй мөмкин түгел диярлек. Чөнки ул—егерменче елларда үлем карары чыгарылып, ерак Мексикада башына кәйлә белән сугып үтерелгән Лев Троцкий ише генә түгел!

Хәер, Нуриевка көн саен диярлек булып торган мәҗлесләр һәм тантаналы кабул итүләрнең берсендә озак тәэсир итә торган зәһәр агу каптырырга да мөмкиндер кебек. Аннары бит, самолетка утырып, ул гел бер кыйтгадан икенчесенә очып тора. Әйтик, Лондоннан Австралия каласы Сиднейга. Аралар артык озын-ерак булу сәбәпле, очкыч багын тиешле ягулык белән тулыландыру өчен, ул самолетлар уртарак бер урында, мәсәлән, Каһирә аэропортында техник тукталыш ясарга мәҗбүрләр. Ә пассажирларын исә, янгын чыгу куркынычы булганга, тышка чыгарып торалар. Менә шул чакта юлчыларның кирәклесен җинел генә эләктереп яки урлап китәргә дә була.

1963 елның 1 декабре көнне Рудольф та шундый бер хәлгә юлыкты. Ул утырган очкыч, гадәттәгечә, Каһирә аэропортында техник тукталыш ясады. Һәр адымын кечкенәдән уйлап ясарга күнеккән хәсиятле Нуриев, бәхетенә күрә, иң арткы рәткә утырган иде. Бәдрәф янәшәсендә булса да, ничектер, монда хәвефсезрәк, ышанычлыграктыр төсле!

Һәм ул үз исәбендә ялгышмаган иде.

Гуантас компаниясенең ышанычлы очкычы җиргә йомшак кына төшеп утыруга, салон радиосы телгә килде:

[1] ЦРУ—Американың Үзәк Разведка Идарәсе

[2] ФБР—Федераль Тикшеренүләр Бюросы

—Хөрмәтле пассажирлар! Техник сәбәпләр аркасында, самолеттан чыгып торуыгызны үтенәбез.

Ерак сәфәрләрдә даими йөреп, көтелмәгән мондый хәлләргә инде күптән күнегеп беткән Рудольфның күңелен, никтер, бу юлы тирән шом басты. Алгы рәтләрдәге юлчылар, урыннарыннан торып, текә трап буенча инде җиргә коела да башладылар. Ә Рудольф, аякларына авыр гер асканда, йомшак кәнәфиенә гел тирәнрәк сеңә барды. Кинәт аның ялтыр-йолтыр каранган күзләре түгәрәк иллюминатор тәрәзәсенә төште. Тәрәзәгә шап та шоп бәреп һәм күңелдәге шомны тагын да арттырып, көчле яңгыр ява иде.

Ярый әле, карыйсы иткән!

Ә анда?!.. Траптан төшкән һәр кешене энә күзеннән үткәреп, өсләренә кара башлыклы пар плащлар бөркәнгән алыптай гәүдәле ике ир заты басып тора иде. Совет чекистларыдыр, әлбәттә! Рудольф, кадаклап куйгандай, йомшак эчле утыргычына һаман тирәнрәк сеңүен дәвам итте. Аның йөзе, җитәрлек кан килмәүдән, кинәт ак кәгазь төсенә керде.

Кемнәргәдер күренәсе килмәгән сәер юлчыга очкыч ишеге төбендә басып торган стюардесса кыз да игътибар итте һәм, йөгерә-атлый, шунда ук аның янына килеп тә җитте:

—Абау!.. Кем икән бу, нишләп шулай яшеренә икән дисәм... Сез икәнсез бит, мистер Нуриев!

—Ә сез мине каян беләсез?

—Ничек инде британнарның иң яраткан биючесенә әйләнгән кешене белмәскә ди?!

—Рәхмәт тануыгызга!—диде Рудольф һәм кулы белән иллюминаторга төртеп күрсәтте.—Ә-әнә, күрәсезме кара плащлы ике карачкыны?

Стюардесса ул күрсәткән тарафка башын сузып карады:

—Күрәм, билгеле.

—Аларга мин кирәк... Зинһар, ярдәм итегез! Берәр җиргә яшерегез мине!

—Аңлашылды, мистер Нуриев! Әйдәгез, алайса!

—Кая?

—Бәдрәфкә! Гафу итегез—бүтән ышанычлы урыныбыз юк. Ә сез анда кергәч, ишек бигеген эчке яктан ике мәртәбә борып куярсыз, ярыймы.

—Ә аны ачтырып тикшерергә уйласалар?

—Йозагы ватылды—эшләми дип әйтермен.

Шулай иттеләр дә. Ләкин кара киемле чекистлар тиз генә тынычланмады. Аларның берсе салон ишеге төбендә калып, икенчесе урындык рәтләре арасына иелеп карый-карый, энәсеннән җебенә хәтле тикшереп чыкты.

Менә чират бәдрәф ишегенә җитте. Ләкин ул эчтән бикле иде.

Усал йөзле чекист стюардесса кызга күзләренең агы белән карады:

—Ачыгыз!

—Юк, бу—мөмкин түгел.

—Ә ник?

—Чөнки бәдрәф ватык—эшләми.

—Ә без нигә әле моңа ышанырга тиешбез? Ачкычын бирегез!

—Юк, югалды ул.

—Карагыз аны!—дип янады иминлек сакчысы һәм, кунадай җилкәләре белән китереп ора-ора, бәдрәф ишеген ватып ачмак була башлады.

Капкындагы куян хәлендә калган Рудольф Нуриев бу минутларда ниләр кичерде икән? Ләкин, ни сөенеч, таза бикле нык ишек тиз генә бирешергә теләмәде. Өстәвенә, эчке яктан Рудольф аны бөтен көченә терәп-этеп торды.

Ул арада кара ниятле совет чекистын стюардесса кыз үзе эссе табага бастыра башлады:

—Сез нишләп әле пассажирлар йөртүче самолет милкен ватасыз? Хәзер

полиция чакыртам!

Нуриевны эзләүчеләргә дипломатик хата, тавыш-гауга чыгарырга һич ярамый иде. Шунлыктан, бәдрәф ишеге белән көрәшүләрен туктатып, алар шундук шым булдылар.

Бу сәфәрнең шомы Рудольф йөрәгендә бик озак сакланды. Ә бит аны, бик теләгән очракта, ялгызын гына яки юлчылар тулы самолеты-ние белән бергә СССРга яки бүтән бер социалистик илгә урлап китәргә дә бик мөмкиннәр иде. Шуңа күрә ул хәзер башка кыйтгаларга илткән ерак рейсларга төп труппа артистлары белән түгел, ә алардан шактый иртәрәк кузгала башлады. Болай кыйбатракка төшә, билгеле. Ләкин Нуриевта акча— бер букча! Иң мөһиме, совет чекистларының озын куллары үрелеп җитмәслек булсын!

Шулай итеп, Рудольф Нуриевның көннән-көн таныла баруы һәм, моның бер тәэсире буларак, британ стюардессасының ярдәм кулын сузуы аркасында, КГБ агентлары Каһирә аэропортында тагын кәкре каенга терәлеп калдылар.

## 38

Илен алыштырган татар биючесенең көнбатыш сәхнәсендәге эшчәнлегенә аяк чалу өчен, КГБ башта «Нуриев—АКШның Үзәк Разведка Идарәсе агенты, аны бу хурлыклы эшкә Париждагы яшьлек мәхәббәте һәм шушы яшерен оешма хезмәткәре Клара Сент тарткан» диюле ялган хәбәр таратып караган иде. Ләкин Рудольф тиздән Лондонга күчеп китеп, чит илдә калуының беренче көннәрендә үзенә бик күп изгелекләр кылган әлеге кыз белән элемтә-бәйләнешләре өзелү сәбәпле, КГБ ялганы сабын куыгыдай шартлады. Ләкин Нуриевны мөмкин булган барлык ысуллар белән пычрату, көнбатыш җәмәгатьчелеге алдында аның дәрәҗәсен төшерү омтылышы туктатылмады.

1964 елның язында, британ балеты белән берлектә, Рудольф Нуриевның АКШтагы гастрольләрдә йөргән чагы иде. Әнә шул көннәрдә Калифорния штатындагы «Хаятт-Хаус» исемле кунакханә коридоры идәненнән, имештер, ялгыш төшереп җибәрелгән яшерен конверт табып алдылар. Аның эчендәге кәгазьдә болай дип язылган иде: «Нуриев MLS агенты белән бәйләнешкә керде һәм әлеге агент 3689001427 номерлы шымчы белән очрашып сөйләшкәнче, аны көтеп торырга риза булды. Бу конверт сезнең белән хезмәттәшлек урнаштыру өчен җитәрлек җирлек булыр дип өметләнәм... Ләкин сез түлисе гонорарлар күләме, дөресен генә әйткәндә, мине һич тә канәгатьләндерми».

АКШның Федераль Тикшеренүләр Бюросы дигән куркыныч исемле оешмасында искиткеч хәйләкәр каләм белән язылган бу хәбәргә теге яктан да, бу яктан да якын килеп карадылар. Ләкин әлеге провокацион хәбәр иясенең максатын барыбер төгәл генә ачыклый алмадылар. Чөнки үзе әйткән бәйләнешне урнаштыру өчен, табылдык хәбәрдә ни исем-фамилиясе, ни адресы күрсәтелмәгән—эзлә менә хәзер кырдан җилне!

Шулай да ФБРда яшерен хәбәрдәге һәр мәгълүматның тамырынача төшеп карарга булдылар. Нуриев «Хаятт-Хаус» кунакханәсендә яшәп караганмы? Юк, яшәмәгән! Ә MLS дигән серле сүз ни-нәрсә анлата? Төпченә торгач, аның Monterey Language School, ягъни америкаи армиясе сугышчыларына төрле телләрне өйрәтү мәктәбе икәнлеге ачыкланды.

Оһо, АКШ армиясе! Бу инде рус шпионнары өчен әкәмәт кызыктыргыч «мишень» була ала! Шунда ук АКШ хәрбиләренә телләр өйрәтү мәктәбенә барып, анда шөгыльләнүче яшь солдатларны энә күзеннән үткәреп чыктылар: алай-болай берсе гастрольдә йөргән биюче Нуриев белән шикле мөнәсәбәткә кереп өлгермәгәнме? Юк, андыйлар табылмады.

Кунакханә коридорыннан табылган сәер конверттагы исемсез хәбәр турында жентекләп һәм кумәкләшеп уйлаша торгач, ниһаять, уртак фикергә килделәр: купме кешенең башын катырган бу язуда бөтен хикмәт «Нуриев» сүзендә һәм әлеге яла-хәбәрне, качкын биючегә карата АКШның тиешле оешмаларында шик уяту өчен, кемнәрдер махсус очыртып жибәргән булса кирәк.

Ә кемнәрдернең кем икәнлеге күптән һәм күпләргә мәгълүм инде— әлбәттә, КГБ!

ФБР хәтле ФБРның очлы күзенә бер юлыктынмы, аннан тиз генә ычкынырмын димә инде. Әлегә Лос-Анджелес каласында биегән Рудольф Нуриевны да, күңелләрендә энә очы хәтле шик тә калмасын өчен, иртәгесен үк ФБРга чакыртып китерделәр. Ана сорауларның мәкле-кәплесен һәм маңгайга терәп бирделәр:

—Сез КГБ шпионымы, мистер Нуриев?

Көтелмәгән бу сораудан Рудольф телсез калды:

—Минме?.. Мин.. Ничек итеп инде үз теләге белән СССРга кайтмый калган кеше шул ук илнең шпионы була алсын икән? Бу миңа һич тә аңлашылмый...

—Ә, кем белә, бәлки сез чит илдә нәкъ менә КГБ кушуы буенча калгансыздыр?

Коточкыч бу гаепләүне ишеткәч, өнсез калып, Рудольф бары тик:

—Кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмиләр!—дип кенә әйтә алды.

Ләкин Рудольф әйткәннәрне АКШның иминлек сакчылары бөтенләй колакларына да элмәделәр:

—Мистер Нуриев, әйтегез—сез чит илдә КГБның нинди заданиесен үтисез?

Бер үк ноктага төбәп бирелгән урынсыз сораулар Рудольфны тәмам чыгырдан чыгарып, ул бөтенләй дәшмәскә булды:

—...

—Ник телегезне йоттыгыз, мистер Нуриев? Югыйсә, без сезне СССРга кире кайтарып та жибәрә алабыз!

Рудольф, утлы күмергә баскандай, утырган жиреннән чәчрәп торды:

—Юк, юк!.. Мине теләсә нишләтә аласыз... Тик, зинһар, КГБ кулына гына кире тапшыра күрмәгез! Бу минем өчен жиде елга сузылачак Себер төрмәсе генә түгел, рухи үлемем дә булачак!

—Ә нигә куркырга? Төрмәдә дә бии-бии яшәргә була.

—Ул инде биеп түгел, көеп яшәү булачак, минемчә. Кабаттан кызыл тышау киеп алай яшәгәнче, мин үз-үземә кул салачакмын!

АКШ иминлеге сакчысының туп-туры төбәлгән күзләрендә, ниһаять, жылылык чаткысы күренде:

—Үләргә ашыкмыйк әле, мистер Нуриев. Сезнең бүген Себердә түгел, мондагы тамашачыларны сөендереп биюегез кирәк! Ә хәзергә хушыгыз—безгә бу бүлмәдә бүтән очрашырга язмасын!—диде сорау алучы һәм яшерен күзәтү астындагы Рудольф өстеннән инде йөз дә алтмыш битлек әләк-рапортлар тупланып өлгергән, тәмам бүселергә житкән калын папканы, әлегә киргә беткәнлектән, кысып ябып куйды.

—Мин дә шулай уйлыймын, сэр!—диде Рудольф һәм, сорау алучының хушлашыр өчен сузган кулын кысып, бүлмәдән чыгып китте.

Шушы китүдән Нуриевны сорау алырга чакыртулар бүтән булмады диярлек. Ләкин КГБ жае чыккан саен ана үзенең үткен тырнакларын батырырга тырышуыннан туктамады әле. Барыннан да элек Рудольфны кадерле әти-әнисе һәм бүтән туганнары белән күрешергә ирек бирмичә

интектерделәр. Жиде еллык төрмәгә ябылу куркынычы гел баш өстендә үткен кылыч кебек эленеп торганлыктан, ул тиз генә Уфага кайтып килү турында хыяллана да алмый иде. Ә чит илдәге Рудольф янына бару өчен, туганнарына виза, ягъни рөхсәт язуы бирми аптыраттылар. Юкса, кеше хокукларын яклауны күздә тотып, Хельсинкида кабул ителгән карарда язмыш аерган якын туганнарның мөмкин хәтле еш күрешеп яки бөтенләй кавышып яшәүләренә булышу кирәклеге дә басым ясап әйтелгән һәм әлеге карарга күпчелек илләр белән беррәттән Советлар Союзы да кул куйган иде. Шушы карар нигезендә Нуриевны газиз туганнары белән күрештерүне таләп итүгә АКШ, Англия, Франция кебек илләрдәге күренекле мәдәният вәкилләре генә түгел, хәтта әлеге илләрнең Джимми Картер шикелле дөньякүләм абруйлы беренче җитәкчеләре дә тартылган иде. Ләкин халыкара карарлар үтәлешен түгел, ә бөек мәмләкәтчел, ялган патриотлык идеяләрен алга сөргән Хрущев, аннары Брежнев белән Андропов һәм СССР империясенең бүтән лидерлары бу таләпләргә күз йомып кына карадылар.

Ләкин, тамчы тама-тама ташны да тишәр ди. Күп илләрнең беренче җитәкчеләре дәрәҗәсендәге озын-озак сөйләшүләрдән соң инде Рудольф күнелендә аз-маз өмет чаткылары да уяна башлаган иде. Тик шул көннәрдә генә, чүп өстенә—чүмәлә дигәндәй, тагын Ленинград биючесе Наталья Макарова тәртәгә тибеп куйды. Кайчандыр бар дөньясын шаулаткан Нуриев гамәлен кабатлап, ул тотты да шулай ук чит илдә калды.

Бу биючене, артык әрсезлеге өчен, Рудольф элек тә бигүк өнәп бетерми иде. Шуңа күрәме, әлеге хәбәр тудырган ачуын бераз басу өчен, татарча белән инглизчә һәм французчаны бергә катыштырып, гадәтенчә, ул авыз эченнән генә усал шаяртулы ботка пешереп куйды:

—И Наталья, Наталья!.. Наташа Макарова түгел, дөрестән дә, Маташтыра Макабрава[1] икәнсең син!..

Шулай итеп, көтмәгәндә Наталья Макарованың тәртәгә тибеп куюы сәбәпле, Рудольф Нуриевның газиз әти-әнисе белән якын араларда очрашу, хәтта чит илдә бергә яши башлау турындагы татлы хыялы сүнде, эреп юкка чыкты. Инде бу турыда, җанны газаплап, бүтән уйламаска да була.

Ләкин тормыш бит ул!

Чегәннәрдәй гел күчеп йөргән артистлык язмышы беркөнне Рудольфны Американың Манхэттен каласында австрияле Арнольд Шварценеггер[2] дигән культурист егет белән очраштырды. Дөресрәге, аларны рәссам Джейми Уайет таныштырды. «Тимер егет» фильмында гаҗәеп уңышлы уйнап, Америка халкы, бигрәк тә яшьләр арасында бик тиз популярлык казана башлаган бу атлет рәсемен ясауга Джейми юкка гына тотынмаган иде. Махсус күнегүләр ясап, Арнольд Шварценеггер үз мускулларын шулкадәр үстерә-ныгыта алган ки, кеше тәненнән бигрәк, ит богылына охшап калган әлеге тере «котлет»тан ниндидер кыргый көч бөркелеп тора. Шуның белән ул бүтәннәр игътибарын җәлеп итә дә. Өстәвенә, табигать бу егетне гүәрдиндәй озын гәүдәле, төскә-биткә дә кырыс-матур итеп яраткан иде.

Арнольд Шварценеггер портретын ясап бетергән көннәрдә рәссам Джейми Уайетны тагын бер көчле шәхес образы үзенә бөтереп алды. Әлеге кеше биюче Рудольф Нуриев иде. Шварценеггерның «штангачы-гер күтәрүче» гәүдәсеннән аермалы буларак, Рудольфның бераз кыскарак, ләкин кин җилкәле буй-сыны йөзүчеләрнекен хәтерләтә иде. Арнольд гәүдәсенең капма-каршысы булса да, шулай ук үзенчә таза, үзенчә матур!

Рудольфның ризалыгын алуга, күренекле рәссам аның портретын иҗат

[1] Маташтыра Макабрава—татарча: Маташтыра—Наташа исеменә төрттерү; инглизчә: ashtray—тәмәке көле савыты; французча: tacabre—ямьсез, коточкыч.

[2] Бүгенге көндә АКШның Калифорния штаты губернаторы.

итәргә дә кереште. Ләкин бераздан тукталып калды. Ярсу канлы Нуриевның узаман холкы да үз киләчәге үрләрен ипләп кенә, ышанычлы адымнар белән бер-бер артлы яулый барган Шварценеггерныкына охшамаган иде. Заманның ике төрле холыклы бу популяр егетләрен әгәр бергә очраштырып карасаң? Моның капма-каршылы холыкларны тулырак чагылдыра алуга ярдәме тимәсме соң?

Нуриев диюгә, никтер, рәссам Джейми Уайетның күз алдына гел бөтерчектәй әйләнә-әйләнә күккә ашучы утлы өермә килеп баса торган булды. Дөресрәге, сәхнә теле белән әйткәндә, гүя пируэтлар ясый-ясый биегән баганалы өермә!

Канатлы һәм биюче өермә! Әйе, Рудольф Нуриевның үзенә генә хас ярсу-башбирмәс холкына гаҗәеп туры килеп торган символик образ иде бу! Аның рәсемен ясарга алынган кеше нәкъ әнә шундый давыллы һәм канатлы өермәне сурәтләргә тиештер дә!

Ә үзләренә тупланган көч-кодрәтне сыйдыра алмыйча, беләк мускуллары каз күкәедәй бүселеп чыккан озын-таза гәүдәле Арнольд Шварценеггер—әйтерсең, күкләргә ашкан корыч манара! Аның рәсеме инде, нигездә, ясалып беткән булса да, кем белә, алдагы очрашудан «тимер егет» холкын тагын да яктыртып җибәрә алырлык өстәмә бизәкләр дә табып булыр әле?

Алар беркөнне төшке аш вакытында Манхэттенның «Илейнс» дигән ин затлы ресторанына кереп утырдылар. Джейми Уайет оештырган бу очрашу артык киеренке шартларда башланып китте. Чөнки кино сәнгате үрләренә әле яна күтәрелә башлаган Арнольдның, үз популярлыгын тагын да арттыру өчен, балет сәнгате кыясына инде менеп җитә язып, көнбатыштагы ин билгеле шәхесләрнең берсенә, хәтта АКШ президенты бажасына әйләнгән Нуриев белән күптән танышасы килеп йөри һәм, шуна күрәме, ул бик дулкынланган иде.

Аш алдыннан бәллүр рюмкаларны бер мәртәбә бушатып куйгач, рәссам үз кунакларын якыннанрак таныштыруга күчте:

—Мистер Нуриев, таныш булыгыз—киләчәктә кайсыдыр штатның булачак губернаторы Арнольд Шварценеггер!—диде ул, шаярту катыш.

—О-о! Бирсен Ходай!—диде Рудольф, бу шаяртуны бик тиз аңлап алып.—Тик бер нәрсә аңлашылып җитми, Арнольд әнекәш...

—Ә нәрсә аңлашылмый?—диде Шварценеггер, Рудольфка сораулы караш ташлап.

—Сез үзегез австралияле икәнсез, фамилиягез исә нишләптер «негр» сүзенә бетә...—диде Рудольф, гадәттәгечә, кеше фамилиясен үзгәртеп дәшү кебек усал шаяртуын эшкә җигеп.

Карачкыл йөзендәге ап-ак тешләрен җемелдәтеп, үпкә-сокта беллермичә генә Шварценеггер көлеп куйды:

—Ә-ә... Кара... Дөрестән дә шулай икән бит, ә!

Кем белә, алар, бәлки, шулай әйбәт кенә танышып та җиткән булырлар иде. Тик эшне Арнольд Шварценеггерның артык дулкынлану сәбәпле бик вакытсыз һәм урынсыз бирелгән соравы бозып куйды:

—Мистер Нуриев, миңа да бер сорау бирергә мөмкинме?

—Рәхим итегез!

—Ишетүемчә, икебез дә туган илкәйләрдән читтә гомер кичерәбез икән. Мин үзем Австриямә еш кайтып йөрим. Ә сез ничек? Россиядә аерылып калган газиз әниегез һәм бүтән туганнарыгыз белән еш очрашып торасызмы?

«Сүз булмаганда сүз булсын—ата казыгыз күкәй саламы?» дип сорагандай килеп чыкты бу бигрәк. Күптән әрнегән йөрәк ярасына кагылучыга Рудольф Нуриевның җавабы артык кыска, үтле-мыскыллы һәм үтергеч кинаяле булды:

—Көн саен!

—О-о, хәтта көн сае-ен?!—дип сокланудан тел шартлатып куйды таза мускуллар патшасы, әле һаман һични аңламыйча.—Димәк, шәхси самолеттадыр инде?

Бу мәгънәсез сорауга да тапкыр җавапны Рудольф тиз тапты:

—Юк, шәхси ракетамда!

Арнольд Шварценеггерның танышу билгесе итеп сузган тимердәй нык кулын Рудольф шундый каты итеп, бөтен җан ачуы белән кысты ки, авыртудан тегесенең хәтта бит урталары тартышып куйды.

Шулай итеп, берсенең күнел халәтен икенчесе тиешенчә белеп бетермәгәч, бу очрашуда күренекле шәхесләр юньләп танышып китә алмады. Ләкин Нуриевның «Көн саен!» дигән үтергеч кинаяле сүзләре ни белдерүне аңлагач, Арнольдка урынсыз соравы өчен бик уңайсыз, хәтта оят булып китте. Туганнары белән күрешү мәсьәләсендә Нуриевка бераз ярдәм итеп булмасмы дип, ул Америкадагы үзе эшләгән кино сәнгате вәкилләренең күмәк имзаларын җыюны да оештырып карады. Янәсе, СССР империясе җитәкчелегенә шул петиция-үтенечне җиткерсәк, кырыс йөрәкләре йомшап куймасмы?

Юк, күп мәртәбәләр һәм күп оешмалардан, хәтта АКШ президентларының үзләреннән җибәрелгән мондый рәсми таләпләргә карап кына ни Никита Хрущев, ни Леонид Брежнев, ни Юрий Андроповның ник бер чәч бөртеге селкенеп карасын! Кызыл империя дилбегәсе бары Михаил Горбачев кулына килеп кергәч кенә, тынчып беткән ил күгендә беренче саф җилләр исә башлады.

## 39

Джейми Уайетның әтисе белән бабасы шулай ук Америкада киң танылган рәссамнар иде. Тиздән Мәскәүдә бу өч рәссамның гаилә күргәзмәсе оештырылды. Башкала тамашачылары игътибарына тәкъдим ителәчәк әсәрләр арасында Рудольф Нуриевның кече Уайет иҗат иткән гаҗәеп уңышлы портреты да бар булып чыкты.

Мондый зур һәм мөһим күргәзмә ачылыр алдыннан, гадәттәгечә, башта аны үткен күзле дәүләт иминлеге сакчылары җиз иләк аша үткәрде: СССРның төп көндәше булган илдән китерелгәч, андый-мондый безгә зыян салырлыклары юкмы? Менә бит, бик тырышып эзләгәч, тырнак астында кер табыла! Ул «кер»—туган иленә әйләнеп кайтмыйча, чит илдә калган биюче Нуриев портреты!

Шунда ук рәсем авторы Джейми Уайетны чакыртып китерделәр һәм, киң-текә маңгаена терәп, аңа нибары ике сүздән торган бик усал сорау бирделәр:

—Бу кем?

Кече Уайет сәер сорау бирүчеләргә гаҗәпсенүле карашын юнәлтте:

—Ник... Рудольф Нуриев ич!.. Әллә дөньяның бүгенге көндәге иң атаклы биючесен бөтенләй танымый да башладыгыз инде?!

Җавап артык кыска һәм мыскыллы булды:

—Сездә бәлки атаклыдыр... Ләкин бездә туган илен алыштырган куркыныч җинаятьче ул!

—Буласы булган—буявы сеңгән дигәндәй... Ул көннәрдән соң инде күпме вакытлар узган түгелме соң?

—Белеп торыгыз—илгә хыянәтне бернинди вакыт-фәләннәр дә кичерә алмый!

—Ничек кенә кичерәчәк әле! Менә күреп торырсыз: Нуриевка кызыл богау түгел, ә рухи һәм хәтта алтын һәйкәл салыр көннәрегез алда әле!

Чөнки ул—туган иленә түгел, ә анда хөкем сөргән черек җәмгыятькә каршы иң беренчеләрдән булып баш күтәргән һәм җинеп чыккан узаман! Хәтта әйтергә мөмкиндер ки, бүгенге илбашыгыз Михаил Горбачевның илне янарту, үзгәртеп кору идеяләре астына шифалы дым булып яткан иң беренче каһарман. Кабатлап әйтәм: СССР дигән явызлык империясе җимерелеп төшкәч, киләчәктә ана Горбачев белән беррәттән һәйкәл куячаклар әле!

—Хыянәтчегә һәйкәл?.. Тотсын капчыгын!!! Ә менә сезгә, мистер Уайет, бу әсәрегезне күргәзмәдән һичшиксез алырга туры киләчәк! Һәм кичекмәстән!!

—Уйламыйм да!

—Ничек кенә уйларсыз... КГБ дигән дәһшәтле көчне монарчы берәүнең дә җинә алганы юк әле!

Ләкин тулы ирек, тулы хөрлек дигән изге төшенчәләрне кечкенәдән бөтен тән күзәнәкләренә сеңдереп үскән Джейми Уайет алай бик тиз җебеп төшүчеләрдән түгел иде:

—Менә нәрсә!—дип мәсьәләне кабыргасы белән куярга мәҗбүр булды ул.—Икенең берсен сайлагыз: йә Нуриев портреты һәм мин, йә сезнең яктан һәм безнең тарафтан инде күпме көч куелган Уайетлар гаиләсе күргәзмәсенең бөтенләй ачылмый калуы!

Эшләр болайга киткәч, совет чекистлары да икеләнә калдылар: чөнки сүз ирегә мәсьәләсендә кайчандыр кысып борылган шөрепләр, ил кәнәфиенә Михаил Горбачев утыргач, дөрестән дә, соңгы вакытларда шактый бушый төште. Белмәссең, ике арадагы мәдәни багланышларның тагын бозылып куюына үз өлешеңне кертеп, киләчәк язмышына зыян китерүең дә бик ихтимал!

Озын-озак бәхәсләрдән соң, ниһаять, ике якны азмы-күпме канәгатьләндерә алырлык уртак килешүгә ирештеләр. Рудольф Нуриев портретына әлегә тимәскә, ләкин өстен киндер пәрдә белән капларга! Вакытлыча, бу мәсьәлә өстә тәмам ачыкланып җиткәнче. Чөнки тиздән, рәсми ачылганчы ук, Американың танылган рәссамнәре күргәзмәсен КПСС Политбюросы әгъзаләре килеп карарга тиеш!

Илнең мәдәни тормышына тирән йогынтылы беренче леди буларак, Раиса Горбачева зур һәм киң сулышлы мондый халыкара күргәзмәләрнең берсен дә калдырмыйча карап барырга тырыша иде. Ялгызы гына да түгел—күп очракта ире Михаил Сергеевич белән! Кырык якта кырык эше көтеп торган нинди генә ашыгыч чаклары булмасын, сөекле хатыны теләгенә илбашы булып хәтта илбашы да һич каршы килә алмый иде. Чөнки Мәскәү университетында бергә уку елларында ук башланган саф һәм тигез мәхәббәт, сүнмичә-сүрелмичә, әле һаман аларны гомер юлыннан озата килә иде!

Америка рәссамнары күргәзмәсенә дә Горбачевлар парлашып килделәр. Атаклы Уайетлар токымының иң яшь һәм талантлы дәвамчысы буларак, аларны Джейми үзе озатып йөрде. Менә өстенә никтер ак җәймә капланган теге картина турысына да килеп җиттеләр.

—Бу кем рәсеме?—дип сорап куйды Горбеачев, аны күргәч.—Нигә өсте каплаулы?

Джейми Уайет тиешле җавапны бирә алмый калды. Совет чекистлары алдан өйрәтеп куйган күргәзмәләр залы хезмәткәре анардан күпкә өлгеррәк булып чыкты:

—Ясалып бетмәгән портрет ул, Михаил Сергеевич!

Горбачев, берни аңламыйча, Джейми Уайетка карады:

—Алайса, нигә остаханәдә түгел, нигә монда эленеп тора?

Югары дәрәҗәдәге мондый көпә-көндез алдашуга түзеп калырга теләмичә, кече Уайет сүз барышын тагын үз кулына алырга мәҗбүр булды:

—Гафу итегез, сэр Горбачев... эш монда бөтенләй башкада.
—Ә нәрсәдә?
—Картинада сурәтләнгән бөек биюче Нуриевнын, имештер, кайчандыр иленә хыянәт иткән булуында.
—Имештер?.. Хыянәт?!
Чибәр-шома мангае өстенә зирәк табигать тарафыннан коңгырт буяулы нәни пумала «тидереп» алынган Горбачевның йөзе кинәт кызарып чыгуны күреп, Джейми Уайет тизрәк аны тынычландырырга ашыкты:
—Юк, юк, сэр Горбачев! Чит илдә калырга мәҗбүр ителү әле хыянәт дигән сүз түгел! Юкса, андый кеше портретын мин ясар идемме?
Ирле-хатынлы Горбачевлар, бер-берләренә карашып, озак кына серләшеп-кинәшләшеп алдылар. Студентлык елларында, әлбәттә, Мәскәү сәхнәсендә аларның Рудольф Нуриев дигән яшь, ләкин искиткеч талантлы биюче чыгышын берничә мәртәбә күргәннәре бар иде. Ә бит, уйлап карасаң, ул—тимер чаршау эленгән совет чикләре аша хөр иреккә иң беренче сикереп чыга алган кеше! Ягъни мәсәлән, аякларына бәйләп җибәрелгән юан тышау белән башына киертелгән авызлыклы йөгәнне бии-бии өзә алган гаярь егет!
Киләчәктә үзеннән дә элгәреге рухи көрәштәше саналып йөртелә башлаячак биюче портретын Горбачевның кинәт бик күрәсе килеп китте. Аның үтенечен үтәп, рәсем өстендәге ак пәрдәне акрын гына шудырып төшерделәр.
Әйе, Нуриев портреты галәмәт оста ясалган иде. Аның башимәс узаман холкы чабыш атыныкыдай киерелгән борын яфраклары, токмач төсле бүрткән кан тамырлары, бөркетнеке кебек ерак төбәлгән кыю күз карашыннан бик ачык күренеп тора. Ул күз карашында бераз гына горур моңсулык та бар шикелле.
Әлеге моңсулыкка сизгер күңелле Раиса Горбачева да игътибар итеп өлгергән икән. Башкортстан белән бәйләнешле якташлыгы аркасындамы, Рудольфның бүгенге хәлләре турында ул, гомумән, күбрәкне белә булып чыкты:
—Беләсенме, Михаил Сергеевич: Нуриевның Уфада калган әнисе белән күрешмәвенә инде чирек гасырдан артык икән.
Джейми Уайет та беренче лединың сүзләрен хуплады:
—Әйе, әйе. Төгәлрәк әйткәндә, егерме алты ел!
—Да-а...—дип куйды Горбачев, авыр сулап.—Ә ник кайтмый икән?
—Чөнки, төрмәгә ябу белән янап, КГБ аяк чала.
—Неужели?.. Хәтта яныйлар???
—Янау гынамы? Нуриевны җиде еллык төрмәгә ябу турында суд карары күптән чыгарылып, аның илгә кайтуын гына көтеп торалар.
—Ярый... Ә әнисе нигә үзе килми икән алайса?
Раиса Максимовна, иренә карый-карый, шулчак авыр көрсенеп куйды:
—Сиксән ике яшьлек әнисе каты авыру инде. Уфадагы кызы белән чит илгә бара да алырлар иде, бәлки. Ләкин аларга да виза бирмиләр.
Михаил Горбачев, күп мәгънәле итеп, илнең беренче ледиена карады:
—Элек бирмәгәннәр! Хәзер исә дөньялар үзгәрде. Бәлки, безгә дә үзгәрергә вакыттыр ә, Раиса Максимовна?
—Мин дә шулай уйлыймын, Михаил Сергеевич!—диде беренче леди һәм, үзен ярты сүздән аңлаган иренә рәхмәт хисләрен белдереп, аңа җылы караш ташлады.

## 40

Төн урталары җитсә дә, кичке спектакльдән соң булып алучан күңелле мәшәкатьләр белән йөреп, Рудольф урын өстенә аварга өлгермәгән иде

әле. Инде керфек очларына кунган татлы йокыны качырып, менә йокы түшәге читенә куелган бик борынгы һәм затлы кечкенә өстәлдә телефон чылтырый башлады. Тавышы үтә шомлы ишетелә—тугызынчы дистәсен ваклаучы әнисенә алай-болай тагын нидер була күрмәсен!

Уфадан кече апасы Резидә чылтырата икән:

—Энем, синме бу?

—Исәнме , Резидә апа! Ни хәлләрегез бар?

—Бездә хәлләр бик начар, энем!

—Ни булды, апа?

—Әнине паралич сукты: ни күрә, ни сөйләшә, ни йөри алмый...

Рудольф, кинәт күз аллары карангыланып китеп, кулындагы телефон трубкасын идәнгә төшереп җибәрде. Аннары, идәнгә иелеп, бераздан аны кабат кулына алды:

—Алло...

—Ни булды, энем?

—Юк, болай гына... Кайчан булды ул күнелсез хәл, апа?

—Берничә сәгать элек кенә... Ник элегрәк шалтыратмадыммы? Беләсен бит инде: сиңа үч итеп, безгә һаман телефон кертергә теләмиләр. Шәһәр үзәгендәге халыкара телефонга көч-хәл белән барып җитсәм—су буе чират!

—Аңлашыла... Миңа кайчан кайтып җитәргә?

—Врачлар әнкәйне озак яши алмас диләр... Аны исән чагында күреп калырга теләсәң, эшне кызу тотарга кирәктер, энем.

—Димәк, никадәр тизрәк—шулхәтле яхшырак?

—Әйе, шулай...

—Көтегез!

—Ярый... Хәерле юллар—тиз арада күрешергә язсын, энем!..

Йокы дигәннәре өреп очыргандай юкка чыкты. Һәм ни гаҗәп: татлы йокы белән бергә Рудольфның бәгырь түрендә чирек гасыр буе туплана-җыела килгән шомлы курку хисләре дә күз ачып йомганчы эреп бетте. Егерме алты ел күрмәгән-күрешмәгән газиз әнисе үлеп ятканда, Себер төрмәләренә ябылудан ничекләр шүрләп тормак кирәк?! Тотсыннар, әгәр хәлләреннән килсә—дөнья сәхнәләрен генә түгел, миллионлаган тамашачылар йөрәген дә тетрәткән көчле-житез аякларына тагын юан һәм сусәргән тышау, тыңлаусыз чәчле башкаена исә тимер авызлыклы черек йөгән кидерсеннәр! Әнисен, фани дөньяда соңгы сулышларын алучы газиз әнкәсен тере килеш һәм ахыргы мәртәбә күреп калу хакына ул барысына да түзәргә, һәммә авырлыкларга да түзәргә әзер!

Себер төрмәләренә ябылудан курку хисләре белән бергә Рудольф бу минутларда оялу, тартыну кебек төшенчәләрдән дә тулаем азат иде. Төн урталары—йокының иң тәмле чагы булуга карамастан, тотты да ул Франциянең Тышкы элемтәләр министрлыгында эшләүче танышына чылтыратты:

—Алло! Месье Местр! Алло...

Кара төн уртасында тәмле йокысынан уятылган Рош-Оливье Местр, ниһаять, телефон трубкасын алды:

—Нишләп төнлә уятасыз?—диде ул, ачулы тавыш белән.—Кем бу?

Тагын бер мизгелдән исә аның янак астына төшеп җиткән бакенбардлы йөзенә канәгатьле елмаю кунды:

—О-о!.. Гафу итегез, месье Нуриев! Исәнмесез! Тыңлыйм... Төн уртасында уяткач, димәк, көтелмәгән бер-бер хәл килеп чыктымы?

—Чыкты, месье Местр.

—Ни булды?

—Менә әле генә Уфадан хәбәр иттеләр. Минем чирек гасыр күрмәгән

газиз әнием, инсульт сугып, телсез һәм хәрәкәтсез калган. Аны тере килеш һәм соң мәртәбә күреп калу өчен, миңа кичекмәстән Уфага кайтып килергә кирәк!

—Ә КГБ тырнагына килеп кабудан курыкмыйсызмы?

—Мондый чакта нинди курку ди ул?! Себер төрмәсенә япсалар-ябарлар... Тик бу минем рухи гына түгел, физик үлемем дә булачак!

—Ничек? Үз-үзегезгә кул салыпмы?

—Әлбәттә!

—И Руди, Руди! Үләргә ашыкмыйк әле... Ә туган иленә ашыгыч төстә кайтып килү мәсьәләсендә шуны әйтә алам: безнең министрлык Франциядәге совет илчелеге белән килештереп, Париж Операсының тиздән Мәскәү гастрольләренә баруын болай да хәл итеп бетерә язган иде инде. Бик әйбәт була бит әле бу: Америка гастрольләрендә әле яңа гына триумфаль уңыш яулап кайткан Нуриев труппасын, минемчә, Мәскәүдә дә кочак җәеп каршы алырлар. Хәзер бит, үзегез дә беләсез, илләр арасына тимер чаршаулар кору түгел, ә алардан котылу заманы.

—Кочак җәепме, каш җыерыпмы—белгән юк әле!—дип куйды Рудольф, үз-үзенә сөйләнгәндәй.—Тик эш бит әлегә бөтенләй бүтән нәрсәдә, месье Местр.

—Ә нидә?

—Уфага минем мөмкин хәтле тизрәк кайтып җитүемдә! Виза миңа бер атнадан яки бер айдан түгел, кичекмәстән, менә шушы сәгатьләрдә үк кирәк!

—Аңлашылды, месье Нуриев: мин хәзер үк мәдәният министры Франсуа Леотар белән бәйләнешкә керәчәкмен. Ә ул кичекмәстән премьер-министрга, премьер исә президентка мөрәҗәгать итәр дип өметләник...

—Шулай була күрсен... Төнлә борчуым өчен гафу итегез, месье Местр!

—Борчылмагыз... Авыру әнкәгез хакына барысы да кичерелә, месье Нуриев!

Төрмәгә япсалар-ябарлар дип күпме генә батыраймасын, Рудольфның ул сасы читлеккә үзе теләп барып керәсе килми иде, билгеле. Бер кызган җайдан, беткән баш—беткән дип, ул тотты да АКШның атып үтерелгән президенты Джон Кеннеди хатыны Жаклин Онассиска да чылтыратырга уйлады. Ни өчен Онассисмы? Чөнки Джон гомеренә кул сузучылар тиздән аның шулай ук АКШ президенты булып сайланырга теләгән бертуганы Роберт Кеннединың газиз башкаена да җиттеләр. Әле алай гына да түгел: көннәрдән бер көнне Джон белән Жаклинның тездән яңа төшкән балаларын үтерү белән дә яный башладылар.

Атып үтерелгән президент хатынына исә, терәк эзләп, кемгә, кая барырга? Ул бөтенләй яклаучысыз калды. Американың гына түгел, бөтен дөньясының иң бай, иң куәтле миллиардерларыннан берсе Аристотель Онассис күптән инде аның кулын сорап йөри башлаган иде. Жаклиннан ул күпкә олырак-олырагын. Тик балаларының хет ышанычлы яклаучысы булыр дип, тәки грек миллиардеры тәкъдименә ризалашырга туры килде.

Ире үтерелгәч тә Жаклин гаҗәеп сөйкемлелеген, искиткеч кешелеклеген һәм галәмәт ярдәмчеллеген аз гына да югалтмаган иде. Киресенчә, Америка халкы, аеруча яшьләр аны көннән-көн күбрәк ярата гына барды. Шуңа күрә аның бөтен җирдә, хәтта чит илләрдә дә сүзе үтә иде.

Ә Жаклин белән Рудольфның рухи дуслыклары, үзләре яшәгән заманның чын һәм яшь лидерлары була алганлыктан, гаять көчле, гаять эчкерсез иде. Дөрес, Жаклин Онассиска өйләнгәч, бу дуслык бераз тоныклана төште төшүен. Чөнки карт миллиардер Рудольф Нуриев дигән яшь биючәнең соңгы елларда тамаша биек сәнгать, дан үрләренә күтәрелүеннән генә түгел,

анын әле чагыштырмача яшь булуыннан да көнләшә иде кебек.

Ләкин үлем түшәгенә егылган ана хәсрәте каршында нәрсә соң ул мондый урынсыз көнләшү?!

Жаклин Онассис бу юлы да кара кайгылар кочагындагы турылыклы яшьлек дустынын тел төбен бик тиз анлап алды. Әлбәттә, беркемнән, хәтта КГБ тырнагыннан дә куркып тормыйча, мондый чакта авыру әнкән янына очарга кирәк! Әгәр алай-болай эләктереп алсалармы? Әлбәттә, ул—Жаклин Кеннеди-Онассис та Рудольфны, һичшиксез, яклашачак! Хәтта СССР лидеры Михаил Горбачевнын сөекле хатыны, шулай ук гаять кешелекле һәм ярдәмчел Раиса Максимовнанын үзе белән телефон аша сөйләшә-сөйләшә булса да!!!

Жаклин, дөрестән дә, сүзендә тора белгән хатын булып чыкты. Рудольф аннан әгәр үзе КГБ кулына эләксә генә ярдәм итүен сорарга уйлаган иде. Ә ул, изге жан, токкан да шул ук сәгатьтә СССРнын беренче ледие Раиса Горбачевага чылтыраткан! Инсульт сугып, үлем түшәгенә егылган газиз әнкәсенен хәлен белергә кайтачак Рудольфны тиешле виза гына түгел, ышанычлы иминлек белән дә тәэмин итүләрен үтенгән. Боларнын барысын да иртәгесен иртүк Франциянен Тышкы элемтәләр министрлыгыннан чылтыратып хәбәр иттеләр. Инде тиешле виза да әзер икән—барып аласы гына калган! Тик шунысы: әлеге виза кәгазе нибары ике тәүлеклек кенә ди. Димәк, Мәскәүдә озак кына тукталыш ясап, Парижлан башта Уфага барып житәсе! Үлем түшәгендәге карт әнкәсе янында нибары берничә сәгать булгач, аннары тагын Парижга кайтып китәсе! Түтелкәгә—түтелкә!

Рудольф, әлбәттә, бик кыска бу сәфәрнен үзен тагын бер кат газаплау өчен шулай оештырылуын яхшы анлады. Ләкин берни кылып булмый, чөнки биргәннен битенә бакмыйлар! Әле чирек гасырдан сон бирелгән бу кырык сигез сәгатьлек рөхсәт өчен дә Жаклин Онассиска һәм анын гозеренә колак сала алган Раиса белән Михаил Горбачевларга кат-кат рәхмәт укырга кирәк! Үлем түшәгенә ауган авыру карчыкны дөньякүләм танылган биюче улы белән сон мәртәбә очраштыра алганнары өчен!

## 41

Рудольфнын туган жиренә алар биш кешелек тулы бер делегация булып кузгалдылар: Нуриев үзе, анын тән сакчысы белән тәржемәче кыз Жанин Регни... Мәскәүдәге кайбер эшләрен жайга салу һәм, ин мөһиме, шундый кайгылы көннәрендә КГБ кулына килеп эләгәчәгенә күнелендә аз гына да шик тумасын өчен, Франциянен мәдәният министры Франсуа Леотар белән Тышкы элемтәләр министрлыгынын жаваплы хезмәткәре Рош-Оливье Местр да Мәскәүгә бер үк рейс белән очарга тиеш булдылар.

Уфага китәр алдыннан, көнбатышнын көндәлек басмалары вәкилләре белән очрашып, Рудольф Нуриев тиздән Уфага—паралич суккан карт әнисе янына кайтып киләчәге турында хәбәр иткән иде. Чирек гасыр буе көрәшми торганнан сон, ниһаять, туган иленә кайтырга рөхсәт бирелү! Көтелмәгән һәм үтә гыйбрәтле бу хәбәрне көндәлек басмалар шунда ук бөтен жиһанга тараттылар. Хәйләкәр һәм гажәеп сакчыл Рудольф бу гамәлен махсус төстә—КГБ аны илгә кайткач үткен тырнакларына шыпырт кына каптырып ала алмасын өчен эшләде.

Тик совет басмалары гына «хыянәтче» Нуриевнын туган иленә ашыгыч сәфәре хакында ләм-мим дәшмәделәр. Ләкин, мона карамастан, Мәскәүнен Ширәмәт аэропортына бер көтү чит ил хәбәрчеләре жыелган иде. Алар, фотоаппаратлар һәм уч төбе хәтле генә диктофон төймәләренә челт тә челт баскалап, Рудольфка авыр-авыр сораулар яудырдылар.

Күпчелеген, изгән дә баскан дигәндәй, шул бер үк мәсьәлә кызыксындырды:

—Месье Нуриев, зинһар, әйтегез әле: Михаил Горбачевның бүгенге сәясәтенә мөнәсәбәтегез нинди?

Рудольф, ата төлке, мондый гына сорауларны күп ишеткән кеше. Моңарчы анның, әкәмәт еш үзгәреп торган сәясәткә тирән кереп китеп, туган иленә һичкайчан яла якканы булмады. Бүген дә ул, шушы гадәтенә тугры калып, җавапны эмигрант шагыйрь, Нобель бүләге иясе Йосиф Бродский сүзләре белән бирде:

—Кемнән дә бигрәк, мин ил дилбегәсенең нәкъ менә Горбачев кулында булуын телим!

Болай бүре дә тук—сарык та исән! Әгәр дә мәгәр СССРда сәяси хәлләр кинәт үзгәреп китсә, Рудольфка кырын карый башлаучыларга анның җавабы шулай ук күптән әзер булачак: мин әйтмәдем—Әйшә Патима, ягъни мәсәлән Йосиф Бродский әйтте!

—Мистер Нуриев! Сез—дөньякүләм танылган күренекле биюче! Татар халкының бер бөек улы буларак, ул милләт исемен йөрткән мәмләкәткә нинди игелек кылганыгыз бар?

Маңгайга бәреп бирелгән бик тә мәкле-кәпле сорау иде бу! Ләкин, четерекле әлеге мәсьәлә хакында үзенең дә моңарчы күп уйлаганы булганлыктан, Рудольф уңайсыз сорауга тапкыр һәм хак җавапны тиз тапты:

—Дөрес, автономия дигән мескен исемле, ләкин аягында нык басып торган Татарстан мәмләкәтенә минем моңарчы бер яңа мәктәп яки балалар бакчасы да салдыртып бирә алганым булмады. Шулай ук Казан яки Уфадагы балет мәктәпләренә дә күпмедер данәдә тупыйк очлы бию чүәкләре бүләк итә алмадым. Һәм моның кирәген дә тапмыйм. Чөнки ышанам: балет биючесе буларак минем дөньяга таныла алуым һәм, димәк, татар милләтен дә бар җиһанга танытуым—үз халкыма кылынган иң зур игелегем!

Бу җавап төнге аэропортка җыелган чит ил журналистларына шулхәтле ошады ки, алар хәтта берара күмәк төстә кул чабып тордылар. «Мескен исемле автономия» дип дөресен әйткәнгә нигә КГБ шымчыларыннан шыр җибәреп торырга? Хәзер инде аларның үзләренә койрык кысар чаклар җиткән! «Хыянәтче» Нуриевның, ниһаять, туган иленә кайта алуы моның бик гыйбрәтле бер дәлиле ләбаса!

Чираттагы Мәскәү—Уфа рейсы башланырга байтак вакыт бар иде әле. Бер сәгатен дә әрәм итәргә күнекмәгән Рудольф, шуннан файдаланып, күпме еллар күрелмәген Кызыл мәйданнан урап килергә уйлады.

Һәрвакыттагыча, илнең үзәк мәйданын чит ил туристлары баскан иде. Алар, еpактан ук танып алып, атаклы биючене баш киемнәрен сала-сала сәламләделәр:

—Мерси, месье Нуриев!

—Һелоу, мистер Нуриев!

—До видзинэ, пан Нуриев...

Илнең орыш, сугыш, инкыйлап белән бәйле кызыл кан түгел, ә «матур, күркәм» мәгънәсен белдергән искиткеч борынгы һәм гүзәл исемле үзәк мәйданда СССР дигән иләмсез зур империянең төрле төбәкләреннән җыелган кешеләр дә күп кайнаша иде, югыйсә. Тик аларның берсе дә Рудольфны инде танымый, һичберсе аны баш киемен салып сәламләми. Арзанлы аракы, очсыз колбаса эзләп, алар Кызыл мәйдандагы бер кибеттән икенчесенә чаба. Аларда балет түгел—аларда билет һәм корсак кайгысы!

Нигә һаман туймый ул корсаклар?

Үз тамагын үзе туйдыра алмаган нинди шөкәтсез ил, нинди котаймас империя бу?!

Хәлләрнең дөресен күбрәк яза торган бер көнбатыш басмадан Рудольф күптән түгел шуны укып белде: җитештерелгән милли байлыкның күпчелек

чит илләрдә биштән бере, ягъни егерме проценты халыкка кире кайтарып бирелсә, бу күрсәткеч СССРда нибары ике процентны гына тәшкил итә икән.

Егерме һәм ике процент!

Димәк, совет кешеләре дөнья халыкларыннан ун мәртәбә хәерчерәк яшәргә дучар ителгән дигән сүз! Нигә шулай? Хурлыклы бу хәерчелекнең иң төп сәбәпләреннән берсе—тарихта булган һәм котылгысыз юкка чыга барган барлык империяләр кебек үк, СССРның да үз күршеләреннән яулап алынган җирләрдә корылган булуында, киң танылган халыкара күләмнәрдән аның хәтта дистәләрчә тапкыр зур булуы сәбәпле, тиешенчә идарә ителү сәләтсезлегендә, сугышларсыз яши алмагач, аның һәрчак ашкынып коралланырга тиешлегендә. Әнә шуңа күрә илнең иң күп байлыгы яңадан-яңа, берсеннән-берсе дәһшәтлерәк кораллар ясауга китеп бетә. Ә ул кораллар бик тиз искерә тора. Булачак дошманнарыңнан калышмас өчен, димәк, аларның яңаларын ясарга кирәк була... Кыскасы, төпсез кое!

Шулай итеп, күренә ки, кырыс һәм бәхетсез язмышлары тарафыннан СССРда яшәргә, дөресрәге, көн күреп газапланырга мәҗбүр ителгән барлык милләтләр, шул исәптән урысларның да кичәге, бүгенге һәм, ихтимал, әле байтак елларга сузылачак иртәгеге хәерчелегенең төп сәбәбе—әлеге ил-империянең кирәгеннән артык, коточкыч зур хәлендә кала бирүендә. Совет империясе тәмам таркалмый торып, бу хәл үзгәрмәячәк! Җир астындагы төп байлыклары саналган кара алтыннарын зуп-зур империянең һич төкәнмәс хәрби ихтыяҗлары өчен суыртып бетерә язган татар һәм башкорт халыклары да әле тиз генә хәерчелекләреннән арына алмаячак, димәк ки. Шулай итеп, «нинди иркен минем туган илем: кырлары күп, урман, суы күп», әйе, әйе, артык күп булуы аркасында, Мәскәү үзе дә юньләп яши алмый, бүтән азчылык милләтләргә дә иркенләп сулыш алырга ирек бирми булып чыга? Нинди кызганыч һәм аяусыз, кешелексез һәм мәкерле хакыйкать! Нишләп гап-гади бу хакыйкатьне илнең кичәге һәм бүгенге җитәкчеләре аңларга теләми? Нишләп алар шундый зур, шундый данлы держава алай-болай чит-читләреннән кителә башламасын дип кан калтырап торуларын дәвам итәләр? Ә бит бер милләт тә, тулы мөстәкыйльлек алдым дип, айга менеп китә алмый. Бәлки, чын дәреслек әүвәл таралуда, ә аннары тигез хокуклы булып кабат тупланудадыр?

Рудольфның ил, үз халкы турындагы фәлсәфи уйлануларын каршы яктан килеп туктаган таныш түгел бер агайның көтелмәгән соравы бүлдерде:

—Гафу итегез, энекәш... минем сезне кайдадыр күргәнем бар кебек...

—Бәлки...

Бәйләнчек адәмнәр, гадәттә, әнә шундый шомарып-каешланып беткән сорауларны бирергә яраталар дип, Рудольф таныш түгел кешегә каш астыннан гына сөзеп карап куйды. Юк, алай дисәң, башына яшел түбәтәй киеп, киң сөякле иягендә тар гына кәҗә сакалы үстереп җибәргән өлкән яшьләрдәге бу агай алай бер дә бәйләнчек кешегә охшамаган иде.

—Сез бит татар кешесе—шулаймы?—диде ул, бер башлаган сүзен дәвам итәргә теләп.

—Шулай да булсын ди...

—Алай дисәң, муеныгызда—чит ил артистлары гына кия торган чәчәкле-чуклы Миссони шарфы, өстегездә—чыршы сурәтле менә дигән пәлтә, башыгызда—шундый ук затлы берет..

—Шуннан?

—Шуннан дип... Сез бит Башкортстан татары—шулаймы?

— Алар Татарстанныкыннанниләре белән аерыла?

—Тәбәнәк гәүдәле, камытрак аяклы димме... Кыскасы, Ходай Тәгалә

тарафыннан нәкъ менә иксез-чиксез дала атларында чабып йөрү өчен яратылганнар. Әйтик, менә сезнең эше кебегрәк...

Рудольф, бит урталарын уймакландырып, йомшак кына көлеп куйды:

—Ә-ә.... Менә нине күздә тоткансыз икә-ән!

—Үпкәли күрмәгез тагын... Мин үзем дә бит Башкортстан татары. Тәкъдир кушуы буенча тик әлегә германякларында яшәп ятмыш. Туган яклар бик сагындырган... Менә шуна, үз якташымны Мәскәүнең Кызыл мәйданында очрату шатлыгына түзә алмыйча, сезгә дәштем дә. Ачуланмагыз, энекәш!

—Юк, юк! Ниткән сүз ди ул...

Мәскәүнең үзәк мәйданында үзе кебегрәк язмышлы якташы белән булып алган көтелмәгән сөйләшү Рудольфнын кәефен бераз күтәрә төште төшүен. Ләкин биредә ул барыбер тулы канәгатьләнү хисләре табып житкерә алмады. Ил күзендәге арпа шеше кебек, әнә, Кызыл мәйданнын нәкъ урта төшендә кукраеп утырган Ленин мавзолее. Илне рәхимсез революцияләр давылларына ыргытып, күп милләтле Ватанына тамаша күп хәсрәтләр китергән юлбашчы бабайны ясалма балавыз түгел, чын туфрак исе килеп торган изге жир куенына әле һаман индерә алмыйча интектерәләр.

Ленин мавзолее артында ук—рәт-рәт тезелешеп киткән ата коммунистлар каберлеге. Кая карама—каберлек тә каберлек! Мәскәүнең кыл уртасындагы әлеге «кызыл зират»ны күргәч, хәтта күңелләр укшый башлый.

Башкаланың инде күптән сагындырды дип уйланылган Кызыл мәйданы белән танышуны ярты юлда туктатып, Рудольф тән сакчысы һәм тәржемәче кыз белән тиздән аэропортка кайтып китте. Курыкканга куш күренер дигәндәй, ул сакчының әлегә кирәге дә чыкмады кебек. Кая ул! Күпме еллар ир-ат президентлар килешә, уртак тел таба алмаганны ике илнен беренче ледие телефон аша хәл итте дә куйды!

Әйе, үзгәрә заманалар, ничекләр генә үзгәрә, шөкер!

## 42

Алар очкан 339нчы рейслы самолет Уфа аэропортына төшеп утырганда төнге өчләр тирәсе иде. Очкыч ишеге төбенә үк килеп терәлгән трапка аяк басуга, анын маңгаен көчле салкын жил көйдереп алды. Ләкин, артык дулкынлануданмы, Рудольфка бик эссе, бик кайнар иде бу минутларда! Әлеге кайнарлыкка түзә алмыйча, ул хәтта жылы эчле көзге пальтосынын изү төймәләрен ычкындырып, чәчәкле-чуклы шарф очларын чишеп жибәрде. Нишләптер тирләп киткән береткасын салып, кулына тотты:

—Исәнме, күпме еллар читтә өзелепләр яши-яши, үлепләр сагынылган туган як! Саумы, әти-бабаларның кендек каны тамган газиз туфрагым минем!

Бая гына салкын-усал тоелган төнге жилләр, инде бөтенләй жылына төшеп, гадәттәгечә, анын уң чигәсенә сибелгән йомшак чәч көлтәләрен килеп иркәләде:

—Башкортстан дигән туып-үскән жирең белән бергә, татар атлы үз халкыңны бар дөньяга биеп таныткан данлы улыбыз безнең! Кайттыңмы? Кара көчләр белән тигезсез көрәштә сынып-сыгылып сынатмавың өчен чиксез рәхмәтебезне кабул кыл һәм әти-бабаларың жиренә рәхим ит!

Тамак төбенә утырган ачы төерне йотып жибәрде дә, тоныкс кына жемелдәшкән төнге аэропорт утларына карый-карый, Рудольф текә трап баскычы күтәрмәләреннән аска таба атлады. «Интурист» залының затлы-мәрмәр вестибюлендә аны инде үсеп житкән ике улы белән кече апасы Резидә һәм уртанчы апасы Лилиянең кызы Әлфия кояштай балкып каршы алдылар. Үзеннән биш яшькә өлкәнрәк бертуган апасын Рудольф башта таный алмый торды. Үзара күрешми яшәлгән шушы чирек гасыр эчендә ул

шактый базык-юантык гәүдәле житди ханымга әйләнгән. Таләпчән йөз чалымнары белән кече апасы, сөбханалла, гел әнисен хәтерләтә иде.

Төнге салкында басып тора-тора, инде шинә, сула да башлаган канәфер чәчәкләрен, бераз унайсызлана төшеп, Резидә Рудольфка сузды:

—Исән-сау гына кайтып життенме, кадерле энебез безнең!—диде ул, керфек очларына эленгән күз яшьләрен жемелдәтеп. Һәм, сулкылдый-сулкылдый, күпме гомерләр күрешмәгән газиз туганының изү төймәләре чишелгән жылы түшенә чәшке бүрекле башын төртте.—И энем, эне-е-ем... Синен кайтуыңны күргәч, әнкәбез ничекләр сөенер инде!

—Ә ул күрә аламы? Хәлләре ничек?

Резидә апасы йөрәк өзгеч тавыш белән әйтеп куйды:

—Юк шул, энем, ю-юк! Күрә дә, сөйләшә дә, йөри дә алмый шу-ул...

—Китик, алайса, тизрәк әнкәй янына!

Нуриевны озата кайткан бүтән кунаклар Уфа каласында иң дәрәжәле саналган «Россия» кунакханәсенә урнаша калдылар. Ә Рудольф белән аның якын туганнары, тиз-тиз атлап, янәшәдә генә урнашкан үз фатирларына китеп бардылар.

Инде тугызынчы дистәсен ваклый башлаган Фәридә карчык, түшәктә үзе шикелле ятып авыручы телсез-чукрак кызы Лилия, оныклары Әлфия һәм Руслан белән, әле һаман ике бүлмәле кысан фатирда көн күрмеш иде. Ире Хәмит исән чагында алар монда барысы алты жан яшәгән! Гаилә башлыгы 1968 елны үпкә рагыннан үлеп киткәч, бер башка кимегәннәр.

Әйтергә генә ансат: ике бүлмәдә—алты кеше! Шуларның икесе—урын өстендәге каты авыру! Коточкыч хурлыклы һәм кызганыч бу хәл асылда Хәмит солдатның артык горур, артык тыйнаклыгы һәм, имештер, «хыянәтче» тәрбияләп үстергән гаиләгә рәсми оешмаларның каш жыерып каравы белән аңлатыла иде.

Рудольф, күнелсез хисләреннән арынып, шырпы тартмасы хәтле генә йокы бүлмәсендәге агач түшәктә яткан әнисе янына ташланды һәм чал чәчле таныш толымнары йомшак мендәргә сибелгән газиз кешесенең тирән сырлы маңгаеннан үпте:

—Исәнме, әни! Менә мин, ниһаять, кайттым.... Син мине ишетәсенме, танийсыңмы, әнием-бәгырем?!

Фәридә карчык ябык-юка ияк очын сизелер-сизелмәс кенә кагып куйгандай булды. Аның зәңгәр томан төсле тоныкланып калган күз төпләреннән хәлсез ике тамчы тәгәрәп чыкты да, көрән-коңгырт таплар белән чуарланган битләреннән аска төшеп житә алмыйча, арып туктап калды.

Үлем чигендәге әнисенең хәрәкәтсез калган, ләкин әле жылы кулларыннан тотып, Рудольф шактый озак утырды. Ул әледән-әле аның тоныкъ күзләренә күтәрелеп карады. Кайчандыр жылы наз бөркелгән ул шәфкатьле күзләр бүген ничектер туктап калгандыр кебек тоелды. Бары тик юка иреннәр, чиста кәгазь бите төсле агарган хәлсез иреннәре генә, уймак кебек бөрешеп, ерак, бик ерак жирләрдән аның хәлен белешер өчен кайткан газиз улына нидер әйтмәкче, нидер сөйләмәкче булдылар шикелле. Телсезләр телен аңлау өчен, үзеңә дә телсез булырга кирәктер шул! Ә менә монысы әлегә Рудольфның хәленнән килми иде.

Карт әнисе белән сөйләшү-аңлашулар берничек тә барып чыкмагач, Рудольф уртанчы апасы Лилия түшәге кырына күчеп утырды. Аның бишектән яна төшкән бу апасын әле колхозлашу елларында ук, коммунист әтиләренә үч итеп, бергә уйнаган кулак балалары кышкы урамда «онытып» калдырганнар иде. Шул туңуыннан ул гомерлек чирле—телсез һәм чукрак булып калды. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, үзе кебек үк гарип бер егеткә кияүгә чыгып кызлары тугач, юл һәлакәтенә эләкте. Әлфия исемле бу

кызга бер яшь тулгач, Рудольф аңа Германиядән көмеш тәгәрмәчле бала арбасы алып кайткан иде. И сөенгән иде шул чакта Лилия апасы, и сөенгән иде! Хәзер менә шул кыз каты авыру хәлендәге әбисе һәм әнисен карап торырлык өй хуҗабикәсе булып алган.

Рудольф, үсмер чакларындагы кебек итеп, Лилия апасының йомшак иңбашларыннан сөеп куйды. Һәм ерак Франция җирләреннән үзләрен сагынып, ниһаять, кунакка кайткан бердәнбер энесен күрү сөенеченә түзә алмыйча, ул үкси-үкси елап җибәрде.

Рудольф Лилия апасы белән мәш килгән арада, әбисе Фәридә янына оныгы Әлфия килеп утырды. Алар икесе телсезләр телендә—ирен хәрәкәтләре аша гына аңлашырга күптән күнегеп беткәннәр иде инде.

Өске һәм аскы иреннәрен уртага җыеп бөрмәләндерде дә, Әлфия Фәридә әбисенә карады:

—Син безгә кем кайтканын беләсенме, әбекәй?

—Беләм, кызым, беләм!—диде Фәридә карчык, ияк очын чак кына аска кагып.

—Кем?

—Улым Рудик!!!

—Дөрес, әбекәй, дөрес!—дип, оныгы Әлфия Фәридә карчыкның тәмам кипшенгән һәм тирән җыерчыклы маңгаеннан үбеп алды.

Әнисе хәсрәтеннән, Рудольф күрешү истәлеге итеп алып кайткан күчтәнәчләрен өләшергә дә оныткан иде. Менә ул дынгычлап тутырылган күп кесәле юл сумкасын алып керде дә, өске биген шыртлатып ачып, иң әүвәл газиз әнкәсенә тәгаенләп алынган озын чуклы бик матур һәм калынҗылы шәлне чыгарды. Һәм аны иплэп кенә әнкәсенең ак мендәр өстендәге хәлсез иңнәренә япты:

—Менә, әни... Җылы иңнәреңдә тузсын!

Мангай күзләре инде берни күрмәсә дә, күңел күзләре белән Фәридә карчык бик тиз абайлап алды: әйе, бу шәл сугыш чоры ачлыгында Уфадан Әсән авылына бәрәңге апкайтырга барышлый ач бүреләрне куркыту өчен ут төртеп яндырылган теге калын шәлгә охшаган иде. Бүләк шәлгә улының җылы сүзләре һәм шуларга Әсән хатирәләре дә өстәлгәч, Фәридә карчыкның кайгы-хәсрәт яшьләре күптән инде агып бетә язган күзләреннән тагын акты-китте ачы тамчылар!

Тик болары инде изге тамчылар, куаныч-шатлык тамчылары иде.

Әнисенең бертуган энесе кайту хөрмәтенә Әлфия үзләре яши торган күрше бүлмәдә аш-су өстәле дә әзерләткән иде. Ләкин Рудольфның бу мәҗлестә утырырга һич күңеле тартмады. Ашамаган ризыгы түгел! Туганнарның да күрәсен күрде. Ә менә рөхсәт ителгән кыска гына вакыт эчендә егерме еллап элек үпкә рагыннан үлгән әтисе Хәмитнең каберен күрми китсә, моның үкенеч-гөнаһын кая куеп бетермәк кирәк?! Инде башта Мәскәүгә, аннары Парижга очып китәргә дә санаулы сәгатьләр генә калып бара бит!

Татар хатыннарына зират эченә керергә ярамаса да, әтиләре каберенең кайдалыгын күрсәтү өчен, кече апасы Резидә дә энесенә ияреpгә тиеш булды. Өйдән ашыгыч чыгып киткәнлектән, киез итек-фәлән дә алып тормаган иделәр. Ә җылырак табигатьле Париж егетенең аякларында салкын эчле көзге туфлилар! Житмәсә, бәхетсезгә жил каршы дигәндәй, әтиләре кабере зират эчендәге юлдан ярыйсы үк эчтә булып чыкты.

Ләкин Рудольф бер атлый башлаган юлыннан тиз генә кире борыла торганнардан түгел! Бию күнегүләре ясау залында, һәрнәрсәдән кадерле аякларына салкын тидертмәс өчен, ул еш кына озын куньчлы җылы оеклар киеп куя торган иде. Чөнки, мәгълүм ки, бүреләр кебек үк, биючеләрнен

тамагын да аяклары туйдыра! Ә монда, чалбар балакларын өскәрәк кайтарып куйды да, тездән кар яра-яра, апасы күрсәткән әтисе каберенә таба атлап китте.

Ә зират кары, билгеле инде, көрәлмәгән һәм, димәк ки, тирән булучан! Тиздән салкын кар аның тар очлы, юка табанлы туфлилары эченә кереп тулды. Бераздан көчле балтырларын, аннары бот төпләрен көйдереп алды. Ләкин Рудольф алтын-зәбәрҗәтләр бәһасенә торырлык аякларын саклау, аларга суык тидерергә ярамау турында һич уйлап та карамыйча, гел кар ерып алга атлавын белде. Биеләсе, кем әйтмешли, инде биелгән! Нәрсә ул чирек гасыр буе бер мәртәбә килә алмаган газиз кешен кабере белән чагыштырганда биюче аяклары?!

Инде тәмам артка ук калган апасы аңа кычкырып та карады:

—Энем, кире борыл! Аяксыз каласың ич!..

Юк, Рудольф кире борылмады! Көрәлмәгән-тирән зират карының үз балтырларын яндырып-көйдереп алуларын ул бәләкәй, бик бәләкәй чаклардан ук кичерергә туры килгән язмыш сынауларының кырыс дәвамы дип кабул итте. Түзәргә икән—түзәргә!

Күп азаплана торгач, менә Рудольф тиешле кабер турысына да килеп житте. Дөрестән дә биредә әтисе ятканлыгына ышану өчен, кабер ташындагы язуларны каплаган юка кар катламын сыпырып төшерде. «Хәмит Нурәхмәт улы Нуриев (1903-1968)» дигән сүзләрне укыгач, бераз тынычланып, куеныннан кат-кат төрелгән кызыл роза чәчәкләрен чыгарды һәм аларны кабер өстен сырган кар өстенә чәчеп җибәрде.

Ап-ак, сап-салкын кар өстендә кып-кызыл һәм кап-кайнар чәчәкләр!

Күпмедер дәрәҗәдә үз язмышын хәтерләткән бу гаҗәеп тирән мәгънәле күренешкә Рудольф озак кына онытылып карап торды. Ә дерелдәвек иреннәре акрын гына пышылдады:

—Исәнме, әти! Һәм хуш-бәхил бул! Сиңа күп кенә хәсрәт-борчулар китергән гөнаһлы улыңны кичер, зинһар, гафу ит!

Зираттан кайтуга, аяк аша өскә үрмәләгән суыкны куып чыгару өчен, Рудольфка көчләп диярлек бер стакан чамасы аракы эчерттеләр. Аннан-моннан гына капкалагач, аңа тагын урамга чыгып китәргә туры килде. Чөнки аны ТАССтан ияртеп җибәрелгән фотохәбәрче көтеп тора иде. Шуның белән икәүләшеп Рудольфның Уфадагы яшьлек эзләреннән тиз генә йөреп кайттылар. Кайчандыр Нуриев биегән опера һәм балет театрын, атаклы очучы Нестеров музеен карадылар. Ләкин, ял көне булганлыктан, аларны эчкә теләр-теләмәс кенә үткәрделәр. Чөнки, совет басмаларында язарга ярамагач, күнеленә бик якын бу калада Рудольфны күптән онытып бетергәннәр иде инде.

Ә Нуриевның, менә мин кайттым бит әле дип, кайларгадыр, кемнәргәдер чылтыратып йөрисе килмәде. Хәер, аның моңа вакыты да калмаган иде инде. Тиздән ул, туганнары белән соң мәртәбә саубуллашып, Башкортстан якларында туып-үскән бер татар биючесен кочак җәеп кабул иткән, аңа дөньякүләм танылырга булышкан, димәк, кабере дә шунда булачак Парижына кайтып китте.

## 43

Мәскәү дирижеры Владимир Вайс белән алар кайчандыр бергә укыганнар иде. Менә шул танышы Рудольфның тырыша-тырмаша дирижерлык серләренә өйрәнә башлавын ишетеп алган да, Вена урамында очратып, аңа сагыз кебек ябышты:

—Котлыйм, Руди!..

—Нәрсә белән?—дигән булды Рудольф.

—Дөньяның атаклы биючесе генә түгел, танылган дирижеры да була башлавың белән!

Күптән күрешмәгән танышының мондый гына мактауларыннан Рудольф, әлбәттә, эреп төшмәде:

—Арттырмыйк инде, Володя!..

—Биючеләр ничектер. Ә менә дирижерларның, гадәттә, бик озак яшәүләрен яхшы беләм. Бу ни өчен шулаймы? Чөнки аларның тән буыннары һәр мизгелдә сәгать теле кебек гел хәрәкәтләнеп тора! Димәк, син дә озак яшәячәксен—безнең түтәлгә дә кереп, бик дөрес эшлисең, Рудик дус!

—Ничек булыр—белгән юк инде, Володя.

—Бер дә аптырама!—диде Вайс һәм, йөнтәс бүрекле башында ниндидер яңа фикер туып, кинәт әсәрләнеп китте.—Беләсеңме, Рудик: бездә сиңа яраклы бик тә шәп бер тәкъдим бар!

Рудольф, моңа бик исе китмичә генә, әйтеп куйды:

—Тыңлап карыйк.

—Синең мәрхүмә әниең Казан якларыннан иде бит әле? Шулаймы?

—Казанның нәкъ үзеннән үк түгел. Ләкин шул бер төбәктән инде. Төгәлрәк әйткәндә, Әлки районындагы Төгәлбай авылыннан...—диде Рудольф, нишләптер, кинәт моңсуланып киткән тавыш белән.

—Синең дөньядагы иң кадерле кешеңне тудырган ул изге туфракта булганың, рәхмәт әйтеп, аңа баш органың бармы соң?

Рудольф, гаепле бала кебек, башын түбән иде:

—Бәләкәй чакларымда бәлки кайтылгандыр да. Хәзер инде хәтерләмим.

—Ә Казанның үзенә?

—Кемгә кайтыйм соң?.. Әти-әнисе үлеп, тома ятим калгач, булачак әниемне Казанга кайсыдыр агасы алып киткән. Кабан күле буендагы кое янында булачак әтием белән очраклы танышып, ул тиздән аңа кияүгә чыккан. Һәм алар, Казанда берникадәр яшәгәч, әтиемнең Башкортстандагы туган якларына кайтып киткәннәр.

Шулчак дирижер Вайс аны бүлдерергә мәҗбүр булды:

—Тукта... Бер кое дидең бит әле?

—Әйе, чыгырлы...

—Ә синең, Рудик дус, ул чыгырлы коены күрәсең килмиме?

—Килүен килә дә...

—Шулай булгач?.. Рәхим ит, Рудик дус!

Чынга ашмастай бу тәкъдимне ишеткәч, сызылган шырпы төсле, Рудольфның йөрәге дә кинәт кабынып китте:

—Чынлап әйтәсеңме, Вайс дустым? Әллә уйнапмы?

— Мондый изге тойгылыр белән шаярмыйлар... Кыскасы, шул: булачак һәм өметле дирижер сыйфатында, тиздән сиңа башта Казанда, аннары Ялта һәм Питер каласында чыгыш ясау мөмкинлеге туачак.

—Кайчан???—диде Рудольф, тәмам сабырлыгын югалтып.

—Март аенда ук инде! Димәк, тагын берәр атнадан—юлга! Йә, ничек—барыргамы теләгең?

—Ничек кенә әле, дустым... Син әйткән ул сәфәрләр, аеруча Казанга бара алачагым—минем бу якты дөньяда әлегә ирешмәгән иң якты һәм татлы хыялым!

Вайс, Рудольфның хәленә кереп, ашыкмый гына әйтеп куйды:

—Тик март салкыннары башлану куркынычы гына менә... Мондый һаваның әле яңа гына операция ясатылган бөерләреңә бик зыянлы булуы бар.

Катгый карарга килгән кешедәй, Рудольф кинәт кулын селкеп куйды:

—Тиешле виза гына булсын!.. Ә мин Казанга язгы янгыр түгел—таш

яуса да кайтачакмын! Газиз әнием истәлеген һәм анын кендек каны тамган туфракны хөрмәтләп кайтачакмын!

—Ә авыр операциядән сон, өзлегеп куйсаң?

—Өзлегү... Сөрлегү...—дип, Вайстан бигрәк, үз-үзенә әйтеп куйды Рудольф.—Мин инде ашыйсын—ашадым, биисен—биедем дигәндәй... Әниемнен туган жиренә кайтып баш ию кирәклеге белән чагыштырганда, болары—хәзер минем өчен ул хәтле әһәмияткә ия түгелләр!

—Борчылма, дустым—виза булачак! Хәзер элеккеге чекистлар заманы түгел. Юл чемоданыңны инде тутыра башласаң да була. Соңгы киңәшем: күп итеп партитураларыңны алырга онытма! Аеруча Сергей Прокофьевның «Ромео белән Джульетта»сын! Казанда сине жирле оркестрлар белән шушы балет музыкасына озын-озак репетицияләр ясау көтә.

## 44

Кайдан ишеткәннәр, кайдан белеп өлгергәннәр диген!

Рудольф Нуриевны чәчәкләр тоткан, шәһәрдәге төрле сәнгать оешмаларыннан вәкил итеп жибәрелгән тулы бер делегация каршылады.Моны күргәч, ана бик, бик рәхәт булып китте. Ни генә әйтмә, әниеннен беренче мәртәбә кайтылган туган жирендә сине чәчәкләр тотып каршы алсалар, бик күнелле була икән ул!

Дөньякүләм танылган биюче якташларын каршылаучылар Нуриевның үзләренә берничә сүз әйтүен көтәләр иде. Әле кайчан гына туган жиренә кайтырга зар-интегеп яшәгән Рудольфның дулкынланулы тавышы исә бу юлы шактый калтыранып чыкты:

—Исәнмесез, газиз кардәшләрем, әниемнең ерактагы якын якташлары! Менә мин дә кайттым, ниһаять... -диде ул һәм, чыршы ылысларына охшаш аксыл-авыш сызыклы пальтосының кесәсеннән кулъяулыгын алып, күз төпләренә бөялгән ачы тамчыларны сөртеп куйды.

—Хуш киләсез! Соң булса да—уң булсын!—диделәр ана.

«Волга» автомобиленең арт капкачын ачып, шунда Рудольфның юл әйберләрен салдылар да, атаклы биючене шәһәр үзәгендәге кунакханәгә илтеп куярга теләделәр. Ләкин Нуриев аларның бу теләгенә ашыгыч төзәтмә керттерде:

—Мөмкин булса, машина янда чакта минем бик ашыгыч бер гозеремне үтәп карыйк әле, дусларым!

—Нинди гозер ул—әйт кенә!

—Кабан күле буендагы чыгырлы бер коены эзләп табасы иде. Әнием шунда булачак әтием белән танышкан.

—Тәк, тәк...—дип, кавалеристлар буденновкасына охшатып тегелгән озын күзерикле калын кепкасын салып, шофер егет баш түбәсен кашып куйды.— Чыгырлы коелар хәзер анда сирәк калды да калуын... Тик менә Кабан күле дигәнебез һаман шул озын килеш тора бит, шөкер! Ул кое кай тирәдәрәк булды икән? Берәр билге-фәләне хәтер төбендә сакланмаганмы?

Рудольф, бераз уйланып торгач, кинәт әйтеп салмасынмы:

—Полигон!.. Ату кыры... Әнә шул ату кырында кинәт шартлаган граната тавышыннан куркып, әнием су чиләгән чыгырлы коега төшереп жибәргән...

Шулчак кемдер шат тавыш белән әйтеп куйды:

—И-и... Болай булгач, ул чыгырлы коены табабыз да табабыз! Урта Кабан артындагы танкодром каршында дигән сүз бит бу!

Тагын ун-унбиш минуттан егерменче еллар коесын эзләгән «Волга» автомобиле, дөрестән дә, Кабан күле артындагы танкодром каршына килеп туктады. Тик анда, ни гажәп, коелы, агач өйле урамнарны йотып, түбәләре күккә ашкан биек-биек ташпулатлар калкып чыккан иде инде. Янәшәдә

генә, тирән котлован казып, тагын бер йорт нигезен күтәрә башлаганнар. Шул котлован читендәге кара җир өеме янына барып, Рудольф киләчәктә әнисе төсе итеп карарга бер уч туфрак алды. Аннары, чиста кульяулыгына төреп, аны куен кесәсенә салды.

Рудольф ашкынып күрергә теләгән икенче нәрсә, әлбәттә, борынгы Казан Кремле һәм... композитор Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты иде. Аның да Мәскәү һәм Ленинград сәхнәләрендә гөрләп барган бозык варианты түгел, ә Казанда уйналган төп, әүвәлге нөсхәсе!

Ни сөенеч, график буенча да бүген кич Казан тамашачыларына нәкъ менә шул балет күрсәтелчәк икән! Шунлыктан Рудольфны хәзер кунакханәгә кайтарып куярга, ә иртәгесен яки оркестр репетицияләреннән бушрак бүтән көннәрне шәһәрнең истәлекле урыннары белән танышуны дәвам итәргә булдылар.

Дөнья сәхнәләрен дер селкетеп үзе дә биегән еллардагы гадәтенә тугры калып, Рудольф кичке спектакльгә байтак иртәрәк китте. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасының эченә үткәнче, башта ул аның тышкы ягыннан бер кат әйләнеп чыкты. Урам яктагы куышка кертеп куелган, дөньядагы үзе иң яраткан шагыйрьләрнең берсе Александр Пушкин һәйкәле каршында уйланып басып торды. Аннары чират ни өчендер мәһабәт бинаның кеше сирәк йөри торган арткы ягында куелган Габдулла Тукай һәйкәленә житте.

Ике милләтнең ике зур шагыйре!

Ләкин берсе никтер икенчесе артында басып тора?! Мондый гаделсезлек шунда ук Рудольф Нуриевның горур җанына килеп тиде. Дөрес, бәләкәйдән урыслар арасында тәгәрәп үсүе, аннары Уфадагы рус мәктәбендә укуы сәбәпле, ул үз халкының бөек шагыйре саналган Тукай иҗатын бик әйбәт беләм дип әйтә алмый. Мәгәр «Шүрәле» балеты либреттосының татар халык әкиятләре һәм әлеге шагыйрьнең шул ук исемдәге атаклы поэмасына нигезләнеп язылуы аңа яхшы мәгълүм иде.

Рудольф моңарчы Бах һәм Бетховен, Чайковский һәм Скрябин кебек олуг композиторлар иҗатын бик тырышып вә яратып өйрәнде, һәм, шөкер, аларны яхшы белә! Ә менә мәгълүм сәбәпләр аркасында бер кыйтгадан һичшиксез икенчесенә йөреп торган араларда үз милләтенең Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Рөстәм Яхин кебек олуг композиторлары моннарын җанына сеңдерә, белеп бетерә алмавы өчен кинәт кенә аңа бик уңайсыз һәм үкенечле булып китте. Әле соң түгелдер: Казанга бу кайтуыннан файдаланып, ул әлеге кимчелеген, һичшиксез, киметә төшәчәк!

Фәрит Яруллин дигәннән...

Аның дөньялар гизгән «Шүрәле» балетын да, ни үкенеч, Рудольф Нуриевка биергә туры килмәде. Чөнки ун еллап соңга калыбрак туган булып чыкты. Аннары төп сәбәбе монда гына да түгел. Илленче елларда Ленинградның Киров театры сәхнәсенә «Шүрәле» дигән искитмәле матур исемен әкәмәт сәер «Али батыр»га (Татарларда Али атлы кешеләр, гомумән, юк һәм була да алмый!) алыштырып, милли моңнардан, милли бизәкләрдән үрелгән асылы әрсез куллардан йолкытылып, хәтта ки, имгәтелеп менгән бу спектакль турында, буласы булган—буявы сеңгән дигәндәй, кырык еллап узгач инде искә алып торасы да килми. Хәер, «Шүрәле» балетының беренче, композитор Яруллинның үз бәгыреннән өзелеп төшкән иң дөрес, иң тулы варианты Казан сәхнәсендә әле дә булса бара икән. Әнә шуны бер мәртәбә генә түгел, буш вакыты бирелдә чагыштырмача күп булудан файдаланып, һичшиксез кат-кат карарга һәм бөек Тукай тудырган шук-шаян Шүрәленең ни өчен ерткыч-явыз Шүрәлегә әверелү сәбәпләре хакында бик ныгытып уйланасы булыр. Чөнки уйланмый ярамый—«Али батыр»ны сәхнәгә куеп

вә биеп, СССРнын ул чакта Сталин премиясе дип йөртелгән зур һәм мактаулы бүләген алуга ирешкән балетмейстер Леонид Якобсон, Юрий Григорович һәм бүтән биючеләрне Рудольф Нуриев үзе дә бик яхшы белә иде. Илнең югары бүләгенә ул чакта лаек булучылар арасында композитор Фәрит Яруллинның юклыгы гына, ни үкенеч, әле дә Рудольфның күңелен әрнетеп һәм тырнап тора.

...Театр бинасы эченнән кинәт тоныкк кына ишетелә башлаган кыңгырау тавышы Рудольфны озын-озак уйларыннан арындырып җибәрде. Ул, пальто җиңен җыерып, алтын сәгатенә карады. Кичке җиде тулып та килә икән. Димәк, театр кешеләрне тамаша залына керә башларга чакыра.

Казан тамашачыларын якыннанрак күрү өчен, Рудольфның Тукай һәйкәле читендәге артист халкы кереп-чыгып йөри торган арткы ишектән үтәсе килмәде. Халык ташкынына ияреп, менә ул театр бинасының алгы яктагы имән ишекләренә таба кузгалып китте. Бер кибеттән икенчесенә чабудан бушый алмаган Мәскәү халкыннан, дөресрәге, турист-юлчыларыннан аермалы буларак, аны бу чиратта танучылар да шактый иде, күрәсең. Чөнки Рудольф басып торган турыга борылып карый-карый, бер-берләренә нидер пышылдашып алалар. Әллә әнисе туган җиргә Нуриевның кайтуын чыбыксыз телефон аша ишетеп алганнармы?

Театр бинасы эченә үтүгә, кочак җитмәс чәчәк бәйләмнәре белән каршы алып, Рудольфны затлы келәмнәр җәелгән мәрмәр баскычлардан өскә алып менеп киттеләр. Директорның зур булмаган бүлмәсендәге өстәлдә эчемлек-кабымлык ише ризыклар да алдан әзерләп куелган иде. Хәл-әхвәлләрне белешә-белешә шулардан бераз авыз иткәч, Рудольф Нуриевны патшалар яки зур түрәләр генә утыра торган ложага озатып куйдылар.

Менә тамаша залы түшәмендә көмеш чүмәләдәй эленеп торган люстрада иренеп, теләр-теләмәс кенә якты утлар сүнә-сүрелә башлады. Шулчак Рудольфның йөрәгенә сары май булып яткан бер хәл булып алды. Тамашачылар берьюлы урыннарыннан тордылар да, ул утырган якка башларын бора-бора, дәррәү кул чабарга керештеләр.

Ә үзләре шат-сөенечле тавышлар белән бертуктаусыз кычкыралар:

—Афәрин, якташ!

—Рәхмәт сиңа, милләттәш!

—Нуриев! Нуриев!! Нуриев!!!

Ярсу алкышлар көченә түзә алмыйча, түшәмдәге бәллүр чүмәләдә менә тагын гөлт итеп якты утлар кабынды. Кул чабулар һаман тынмагач, Казан тамашачыларын хөрмәтләп, Рудольф Нуриев патшалар кәнәфиеннән торып басты һәм, биленә хәтле башын ия-ия, аларга чиксез рәхмәтен белдерде.

Залда тагын утлар сүнеп, ниһаять, «Шүрәле» балеты башланып китте. Барлык кыйтгалар һәм бөтен җиһан сәхнәләрендә монарчы ирешкән галәмәт зур, татар исемен үз биюләре белән дөнья биеклегенә алып менгән казанышлары өчен газиз әнисе якташларыннан рәхмәт сүзләре ишетә-ишетә, композитор Фәрит Яруллинның бер тынлауда йөрәкләргә үтеп керүче, милли бизәкләр белән гаять мул һәм оста чигелгән аһәңнәрен тыңлау, халык әкиятләре нигезендә бөек Тукай тудырган образларның чын асылы бозылмаган чагылышын карап утыру Рудольфка рәхәт, бик тә рәхәт иде.

*2004—2007 еллар.*
*Казан—Уфа—Санкт-Петербург.*

**Искәрмә.**
*Шушы елның 17 мартында атаклы биюче Рудольф Нуриевның тууына 70 ел тулды.*



Халисә Мөдәррисова

# КҮҢЕЛЕМӘ ЯУГАН КАРЛАР

***

Аерылды җәй көздән—
Кул болгап озатты,
Астра керфегенә
Тәүге рашкы ятты.

Утын салам утка,
Янсын учак, янсын.
Күшеккән җаннарга
Җылы дулкын барсын.

Бу әле—тәүге кар,
Юк, әле кыш булмас,
Кыш булуын булмас,
Җылы да еш булмас.

Хуҗа булыр тиздән
Чыңлап торган кышлар,
Кунар тәрәзәгә
Кызыл түшле кошлар.

Кызыл түшле кошлар—
Кояш ярчыклары...

Әй, син, алтын көзкәй,
Китмә, ашыкмале!

Илтмә әле кышларга,
Кышлар шундый озын,
Кыш үлемгә охшаш—
Яба җиргә бозын.

Елның бу мизгеле,
Минем гомер кебек,
Уты сүнеп барган
Учак көле кебек.

Ләкин көл астында
Учак жаны тере!
Кузда—өмет көче,
Кузда—яшәү сере.

Утын салам утка,
Янсын безнең учак,
Өмет һәм ышаныч
Өстим кочак-кочак.

***

Бу җәй синсез үтеп бара,
Үтеп бара... бара.
Шомыртларның тәлгәшләре
Кызыл түгел—кара.

Җәйнең соңгы бар җылысы
Яңгыр булып тама.
Вакыт җиле, аямыйча,
Чәчкә кырау сара.

Алтын шәфакъ утларында
Ак болытлар яна:
Соңгы өмет, кисәтүме,
Әллә әче яра?

...Җәең минсез үтеп бара,
Үтеп бара, кара!

## Дусларыма

Ярлар алар оныталар,
Дуслар янда калалар,
Синең белән терек-терек
Ахыргача баралар.

Дус—түремдә, яр—үтәлми
Ожмах капкаларыннан,
Адәм кебек бер куылса
Күңел бакчаларыннан.

Дус—җыр кебек, яр—укылып
Ябылган бүлек кебек.
Сөю китсә, моңы бетә—
Өзелгән күрек кебек...

Яр—җәсадеңә килсә дә,
Күренми генә килер...
Елый-елый бары дуслар
Ләхетеңә иңдерер.

Исерсәң дә, искерсәң дә,
Ярлар ташлап китәләр,
Бары дуслар—ничек барсың,
Шулай кабул итәләр.

Талда—ярлар, янда—дуслар,
Сез бит—күңел кошларым.
"Үпкән-кочкан җилгә очкан",
Гаепләшмик, дусларым,
Бергә булыйк, дусларым!

* * *

Әй ява да, ява яңгыр
Ничә көннәр туктамыйча,
Ага сулар, ага шаулап,
Ял итмичә, йокламыйча.

Шуа камыш телләреннән,
Үләннәрнең иңнәреннән,
Ява таңнан, ява көндез,
Ява кичтән, төннәреннән.

Ага яңгыр кыеклардан,
Урамнардан, басулардан,
Бүрткән сынын күтәралмый
Арышкайлар җиргә аутан.

Күбек-күбек күлләвекләр,
Бәллүр тамчы сәйлән таккан.
Күзен ачып карый алмый—
Канәферләр керфек япкан.

Тама тамчы, юк, йөгерә
Каеннарның алкасыннан,
Бөтен дөнья бергә-бергә
Диңгезгәчә ага сыман...

(Минем генә ялгыз җаным
Тар дөньяда тына бара,
Куырыла, яргалана,
Корылыктан сула бара.)

...Ничәнче ел туктамыйча
Тәрәзәгә яңгыр ява...

* * *

Тына бара дәрьяларым,
Тарая бара,
Төшә бара төн пәрдәсе,
Карая бара.

Акрыная күңелем сазы—
Сагая бара,
Бәллүр боздай бер нечкәрә,
Бер тая бара.

Ашыга-ашыга бу гомерем
Ай, кая бара!...

## Ике арада

Тибрәлә болыт түбәмдә,
Уйнамый яшен-камчы,
Остаз кебек спас керде,
Тәрәздә елак тамчы.

Оеп калган кебек дөнья,
Тынган-тыелган җил дә,
Ә күңел күкләргә дәшә,
Тик нидер баса иңгә.

Туктатма мине, күзләрдән
Эзләмә көзге чалым:
Җәй дә, көз дә түгел җанда,
Минем—дивана чагым.

Күңел сизә, зәңгәр күкләр
Тагын бер күкрәр әле;
Соң түгел, җәйләрнең көзгә
Авышкан гына мәле,
Туктатма мине, яме!

## Тоз һәм шырпы

Җиде төндә урман шырлыгында
Калганым бар минем адашып,
Юк, куркудан түгел, ялгызлыктан
Мең җанварның тоеп карашын.

Каңгырган бар—ялгыз юл табалмый,
Күзне каплаганда өермә,
Юлыккан бар—дәрвиш кебек ялгыз,
Өметкә тиң аучы өенә.

Шушы өйдә җанда җылы туа,
Әйтерсең лә язгы яшь курпы.
Иң кыйммәтле хәзинәдән кыйммәт—
Киштәсендә ята тоз-шырпы.

Җаннарыма салкын үтеп кергәч,
Инде бетте дигәч өметем,
Калтыранган бармакларым белән
Бер шырпыдан учак терелттем.

Төнге учак, мәңгелеккә өндәү,
Мин Җиһанда—тере төерчек.
Йөрәгемә шифа булып ятты
Күз яшедәй тозлы кыерчык.

Гомерем үтеп, алыш-биреш бетеп,
Фани дөнья миннән узса да,
Кешеләргә калдыралсам иде
Тоз һәм шырпы гына булса да.

***

Еллар аша, юллар аша
Мин сиңа дәштем бүген,
Син минем гомерлек бәйрәм,
Мәңгелек җырым минем.

Танымадың тавышымны,
Өздем телефон өнен.
Син мине мең гамь эченнән
Танырга тиеш идең.

Сагынырга, онытмаска
Бары син хаклы идең,
Син минем гомерлек газап,
Мәңгелек моңым минем.

Акыл белә: җеп очы буш.
Йөрәк тыңламый мине:
Буш телефон өне кебек
Һаман чакыра сине.

* * *

Таң алдыннан тагын буран,
Март аеның соңгы җиле.
Карамыйча тамчыларга,
Ак кар белән күмә җирне.

Өерелә, бөтерелә,
Әйтерсең лә кыш арада.
Күңелемә карлар ява—
Салкыннардан кем аралар?

Яз—яз булыр, соңгы буран
Соңгы тапкыр бөтерелер.
Күңелемә яуган карлар
Кайчан туктап, кайчан эрер?

## Серле җыр

Шаян нур булып төштең учыма,
Урамда майның чәчкә коены[1].
Тотып та булмый, китеп тә булмый,
Юк, алалмыйм мин нурдан кулымны.

Урап-уралып сүттең толымны,
Түгелә шомырт, гүя ак күбек.
Тотып та булмый, узып та булмый,
Әйтерсең, син—җил, иркә җил кебек.

Серле моң булып кердең җаныма,
Үзеңнән-үзең билэп күңелне.
Отып та булмый, онытып та булмый,
Әйтерсең, син—җыр, син—җыр шикелле.

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

*Бу айда Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Башкортстанда яшәүче каләмдәшебез, даими авторыбыз Халисә Мөдәррисованың юбилее. Шагыйрәне ихлас котлап, аңа яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.*

---

[1] Коен(диалект)—коеп яуган яңгыр.



Марат
Әмирханов

# ҮРБӘТ ХАНӘКӘ ГЫЙШКЫ[1]

РОМАН

Үрбәт үзенең мәхбүслек язмышы белән килешкән иде инде. Югыйсә, мәшһүр Казан-йортның иркә хуҗабикәсе иде ләбаса! Алтын-көмеш, ука-чука, асылташ, сый-нигъмәт, кадер-хөрмәт эчендә генә йөзәргә тиешле зат иде. Чынында да, андый балдай татлы Багы Ирәм, җирдәге оҗмах тормышын сигез ел буе татырга насыйп итте аңа Ходай. Шушы хәл-халәтенә тәмам күнгән иде. Хәтта сарай бикәләренең ихтирамлы мөнәсәбәтен, һәрвакыт көләч ачык йөзләрен, хадимә-туташларның тузан бөртеге кадәре генә теләген дә үтәргә җан атып торуларын санлап та бетерми башлаган иде.

Хәер, төшкән мәлне хәләле, Илһам ханга да баш бирергә ашыкмады ул. Ник дисәң, аңа курчаклы уйнаган җиреннән никах күлмәге кигезделәр. Унбер яше дә тулып җитмәгән үсмер кыз бала ир хатыны булу серләрен ничек белеп бетерсен соң?

Каенанасы Фатыйма-Солтаннан гына шүрли иде. Чөнки ни сәбәпледер, ханбикә киленен үз итмәде. Бигрәк тә әүвәлге чорда якты чырай күрсәтмәде, эткәләде дә төрткәләде. Күзенең агы белән каш астыннан гына карап ала да, китереп чага, гүя агу чәчкәсе. Ничек сүзләрен табып бетерә? Нинди генә кушаматлар такмады: надан да ул, аңгыра да, мәнсез дә...

И кимсенгәннәре... Аны бит горур булырга, бераүгә дә бил бөкмәскә өйрәттеләр. Хурлыктан үлем артык, дия иде анасы. Фатыйма-Солтан үзен "аслыһи нәслеһи"ләр рәтенә кертә, җае килсә дә, килмәсә дә нәсел-нәсәбе белән мактаныргa ярата. Имеш, би кызы, Нугай иленең иң мөхтәрәм аксөяге. Ике сүзнең берендә:

—Ханнарның ханы бөек Ибраһим җәнабе гали мине сорарга үзе килде,— дип шапырына иде.

Тора-бара Үрбәт каенанасының сүзләренә колак салудан туктады. Шулай булмыйча, ул да "аслыһи нәслеһи" зат ич. Атасы Муса тирә-якта иң дәрәҗәле бәкләрдән йөри. Көтүлек-биләмәләре генә Иделдән Журҗан (Каспий) диңгезенә кадәр өч көнлек юлга тиң...

[1] Журнал варианты.

Марат ӘМИРХАНОВ (1933)—*прозаик, публицист; «Чулманның ак йолдызы», «Таш һәйкәл», «Сөн моңы», «Тәкъдир» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Их, кайтып күрәсе иде, сулыйсы иде иркен дала һавасын! Туйганчы ат менеп чабасы иде. Юк шул, хәзер Нугай далалары хәтердә, төштә генә яши.

Төш дигәннән, соңгы арада һаман бер үк сурәттәге төш керәп йөдәтә. Күзләре йомылуга, каяндыр шайтан дисәң, шайтан түгел, пәри дисәң, пәригә охшамаган әллә нинди куркыныч җанвар килеп чыга да куып алып китә. Үзе төрле рәвешләргә керә: бер карыйсың, тилгәнгә әверелеп, баш очында эт тавышлары чыгарып чиный. Икенче караганда, ул инде ач бүре кыяфәтендә. Тешләре ыржайган, күзләрен кан баскан, һич качып котылырмын димә...

Бетерде, харап итте генә дигәндә, күктән төшкәндәй таяклы юлчы пәйда була. Ап-ак сакаллы, сәләмә киемле мөсафир.

Таягын селтәп җибәрүгә, теге албасты күздән югала. Аннан соң, ак бабай, гадәттәгечә:

—Су буйсыныр буага, ил буйсыныр җолага, мин сина әйбәт хәбәр алып килдем, акбикә,—дип Үрбәткә мөрәҗәгать итә.

Ә аның ачуы кабара. Чөнки ул үзенең мәхбүс икәнлеген исенә төшерә. Тоткын әйбәт хәбәргә өмет итә ала димени?

—Ни лыгырдыйсың син, дәрвиш, төш кенә бит бу,—дип чеәя Үрбәт.

—Кырык төшнең берсе—пәйгамбәр төше, акбикә, көт, әйбәт хәбәр бирдән-бер көнне килеп ирешәчәк әле сина. Бу—Тәңребез әманәте...

Нәкъ шушы урында уянып китә Үрбәт. Бернәрсә үзгәрмәгән, һәммәсе элеккечә. Җырудагы кебек:

Госман бер хафиз кызы идем,
Ханәкә—Солтан атлы идем.
Җефәк тә тотмас наз идем,
Тезген тотып барамын...

Нугай йортында аларның төш юраучылары бар иде. Иртә белән барысыннан да нинди төш күрүләре турында төпченеп-төпченеп сораштыра иде. Шулардан әллә нинди мәгънәләр таба иде. Бервакыт төшендә ак атка атланган яшь яугир белән кул биреп күрешкән иде Үрбәт.

—Тиздән яучы көт,—дип пышылдады юраучы колагына.

—Алама син, әллә нәмәләр сөйлисең,—диде Үрбәт әлеге сүзләрне охшатмыйча. Бала гына иде шул әле.

Тик төш юраучының гөманы акланды. Озак та үтми, Казан-йорттан яучылар килеп төшмәсенме! Хәер, бу инде көтелгән яңалык иде. Ник дисәң, анасы колак итен ашап бетергән иде инде бу хакта. Хан булмагае. Ә ана атакае белән анакаеннан башка беркем дә кирәкми.

Үксеп бетә иде. Һәм елата-елата биреп тә җибәрделәр. Хәзер исә Иван патша Нух каргасы да очып житә алмастай Каф тау артына олактырды. Хәтта чәчен дә үзе тарап үрергә мәҗбүр. Чөнки кыз-туталарын тартып алдылар, бер кара хезмәтче белән торып калды. Ә ул хуҗалык мәшәкатьләреннән артмый. Әле ярый каенанасы белән җанагаларын башка урынга, Ак күлгә сөрделәр, күз көеге булып йөрмәделәр. Фатыйма-Солтан фани дөнья белән хушлашкан икән инде, урыны оҗмахта булсын. Төпчеге Миңлетаһир да анасыннан соң озак тормаган.

Үрбәт каенанасына ачу сакламый, ул аны ярлыкады инде. Баксаң, мәрхүмәне карт бичә була торып "кечкенә хатын" дип йөрткән икән казанлылар: түбән ыруга мөнәсәбәтле ишарә. Менә ни өчен үрсаләнә-үрсаләнә үзен затлылар мөнбәренә индерергә тырышкан бичара.

Илһамның ханлыгы әнә шулай бик фаҗигале төстә тәгәлләнде. Үзе гаепле. Нигәдер эчүгә сабышты, хәмер белән дуслашты. Иван Казанга яу белән килгән көннәрдә дә акылына килмәде. Гаскәре дә хәзерлексез иде, бик тиз хәлдән

тайдылар. Алгазый морза гына урысларга чын каршылык күрсәтеп, аларга күп зарар китермәктә иде. Тик көчләрнең тигезсезлеге, бердәм житәкчелек булмау, оешмаганлык морзаның каһарманлыгын юкка чыгарды. Урыслар Казанны илле ике көн камап тордылар.

Ә Илһам хан, дошманга каршы һөҗүм оештырырга тиешле кеше, мәжлес корып, кыжыкыян-дупыян килеп эчеп яткан. Аны исерек хәлендә үз даирәсе кешеләре үк, Мәскәүгә йөз тотучы баш карачы кара йөрәк Кәлимәт бәк кушуы белән, урысларга тотып биргәннәр.

Шулай итеп, 1487 елның 9 июле Иван патшага җиңү шатлыгы алып килде.

Илһам тоткынлыкта бөтенләй бетереште, тернәкләнеп китә алмады. Тәмам күздән төште, исәпкә бар, санга юкка әйләнде. Хатыннарын да бар дип тә белмәде, ике дөнья бер кәнди иде аңа.

Вакыт уза. Рәхәттә дә, михнәттә дә уза. Урысның бу каһәрле кар даласында менә инде ундүрт мәртәбә кыш булды. Жәйнең дә ундүртенчесе башланды. Әйтүе генә ансат, ундүрт кыш вә ундүрт жәй! Бу бит әсирлектә үткән гомер. Аның һәр көне елга бәрабәр. Моны башына төшкән кеше генә белә. Әмма түзми чараң юк, түзәсең.

Шулай да, ничек кенә авыр булмасын, ничек кенә жаның кыелмасын, бу әле дин алыштыру түгел. Әсирлек язмышын кабул итсә дә, динен алыштыруга теше-тырнагы белән каршы ул. Ничек үз асылыңны үзгәртмәк кирәк? Бу соң сиңа тормыш биргән, сине бар иткән атаң-анаңны алыштыру булыр иде ләбаса. Ә атай-анай алыштыргысыз. Алар—бердәнбер. Ходай шулай фарыз кылган.

Буаз биядәй кап корсаклы, кәжә сакаллы димче боярларны күп күрде Үрбәт. Башларын селки-селки бил бөгеп сәламләгән булалар үзләре, хөрмәтлиләр, имеш. Аннан каргалар шикелле стена тирәли куелган кин кәнәфиләргә тезелешеп утыралар. Тылмач тәбәнәк өстәл янына чүгәли. Хәл-әхвәл сорашкандай итәләр. Монысы, әлбәттә, сүз кузгату өчен бер сәбәп кенә. Сүз иярә сүз чыга бит ул, дип уйлыйлар, күрәсең.

Сүзләре озын боярларның, аркан буе. Тик һаман шул бер балык башын чәйниләр: православиегә күч, рәхәт тормышка чыгарсың, үзеңне олуг кенәз даирәсендәге бер тол боярга кияүгә бирербез...

Әлеге сүзләрне тылмач селәгәен йота-йота әйтә, майлы күзләрен әле хуҗаларына, әле аңа таба борып ала. Тавышына да вәсвәсәле төсмер куна.

Үрбәт әлеге тылмачны ялагай эткә охшата. Була бит гел койрыгын болгый торгач, өрүен оныткан этләр. Бу җанын Иблискә сатып, кыйбласын җуйган адәм актыгы. Билен бөгә-бөгә гәүдәсе әлеп тягына әйләнгән инде. Биек ишектән дә иелеп кергән була, кәрлә.

—Син әсир зат, ханбикә, жинелүче як буларак, безнең таләпләрне үтәргә бурычлысың,—дип вәкарь белән генә тезеп китә,—орышның кагыйдәсе шундый. Ә таләбебез ачык: православиегә күчәргә, муеныңа тавык тәпие тагарга. Кәгазьләргә имзаңны сал да, бетте-китте, вәссәлам. Калганын архиерей атакай бәйнә-бәйнә төшендерер.

Үрбәт кәгазьләргә күз дә төшерми, турыга катып утыра бирә, гүя урындыгына ябыштырып куйганнар.

Арада Мефодий Калистратович дигән бояр аеруча хәтеренә сеңеп калды. Теле-телгә йокмый. Шырыйныкы шөрепле, дигәндәй кайчакта ни сөйләгәнен дә онытып җибәрә. Аннан сирәк тешле иләк авызын җәеп көлгән була, янәсе, үз кеше, янәсе, аңа ышанырга мөмкин. Үрбәтне кияүгә димләү фикере дә беренче аның авызыннан чыкты бит.

—Синең шикелле абруйлы ханбикәне тол итеп тотуыбызны, ай-һай, ходай хуплармы икән? Үзең акыл иясе, нәсел-нәсәбең асыл затлардан,—дип сайрый башлады көннәрдән бер көнне,—кара инде ул килеш-килбәтеңә, буй-сыныңа, зифа камыш кебек бит, исәр. Бер битең ай, икенчесе—кояш. Бөтен Нугай

даласының гүзәллеген үзенә җыйгансың. Бәхет өчен туган аккош ич син. Илһам хан сина андый бәхетне бирә алмады. Ул бирмәгәнне без бирәчәкбез. Күч православиегә!

Әйе, Үрбәт боярларның төрлесен күрде. Олуг кенәз димче боярларны нигәдер алыштырып кына тора иде. Мефодий Калистратович кайсы ягы белән ошамагандыр, бераздан ул да күренми башлады. Югыйсә оста, астыртын, хәйләкәр димче иде, хатын-кызның акылын белеп кора иде гәпләрен. Аны тыңларга да кызык иде.

Иван патша Үрбәтне үз диненә аударырга бик тә, бик тә тырыша иде. Ул Илһам ханның бичәсе ләбаса, ханбикә! Ханга тиярга ярамагач, ни өчен ханбикәсен шулай иза чиктерергә? Үндүрт ел буена сөлектәй ябышты олуг кенәз, һич тынгы бирмәде. Бәлкем, шуның аркасында кешелек абруен саклап калгандыр да әле Үрбәт. Ник дисәң, ана һәрвакыт уяу булырга, җебеп төшмәскә кирәк иде.

Хак, дошманнары каныккан бер мәлдә, ни гаҗәп, Үрбәтнең өмете уяна иде. Хәлбуки, мона, әлеге сәер төшне исәпкә алмаганда, тары бөртеге кадәр дә нигез юк иде үзе.

...Үрбәтнең уйлары өзелде. Йомышчы кереп, галәттәгечә, оран салды. Күпме гомер узды, ә ул һаман үзен Казандагы хан сараендагыча тота. Янәсе, тоткынлык кануннарын санга сукмый. Хуҗабикәсеннән үрнәк аладыр, мөгаен.

—Мөхтәрәм ханбикә галиҗәнаплары, олуг кенәздән илчеләр килде, кабул итәргә әзер бул!

Бу юлы ишектән чапан итәкләрен җилфердәтеп, ниндидер төрки зат килеп керде. Үрбәт җилкенеп куйды. Әллә чыннан да дөньялар үзгәреп китәрме? Сабыр соңында нсорат[1] бар, михнәт соңында рәхәт бар, кайгы соңында шатлык бар, диләр бит.

Үрбәт үзенә бер үҗәти җәһәтлек белән чапанлы бәндәне күз уңыннан үткәрде. Йөзе какланган казныкы шикелле каралып каткан икән. Күрәсең, мул кояшлы төбәктә туып-үскәндер. Сакал-мыегы да нәкъ йөзе кебек—соргылт төстә. Бердән-бер игътибарга чалынган нәрсәсе—борын! Мәгәр, борын дисәң дә борын. Кызыл борыч кузагыннан һич тә ким җире юк.

—Ханбикә галиҗәнапларына олуг кенәз Иван Васильевичтан күптин-күп сәламнәр алып килдем,—дип, боярлар шикелле исәнлек-саулык та сораштырып тормастан, чаптарның ялыннан алды бу. "Аңлашылды, Иван мине кимсетергә ният иткән икән, түбән дәрәҗәдәге адәмен җибәргән", дип кимсенеп уйлап куйды Үрбәт. Димәк ки, үзгәреш унай якка түгел.

Димче сүзен дәвам итте:

—Син, ханбикә, бөек нәселгә мөнәсәбәтле. Хәләл җефетен Илһам хан мәшһүр Чыңгызхан ыруыннан иде. Шушы олпат җиһангирның оныгы, Алтын Урда дәүләтен бар иткән Бату хан да зирәклеге, тәвәккәллеге, миһербанлыгы белән дан тоткан. Әйе, дошманнарына карата аяусыз һәм кырыс булган ул. Әмма гадел һәм миһербанлы. Миһербанлылык ханга христиан дине аша йоккан. Сәбәбе дә анык: үзе шул динне йөрәгенә якын алган.

Сүзләренең мөһимлегенә ишарә итеп булса кирәк, агай имән бармагын тырпайтып, чигәсе янында селеккәләп торды. Үрбәт чак кына көлеп җибәрмәде, чөнки бармагы ыргак кебек кәкре иде.

Олуг кенәзнең ана беренче тапкыр шундый җаваплы бурыч йөкләве иде. Боярлар кулыннан килмәгәнне кыпчак бие башкарып чыгарга тиеш булды. Әлеге бурычны җиренә җиткереп үтәгән очракта гына зур бүләкләргә, ташламаларга өметләнергә мөмкин. Шуна күрә тәвәккәллек өчен дип тел астына Бохари шәриф мәгъдәсен дә кыстырып куйган иде. Җинелрәк сөйләшүе,

[1] Нсорат—ярдәм.

калыптан ычкынып-ычкынып алуы шуның аркасында иде.

—Бату хан Киевградны зур көч, күп югалтулар бәрабәренә яулап алды. Киевлеләр хәтта кан коюсыз гына бирелергә тәкъдим иткән илчеләрне кылычтан үткәрделәр. Монголларда илчеләрне үтерү зур җинаять санала. Шуңа да карамастан, бөек хан,—дип рухланып чәчәнләнде ул,—бер генә храмга да зыян салмады. Алай гынамы, әсирлеккә төшкән Дмитрий воеводаның тормышын саклап калды, батырлыгы алдында башын иеп сокланды. Ыруында менә шундый асыл затның булуы православиегә туп-туры юл лабаса, мөхтәрәм ханбикә!

Үрбәтнең иреннәре бүлтәйде: алдаша, мәлгунь. Хәер, димче аның алдында, Иван тәсҗил[1] кылган вәкаләтләренә дә карамастан, абруен җуйган иде инде. Хыянәтчеләрне аның җаны сөйми.

—И, ханбикә, йөзеңне ачмасаң ачмассың, авызыңнан бер генә кәлимә сүз очыр,—дип өзгәләнде димче.

Үрбәтнең үз телендә сөйләшүче бу адәм дә буш кул белән кайтып китте.

Шуннан соң Үрбәтне тынычлыкта калдырдылар, ике-өч ай буе бимазалаучы булмады. Иван акылына килде, ахры, дип сөенде ул.

***

Олуг кенәздән чапкын илче килгәндә Мөхәммәдәмин сөяркәсе Серафима катында кәеф-сафа корып утыра иде. Марҗаның чибәрләренә мөкиббән иде ул. Ике хатыны өстеннән җарияләр дә тота. Тәтиләр катына бик яшьли йөри башлады. Кырым ханының оныгы Бир-Дәүләт тә Мәскәү кенәзенә сыенган икән. Тузынып, тугарылып фарсит итә бу. Мөхәммәдәминне дә үз канаты астына алды. Чөнки өлкәнрәк иде. Уҗымга керергә шаһзадә өйрәтте. Ә алтыдагы алтмышка ул, әле булса куа шул гадәтен. Казан-йорт тәхетенә утыргач та нәфесен тыя алмады. Себердән Мамык хан яу чапкач кына койрыгын кысты. Мәскәүгә үк качып китте. Әмма тәхеткә өметен өзмәде. Тавыш-гауга тынуга, Казанга кайту иде исәбе.

Көтмәгәндә олуг кенәз аның ниятләренең тамырына балта чапты. Мөхәммәдәмингә каршы булган казанлылар ягына ауды, мөртәт. Казан-йорт исеменнән Бараш-Сәед атлы бәк Иванга килеп йөз сөргән, имеш. Әүвәл Мамык ханга Казан тәхетенә юл арчулары өчен түбәнчелек белән гафу үтенгән, гөнаһларын ярлыкавын сораган. Шунда ук теләген белдергән. "Олуг падишаһ! Син безгә хан җибәрсәң иде, алай да Мөхәммәдәминне җибәрмәсәң иде. Ул безгә зур көчләүләр, хатыннарыбызга зур оятсызлыклар кылды. Шуның өчен без аңа хыянәт иткән һәм дә Мамык ханга багынган идек", дип, елый-елый Иванның аяк астына ауган, олтаннарын үпкән.

Иван, казанлыларның гөнаһларын ярлыкап, Мөхәммәдәминне яңадан хан итеп җибәрмәү хосусында булган үтенечләрен кабул иткән.

Шул рәвешчә Мөхәммәдәмин тәхеттән колак какты. Казан йортына бертуган энесе Габделлатыйфны билгеләделәр. Тик Иван яңа ханнан да уңмаганга охшый. Тегесе аның сүзләренә колак салып бетерми, тезгенне үз ягына каерырга тырыша, имеш. Ханлыктагы урысларны кимсетә, юлларына аркылы төшә икән дигән сүзләр дә йөри.

Андый хәбәрләр Каширага соңрак килеп ирешә, чөнки олуг кенәз аны үзеннән читләштерде. Мөхәммәдәминнең шуңа күрә Иванга үпкәсе зур. Ә ул аңа һәрвакыт турылыклы хезмәт итте, ни кушса, шуны үтәде. Элегрәк патша белән: "Бөтен Рәсәйнең олуг кенәзен, туганым Иван Васильевичны мин—Мөхәммәдәмин—башымны иеп сәламлим",—дип, бил бөгеп исәнләшә иде. Олуг кенәз үзе дә: "Мөхәммәдәмин патшаны, туганымны, башымны иеп

[1] Тәсҗил – рәсмилек

сәламлим",—дип җавап кайтара иде. Бараш-Сәед ике арага чөй кагып китте, явыз.

Мөхәммәдәмин бу хакта еш уйлана. Уйлана-уйлана да, барысына да кул селтәп, әшнәсе Бир-Дәүләт хан әйтмешли, кутежга тотына.

Кутеж, кагыйдә буларак, атна буена сузыла. Әле дә шул халәттә иде хан. Борчып йөргәне өчен тоткаулны[1] эт итеп тиргәп ташлады. Сүз әйтергә дә ирек куймады. Кызу канлы ул шулай.

—Бар, эшендә бул, мәнсез, минем тарафка чебен дә очып кермәсен,—дип кычкырды.

Тоткаул китми, иреннәрен мелт-мелт китереп, тик басып тора.

—Җә, ни көтәсең, ангыра бәрән?—дип йодрыкларын йомарлады Мөхәммәдәмин,—типкәләп чыгарганны көтәсеңме?

—Мөхтәрәм хан галиҗәнаплары...

—Мин үземнең мөхтәрәм хан галиҗәнаплары икәнемне синнән башка да беләм,—дип кисте Мөхәммәдәмин куркынган сакчыны.

—Анда... олуг кенәз...

Олуг кенәз дигән сүзне ишеткәч, Мөхәммәдәмин айнып киткәндәй булды.

—Ни лыгырдыйсың, кара авыз,—дип, тоткаулның янына ук килеп басты.

—Олуг кенәздән чапкын килгән, сине күрергә тели...

—Нигә аны башта ук әйтмәдең, кара авыз?!—дип элеккедән дә арттырыбрак төкрекләрен чәчте Мөхәммәдәмин.—Бар, чапкынга әйт, хан көтә диген. Мин үз диварымда булырмын!

Серафима болай да мул күкрәк алмаларын тагын да киерә төшеп, Мөхәммәдәмингә елышты. Хан аны ачу белән этеп җибәрде.

—Соныннан... Олуг кенәздән чапкын килгән анда,—дип пышылдады Мөхәммәдәмин киенгән арада катырак кылануына гафу үтенгәндәй.

—Нехороший ты мальчик, Аминка, за что я тебя люблю, ей богу не знаю.

—Потом, потом...

—И, бөек хан, сина Бөтен Рәсәйнең олуг кенәзе Иван Васильевич хәзрәтләре күп сәлам юллый һәм чәршәмбе көнне, нәкъ өйлә вакытында түгәрәк залда көтә,—дип белдерде чапкын, бар кагыйдәләргә дә туры китереп.

—Баш өсте,—диде Мөхәммәдәмин дулкынланыбрак.—Туганым Иван Васильевичка миннән дә күп сәлам, аңа карата ихтирамым чиксез, исән-сау булсын.

Әлеге сүзләрне ишеткәч, Мөхәммәдәминнең йөзе яктырып китте. Әллә Габделләтыйфны тәхеттән төшерәләр дигән хәбәр дөрескә чыгамы? Ул чагында ханлык аңа күчәчәк ич инде...

Иван төгәл кеше иде. Вәгъдәле. Мөхәммәдәминне дә нәкъ әйткән көнендә, нәкъ билгеләнгән вакытында түгәрәк залга чакырып керттеләр. Аудиенция көтүче боярлар, дәүләт эшлеклеләре шактый иде үзе. Олуг кенәзнең якыннары да күренә. Әнә, азау ярган мәшһүр илче кенәз Дмитрий Шеин. Казанда Мөхәммәдәмин ханлык иткән чорда рус дәүләтенең калагае[2] иде.

Бик үзсүзле, үҗәт кеше. Аның тырышлыгы белән ул чакта урыс сәүдәгәрләре бөтен Казан базарларына, бөтен ярминкәләргә кереп тулды. Мөхәммәдәмин олуг кенәз сүзеннән чыкмады, барысын да ул теләгәнчә башкарды. Шеин исә: "Иван патша моны кушты, Иван патша тегене кушты", дип Мөхәммәдәминнең өстендә торды. Тынычмаган чаклары да булгалады.

Калагай үзе кебек үк мөхтәрәм илче кенәз Михаил Андреевич Кляпик белән сөйләшеп тора иде. Күз очы белән генә Казан йортының элекке ханын күреп алды, әмма килеп кул бирмәде. Сөяк сарае, кыланышын гына күр, дип

[1] Тоткаулны—каравылчы.

[2] Калагае—наместник.

сызланып куйды Мөхәммәдәмин. Ашыккан ашка төшкән, ди, шатлыгы иртәрәк булмагае тагын, болар җилнең кай тарафтан искәнен белә дә белә инде.

Хәер, ул үзе дә беркемгә дә аерым ихтирам билгесе күрсәтмәде. Вакыты да тар иде, теләмәде дә. Чөнки күнеле урынында түгел, тизрәк Иванның ни өчен чакырганын беләсе килә. Ул аны һич тә мәҗлес корырга, яисә ауга чыгарга дәштермәгән. Андый чакыруның урыны башка. Хикмәт шунда, бу Мөхәммәдәмин көткән сүзме, әллә Иван бер-бер хәрби ыргым ясарга ният итәме? Элек-электән ул аны хәрби кампанияләрдә катнаштыра иде.

Ничек кенә булмасын, аны мөһим сөйләшү көтә. Очрашуның түгәрәк залда булуы да күп нәрсә турында сөйли. Чөнки түгәрәк зал олуг кенәзнең аеруча җитди сөйләшүләр, җитди карарлар кабул итә торган дивары.

Ходаем, мәрхәмәтеңнән ташлама, тел ачкычлары бир, дип теләде Мөхәммәдәмин күнеленнән.

Иван күрер күзгә шактый бетерешкән иде. Йөзе саргаеп киткән, әйтерсең лә, зарарлы үлән суы эчергәннәр. Шулай да үзен элеккечә үк ипле, итагатьле һәм тәкәббер тота. Бу җәһәттән бер үзгәреш тә сизелми. Табигате белән ул дәшмеш[1] кеше. Әмма әйткәнен уйлап әйтә, сүзләренең мәгънәсенә тора-тора төшенәсең. Мөхәммәдәмин мондый мөгамәләгә күнекте инде. Иван канаты астында яшәвенә унҗиде ел тулып килә икән ләбаса. Атасы Ибраһим хан дөнья куйганнан соң, анасы Нурсолтан аны Мәскәүгә озаттырды, түбәнчелек белән олуг кенәздән улын үз карамагына алуын, үзе муафыйк калган тәрбияне бирүен үтенде. Мөхәммәдәмингә ул чакта унбиш кенә яшь иде әле. Чөнки Нурсолтанны Кырым ханы Минлегәрәйгә никахладылар. Сабый булуы сәбәпле, төпчеге Габделләтыйфны үзе белән алды.

—Атакай, олуг кенәз Иван Васильевич, сине исән-сау вә күтәренке рухта күрүемә бик шатмын,—дип сәламләде патшаны Мөхәммәдәмин,—нинди бурыч йөкләсәгез дә үтәргә, шул юлда корбан булырга әзермен.

Олуг кенәзнең какча йөзе аз гына яктыргандай итте. Ләкин күз карашы җитди иде, кашлары бер-берсенә кушылган килеш калды. Мөхәммәдәмин аның шома битенә игътибар итте. Көрәк сакалы, иреннәрен каплап торган асылма мыегы, әйтерсең лә, ябыштырып кына куелган. Башындагы чит-чите зиннәтле кеш мехы белән камалып алынган күн кәпәче[2] дә сакал-мыегының дәвамы кебек күренә.

—Корбан булырга ашыкма, туганым,—диде Иван тамак төбеннән генә чыккан тонык тавыш белән.—Алтмышның аръягына аяк баскан кешенең акыллы киңәш бирәчәгенә дә ышанып бетмә. Картларны зирәк диләр, дөрес түгел, алар сак кыланалар, шуңа күрә зирәк булып күренәләр.

Иван каш астыннан гына элмәкле без карашы белән Мөхәммәдәминне чәнчеп алды. Күренеп тора, әлеге сүзләрне ул сынау өчен генә әйтте.

—Атакай, сиңа чын күнелемнән бирелгәнемне күп тапкырлар исбатладым ич инде, үзең беләсең.

Иван аны элмәгеннән ычкындырды. Шулай да төрттерәсе итте.

—Халыкта "Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый",—дигән тирән мәгънәле әйтем бар,—диде ул хәйләле елмаю тәэссоратында,—ишарәмне аңлыйсыңдыр, шәт?

—Бу җөмләдән сиңа бернинди дә куркыныч янамый, олуг кенәз,—диде Мөхәммәдәмин.

Иван фикерен үстереп дәвам итте:

—Атаем олуг кенәз Василий Васильевичның яраткан тәкъбире исемә килеп төште әле,—диде үз алдына уйлангандай,—ул әйтә иде: "Государь фәкать үтергеч

---

[1] Дәшмеш — аз сүзле.

[2] Кәпәче — бүрек.

тукмаклар гына ясарга тиеш. Әгәренки аның тукмаклары үтергечлектән туктый икән, түбәнгә тәгәрәү шушы инде",—дия иде.

—Сина кагылмый бу, атакай, олуг кенәз, Иван Васильевич!

—Бу мөхтәрәм ыруг адәмнәренен барысына да карый, туганым, шул исәптән синен үзенә дә. Безне Ходай кешеләрдән өстен итеп яраткан. Без—патшалар!

—Синен тукмакларыннын жәрәхәте бетә торган гынамы сон, атакай?

Елмаю бу юлы Иванның күзләренә дә кунды. Күнеленә хуш килердәй сүз әйтте вассалы. Әйе, кырык елдан артык хаким булып тору чорында күп үтергеч тукмаклар ясады ул. Үзара ызгышып, бер-берсенә аяк чалып яшәгән төбәк кенәзләрен бер йодрыкка туплау үзе генә ни тора! Башта Мәскәүгә Ярославльне кушты, аннан соң Новгород, Тверь, Вятка, Пермь кенәзләренен кикрикләрен кыеп төшерде. Русь дәүләт буларак, шөкер, тәгаенләнде. Татар-монголларга үтергеч тукмак ясауны да Ходай ана насыйп итте. Мәскәү хәзер берәүгә дә салым түләми.

Әйе, анын кенәзлеге чорында Рәсәй күләгәдән чыкты. Мона кадәр өч гасыр дәвамында аны Аурупа өстәленә якын китермәделәр. Ни сәясәттә, ни халыклар тормышындагы үзгәрешләрдә катнаша алмады. Хәлбуки, бернәрсә дә капылт кына, үзеннән-үзе генә пәйда булмый. Уңыш акрынлап тәгаенләнә. Әйтик, Мәскәү йортына Иван Калитадан алып Василий Темныйга кадәрге кенәзләр тырышлыгы белән нигез салынды. Хакимиятне бер йодрыкка туплауга алар да өлеш кертте. Тик әлеге кенәзләргә тотрыклылык житенкерәми иде. Дмитрий Донской, мисал өчен, Куликово кырында Мамай морзаны яхшы гына каезлады. Шул ук вакытта, Туктамыш хан алдында билен бөкте. Кенәз Донскойның улы Василий Литва короле Витовтка Смоленск һәм анын тирәсендәге төбәкләрне үз ирке белән бирде.

Бу хаталарны ул, олуг кенәз Иван Васильевич төзәтте. Ана римлеләрдә кулланыла торган император сүзе охшый иде. Ә чит мәмләкәт илчеләреннән исә патша дип мөрәжәгать итүләрен таләп итте. Патша—царь! Фарсы тамырлы әлеге дәрәжәле атама белән ул үзен Ассирия һәм Вавилон монархлары Фалассар, Набонассар кебек бөек хакимнәр рәтенә куя иде.

Иоанн. Монысы поп кушкан исем. Руханилар арасында шушы исем белән йөртәләр. Соборларда да үзе рәислек итә. Бу да ана зур абруй өсти иде. Монархның кулын үбү йоласын шулай ук Иван кертте.

Русьне бөртекләп жыйды. Шуна күрә ул ана бик кадерле дә.

Мөхәммәдәминнен бер матур сүзе, әнә, күнелендәге нинди катламнарны актарып чыгарды.

—Буш сүз бозау имезә, диләрме әле татарлар, төп сүзгә күчәргә вакыт житте кебек,—диде Иван.

—Бер дә буш сүз түгел, атакай, атаң Василийнын, мисал өчен, Мәскәү кенәзлегендә генә сүзе үткән. Син олуг кенәз титулына ия булдын. Күрше мәмләкәтләр дә таный бу титулынны. Патша титулы да ерак йөрми.

—Туганың Габделләтыйфны әйтәм, чыгынчы ат...

Әһә, бүректәге бүре баласы турында искә алуының мәгънәсе менә кайда икән? Мөхәммәдәмин сагаеп калды.

—Килешүне бозды,—дип шәрехләде фикерен олуг кенәз.—Кырым һәрвакыт сандал белән чүкеч арасында чуалды. Ни чүкеч, ни сандал була алмады.

—Мин энемне белмим дә диярлек, атакай, ул Минлегәрәй хан тәрбиясендә үсте.

—Мин дә шуны такылдыйм ич, синең белән төзелгән килешүне бозды, дим.

Әлеге килешү теге вакытта Мөхәммәдәмингә бик кыйммәткә төшкән иде. Имзасын салмаса, ул хан була алмый иде. Ә хан буласы килә. Аннан сон, тулысы белән ышана иде Иванга. Хәзер дә ышана. Сенлесе Гәүһәршад шул килешү өчен аны атабызга хыянәт иттен, дип битәрләде. Кайбер бәкләр дә

хупламады әлеге адымны. Тик бу аларның үрә каравыннан гына килә. Казан һәрвакыт үзеннән көчлеләргә сыенып яшәгән. Аның иң зур таянычы Алтын Урда булган, билгеле. Әмма хәзер Алтын Урда юк. Алга Мәскәү кенәзлеге чыкты. Шуңа күрә Казан җиренең язмышы турыдан-туры Мәскәүгә бәйле. Гәүһәршад та, аңа иярүчеләр дә шушы хакыйкатьне анларга теләмиләр.

—Дәүләт эшендә кода-кодагыйлык та, ярату-яратмау да була алмый, туганың Габделләтыйф ханны Ак күлгә сөрдек,—диде Иван күңелле хәбәр җиткергәндәй үзенә бер йомшаклык белән.—Югыйсә, анагыз Нурсолтан минем якын дустым, ике дистә елдан артык хәбәрләшеп, язышып торабыз. Сине дә анаң үтенече белән үз канатым астына алган идем. Балаларым, дип җан атып тора. Моның өчен мин аны мактыйм. Зирәк хатын. Ләкин Рәсәй мәнфәгатьләре шәхси бәйләнешләрдән өстен.

Иван янә сакалын сыпырып куйды. Шунда ук елъязмачыга да сүз катырга өлгерә, барысын да теркәп барасыңмы, житешәсеңме, янәсе.

Олуг кенәз һәр адымын киләчәк буыннарга багышлый иде. Аның бу тырышлыгы да җимешләрен мулдан бирде. Урыс дәүләте тарихында аның урыны түрдән.

Иван асравы Мөхәммәдәмингә ташка ышангандай ышана иде. Хәтта ки, бу асау айгырдай мәһабәт буй-сынлы, кара-тут йөзле егет солтанын ярата да иде. Шул ук вакытта, ул аны һаман күз уңында тота, тәрбия кыла. Әнә, әле хәзер дә, Ак күл сүзен ишеткәч, Мөхәммәдәминнең калтыранып китүен сиземләп, эчтән генә бармак янады, шүрләвең бик яхшы, туганым, алдыңны-артыңны карап йөрергә әйбәт булыр, дип уйлап куйды. Туганнарың Илһам хан белән Габделләтыйф хан язмышын кабатлыйсың килмәсә, сүземнән чыкмассың.

Габделләтыйфка ул башта ук өмет багламады, күз буяу өчен генә, казанлылар алдында яхшы атлы булып күренү өчен генә тәхеткә утыртып торган иде.

Мөхәммәдәмин башка камырдан җәелгән. Ул камырны Иван үзе изде. Шуның нәтиҗәсе буларак, Мөхәммәдәминнең тәүге ханлыгы чорында Мәскәү өчен искиткеч кулай Килешүгә кул куелды да инде. Анда өч кенә матдә: Мәскәүгә каршы яу чапмаска; Казан тәхетенә Мәскәү фатихасыннан тыш хан утыртмаска; ханлыкта яшәүче урысларның хокукларын чикләмәскә, тулы ирек бирергә.

Шушы гади генә өч матдә Казан ханлыгын вассал хәленә төшерде дә куйды. Дөрес, әлегә ханлык мөстәкыйльлеген җуймады. Әлегә…

—Улым, Мөхәммәдәмин, бер атнадан Казанга чыгып китәсең, җыен, ханлык сиңа күчә, бик озакка күчә. Ходай рәхмәтеннән ташламас, иншаллаһ. Ә олуг кенәз сиңа элеккечә һәрвакыт хәерхаһ булыр. Амин.

Мөхәммәдәмин олуг кенәзнең аягына егылды, озын камзулының итәкләрен үпте, үзе бертуктаусыз: "Сүзеннән чыкмам, атакай",—дип мыгырданды.

Ул чиксез шат иде. Бөек Казан ханлыгының башында тору бик зур дәрәҗә. Ул аның ләззәтен татып караган иде инде. Илнең төтене дә тәмле, ди.

—Җә, житәр, тор, улым, тагын бер теләгемне җиткерәсем бар әле минем,—дип, Иван Мөхәммәдәминнең аркасыннан какты.

Мөхәммәдәмин торып басты. Ләкин дулкынлануын басар хәлдә түгел иде әле. Ниһаять, халәтенә тиң кирәкле сүзләре дә табылды.

—Җирнең чиге бар, атакай, ә күкнең чиге юк. Минем сиңа булган ихтирамым да күк шикелле чиксез,—диде ул чын рухлану белән.

—Беләм, улым, беләм…

Иванның да керфекләренә чык кунды.

—Инде чираттагы теләгемне тыңла,—диде Иван.

—Баш өсте, атакай.

—Синең озын итәкләргә һәвәслегеңне Рәсәйдә белмәгән адәм юктыр,—диде ул көлемсерәп,—шуның аркасында беренче ханлыгың хурлыклы рәвештә

өзелде дә, казанлылар синнән баш тартты. Хатыннарың жебегән, күрәсен. Уйладым-уйладым да үзем кәләш табарга булдым. Һәм ифрат та көчле, искиткеч тотрыклы, вәгъдәсендә үләргә әзер торган хәләл жефет таптым. Сезгә, мөселманнарга, ислам күп хатынлыкны рөхсәт итә бит, шулаймы?

—Дүрткә кадәр,—диде Мөхәммәдәмин басынкы гына.

—Ә синеке ничәү?

—Икәү...

—Тиздән өч булыр.

—Кем соң ул, атакай?

Иван күзләрен кыса төшеп, Мөхәммәдәмингә карап торды. Бу аның елмаюы иде. Ләкин ана елмаю килешми иде, йөзе чытылып, ямьсез кыяфәткә керде.

—Илһам ханның яшь хатыны.

—Атакай, башымны ашама, атакай...

—Бу инде хәл ителгән,—диде Иван коры гына,—ахмак дустан акыллы дошман артык, ди. Ул синең иң ышанычлы терәгең булачак. Ундүрт ел буе мин аны православиегә күчерергә тырыштым. Иң оста чәчән боярларымны, иң уңган тылмачларымны жибәрдем. Шул гомер эчендә авызыннан "әйе" дип тә, "юк" дип тә бер кәлимә сүз ала алмадылар. Мин ул хатынның ныклыгы алдында башымны иям. Сиңа нәкъ шундый каты куллы, турылыклы вә вәгъдәле җәмәгать кирәк иде. Мин бик шат.

—Атакай, зинһар, башка берәүне димлә, бер ул гына каты куллы түгелдер лә.

—Сүз көрәштермибез, улым. Син аңа болай да өйләнергә тиеш. Ул аганның тол хатыны.

Иван кулларын чәбәкләгәндәй итте. Баш сакчы ишекләрне киереп ачып куйды да оран салды:

—Бөтен Рәсәйнең олуг кенәзе Иван Васильевич сезгә бусагадан кереп, баш орырга рөхсәт итә!

Керүчеләр чират торып, берәм-берәм олуг кенәзнең камзул итәген үбеп чыктылар.

Иван аларга Барча Казан жиренең чираттагы ханын тәкъдим итте. Боярлар бил бөгеп, әлеге карарның хаклыгын таныдылар. Шуннан соң Түгәрәк зал хуҗасы икенде күләгәседәй озын буйлы Михаил Кляпикны бармагы белән ишарәләп үзе янына чакырды.

—Кенәз Михаил Андреевич Кляпик минем иң мөхтәрәм илчеләремнең берсе,—диде Мөхәммәдәмингә мөрәҗәгать итеп,—ул сине тәхетенә утыртыр. Аны үзеннең уң кулым дип исәплә. Сүзеннән чыкма. Ул яклаучың да, таянычың да, хуҗаң да.

Әле ярый, Шеин түгел, дип сөенде Мөхәммәдәмин олуг кенәзнең кулын үпкән арада.

•••

Хан бичәсе алтмышта да кәләш, дип әйтә торган иде түшәкчесе Бәһиҗә тәтә. Бик мәрхәмәтле, ифрат та йомшак күңелле иде мәрхүмә. Ул аңа ике дистә ел фидакарьләрчә хезмәт итте. Фидакарьләрчә, чөнки Үрбәт кечкенәдән атам иркәсе булып үсте. Атае да, анае да төпчекләрен бик үсендерделәр. Кыз "юк" дигән сүзне бөтенләй белмәде. Ярәшер вакыт житкәч кенә тезгенне кыскартып караганнар иде дә, соң булып чыкты. Холкы үз дигәнчә тәгаенләнгән иде чибәркәйнең. Чын дала кошы, кая тели, шунда куна. Яучылар килгән көнне дә ут булды да, су булды бу. Кияүнекеләрнең исә кәләшне күрәселәре килә.

Муса тирә-якка чапкыннар чыгарып жибәрде. "Кирәк икән, Каф тауның ташын-ташка актарыгыз, даланың астын өскә әйләндерегез, дингезне күккә

асып куегыз, әмма да ләкин кызымны каршыма китереп бастырыгыз",—диде.

Бу чакта Үрбәт шактый җир киткән иде инде. Ул яучылар дигән сүз колагына килеп ирешүгә, өс-башын да алыштырмыйча утарга элдертте. Аның берничә чапкыны бар. Шулар арасында иң затлысы, иң җитезе Күбәләк атлысы. Моннан ике-өч ел элек атае бүләк иткән иде. Тай гына иде әле. Сөт шикелле ап-ак иде, нәкъ Чыңгызханның Сәтәр кушаматлы толпары. Сәтәр дә ап-ак булган, имеш. Күпме орышларда катнашкан, үзенә дә яра алмаган, хуҗасын да саклаган. Тылсым иясе дип йөрткәннәр аны.

Әлеге елгыр тайны күргәч, кызчыкның кабарынкы иреннәре арасыннан бер генә сүз чыкты:

—Күбәләк!

Дөрестән дә, күбәләк кебек иде ул. Менә-менә канатларын җилпеп алыр да очып китәр сыман.

—Исем дә таптың, кызым,—дип, атасы Үрбәтнең чәчләреннән сыйпап алды.

Күбәләк хәзер элеккедән күркәмрәк тә, матуррак та. Мәһабәт! Бер сүз белән генә аны шулай сыйфатлап булыр иде. Ул күкрәк дисеңме, ул аяклар дисеңме—һәммәсе чын ясау. Буй-сыны тоташ аяктан гына тора кебек. Томырылып чапканда исә еландай сузылып, җиргә ятып бетә ул.

—Күбәләк, коткар мине,—диде Үрбәт,—бу мәрхәмәтсез йортта миңа урын калмады.

Үрбәт әнә шулай елгырына эчен бушата. Барысын да сөйли. Тегесе аңлагандай, башын хуҗабикәсенең иңенә салып тыңлап тора. Хәзер дә бик тиз аңлаштылар. Кыз сыртына менеп тә җитмәде, Күбәләкнең тояклары астыннан аҗагандай очкыннар сибелде. Гадәттә, ул тезген тоттырмый, юлны да югалтмый.

Өйлә вакыты иде. Даланың утлы шар шикелле иң кызган чагы. Бу вакытта кешеләр генә түгел, маллар да күләгәле урынга елышалар. Кояш зәһәрләнепме-зәһәрләнә. Һава булып һава эри. Әнә, офыкта дөрләп янган һава су өстендәге томан сыман дулкынланып тора. Ат җиле дә өттереп-өттереп ала. Үрбәтнең үз кайгысы да нәкъ шушы мәрхәмәтсез көн шикелле иде. Юан бүксәле яучылардан ничек тә ераккарак китеп олагасы килә аның. Ата-анасының ут йотуы да, бөтен утарның аякка басуы да аны кызыксындырмый. Боларны белми, һәм беләсе дә килми. Алда ни көтә, бу уен ни-нәрсә белән бетәр—бу хакта да борчылмый. Күбәләк. Дала. Үзе. Дөньясы менә шушы өч затка сыеп беткән. Әлеге дөньяда яучыларга гына түгел, якыннарына да урын юк. Чөнки алар аны бик нык кыерсыттылар.

Кызу капты, күрәсең, берзаман Үрбәтнең башы авыртырга тотынды. Күбәләкнең дә колаклары шиңде, сүлпәнләнде. Аларның икесенә дә ял кирәк иде. Ялдан да битәр, су кирәк, су! Кайдадыр күл булырга тиеш. Үрбәтнең анда су коенганы да бар. Дингез белән тоташкан зур күл ул. Суы да бик чиста. Тик анда ничек барып җитәргә?

Шөкер, Күбәләк бу юлы да сынатмады. Кояш тәгәрмәче офык артына кереп бетәр-бетмәстә яшь бикәне Ак күл янына китереп төшерде. Дөресрәге, килә-килешкә туп-туры суга керде дә, голт-голт эчә дә башлады. Кабыккан чибәркәй. Шулай булмыйча, көне буе аяк өстендә ләбаса.

—Күбәләк, кызган килеш алай күп чүмермә, аягыңа су төшер,—диде Үрбәт тезгенен тарткалый-тарткалый. Бахбае гына тыңламады.

Кызның шиге дөрескә килде. Күп тә үтми, Күбәләкнең аяклары тубырланды. Далада көн күрүче буларак, Үрбәт бу хәлләрдән хәбәрдәр иде. Мондый чакта атны акрынлап йөртергә, аякларын язарга кирәк.

Йөренә торгач, күктә йолдызлар кабынды, җиһанга төн пәрдәсе эленде. Ул исә дала уртасында чатанлаган аты белән ялгызы калды. Далада кунып та калганы бар Үрбәтнең. Тик аның янында һәрвакыт, айт иткәндә тайт, дип

торучы хезмәтче кешеләр була иде. Бүген барысын да үзбашына башкарырга тиеш. Иң кирәк чакта, Күбәләк тә сафтан чыкты бит, хәзер ана хәтта үз койрыгы да авыр йөккә әйләнеп бара.

Ана ничек тә атын аякка бастырырга кирәк иде. Шуна күрә Күбәләккә тынгы бирми. Тирги-тирги, чыбыклый-чыбыклый йөртә.

Бервакыт ат, колакларын шәмдәй катырып, пошкырып җибәрде. Үрбәтнең эче жу итеп китте. Нииндидер шомлы пошкыру иде бу.

—Әллә төшләнәсең инде, бирән маржа,—дип, үзенең күнелен күтәрү өчен генә сукранып та алды. Ат чынлап торып тынычсызлана иде: ялт та йолт карана, боргалана, еш-еш пошкыра. Шунда Үрбәт учактагы күз шикелле ялтырап торган ут шарчыкларын шәйләп алды.

Бүреләр! Ауга чыккан бүреләр! Су эчәргә килгән хайваннарны сагалыйлар, күрәсең.

Хәл куркыныч. Хәзер үк, шушы мизгелдә үк, бер-бер әмәлен табарга кирәк. Ач бүре усал була. Иярга тагылган күн капчыкта үткен пычак та, кыска саплы чукмарбаш та бар, билгеле. Ләкин бу кораллар белән дә бүреләргә каршы тора алмаячаксың. Өер ич алар. Шундый көтелмәгән адым ясарга кирәк ки, ул адым бүреләрнең өнен алырдай булсын.

Ятып калганчы, атып кал, ди. Үрбәт атына сикереп менде дә бар тавышына кычкырып җибәрде:

—Күбәләк, оч! Күбәләк! Күбә-ә-ә-ләк!!!

Могҗиза әкияттә генә була диләр. Баксаң, могҗиза тормышта да бар икән ич. Әле генә аякларын көч-хәл белән атлаучы Күбәләк, берни булмагандай, алга ыргылмасынмы.

Бүреләр, дөрестән дә, берара аңышмыйча аптырап тордылар. Күбәләк икеөч ат сузымы җир киткәч кенә исләренә килеп, куа башладылар. Берсе, ата бүре иде булса кирәк, чапкынның бугазына сикерү ниятеннән каршыга төшеп, юлны бүлмәкче дә итеп караган иде, кая ул, әйтерсең лә, Күбәләккә канатлар үсеп чыкты, оча гына.

—Күбәләк, бирешмә, Күбәләк!

Күп тә үтми, үзләрен эзләп килүче Муса бәкнең кешеләренә тап булдылар.

...Түшәкче Бәһиҗә тәтә белән Күбәләк Үрбәтне гомерләре буе кадерләп йөрттеләр. Күбәләкне ул Казанга да алып килде. Иван әсир иткәч, ишетүенчә, елгырны урыслар үз утарларына алганнар. Кәфер кулларына эләкте бит балакаем, дип бик кайгырган иде. Түшәкчесе соңгы сулышына кадәр турылыклы хезмәт итте, тоткынлыкта да читләшмәде. Әҗәлен генә урыс җирендә тапты, җанашым. Ә нинди зирәк хатын булган ул дала кызы. Төшенә кергән ак сакаллы мосафир кебек ул да хуҗабикәсенең киләчәген яхшыга юрый иде. Аның тормышында чынлыкта да ак атка атланган ак киемле яугир пәйда булды.

И, Бәһиҗә тутаем, мең-мең рәхмәт сиңа, урының җәннәттә булсын. “Син башкаларга охшамаган, бикә, сине ходай җиһанга изге гамәлләр кылу өчен җибәргән”,—дия иде ул.

—Каян беләсең?—дип, ышанасы килмичә башын чайкаганы хәтерендә,—мәхбүс нинди изге гамәлләр кыла алыр икән?

—Кырыклаган вакытында тәнеңнән көлтә-көлтә нур чәчелде,—диде Бәһиҗә түшәкче,—кырык кашык суны башыңа кырык кашык белән үзем коеп тордым. Кашыклары көмеш иде.

—Нишләп соң анамның бу хакта бер сүз дә әйткәне булмады?—дип гаҗәпләнде Үрбәт.

—Ул нурны мин генә күрдем бит, бикәм.

—Ничек инде...

—Монысы ходайдан ханбикә...

Ак төс—шат төс. Дөрес юраган түшәкче. Мәңге бетмәс кебек тоелган төн,

ниһаять, үтеп китте, аның талына да әкияттәге кебек каурый кош килеп кунды.

Мөхәммәдәмин Илһамга бөтенләй охшамаган. Илһам саргылт йөзле чирләшкә кеше иде. Хатыннарына да игътибар булмады, түшәкләре һәрвакыт салкын иде мескенкәйләрнең. Үзе, чарасызлыктандыр, мөгаен, сафа сөрүгә һәвәсләнеп китте.

Мөхәммәдәмин жиненнән елан чыгара торганнардан. Буй-сынына да карап кына торырлык. Киң җилкәле, кырыс йөзле. Яшьтән үк шушындый егетләр охшый иде аңа, баһадир гәүдәлеләр.

Илһам үлгәндә ул унҗидесен генә тутырган иде әле. Инде аннан соң ундүрт ел вакыт үтеп китте. Егерме тугыз яшьтә кара халык бичәләре бер олау бала тудырып, оныкларын сөеп, түр башына менеп кунаклый, тегене тегеләй итегез, монысын монда аударыгыз, дип оланнарына әмер генә биреп утыра.

Ә Үрбәт бернинди олыгаю да сизми, үзен яшь чагындагыдай хис итә. Әле бит аның юньле-башлы ир назы да күргәне юк.

Кызык бу җиһан. Кайчан гына, гомерем ахырына якынлашты, иманыма тугры калып, догада килеш өзелсәм иде, дип теләк тели иде. Хәзер гыйшык утында яна, башы-аягы белән мәхәббәт дәрьясына чумды. Шулай да була икән.

Мөхәммәдәмин исә үтә дә каршылыклы тойгылар кичерә иде. Чөнки Илһам агасын ул үзенең дошманы дип санады. Атасы Ибраһим хан вафатыннан соң көнчыгышка йөз тотучыларның мәнфәгатьләрен алга сөрүче фирка, нугайларның турыдан-туры хәрби булышлыгы белән, тәхеткә Илһамны утыртты. Шул рәвешле, кануни ханны, Мөхәммәдәминне читкә типтеләр. Дөрес, Мөхәммәдәмингә атасы вафатында тугыз яшь кенә тулган иде. Ләкин тәхет мәсләгендә кемнең ничә яшьтә булуы мөһим түгел. Имчәк бала да, алтмыш яшьлек бабай да тигез хокуклы.

Мөхәммәдәмин Мәскәүгә китеп, Иванның үкчәсен үбәргә мәҗбүр булды. Дөрес, ул олуг кенәз фатихасы һәм ярдәме белән яу чабып, агасын тәхеттән читләштереп торган иде торуын. Бугазына янә шул нугайлар басты. Ә Иван Сарай белән мәшгуль иде, ныклап булыша алмады. Илһам тагын хакимлекне үз кулына алды.

Хәзер дошманының хәләлен бичә ит инде. Тәрәк, имеш. Үзе әйтмешли, бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый инде ул. Дошман хатыны барыбер дошман булудан туктамас.

Иванның талканы коры. Каршы килә алмыйсың, чөнки тәхет тоткасы аның кулында. Әле кәләшен күргәне дә юк. Ниндиерәк нәмәстәдер. Бик үзгәргәндерме? Хәер, тоткын хатынның рәте була ди мени? Серафимага җитәме соң? Татлы, чукынмыш. Мәмрәп пешкән җиләк кебек бит.

Тәхет тә татлы шул. Аның өчен теләсә-нинди корбаннарга да барырга ярый. Тәхет булса, калганы була да була инде. Даны да, байлыгы да, хөрмәте дә...

Тәхет ул җирдәге оҗмах.

***

Кабат никахта зөфаф кичендә, күптәннән килгән гадәт буенча, кәләшне кияү буласы кешенең өлкән хатыны әзерли. Бу эшкә ул җитәкчелек итә. Үрбәтне дә Мөхәммәдәминнең карт җәмәгате Җөһдә ханбикә үз канаты астына алды. Сарайда аны баш хатын дип йөртәләр. Чөнки зур гаиләгә ул—күз-колак.

Үрбәт яшь хатын саналырга тиеш булса да, Җөһдәдән ике яшькә өлкәнрәк иде.

Никахтан соң Үрбәтне мунчага алып киттеләр. Анда аны анадан тума чишендереп, Җөһдә ханбикә каршына китереп бастырдылар. Үрбәт яшь тал

шикелле зифа буйлы, ыспай, чибәр иде. Һәр нәрсәсе урынында, артык жире дә, ким жире дә юк. Мондый буй-сынга, бу күкрәкләргә наз өрсәң, мизгелдә кабынып китәчәкләр...

Ишектән көндәш керсә, тишектән җәнҗал керә, ди. Җөһдә дә ирексездән үзенең арыш боламыгыдай җәелгән эленке-салынкы гәүдәсен күздән кичереп, сыкрап куйды. Теле дә үзенә буйсынмады.

—Чәчен тар толым итеп үрегез, бу өтермә түгел, иштәбәйлекне ташларга вакыт,—дип зәһәрен куды.

Кәнизәкләр бер-берсенә карашып куйдылар: чәче дә бик килешле яшь бичәнең, үзе дә...

—Авызыннан ис килмиме, ханның җене сөйми исле хатыннарны,—дип, Җөһдә янә һөҗүмгә күчте. Болай тугарылырга ярамаганны ул, билгеле, үзе дә бик яхшы белә, тик акылыннан битәр, көнчелек баш иде ана бу мизгелдә. Тәки күрше бүлмәгә кереп китте дә, туйганчы елап күңелен бушатты. Шуннан соң гына тынычлангандай итте, вазифасына керешге.

Ниләр генә кыландырмадылар Үрбәтне. Түзде, тынын да чыгармады. Иң соңыннан өстенә бер ләгән җылы сөт койдылар да, авыз-борынын берничә тапкыр нindидер татлы төнәтмә белән чайкаттылар. Янадан тугандай булып калды Үрбәт, тәне каз каурыедай җиңеләеп китте. Аңа хәзер ашарга да, эчәргә дә ярамый. Зөфаф кичендә кияү егете сыйласа гына ризыктан авыз итәргә була. Анда да күгәрчен томшыгына гына эләгерлек микъдарда, тәненең татлылыгын аш-су исе басып китәргә тиеш түгел.

—Хан куштанлыкны ярата, шуны исеңдә тот,—дип соңгы киңәшен җиткерде Җөһдә.

Мөхәммәдәмингә, мөселман өммәтендәге кешe буларак, сөннәт кагыйдәләрен төгәл үтәү фарыз. Шулай да бик хикмәтле хәл килеп чыга бит әле монда. Илһам ханга каршы Казан-йортка яу чабып, беренче тапкыр тәхеткә утырганда да Иван патша фатихасы белән Нугайбәк токымы кызы Җөһдәгә өйләнгән иде. Ул чагында да олуг кенәз аны буйдак хәлендә тәхеткә якын җибәрмәде. Хәзер дә, икенче тапкыр хан дәрәҗәсенә ирешкәндә дә, ул Мөхәммәдәминне тагын яшь хатын куены аша уздырды. Абынмасын-сөртенмәсен өченгә үзе кирәк санаган ышанычлы чараларын күрүе ахры.

Үрбәткә куштанланырга туры килмәде. Ихтимал, күзләрен уйнаткалап алган булыр иде, ләкин, хан кияү егете сыйфатында аның янына кергәч, ризык өстәленә таба борылып та карамады.

—Ханбикәне хәзерләгез,—дип әмер бирде түшәкче тәтәләргә. Тегеләр балга кунган шөпшәләр кебек Үрбәтне әйләндереп алдылар.

—Сез азат, бикәчләр, үзебезне генә калдырыгыз!—дип, үз чиратында яшь кәләш тә әмерен җиткерде.

Бикәләр аптырашты. Гомергә булмаган хәл ләбаса бу, ханбикә үзе чишенә ди мени? Беләзек-балдаклары гына күпме? Алка, чулпы... Ә ул катлы-катлы затлы киемнәр?

—Ишеткәнсездер бит?—дип түземсезләнде Үрбәт,—чукрак түгелсездер, шәт.

Ниһаять, кияү белән кәләш үзләре генә калды.

—Мөхәммәдәмин, исән-сау гына йөрисеңме, бик сагынып көттем мин бу көнне,—диде Үрбәт керфекләрен идәнгә чәнчеп кенә,—әйдә, мөселманнарча, үзебезчә күрешик, без никахлы ич инде хәзер.

Үрбәт үзенә бер нәзакәтлелек белән йөзен ачыбрак куйды да, иренә ике кулын сузды. Куллары йомшак вә кайнар иде. Нindидер сихри көч бар иде бу кулларда. Мөхәммәдәмин әллә нишләп китте, тәне уянды, хатынының йөзенә күтәрелеп бакты. Бу аның Үрбәтне ачык килеш беренче тапкыр күрүе иде. Кара, нинди гүзәл икән аның яшь кәләше! Шомырттай кара күзләре, тулы алсу иреннәре, кабарыбрак торган алма бите, сызылып киткән нәзек

кашлары, йомры ияге күңелне вәсвәсәләндереп, үзенә тартып тора. Чибәрлеге өстенә, гаҗәеп нурлы иде аның йөзе. Җанга ягымлы. Килеш-килбәте, буй-сыны да урта бармак шикелле, төз, ыспай.

Мөхәммәдәмин хәтта берара тәҗрибәсез яшь мәгъшуктай югалып калды. Ул моңа кадәр дә ике тапкыр өйләнгән, өстәвенә, жарияләр тоткан, күпне күргән ир-егет. Утыз өч ел яшәп, аның күнелен бер күз сирпеп карау белән әсир иткән тәтә затның моңарчы булганы юк иде.

—Мөхәммәдәмин, бераз гына түз, җанашым, утларны сүндерәм дә, сине үзем чишендерәм,—дип гөлдердәде хатын.—Син каршы түгелсеңдер бит?

—Юк,—диде Мөхәммәдәмин тыңлаучан баладай,—каршы түгел... Аннан соң малайларча җитезлек белән кабалана-кабалана утларны барып сүндерде.

Үрбәт үзе дә Мөхәммәдәмин хәлендә иде. Чын-чынлап гашыйк булу өчен мәһабәтлек, чибәрлек кенә дә җитми бит әле ул. Ямьсез кешеләр дә мәхәббәтле була, аларны да яраталар. Моның өчен кешедә, мөгаен, синең генә йөрәгеңне алгысыта, синең күңелеңне генә кузгата торган ниндидер бары тик сиңа гына аталган җирсү зарурдыр. Ә ул бар иде. Үрбәт иң элек шуны абайлап алды. Аны дулкынланырга мәҗбүр иткән бу тылсым-җирсү Мөхәммәдәминнең кырыс ияген урталай бүлеп сузылган җөй иде. Яра—батырлык билгесе. Дала кызларының хыялы иде яра иясе егет. Күр инде, ходай аны үзенә насыйп яры белән кавыштырды лабаса! Һич уйламаган җирдән ишелеп төшкән бәхет ич бу. Озын гомерле генә була күрсен, Ходаем.

Ханнар никахы, гадәттә, исәп-хисапка, сәясәт мәнфәгатьләренә корыла. Мәхәббәт меңнән берәүгә генә тәтидер тәтесә дә. Мөхәммәдәмингә дә әнә шундый сирәк бәхет елмайды. Әйтерең бармы, ак шайтан булып чыкты Үрбәт атлы ханбикә, үзенә каратты тәки, мәхәббәте белән чорнап алды.

Ике йөрәк бер дулкында тибә башлады. Барысы да онытылды: Илһам да, Иван да, гүзәл Серафима да, хәтта Казан тәхете дә...

—Мин синең теләсә-нинди әмереңне үтәргә әзер, әйт кенә,—дип пышылдады Мөхәммәдәмин.

—Син—хан, җанашым, әмер бирүче дә син,—дип, Үрбәт иренең күкрәгенә сыенды.

—Нигә без элегрәк кавышмадык икән, күпме вакыт синсез үткән,—диде Мөхәммәдәмин.—Моның өчен олуг кенәзгә мәңгегә бурычлымын.

—Безне Тәңре кавыштырды,—диде Үрбәт ире белән килешмичә,—бел, насыйплар никахы иң элек күктә укыла, алар шуннан соң гына бер-берсен табышалар.

***

Мәчет эче шыгрым тулы. Монда Казан йортының иң күренекле шәхесләре җыелган. Әмирләр, бәкләр, бахшылар, морзалар, тарханнар, угланнар... Күбесе—дәрәҗәле түрә. Кайсы карачы, кайсы аталык, кайсы имидәш. Әмма дәрәҗәләрнең дә дәрәҗәлеләре—дин әһелләре. Күпчелекне дә алар тәшкил итә. Әнә, никадәр чалма! Куй көтүеннән ким түгел.

Мәчетне бик матурлаганнар. Баш-башлары түгәрәкләнеп уелган озынча тәрәзәләрдә язгы кояш нурлары балкый. Бу нурлар балкышында стеналар, түшәмнәр белән бергә, кешеләр дә алтыннан коелган кебек күренә.

Идәнгә мамыктай йомшак калын-калын келәмнәр җәелгән. Кая карама, күзләр гүзәллек, зәвык, зиннәтлелек, муллык вә купшылык белән очраша.

Барысы да дулкынландыргыч мизгелләр кичерә. Шулай булмыйча, хан күтәрмәк тамашасына җыелдылар лабаса!

Менә ханлыкның Диния нәзарәте җитәкчесе, мөфти Бураш сәед мөнбәр алдына килеп басты. Чәчәктән бал җыючы кортларның канат каккан тавышын да ишетерлек тынлык урнашты. Сәеднең тын алуы да сизелеп торды. Күрәсең,

ул да дулкынлана иде. Эчке калтырануын басу өчен, тамагын да кыргалап алды. Аннан соң бизәкле кул таягына таянарак төшкән хәлдә дога укып, хөтбәсен башлады:

—Аллаһы тәгаләнең рәхмәте белән, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссалам васыятьләренә тугры калып, мәшһүр Казан йорты халыкларының ихтыяжы вә теләген гамәлгә ашыру максатларында мәмләкәтебезгә баш кеше билгеләү саваплы да, игелекле дә бер күркәм гамәлдер. Баш кешене хөрмәт итү—Аллаһыны олылау дигән сүз ул. Чөнки баш кеше, ягъни дә хан—Күкләр ихтыяжын башкаручы зат. Бүгенге затыбыз исә шанлы Чыңгызлар ыруыннан килүче Олуг Мөхәммәд бине Мәхмүдәк бине Ибраһим бине Мөхәммәдәмин булыр. Ходай аңа озын гомер бирсен, гадел вә шәрәфле гамәлләр насыйп итсен. Аның хакимлеге чорында Барча Казан җире тыныч һәм мул тормыш кичерсен. Амин!

—Амин! Амин! Амин!—дип кабатлады гавәм сәеднең соңгы сүзен.

Мөхәммәдәмин ничек кенә кыю булып күренергә тырышмасын, бу сүзләр барыбер тәэсир итмичә калмады. Тез буыннары йомшарып китте. Сәед каршысына да авырлык белән генә килеп басты. Аннан ике-өч кенә адымда баш карачы, корылтай рәисе, тагын берничә мөхтәрәм бәк урын алды. Шунда ук алдан билгеләп куелган угланнар келәмгә турыпочмак рәвешендәге тәгыймәтне китереп җәйделәр. Ул алтынлы җепләр белән чигелгән, асылташлар белән бизәлгән иде.

Мөхәммәдәминнең күзләре шул купшы киезгә килеп төртелде. Дәгъва тудырган тәгыймәт шушы икән инде алайса, дип уйлап куйды. Әлеге мәсьәлә буенча кичә иртәнге якта ул илче Кляпик белән хөкүмәт башлыгы Кәлимәтне кабул иткән иде.

—Хан, синең кебек заманыбызның укымышлы вә зыялы затына иске йолаларга ябышып яту ярамас, олуг кенәз Василий да, Аурупа да аңламас. Син монгол ханы түгел, татар ханы,—дип, иң элек илче үз фикерен белдерде.

—Әгәр тамаша вакытында ялгыштан киез ярылып китсә, адәм мәсхәрәсенә калуыбыз бар бит,—дип өстәде баш карачы.

Ә Үрбәт алардан да алданрак житешкән иде. Бичәсенә, аның белән килештермичә, баш карачыны кабул итүе өчен, бик ачуы чыккан иде дә, сәбәбен белгәч, сүнде тагын. Сүнмәде, юк, киресенчә, хатыны көтелмәгән яктан ачылып китте.

—Хөрмәтле Мөхәммәдәмин хан,—диде ул рәсми мөнәсәбәттә,—Казан ханлыгына синең бабаң Олуг Мөхәммәд нигез салган, бөек дәүләтләр сафына бастырган. Син шул юлны дәвам иттерүче. Элекке дан, элекке шөһрәтне кайтаруны да ходай сиңа язган дип беләм. Казан йорты әвәлгечә бөтен тирә-якны куркытып, дер селкетеп торсын иде...

—Болары синең эш түгел инде,—диде Мөхәммәдәмин бик үк каты бәрелмичәрәк кенә,—үз вазифаларымны ничек тә үзем үтәргә тырышырмын.

—Беләм, җанашым, беләм,—дип, хатын иренә килеп сарылды.—Сакалың шундый йомшак, күркәм синең, Мөхәммәдәмин, көннәр-төннәр буе сыйпаштырып утырсам да ялыкмас идем...

Хан хатынын кочагына тартып кертте.

—Син минем аллам,—дип пышылдады бәхетле бичә.—Ә әлеге сүзләрне оныт, җәме, җанашым, мин шулай җилбәзәк бер нәмәстә инде, хатыннарның чәче генә озын бит аларның, акыллары кыска...

Ай-һай, кыска акыллы кеше тарих төпкелләрен айкап чыгара алыр иде микән? Дөрес, әлегәчә алар гыйшык телендә сөйләштеләр, наз телендә. Араларына бүтән сүз дә, бүтән гамәл дә керми, керә дә алмый иде. Ширбәт ае башканы кабул да итми, якын да җибәрми.

Ә бүген бу язылмаган канун бозылды. Һәм аны Үрбәт үзе бозды, белә

торып, күрә торып бозды. Чөнки Мөхәммәдәминне менә хәзер, шушы мизгелдә үз ягына аударырга, теләктәшен итәргә кирәк. Югыйсә сонга калуын ихтимал. Үрбәтнең ниятләре зурдан. Ул ундүрт елга сузылган кимсетелү-җәберләүләрне болай гына калдырырга теләми. Үчен исә фәкать Мөхәммәдәмин булышлыгы белән генә кайтара ала.

Мөхәммәдәмин хатынының сүзен өскә чыгарды. Сорасалар, могаен, ни өчен икәнен аңлатып та бирә алмас иде. Кляпикка "әйе" дип әйтергә ачылган авыздан "юк" дигән сүз очты. Үзе дә сизми калды, гүя аның белән ниндидер тылсымлы көч идарә итә иде.

—Тәгыймәт кулайрак булыр,—диде.

Тегеләрнең дә берешәсе килми. Имеш, без синең абруең, Казан йортының дан-дәрәҗәсе хакында ут йотабыз.

—Мин шулай хәл иттем,—дип кисте хан.

Менә хәзер ул зур бәхәсләр тудырган әлеге тәгыймәткә карап тора. Олуг Мөхәммәдкә чыдаган киез миңа да түзәр, дип уйлап куйды.

Бураш сәед мәчет эчен яңгыратып, тамашаның иң мөһим сүзен әйтте:

—Барча Казан җиренә дәгъва итүче Мөхәммәдәмин галиҗәнапларын, хан күтәрмәк йоласы буенча, тәгыймәткә бастырам, ходай бәрәкәтле ханлык насыйп итсен.

Сәед, Мөхәммәдәминне кулыннан җитәкләп, киез уртасына кертеп бастырды. Шунда ук ханны күтәреп тә алдылар. Шатлыклы авазлар яңгырады.

Мәчет буйлап йөргәндә тәгыймәт алтын-көмеш тәңкәләр, асыл ташлар белән тулды. Халык гөж килә.

—Төкле аягың белән, Мөхәммәдәмин хан!

—Афәрин!

—Сөбханалла!

—Дан сиңа, Мөхәммәдәмин хан!

Хан исеменә бик күп мактау вә данлау сүзләре әйтелде. Баш карачы исә барысыннан да уздырды.

—Мөхәммәдәмин хан, син—Атабыз, без синең колларың. Ни боерсаң, шуны үтәрбез. Мәңге яшә!—дип кычкырды.

—Амин! Амин! Амин!

Ханны тәхеткә утыртуга, баш угланның әмере яңгырады:

—Хан байракларын кертегез!

Угланнар байракларны өскә күтәреп, горур вә җиңүле кыяфәттә мәчетне әйләнеп чыктылар да, тәхетнең як-ягына тезелешеп бастылар.

Тантана дилбегәсен сәед янә үз кулына алды.

—Җәмәгать!—дип мөрәҗәгать итте ул җыенга,—Иншаллаһ, Казан йорты ханлы булды. Хәзер мин ана бисмилла әйтеп, хан бүреген кигезәм.

—Әлхамдулилләһ!

Мөхәммәдәмин тагын да мәһабәтрәк төскә керде.

Бүрек бик күркәм, бик затлы вә зиннәтле иде. Киң кырпуы күз явын алырдай телем-телем ап-ак кеш тиресеннән тегелгән, оч өлешен дә аксыл төстәге вак йомшак күннән җыйганнар. Кырпуның нәкъ урта бер җиреннән кылыч рәвешендәге шома кош кавырсыны чыгып тора. Ул бүреккә ниндидер тылсым, илаһилык өсти иде.

—Бисмилләһи тәвәккәлтү галәллаһ. Вәлә хауле, вәлә куввәтә иллә билләһ,—дип дога кылганнан соң, сәед кулына яшел бәрхет бөрмәкәйне алып, нотыгын дәвам итте.—Көч һәм куәт бары тик Аллаһта гынадыр. Вә шуның белән бергә, Аллаһ үзенең җирдәге илчеләренә дә зур вазифалар йөкли. Алар аны үҗәтлек белән үтәргә бурычлылар. Шул җөмләдән, Барча Казан җире бөек ханының да сүз вә гамәлләренә кануни хокук бирүче үз шәхси билгесе бар. Бу—нашан, мөһер суккыч. Мин ул нашанны да шаһитлар каршында

Мөхәммәдәмин ханга тапшырам.

Мәчет тагын бер тапкыр гөж килеп алды. Аллаһ йорты, гадәттә, салмак кына агучы ярым йокылы тормышка көйләнгән. Көндәлек дөньяви мәшәкатьләр аны урап уза. Хан мәчете исә башкалардан аермалы буларак, хан күтәрмәк тамашасы вакытында әнә шулай язгы ташкын шикелле ярларыннан чыгып, бер кузгалып ала. Бу һич тә хилаф гамәл түгел. Киресенчә, диннен, дин әһелләренең абруен гына күтәрә. Дәүләттә диния нәзарәте башлыгы мөфти хәзрәтләре ханнан кала икенче зат санала икән, бу табигый хәл. Шуна күрә тамаша Бураш сәед идарәлегендә бара да.

Сәедкә чигүле мендәрчек тоттырдылар. Ул, бөрмәкәйдән алып, нашанны шунын өстенә куйды да ханга тапшырды. Шушы мизгелдән Мөхәммәдәмин тулы хокуклы хан дәрәҗәсенә иреште.

Нашан үзе кызыл төстә иде. Ярлыкларга, аерата мөһим эш кәгазьләренә бүгеннән башлап, Мөхәммәдәмин ханнын мөһере сугылачак. Туры почмак рәвешендәге нашанның читенә түбәндәге сүзләр язылган: “Мөхәммәдәмин хан—кодрәтле солтан, гамәлләрендә һәм дини мәнфәгатьләрдә данлыклы, бөек яулап алучы, каһарман—Аллаһы Тәгалә аның мәмләкәтен гомер-бакый сакласын вә дә патшалыгын күкләргә чөйсен!»

“Лә иләһә илләлаһ, әшһәдү әннә мухәммәдәр-расүлүллаһ”—бу нашанның эчке каймасына теркәлгән дога.

Ханның нотыгы кыска һәм үтемле булды.

—Аллаһым! Синнән исәнлек-саулык, файдалы гыйлем, гүзәл һәм хәләл ризык, кабул булачак гамәл һәм эш телимен,—диде ул тирән ихласлык белән,—Синең ризалыгың һәм теләгең аркасында Барча Казан жиренең тәхетенә утырдым. Кулыма Коръән тотып, мәмләкәтебезнең данын, кодрәтен, дәрәҗәсен саклау вә арттыру мәнфәгатьләрендә барысын да эшләргә ант эчәм. Казан йорты кешеләренең дә, ошбу вазифага хәер-фатихасын биргән Бөтен Русиянең олуг кенәзе Иван Васильевичның да ышанычын акларммын. Амин!

Тантана бер ай буе дәвам итте. Мәжлес арты мәжлес. Чалынган малның, эчелгән эчемлекнең, ашаган ризыкның чутына да чыгарлык түгел иде. Хәер, аларны санар чак идеме соң? Түрәләр, дин әһелләре, һәркайсы утырган урынына бәрабәр бүләк алды. Толлар, ятимнәр, фәкыйрьләргә сәдакадан өлеш чыкты. Хәтта зинданнарның да ишекләрен ачтылар. Шул көннән башлап, муллалар һәр хөтбә вакытында Мөхәммәдәмин хан исеменә мактау сүзләре яңгыратырга бурычлы иде.

Кыз-хатыннар үзләренчә бәйрәм итте. Дәрәҗәле ир-атларның бичәләре хан сараенда күңел ачты. Бу хажәттән, хәтта жәнжал дә чыга язды. Гадәттә, хан сараенда аш-су мәжлесләре белән карт бикә идарә итә. Мөхәммәдәминнең исә Үрбәткә өстенлек бирәсе килә иде. Жөһдә ханбикәгә, билгеле, бу ошамады, көндәшенә карчыга урынына очып кунды.

—Морза кызы башың белән әмирләр нәселенә аяк чалмакчы буласыңмы,—диде зәһәрен чәчә-чәчә,—мәжлес жыю карт ханбикә вазифасы, тыкшынасы булма!

Үрбәткә ханбикәнең кара халыкка хас тупаслыгы охшамаса да дустанә кыяфәттә әйбәт киңәшен бирде.

—Безнең барыбызның да хужабыз Мөхәммәдәмин хан. Ул нәрсә теләсә, шул булыр,—диде,—мин аның сүзен бик хөрмәт итәм. Әгәр элеккечә булсын дисәң, сөйләш, ышандыр.

Карт хатын Үрбәтнең иплелеген дә охшатып житкермәде, ишекне бик каты ябып чыгып китте.

Үрбәт хан белән үзе сөйләште, хәлне аңлатты, хатасын төзәтүен үтенде.

Жәнжал уты үзеннән-үзе сүнде.

***

Кала кешеләре тантанада бик теләп катнаштылар, тамаша чын мәгънәсендә бөтенхалык бәйрәменә әверелде. Ханны олылап ни генә кыланмадылар. Хәсән исемле бер шәкерт, әнә, мәчет манарасына аркан асып, ай гөмбәзенә кадәр үрмәләп менәргә рөхсәт сорады.

—Азан әйтеп, Мөхәммәдәмин ханның исемен күкләргә ирештерәсем килә,—диде.

Ничек инде шушындый тәвәккәл егетнең изге ниятенә каршы киләсең, ди, хупладылар. Мондый тамашаның әле булганы юк иде, ханның үзен чакыруны да кирәк таптылар. Ул килгәч, билгеле, барча түрәләр дә кузгалды.

Егет җилле иде. Арканын да әзерләп куйган, манарага элү җаен да тапкан. Хан күтәрмәк тамашасының таҗы саналырдай тәвәккәл адым иде бу.

—Татар балаганы татарча булыр инде, аюлары да юк,—дип пышылдады дьяк Телешев. Кляпик ата каздай ысылдап анын җиңеннән тартты. Теленне тый, янәсе, басурманнар арасында икәнлегеңне исеңнән чыгарма. Хәер, энәләрен кабартмаса, Телешев була ди мени ул. Татарларны күрә дә алмый, татарлардан башка яши дә алмый. Шундый сәер ярату белән ярата иде дьяк дошманнарын.

Мәчет яны мәйданы Идел типкәндәге су дәрьясы шикелле тулганнан тула бара, анда инде борын төртермен димә. Һәммәсе манарага төбәлгән.

—Ай-һай, куш йөрәкле икән бу шәкерт,—дип сүзды сакалына чал кергән бер агай.

—Әйтмә дә, кода,—дип сүзгә кушылды күршесе,—мондыйны әле күрмәгән, валлаһи.

Әмер бирелгәндәй халык бер тында ухылдап куйды. Чөнки нәкъ шушы вакытта мәчет түбәсендә батыр егет үзе күренде.

—Караң, караң, Хәсән шәкерт!—дип бер-берсенең кабыргасына төртешеп алдылар. Тик үч иткәндәй, тамашаның иң кызык чагында гына чәүкәләр чырылдашырга тотынды.

—Көшегез, көш,—дип түземсезләнде халык.

Чәүкәләр үзләренә куркыныч янамавын аңлап алдылар, ахры, тынычланып янә манара арасына кереп тулдылар.

Шәкерт арканына чытырмандай ябышып береккән хәлдә, өскә карап бакты, үтәсе юлын күзеннән кичерде булса кирәк.

—Арканы түзәрлекме?—дип белеште Мөхәммәдәмин.

—Түзәрлек, сүс аркан, үзем тикшердем,—диде баш карачы.

—Нигәдер күңелем урынында түгел...

—Барысы да Аллаһы Тәгалә иркендә,—дип, ханны тынычландырырга ашыкты Бураш сәед. Бу анын, тамашаның ничек тәмамлануына карамастан, үзен аклавына ишарә итүе иде. Чөнки фатихасын биргәндә дә шәкертне бик нык кисәтте: "Бу синең үз теләгең белән гомереңне хан күтәрмәк йоласына багышлавың,—диде.—Фаҗигага юлыксаң да, исән калсаң да исемен хөтбә вакытларында телгә алыныр. Шулай да башыңны сакларга тырыш".

Шәкерт талпынгандай итте дә, гәүдәсен өскә ыргытты, терсәк буе җир китте. Житез, каһәр, маймылдан ким түгел. Малай чакта бик күп карга ояларын туздырганга охшый.

Хәсән азан мөнбәренә, мәэзднәгә бик тиз менеп житте. Ул тирәдә озак юанмастыр да, мөгаен: тәрәзә кашагаларына тотынырга җай бар. Менә ул аягын тәрәзә тупсасы астыннан чыгыбрак торган такта башына терәп, яңа ыргымга хәзерләнде. Йөрәге еш-еш тибә. Моның сәбәбе дә бар: атасы Сәмигулла мәзин, әгәр морадыңа ирешсәң, Таһир хәзрәт кызына яучы җибәрермен, диде. Мәдрәсәне тәмам итте инде, сәвәтле кеше ул хәзер, кәгазен генә аласы калды. Башлы-күзле булырга вакыт. Бәлки, Таһир хәзрәт үз мәхәлләсенә дә алып куяр. Хан да бүләксез калдырмас...

Боларны үзе генә белә. Башкалар өчен ул эчкерсез каһарман.

Егет уйларын уйлап бетерергә өлгермәде, такта башы сынып аска очты. Үзе арканга эленеп калды.

Халык аһ итеп, күзләрен йомды. Берәүнең дә күрәләтә олы фаҗиганың шаһиты буласы килми иде, әлбәттә.

Юк, бу фаҗига түгел иде әле. Егет тә каушавын басып, үрмәләвен дәвам итте.

—Угланнар йөзлегенә теркәгез бу шәкертне,—дип, хан аның киләчәк язмышын да хәл итеп куйды. Таһир хәзрәт мәхәлләсе генә түгел инде бу сина.

Җай-җай гына көенә китереп, Хәсән ыргымы саен айга якынлаша бара. Аның мәсләгенә ирешәчәге берәүдә дә шик тудырмый иде инде хәзер. Тиздән мыймылдап торган йомшак гәүдәле, кабартмадай симез битле Бәдернисаны куеныма кертәчәкмен, дип куанды Хәсән үзе дә. Таһир хәзрәтнең кияве булу зур дәрәҗә ләбаса! Ханның әмерен белсә, ни әйтер иде икән, анысын берәү дә белмәде.

Ярык кайда, җил шунда, ди, искәрмәстән генә җилбикә канатларын җилпеп җибәрде. Казансу ягында гына посып торган, күрәсең. Җилпенүе бер хәл иде, бүрек каләре генә болытны да куып китерде, хәерсез. Янә күзләргә күләгә ятты. Шәкерт тә хәвефләнде, явым-төшем эшне бозып куймасын тагын, дип борчылды.

Шөкер, җилбикә дә мәрхәмәтенә килде. Күп тә үтми, Хәсәннең бармак очлары ялтыравыклы ай өслегенә тиеп узды.

И, сөенгәне! Мин сүземдә тордым! Кешеләр, күрегез, күккә ашкан изге мәчет аен кулым белән сыйпыйм!

Ә аста чып-чын мәхшәр: кешеләр шатлыкларына чыдый алмыйча сикерешәләр, кычкырышалар, кул болгыйлар…

—Аллаһу әкбәр!..

Шул вакыт мәчет өстендә асылынып калган болыт чиләген кыйшайтып җибәрде. Эчендә карлы янгыр йөрткән икән. Түкте.

—Аллаһу әкбәр!..

Артык дулкынлануданмы, булдырдым бит, дип тынычлануданмы, бәлки, башы әйләнеп киткәндер, аны инде хәзер берәү дә белә алмый, Хәсән шәкерт атылган таш шикелле аска тәгәрәде.

—Аһ, харап булды шәкерт,—дип кычкырып җибәрде Мөхәммәдәмин.

—Татарларның ашына таракан төште,—диде Телешев көлемсерәп.

—Да-а-а,—дип сузды Кляпик. Кызгану идеме бу, сөенүме, хәтта Телешев та аңламады.

Сәед фаҗиганы үзенчә шәрехләде:

—Аллаһы Тәгалә теләгән нәрсәләрнең һәркайсы булыр. Барыбыз да Аның кулында,—диде.

Хан гына тынычлана алмады. Шәкерт аны олылау, аны данлау ниятеннән әлеге адымга барды ләбаса. Юк, фаҗиганы сәед фәлсәфәсе күләгәсендә генә калдыра алмый ул. Бу мәрхүмгә карата бик зур гаделсезлек күрсәтү булыр иде.

Күп тә үтми, Ак күл мәдрәсәсенә Хәсән шәкерт исеме бирелде.

*Дәвамы киләсе санда*



Марис
Нэзиров

# КОШ ЮЛЫННАН КИТЕП БАРАМ

## Янып яшәргә!

**Көннәремне ура барган саен**
**Мин Акылга күбрәк тезләнәм:**
**Гомерем басуында еллар ята—**
**Уй-фикерләр җыйган тезмәдәй...**

**Миңа шуны суктырырга кирәк,**
**Түкми-чәчми җыеп алырга.**
**Яз шытачак тук орлыктай итеп**
**Халкым күңеленә салырга.**

**Салырга да, тагын көннәр урып,**
**Тик шатлыклар гына чәчәргә:**
**Аек акыл хисне җиңгәндә дә,**
**Көйрәп түгел, янып яшәргә!**

## Мирсәй Әмир урамы

**Көртләр өйгән—**
**Җилләр билен бирми тынлык мизгеленә;**
**Җибәрмичә кышны бозлы тезгененнән**
**Бурый гыйнвар бураны.**
**Утлар сүнгән:**
**Ап-ак төшләр түшәгендә йоклый Җиргән[1];**
**Сеңгән аның җылы кочагына**
**Мирсәй Әмир урамы.**

**Иҗат учагына**
**Илһам кузы өстәп торган һәрбер нигез**
**Саклый монда дуслык утын сүрелүсез,**
**Кар яткызмый сукмакка.**

[1] Башкортстанның Мәләвез районындагы авыл.

Марис НӘЗИРОВ (1949) — *Башкортстанда (Чакмагыш) яшәүче татар шагыйре. Башкорт һәм татар телләрендә дөнья күргән ун китап авторы.*

Җылы учларыннан
Чөйгән авыл Уфа, Казаннарга улын—
Данын чал тарихлы Агыйдел[1]нең
Таратырга еракка.

Әй, күңелнең
Татар, башкорт, урыс, чуаш туганнарны
Бергә кичерткәне давыл-бураннарны,
Атлатканы иңгә-иң!
Әй, күмелеп
Кардәшлекнең балдай татлы ләззәтенә,
Рәхәтенә рухи якынлыкның
Яшәүләре тиңгә-тиң!

Ялкын юклык
Һич янамый бу авылның учагына;
Сыенганга бакый дуслык кочагына
Такыр әдип урамы.
Якты аклык,
Пакьлек, сафлык өстәп тынлык мизгеленә,
Җибәрмичә кышны тезгененнән
Бурый гыйнвар бураны...

## Нинди кодрәт

Нинди көчләр тарта күккә безне:
Зәңгәр тынлык, кояш нурымы,
Ай сәламе, йолдыз җырымы?

Ник алмыйбыз күктән күзебезне:
Уй саламы болыт агышы,
Чакырамы киңлек тавышы?

Җир асылын күктән эзлибезме:
Тәнгә—туфрак, җанга—һавамы,
Җан дәвамы—җиргә дәвамы?

Эзлибезме күктән ишебезне:
Галәмдәш зат, камил акылны,
Рухы белән безгә якынны?

Эзлибезме күктә үзебезне:
Халәтме бу, гадәт кенәме?
Җан кергәндә канга кирәме?!

Нинди кодрәт әйди күккә безне?..

## Кыяр-кыймас кына

Авырып егылдым. Күз йомдым.
Үлем килде янга кабарып.
Кара көн, кара ут, кара кул...
Тирә-юньдә бары каралык.
Йөрәгемә тора кадалып.

[1] М. Әмир повестена ишарә.

Авырып тереллдем. Күз ачтым.
Арып, изрәп бактым яктыга.
Ап-ак көн, ап-ак ут, ап-ак кул...
Бөтен дөнья, гүя, ак кына.
Пакь дөньяга бастым сабый сыман
Кыяр-кыймас кына, сак кына.
...Яшәү кадерен белдем чак кына!

## Туу белән үлем арасы

Ак биләүдә адәм баласы,
Авыз ачып аваз саласы.
Нур уйнатып кояш карасы,
Керфек сирпеп аңа багасы.
Бишек белән ишек арасы,
Тәпи басып атлап барасы.
Ак биләүдә адәм баласы...

Ак күлмәктән адәм баласы,
Наз туфрагы, сөю һавасы.
Тормыш агы, кормыш карасы,
Тән ләззәте, күңел ярасы.
Яшьлек белән картлык арасы,
Югалтулар аша барасы.
Ак күлмәктән адәм баласы...

Ак биләүдә Адәм баласы,
Һәр адәмгә Ходай бәһасы.
Җир-су, кояш һәм җил дәвасы,
Сират күперенә барасы.
Туу белән үлем арасы,
Биләү агы, туфрак карасы.

Һәр бәндәгә Ходай бәһасы:
Оҗмах түре, тәмуг җәзасы...

***

Гел кызарып, көлеп таң уята,
Кояш бата көн дә алланып.
Гомер узып бара, "хаклык җиңә!"
Дигән гыйбарәгә алданып.

Фасылларны фасыл алмаштыра,
Җәй җуела көзгә ялганып.
Гомер узып бара: «Күңел яшь-яшь,
Китмә, сөю!»—диеп, ялварып.

Көз үткәндә кызгылт ачы миләш
Кыш башында кала балланып.
Гомер узып бара, әчедән соң
Татлы килер диеп алданып.

***

Җилекләргә кадәр үтә зәһәр суык,
Ә кояшның нуры якты, чагылдыра күзне.
Үлүчеләр булыр тагын юлда туңып...
Ниләр өчен кемнәр каһәрләгән шулай безне?

**Нәселенме корытырга шулай каһәрләнгән:**
**Тынар тагын кемдер, хәле беткәч көртләр ярып.**
**Көч агымы тукталамы безгә Галәмнәрдән,**
**Дәрт-дәрманның әллә чыганагы күктә ябык?**

**Җилекләргә кадәр үтә бүген зәһәр тынлы суык,**
**Шундый суыкта да булыр суга баткан, утта янган.**
**Китүчеләр булыр тансык тормыш ләззәтеннән туеп,**
**Зәһәрлектән гарык кемдер китәр тагын бу дөньядан...**

**Ә мин, шөкер, исән әле, көләм әле, киләм юлым ерып,**
**Тормыш салкыныннан, утлы давылыннан яшермичә йөзне.**
**Кемгә чират тагын? Кайсыбыз соң бүген капылт авар арып?**
**...Ә кояшның нуры ымсындыргыч якты, чагылдыра күзне...**

*** * ***

**Гөнаһларың чамасыздыр, адәми зат!—**
**Шул хәтле дә шашмас иде бу Табигать...**

**Сабыйлар күз яшеннәндер дөнья тулган,**
**Калаларны, салаларны баса туфан.**
**Ут аттыра таудан ап-ак карлы тынлык,**
**Ялкын баганасын каплый караңгылык.**

**Аналар әрнешеннәндер мондый мәхшәр,**
**Илләр йөрәгенә ирләр кадый хәнҗәр.**
**Туганнары белән туган якалаша,**
**Ата—улны, ул—атаны дарга аса.**

**Ничек тыныч кала алсын бу Табигать,**
**Аңа язык ваемсызлык, чит-ят сыйфат.**
**Күпме каза—яшен яшьнәп, күк күкрәүдән,**
**Күпме газап-югалтулар җир тетрәүдән.**

**Каргышларны лава булып җиргә тулган?**
**Кабатлангач Помпей хәле, тына вулкан...**

**Бу табигать тыныч кына ничек булсын:**
**Диңгез кибә, чүл көченә, үрчи упкын.**
**Хәтта кояш, һич аямый, ут очыра,**
**Ай тотыла, магнит давылы котыра...**

**Ничек сине атарга—дип галәми зат,**
**Җиһанга да бомба аскач, адәми зат?**

**Казалардан яклар дисәң бу Табигать,**
**Гөнаһлардан арын, пакьлән адәми зат.**
**Күз яшьләрен киптер, сафлан, адәми зат,**
**Вөҗдан газабыннан саклан, адәми зат!**

♣

Рәмзия
Габделхакова

## КИТМӘ!!!

Подъездда ут юк иде.

Дөм караңгыда кармалана-кармалана, Шакирә баскыч култыксасын эзләп тапты, суга батучы үзенә сузылган кулларга ничек ябышса, ул да аңа шулай килеп ябышты. Әллә кемнәрнең тирле учлары сыйпап үткән бу култыкса аны тугрылыклы дусты сыман җитәкләп, өскә, үзе яшәгән жиденче катка алып менәчәк иде.

Җәйге көн ни озын булса да, вакыты җиткәч, шәһәр өстенә кара чапанын җәеп, төн сузылып ята. Караңгылык өркетә, шикләндерә. Бина эчендә бигрәк тә. Һәр борылышта хәвеф сагалап тора кебек. Ишекләр әллә ничә йозакка бикләнгән. Андый-мондый хәл була калса да, алар ачылмаячак. Берни күрмәдек, берни ишетмәдек... Шулай тынычрак. Заман кешеләрне битараф булырга өйрәтте. Шаһит белән корбан бер сызыкта басып тора. Бүген—шаһит, иртәгә—корбан...

Шакирә тавыш-тынсыз гына атларга тырыша. Әмма, ничек сак басса да, дулап-ярсып типкән йөрәк тавышы үз колагында гына түгел, бөтен подъездга яңгырый кебек. Ул балачактан ук караңгылыктан курка иде. Күнеленнән генә әбисе өйрәткән догаларны пышылдады: «Лә хәүлә вә лә куәте... Йә Ходаем, юньсез бәндәләрдән сакла! Үз өемә исән-имин кайтып керергә насыйп ит!»

Менә инде бишенче кат. Тагы икене менәр дә, үз бусагасыннан атлап керер, ике ишеген дүрт йозакка бикләп, иркен сулап куяр... Үз өем—үз өнем, үз көем.

Алтынчы катны үтеп, жиденчегә күтәрелгәндә, хатын чак кычкырып җибәрмәде. Ике кат арасындагы мәйданчыкның тәрәзә төбендә, тезләрен кочып, ниндидер кеше утыра иде. Әллә ир-ат, әллә хатын-кыз—урамнан төшкән саран ут яктысында карга оясыдай тузган баш кына шәйләнә.

«Наркоман!»—болай да куркудан куырылган йөрәген чеметеп, башыннан иң әүвәл никтер шул уй йөгереп узды. Үз акылында булса, киерелеп ачылган тәрәзә төбендә шулай иркенләп, җәелеп утырыр идемени бу бәндә?! Чак кына сулга авышты исә, түбәнгә атылачак бит.

Шакирә күләгә-кеше янынннан шым басып, тыныч кына үтеп китмәкче иде, тегесе үзе сүз катты:

—Мин сине көтәм...

Кое төбеннән бәрелә-сугыла гөбердәп күтәрелгән кайтаваз сыман калтыравык, тынгысыз тавышны ишетеп, хатын шып туктады, дәшүчегә

арты белән баскан килеш:
—Нигә?—дип сорады.
—Мина шаһит кирәк. Югыйсә, анламаячаклар.
—Мин сине күрмәдем,—диде хатын һәм юлын дәвам итте.
—Ә мин синен күрүенне телим!
Шакирә ярты сыны белән генә тәрәзә ягына борылып, кайгыртучан, йомшак тавыш белән шәүләгә дәште:
—Егыласың бит...
Шүрләвен сиздермәскә, саксыз сүз әйтеп, тәрәзә уемындагы ир-атны ярсытмаска кирәк иде.
—Ә бәлки минем егыласым киләдер,—диде күләгә-кеше һәм кискен хәрәкәт белән кулларын кош канатыдай як-якка җәеп җибәрде.
Тәрәз артындагы бушлыкны уйлап хатынның тәне чымырдап, тез буыннары калтырап китте. Егетнең йөзендә исә илаһи тынычлык иде.
—Уң якта—караңгы, пычрак подъезд. Бу—тормыш,—диде ул.—Ә сул якта—ирек, биеклек, чиксезлек. Бу—үлем. Кайсы як сөйкемлерәк? Үлем түгелмени?
Шакирә эченнән генә тиргәнеп алды: «Кысыр хәсрәт! Төн уртасында кеше куркытып, саташып йөрмәсән соң!» Уйлары сүзләргә әверелеп, карангылыкка сибелде:
—Канга батып, асфальтта чәчрәп яткан мәет сөйкемледер шул...
Хатын юлын дәвам итмәкче булып, бер генә адым ясарга өлгерде.
—Китмә!!!—дип кычкырды егет.
Китмә... Китмә!!! Кайчандыр ул да әрнеп-өзгәләнеп шулай кычкырган иде... Тик китүчене барыбер туктата алмады.
Шакирә, артка борылып караудан үзен көчкә тыеп, алгы баскычка күтәрелде.
—Китмә!!!—дип кабатлады егет.—Соңгы мизгелдә ялгыз буласым килми. Очышымны кемнендер күрүен, мине озатып калуын телим.
Шакирәнең бу исәр затның куркыныч уенында катнашырга бернинди теләге юк иде, әлбәттә. Тегенең ачу-ярсуын кузгатмас өчен, йомшак кына аклангандай итенде:
—Минем эштән кайту, үлеп ашыйсым килә. Көне буе авызга ризык капмадым...
Хатынның теләге дә, сүзләре дә җан асрау, яшәү белән бәйләнгән, артык гади, табигый иде. Тормышка артын куеп, упкынга ашкынган җан аларны ишетергә теләмәде.
—Курыкма. БУ... озак булмаячак... Мин очам да китәм.
—Синен канатларың юк. Таштай түбән атылачаксың.
Егетнең хәтере калды:
—Мин таш түгел...
—Кош та түгел. Синең канатларың юк,—дип кабатлады хатын.
Ул бары өч баскыч күтәрелгән иде, артында кабат үзәк өзгеч тавыш яңгырады:
—Китмә!!!
Хатын иренеп кенә артына борылды, берничә баскыч түбән төшеп, салкын диварга сөялде:
—Ни кирәк сиңа?—Тавышы арган, битараф иде.
—Ник качасың син? Нигә мине калырга үгетләмисең?
—Мин язмышны үзгәртә алмыйм, балакай. Әгәр сиңа бүген тәрәзәдән сикереп үләргә язган икән, син барыбер сикерәчәксең. Тәкъдирне узып булмый. Аннары сине көйләп утырырга вакытым да юк. Синең үз тормышың, минем үземнеке. Арыдым мин...

Шакирә сүзләренең чынлыгына ышандырырга теләгәндәй авыр сулап куйды.

—Мине беркем аңламый. Аңларга да теләми...

Ике яр уртасына басып, икеләнеп торган мизгелдә каршында пәйда булган бу җан иясен егет үз яныннан җибәрергә теләми иде бугай. Әллә коткару көтте ул аннан, әллә упкынга очышын җиңеләйтү өчен күңелен бушатасы килде.

—Ә син кемне аңлыйсың соң?!

Сорау егеткә ошамады, ул аны җавапсыз калдырды. Аңа бу хатынның үзен кызгануы, «китмә!» дип ялваруы, үгетләве кирәк иде. Ул чагында дөньяга булган бар ачу-үпкәсен аның өстенә түгеп калдырачак иде.

—Миңа шундый авыр... Мин гел ялгыз булдым...

—Барыбыз да ялгыз,—диде хатын.—Һәркемнең үз сукмагы.

—Мине саттылар. Хыянәт иттеләр.

—Беренче тапкырмы? Беренче хыянәт бик авыр була шул...

—Калганнары җиңелме?

—Беренче хыянәт авыр,—диде хатын.—Аннары өйрәнәсең.

—Хыянәткә өйрәнеп буламыни?

—Хыянәткә өйрәнеп булмый. Ышанмаска өйрәнәсең.

—Ышанмыйча ничек яшәргә соң?

—Шуңа күрә тормыш катлаулы да инде, балакай. Таяныр кеше табу авыр.

—Ник җирдә явызлык күбрәк?—дип сорады егет. Шакирә белән сөйләшү аңа ошап китте бугай.

Бу сорауга һәр кешенең үз җавабы бар.

—Яхшылыкның кадерен белү өчен,—диде Шакирә.

Чөнки ул күптән аңлады инде: саулык кадерен авырулар, бәхет кадерен бәхетсезләр, бар кадерен юк белә...

—Мин яхшы булдым. Ләкин Ул мине барыбер ташлады. Егет «Ул» сүзен аерып, басып ясап әйтте. Бу сүзгә мәхәббәт тә, нәфрәт тә берьюлы сыйган иде. Әче камырдагы йөзем кебек.

—Димәк, яратмаган. Яратса, ташламас иде,—диде Шакирә.

—Яратты! Тик аңа хәерчеләр кирәкми. Акча, байлык кирәк, машина... Ул мәхәббәтне байлыкка алмаштырды.

—Мәхәббәтне байлык алыштыра алмый. Ул да моны аңлар. Ләкин ул сиңа кирәкми. Хыянәтчеләр өчен яшь түкмиләр, тәрәзәдән дә сикермиләр. Аларны үз сукмагыңнан куарга кирәк, бары шул гына. Тормыш сукмагында чүп-чар ятмаска тиеш. Югыйсә абынуың бар.

Егет аны әллә ишетте, әллә юк.

—Ул киткәч, мин кулымдагы бөтен акчаларны яндырдым,—дип үзенең шыңшуын дәвам итте.—Алар бәхетсезлек алып килә. Акча үзе явызлык чыганагы. Шул пычрак кәгазьләр хуҗа булган дөньяда яшисем килми. Акча мәхәббәтне үтерә...

—Ялгышасың, балакай. Мәхәббәтне акча түгел, хыянәт үтерә.

—Син хаклыдыр бәлки... Ләкин хыянәт булса да, мәхәббәт үлмәде бит! Ул хәзер дә миндә яши. Үземнеке генә түгел. Аныкы да... Артык күп ул, артык зур. Бәлки шуңа күрә миңа авырдыр. Ике кешелек мәхәббәтне берүзем ничек күтәрим...

—Алай булгач, син үзеңне түгел, мәхәббәтне үтерергә телисең. Аныкын, үзеңнекен, Аллаһныкын...

—Аллаһның монда ни катнашы бар? Бармы соң ул? Минем аны күргәнем юк.

—Без күрмәгән нәрсә юк дигән сүз түгел...

Егет, башын тезләренә салып, байтак дәшми торды. Икесе дә караңгылыкта, тынлыкта ялгыз калдылар. Тугыз катлы йортта да шундый тынлык булыр икән! Алардан башка биредә бер исән кеше калмаган диярсең. Ни менүче, ни төшүче күренми. Бу саташкан бәндәне төне буе берүзе саклап утырмас бит инде Шакирә. Китәргә кирәк. Терәк табудан сөенеп ойый башлаган сынын дивардан кочкә аерып, ул әкрен генә баскычка таба чигенде. Ләкин егет аның ниятен сулышыннан сизеп алды бугай, ялт итеп бу якка борылды:

—Китмә!!! Мине кемдер тынларга тиеш. Бәлки бу соңгы теләгемдер.

—Мин арыдым,—диде хатын.—Гафу ит, минем сине юатырлык көчем юк.

Ләкин егеттә аның кайгысы түгел иде, елак, мескен тавыш белән үз зарын түкте:

—Син юатма, тыңла гына. Ул—минем Кояшым иде! Шашып-саташып яраттым мин Аны. Хәтта әниемнән дә артык яраттым. Барысын да оныттым. Ул гына калды. Ул гына! Мин Ансыз бер көн дә, бер мизгел дә яши алмыйм! Теләмим дә...

—Ә ул яши ала! Андыйлар озак һәм рәхәт яши. Буш жаннарны жил күтәреп йөртә.

«Ни сөйлим мин?—дип уйлады Шакирә.—Күрмәгән-белмәгән кешене гаепләргә ни хакым бар? Ул кыз бәлки фәрештәгә тиң бер гөнаһсыз заттыр. Бәлки эш байлыкта да түгелдер... Бәлки бернинди хыянәт юк, ул үзенең чын мәхәббәтен тапкандыр... Ялгышлар кабатланса да, язмышлар кабатланмый... Ташланган яр—үртәлгән жан, ни сөйләмәс? Ирләрнең хатын-кыз күңелен аңлыйсы бармы?!»

Уйларын егетнең үпкәле-янаулы усал тавышы бүлде:

—Мин китсәм, Ул үкенәчәк!

«И беркатлы жан! Ул кызый синең дөньяда барлыгыңны да оныткандыр инде. Ташлап китүчеләр артка борылып карамый...»

—Ялгышасың! Үкенмәячәк! Каберенә дә килмәячәк!

Өзеп-кистереп әйтелгән рәхимсез сүзләр, таудан ишелгән авыр ташлар сыман, егет ягына тәгәрәде. Хакыйкатьнең кайчан татлы, жинел булганы бар?!

Бу сүзләр бушлыкка сикерү өчен тәрәзә төбенә менеп кунаклаган кешене үртәргә-ярсытырга тиеш иде кебек. Ләкин күңел күңелгә ошамый. Егет, аклангандай, гаепле, күндәм тавыш белән:

—Мин Аның елавын телим...—дип кенә куйды. Әңгәмәдәшенең көчсезләгән тоеп, Шакирә тагы да кыюланды:

—Жүләр! Еласа-еламаса... Сиңа соң... Мәеткә барыбер түгелмени?!

Барыбер түгел... Иртәгә монда журналистлар, тикшерүчеләр киләчәк. Аларга сенсация кирәк. Син сөйлә, барысы да белсен: минем үлемемдә Ул гаепле.

—Сине төртеп төшергән кеше юк. Үз гаебеңне башкаларга аударма,—диде Шакирә тыныч кына.—Әниең сине тәрәзәдән сикерер өчен үстермәгәндер. Саташып йөрмә, өеңә кайт!

Егет аны ишетмәде дә бугай:

—Син минем соңгы теләкне үтәргә тиеш!

Тугыз катлы таш йортның шыксыз тәрәзә төбен яшәү белән үлем чиге итеп сайлаган бу исәр бәндә Шакирәне күзгә күренмәс жепләр белән гүя үзенә бәйләп куйган иде. Дөрләп янган ут та кешене үзенә шулай тарта, имеш. Әгәр егет янында озаграк тоткарланса, тегә якка икәүләп сикерүләре дә бар...

Хатын, ике арадагы чияләнеп-чуалып беткән жепләрне берьюлы өзәргә теләгәндәй, кисәк борылды:

—Өметләнмә! Мин сине күрмәдем, ишетмәдем. Сүзең булса, язып калдыр. Хуш!

Китешли егеткә шул сүзләрне ташлады да, үзен кабат туктатуларыннан курыккандай, кызу-кызу баскычтан менә башлады.

Аны:

—Минем кәгазем дә, ручкам да юк...—дигән мескен сүзләр куып җитте.

—Булгач сикерерсең!—дип кычкырды хатын жиденче каттан.

—А-а-а!!!

Шакирә сискәнеп артына борылды, култыксага таянып, аска үрелеп карады. Егет башын кочып урынында утыра иде...

Ишекне ачуга борынына әчкелтем исләр килеп ягылды, түр яктан таныш тавыш ишетелде:

—Ыгыгы... Ыгы...

—Хәзер, улым, хәзер...

Шакирә ишек төбендәге трюмо тумбасына килеп утырды да, көзгедә чагылган хатынның салкын аркасына сөялеп, күзен йомды. Утыруның никадәр рәхәт икәнен аның кебек аңлаучы бармы икән дөньяда? Ун сәгать буе аяк өсте тору коточкыч авыр. Арып хәлдән тайсаң да, эчең тулы ут булса да, елмай-көл, кесәсен бушатып, акчасын шунда калдырып китсен өчен, ишектән кергән һәр кеше алдында шат кыяфәт белән биеп тор. Ул эшләгән кибеттә таләпләр шундый. Түзсәң түз, түзмәсәң, бигайбә, «Китмә, кал!»—дип ялынучы юк. Адәм баласы кадерсез заман. Син киткәнне, урын бушаганны көтеп ишек төбендә унлап эшсез таптана.

«Ник яшим мин?»—дип еш уйлый иде Шакирә. Яшәвен, балам өчен, дип акларга тырыша иде. Ләкин сәламәт кеше дә артык булган бу илгә, үзе дә авыру җәмгыятькә аның чирле баласы тансыкмы соң?!

—Ник яшим мин?—дип сорады берчак Шакирә нурлы йөзле, җылы карашлы бер яшь мулладан. Бәлки ул мулла да булмагандыр әле. Башына түбәтәй киеп, бик эшлекле кыяфәт белән мәчеттә йөргәч, Шакирә никтер нәкъ менә аңа ышанып сүз катты.

Аптырап-йөдәп йөргән көннәренең берсендә, җанын кыйнаган сорауларга җавап, күңеленә юаныч эзләп кергән иде ул бирегә. Үзен тыңлаучы табылуга сөенеп, гомерендә тәүге тапкыр күргән шул егеткә моң-зарын түкте.

—Аллаһы Тәгалә безне сынар өчен яраткан,—дип җавап бирде мулла.

Хатын киная белән мыскыллы елмайды:

—Балда-майда йөзүчеләрне дә сыныймы?

—Кемне байлык, кемне юклык, кемне хаста белән сыный, һәркемгә үзенеке.

—Нигә миңа барысы берьюлы? Ялгызлык та, хәерчелек тә, чир дә? Ничек күтәрим, ничек түзим?—дип әрнеп сорады Шакирә.

—Һәркемгә күтәрә алырлык бирермен, дигән. Авырлыгына күрә сабырлыгы, чиренә күрә дәвасы, гөнаһына күрә җәзасы бар. Сез көчле. Сез күтәрә аласыз.

Аның сүзләре хатынны гаҗәпләнергә мәҗбүр итте:

—Минме көчле?! Ю-у-ук... Мин бик арыдым... Яшәргә теләгем дә, көчем дә калмады. Күземә тилмереп карап яткан чирле улым булмаса... бүген үк... баугa... менәр идем.

Әллә үзен ныграк кызгануларын теләп, әллә хәленең ни дәрәҗәдә авыр, чарасыз икәнен аңлатасы килепме, Шакирә үзе дә сизми арттырып җибәрде.

Бауга менәргә аның уенда да юк иде.

Бу чуар, болгавыр дөньяда әле бик аз яшәгән инсафлы егет, аның сүзләрен йөрәгенә якын алып, юатырга, үгетләргә кереште:

—Т-т-әүбә, диегез, апа. Анда ни көткәнен беләсезме соң? Үзегезгә кул салып, тынычлык табармын дип уйлыйсызмы? Мордарлык иң зур гөнаһ бит ул.

Шакирә исә үҗәтләнеп баш чайкады:

—Мин үз тормышыма үзем хуҗа!

—Юк,—диде яшь мулла.—Сезне дөньяга ана тудырган, Ходай җан биргән. Аллаһы Тәгалә әмереннән башка гомер өзгәннәрнең җаны иблис кулына күчә. Сез шуны телисезме? Түзәргә кирәк, апа. Газабына күрә савабы булыр.

«Матур сөйләп, акыл өйрәтүе җиңел ул. Үзең минем урында булсаң, нишләр идең икән?—дип үртәлде хатын.—Хәер, син минем урында булмассың... Син дә шуларның берсе бит...»

Шуларның берсе Шакирәгә хыянәт итте инде һәм шуннан соң ул ир затларын күралмас булды. Хыянәт гүя үзенең үтмәс пычагы белән тәнен, җанын телә-телә, һәр күзәнәктә нәни кояш булып балкыган мәхәббәт тамчыларын суырып алды. Буш урынга кара кан булып нәфрәт кереп урнашты. Күңелендә кара сумала булып кайнаган шул нәфрәт юлында очраган һәр ир-ат өстенә шаулап түгелергә әзер иде. Мәчеттәге тыныч, якты йөзле яшь мулла да, аның акыллы сүзләре дә нәфрәт юлын бүлә алмады. Шакирә егетнең яшьлек нуры балкыган матур күзләренә туп-туры карап, тегенең каушап-югалып калуыннан үзенә күрә бер тәм табып, эчендәге агуын түкте:

—Без түзәрбез анысы... Ә сез ник түзмисез соң?! Авырлык килде исә, койрыкны сыртка салып, тизрәк качу ягын карыйсыз. Барыгыз да бер! Җиңел, рәхәт яшисегез килә. Ялгыз ананы да, карт хатынны да, чирле баланы да ташлап китәсез. Бөтен бозыклыкның башында ирләр тора. Ирләр, чынлыкта, хайваннардан берни белән дә аерылмый. Җан юк бит сездә... Тик мин шуны аңламыйм, әгәр Ходай гадел икән, ник соң тигезлек юк? Әллә Аллаһ үзе дә ирләр яклымы?!

Аның сүзләре егетне тагы куркуга салды, сөйкемле йөзенә күгелҗем тимгелләр бәреп чыкты, ул хәтта тотлыга ук башлады:

—А-п-па, алай ярамый. С-с-ез бик куркыныч сүзләр сөйлисез. Аллаһ каршында барчабыз да тигез. Аңа тел тидермәгез. Улыгыз бар лабаса. Ул да ир-ат женесеннән. Сезнең нәфрәт аны үтерәчәк. Нәфрәт нәфрәт үрчетә. Мәхәббәт кенә терелтә, яшәргә көч бирә. Сабыр булыгыз, апа...

Егет бу сүзләрен ялварып, еларга җитешеп әйтте. Күрәсең, ул әле мулла да булмагандыр, шунда укып йөрүче шәкерт кенә булгандыр. Чөнки икенче юлы мәчеткә килгәндә Шакирәне башка кеше—чал сакаллы, бик җитди, тәкәббер кыяфәтле бер карт каршы алды. Үтеп барышлый, аяк өсте генә:

—Намазга бас, мәчеткә хәер бир. Аллаһы Тәгаләдән сабырлык сора,—дип киңәшләрен бирде дә, җил-җил атлап, кызыл ләлә чәчәкләре төшерелгән яшел ишек артына кереп югалды...

Ирләрнең яше дә, карты да аңа сабыр итәргә, түзәргә куштылар. Хатын-кыз бу җиргә түзәр өчен дә, ирләр тормышын бизәр өчен генә киләдер, күрәсең...

Түзми кая барсын, түзә Шакирә... Сабырлык касәләре мөлдерәп тулган гына түгел, ташып аккан инде. Менә утыра бит ярты мәет булып. Урыныннан кузгалырга көч табалмый. Шунда утырган килеш йоклап кына китәсе иде. Башка берни кирәкми. Бары ял гына, бары туйганчы рәхәтләнеп бер

йоклыйсы гына! Дөньяда иң татлы нәрсә йокы икән...

Күзләр йомыла, тәнен рәхәт дулкын биләп ала. Зәп-зәңгәр күктән алтын нурлар тама. Күз алдында иксез-чиксез яшел болын җәйрәп ята... Кулына бер бәйләм кыр чәчәкләре тоткан ак күлмәкле көләч егет Шакирәгә таба атлый. Якыная, якыная... Менә инде артка таралган кара чәчләре, куе керфекләре астында йолдыз булып җемелдәгән зәңгәр күзләре, яңакларын чокырайтып елмайган тулы иреннәре дә ап-ачык булып күренә. Шакирә шатлыгыннан кулларын җәеп аның кочагына атыла:

—Ризван!!!

—Ыгыгы, ыгы...

Хатын сискәнеп күзләрен ачты. Улы аны көтә, чакыра... Улының ашыйсы килә... Асты юештер, чүпрәкләрен алыштырасы бар...

Ләкин кыймылдыйсы да килми. Арыган-йончыган тән үзенә ял, тынычлык сорый. Түзмәс, беркөн өзелер дә инде...

Йокылы-уяулы килеш күргән төше үткәннәр куенында калган кояшсыз мизгелләрне яңартты...

—Илтеп ат моны гариләр йортына!

—Ни сөйлисең, Ризван?! Ул бит безнең бала.

—Бу минем бала түгел! Безнең нәселдә мондый букайлар юк! Сиңа алкаш баласын тагып җибәргәннәр. Бар, кире үзләренә илтеп бир! Миңа бу утын түмәре кирәкми. Йә мин, йә ул!

—Ул да җан иясе...

—Ә мин? Мин җан иясе түгелме, мин хайванмы? Гомеребезне шул букайны көйләп үткәрикме? Аның мәңге кеше буласы юк! Тыңла сүземне, Шакирә! Мин сине кызганып әйтәм. Сайла—йә мин, йә ул!!!

Шакирә сайлады. Икесен дә. Хатынга ир, анага бала артык түгел, икесе дә тансык, икесе дә кадерле, газиз иде. Ләкин карар иргә ошамады...

—Китмә, Ризван... Ялгызым нишләрмен?! Ничек яшәрбез синсез?!

Ир дәшми, очынып-тузынып әйберләрен җыя.

—Ташлама безне, Ризван... Зинһар, китмә... Мин синсез яши алмыйм... Мин сине яратам!!! Син безгә кирәк!

—Аңлаштык инде! Җитте!

—Нишлим мин синнән башка?!

Горурлык турында уйлар чак түгел, гарип баласының, үзенең язмышы, киләчәкләре шул ир кулында. Уртак ояның нигезе дә, түбәсе дә ул чакта Ризван иде. Ул китсә, ипсез калалар.

—Ташлама безне, Ризван... Зинһар, китмә...

Бөтен сыныннан, торыш-килбәтеннән күндәмлек, табыну кычкырып торган, Ходайның үзе каршына баскандай, кулларын күкрәк турысына кушырып, яшьле күзләре, мәхәббәт тулы карашы белән иңәлеп-өметләнеп иренә төбәлгән хатынның аяк астына бер бәйләм ачкыч килеп төшә. Ишек шапылдап ябыла...

«Син—минем сулар һавам, эчәр суым, аем-кояшым»,—дип, кайчандыр Шакирәнең эзләренә басып йөргән Ризван бу йортта башка күренмәде.

Ирләр шундый ышанычсыз икән... Ирләр шундый куркак һәм көчсез икән...

Ләкин хыянәтчеләр бушлыкка китми. Аларны кемдер чакыра, көтә, җылы куенын ача. Шәһәр зур түгел, күреп тә, ишетеп тә белә Шакирә: Ризван шат күңелле яшь хатыны белән тупырдап торган ике бала үстерә.

Ә алар шулай... һаман шулай әле...

Үткәннәрне уйлап, үзеңне кызганып утырудан файда юк, тор, Шакирә, сине улың көтә. Колакка үтә сизгер ул, әнисе кайтканын белә. Ләкин

Шакирә ашыкмый. Йокының жылы, йомшак куенына кереп, оеп-изрәп киткән тәнне урыныннан кузгату үлем белән бер. Хатын, кан тамырлары бүртеп, кызарып шешенгән аякларын, чәнчешеп торган табаннарын ышкый. Бичаракайлар... Кемнәргәдер ярар өчен арып хәлдән тайган нечкә аяклар. Кошларның да аяклары нечкә... Тик аларның канатлары бар. Ходай кошларга канат биргән, ә кешеләр җирдә үрмәләргә мәҗбүр. Ник безгә дә канатлар бирмәдең, Раббым?! Канатлары булса, Шакирә бу тиклем армас иде бит.

Ул аксый-туксый залга үтте, улы яткан караватн янына килде. Зур башлы, акай күзле малай, зәңгәр уртларын күрсәтеп, бәхетле елмайды: «Ыгыгы...» Шакирә улының каз мамыгыдай йомшак чәчләреннән иркәләп, янагыннан үбеп алды. Нинди булса да, үзенеке, йөрәгеннән өзелеп төшкән кадерле җан.

—Хәзер, улым, хәзер...

Хатын баласының урын-җирен алмаштырды, боз кебек салкын аякларын, хәлсез кулларын дымлы сөлге белән сөртте, иртән пешереп калдырган ризыкларны җылытып ашатты, алма, кишер кырып бирде... Малай үзенчә нидер гөрелдәп бераз ятты да, иртәгә кабат ыңгырашып уяныр, ун ел буе күзәткән тар, кысан бүлмәне кабат күрер өчен шешенке кабаклы, зур күзләрен йомды... Кичә бүгенгә, бүген иртәгәгә охшаш, бернинди үзгәреш юк һәм булмаячак...

Бер чынаяк сөтле чәй эчкәч, Шакирә дә урынга ауды. Тик аруы баштан ашса да, йоклап китә алмыйча, байтак борсаланып ятты. Тәрәзә төбендә бөрешеп утырган теге хәерсез бәндә кабат күз алдына килеп басты, кердәле-чыктылы сүзләре колакта кат-кат яңгырады. Тәки сикердеме икән ул? Өендә бәлки бичара әнисе тилмереп көтәдер... Кысыр кайгысы аркасында чын хәсрәт үрчетеп йөрмәсә соң! Үз кадерен үзе белмичә... Аның кебек исәрләр ирекле көннән үзләренә үлем эзләп чапканда, өметсез авырулар, әрну-газапларга түзә-түзә, якты дөньяда бер генә көн, бер сәгать булса да артыграк яшәр өчен җан тырмаша...

Сөйгәненең хыянәте аркасында акылын җуйган егетне юата да, яман ниятеннән кайтара да алмады Шакирә. Әллә теләмәдеме? Әллә үзенең дә күңеле каткан, җаны үлгәнме? Китәм, дип яшәү белән үлем арасындагы кылдай нечкә сызыкка чыгып баскан кешене юлыннан борып, кабат тормыш кырына кайтару өчен кайдан көчләр аласы да, нинди сүзләр табасы?! Көчсез көчсезне, мескен мескенне юата аламы? Хәер, көчлеләрдә мескеннәр кайгысымы?! Ләкин... Кем кемне саклап, яклап бетерсен соң бу дөньяда? Чынлыкта һәр кеше ялгыз бит. Ялгыз икән, димәк, көчле булу кирәк. Димәк, бар ышаныч үзеңдә. Кешелек—ялгызлар җәмгыяте...

Үзен аклау өчен күңел төбеннән тартып чыгарылган бу уйлар да Шакирәне әлләни юата алмады, үзен-үзе гаепләү хисе җанына дегет булып ягылган иде. Әгәр икеләнгән, адашкан җан юлына Ходай нәкъ менә Шакирәне чыгарган икән, димәк, шулай кирәк булган, димәк, ул аның көченә ышанган. Упкын каршында басып торган егетне авыр мизгелендә ялгызын ташлап китеп дөрес эшләмәде Шакирә. «Китмә!!!»—дип ялваргач та китте бит... Шакирәдән дә шул сүзне көтте бугай ул. Бәлки аңа бу якта калырга, үзенең көчсезлеген акларга бер сәбәп кирәк булгандыр. Сикерәсе кеше бер сәгать буе фәлсәфә корып утырмый лабаса, тота да сикерә. Ә Шакирә аны аңламады, тынычландырасы, үгетлисе урында, ярасына тоз салып, үртәп-үчекләп китеп барды...

Төнге тынлыкны бозып, ачкычлар шылтырады, ике ишекнең дүрт йозагы кабат ачылды...

Подъездда ут бар иде.

Шакирә берничә баскыч түбән төшеп, аска күз салды. Тәрәзә киерелеп ачылган, шул бушлыктан кое төбедәй салкын күзләрен тондырып карангылык карап тора. Ә теге егет анда юк, ул каядыр киткән...

Каядыр...

Шакирә тәрәзә янына килеп, урамга үрелеп карады. Аста кин итәкләрен җәеп утырган бөдрә чәчле сирень куакларын күрде. Урамда тыныч иде. Әллә берни дә булмаган, әллә булып та узган...

Егет киткән, тау хәтле мәхәббәтеннән, йөрәк әрнүеннән котылган. Әллә тотылган... Кем белә, аннан кайтып сөйләүче юк. Үзенә кул салган гөнаһлы җаннарны бәлки мәңгелек газап көтәдер... Ә син түз, Шакирә. Йолкынып беткән җаныңны Аллаһы Тәгалә кулына ару килеш тапшыру өчен сакла... Әйтте бит мәчеттәге егет: «Гомереңне Аллаһ әмереннән башка өзсәң, җаның иблис кулына күчәр...»—диде.

Сирень исләре сеңгән салкынча дымлы һаваны сулап, ачык тәрәзә каршында шактый басып торды Шакирә. Җәйге төн серле һәм уйчан иде. Кояш офык артына югалып, җиргә карангылык ингәч, кеше күнеленә әллә нинди сәер уйлар килә башлый. Шакирә дә галәмнең төпсез күзләренә багып, фәлсәфәгә бирелеп алды: «Менә шулай... Бөтен нәрсә үзгәрә... Караңгылык белән яктылык, тормыш белән үлем гел янәшә. Ә чиксезлеккә азат җан гына очадыр. Җан ирекле булсын өчен әүвәл җирдәге бурычларны үтәп, күрәсене күреп бетерергә кирәк...»

Кинәт аңа куркыныч булып китте. Гүя урамның кайсыдыр бер ноктасыннан кемдер аны күзәтеп, сынап-тикшереп тора иде. Төн куенына яшеренгән ул билгесез затка яктылык учында басып торган Шакирә аквариумдагы балык кебек ап-ачык күренәдер. Хатын бу карашның көчен җаны-тәне белән тоеп, калтыранып куйды, караңгылык борын сузган тәрәзәдән тизрәк ерагаерга теләп, ашыга-кабалана, үз катына менеп китте.

Шулчак сул якта лифт тирбәлгән тавыш ишетелде. Җиденче катта туктап, ишекләрен ачты һәм Шакирә каршында кулына бер кочак сирень чәчәге тоткан тузган чәчле егет пәйда булды. «Бер бәхетле җанга тансык кунак килә...»—дип, үзе дә белмәгән кемнәндер көнләшеп куйды хатын. Аңа инде күптән чәчәк бүләк иткәннәре юк иде.

Әмма...

—Бу сезгә...—диде егет.

Кое төбеннән кайтаваздай бәрелә-сугыла гөбердәп чыккан бу тавыш хатынга таныш иде.

Егет, гаепле елмаеп, кулындагы сиреньнәрне Шакирәгә сузды. Аннары кире чигенеп, әле һаман кочагын ачып үзен көтеп торган «серле сандык» эченә кереп югалды. Ишекләр шаулап ябылды. Тимер читлек, егетне үз куенына яшереп, аска төшеп китте...

Ап-ак, нәфис чәчкәләрне, сабыен кочкандай, күкрәгенә назлап кыскан хатын җиңел сулап куйды: «Сикермәгән...»

Гөлзадә
Бәйрәмова

# ТЕЛӘК

—Илаһым, ялгыз картлыклар насыйп итмә, кеше кулларына карап ята торган чирләр бирмә, кадерсез көннәргә калдырма...

Фәнисә бүлмәгә килеп кергәндә карчык инде намазын тәмамлап килсә дә, эндәшергә, түргә узарга базмады. Әнисенең: «Намаз укыган кеше каршыннан үтеп-сүтеп йөрмәгез, шаулашып утырмагыз, бу вакытта фәрештәләр җиргә төшәр, теләкләр кабул булыр, теләк теләп, Амин, дип утырыгыз» дигән сүзләрен хәтеренә гомерлеккә салып куйган иде.

Әллә чынлап та бар микән соң бу Ходай? Әнә бит карчык та ничек бирелеп, ихластан ялвара. Ялгыз калганга күрә биредә бит үзе юкса, һаман: «Ялгыз картлыклар насыйп итмә», ди. Сәер... Кучтәнәчләр салынган пакетын кочаклап ишек төбендәге урындыкка чүмәшкән Фәнисә әнә шулай уйланды.

Бүген аларны картлар йортына өлкәннәр көненә бүләкләр илтеп кайтырга җибәрделәр. Дөресрәге, ул аны үзе оештырды. Ниндидер бер үзгә дөньяны күрәсе, ниндидер изге гамәл кыласы килә иде.

Матур гына җырлаучы бер-ике кызны, биюче һәм баянчы егетне алып, хәйран гына тәм-томнар төяп килделәр. Әйе, хәзер мондый җирләрдә хәйрия бүләкләрен үз кулларың белән бирә аласың, элек кенә ул ниндидер бүлмәгә куеп китәрләр иде дә, әллә барып җитә ятимнәргә, әллә юк—эчең пошып йөр аннары. Һәрхәлдә, халык арасында сүзнең төрлесе бар иде.

Гомер буе ятимлектән курыкты Фәнисә. Әти-әнисенең өлкәнәйгәч кенә туган баласы булгангамы, үлеп китәрләр дә ятим калырмын дигән шом аның күңелендә кечкенәдән үк урын алды. Кияүгә чыгып балалары тугач икенче төрлегә әйләнде: үзенең балалары ятим булмасмы? Кызы белән һава суларга чыккач балалар йорты яныннан узганда барысы да бер төсле диярлек киенгән ниндидер монсу кыяфәттә уйнап йөрүче балаларны күреп: «Үземнеке дә ятим була күрмәсен, үземә дә ятим бала бирмәсен», дип пышылдар иде. Ятим баланы багудан, ашату-эчертүдән бигрәк, аның күңелен рәнҗетүдән курка иде ул.

Ә үзенекеләрне ятим итте Ходай. Бер генә дә түгел, ике тапкыр. Теләге фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килмәде, ахры...

—Мин монда үз теләгем белән, кызым,—диде карчык кучтәнәчләргә рәхмәт әйтеп дога кылганнан соң, кунагы начар уйлап китә күрмәсен тагын дигәндәй акланган сыман итеп.—Кызым—зур, укымышлы кеше минем. Күбрәк чит илдә яши. Иремнең бик тә укытасы килде балабызны. «Укыган кеше генә түгел, укымышлы кеше булсын», ди торган иде. Шуңа да микән, үлгәндә кабаттан кияүгә чыкмавымны үтенде. Үлем ачысын җиңеләйтергә теләпме, ирең үлеп ятканда ничек итеп әле икенче иргә чыгу турында уйлап булсын, вәгъдә бирдем. Шөкер, сүземдә тордым. Ирләр бит алар хыянәтне үлгәч тә кичермиләр, кызым, ир хакы бар... Бик зур хак ул аңлаган кешегә. Тик моны күпләр аңламый гына...

Фәнисәнең йөрәген нәрсәдер чеметтереп куйды. Ир хакы... Хыянәтне

кичермиләр, кичермиләр... Әллә аңа да Салихы рәнҗеде микән?

—Биредә мин ялгыз түгел, кызым, үз ишләрем арасында. Яшьтәшләрем, язмышташлар арасында. Капкага җил кагылганга да «Кем килде икән?»,—дип ымсынып утырмыйм.—Әбекәй кунагының да тормышын беләсе килеп, карт-корыга хас кызыксыну белән сүз сөрешен Фәнисәгә борды. Ә Фәнисә исә саубуллашып, тизрәк китү ягын карады. Сөйлисе килми иде аның. Очраган бер кешегә хәлен сөйләп йөрү халәтеннән узган инде ул. Алай гына да түгел, үзе сүз башлап Идрис турында нәрсә дә булса беләсе, «бик ябыккан, шыксыз киенгән, «тегесе» бер дә карамый, ахры, үкенәдер әле» кебек сүзләрне дә ишетәсе килми инде хәзер. Эчтән генә сызарга, сызланырга өйрәнә башлаган иде инде ул.

Карчыкны да, бәхетле үк дип әйтеп булмаса да, бәхетсезләр рәтенә дә куеп булмый. Биредә булган кыска гына вакыт эчендә төрле кешеләрне күрергә өлгерде Фәнисә. Тормышка, балаларына ачулысын да, битарафларны да, язмышлары белән килешеп тыныч кына яшәүчеләрне дә... Әлеге карчык та соңгылары рәтенә керә иде кебек. Бәлки әле соңгысыннан өстенрәкләргә дәдер.

«Бер кеше күпме кешенең тормышын пыран-заран китерергә, үзгәртергә сәләтле»,—дип уйланды Фәнисә юлда кайтканда. Күңеле белән әллә кайчангы вакытларга—сугыш чорларына да китеп алды. Ә үзенең язмышында «бер кеше» ул кем соң? Ире Идрисме, үземе, дусты Ләбибәме, әллә иренең яңа хатыны Рәхимәме?

Ул вакытта Фәнисә, Ләбибә, Рәхимә—өчесе дә бер оешмада эшләделәр. И мактый да иде соң абыйсын Ләбибә! Җир йөзендә аннан булдыклы, аннан әйбәт ир-ат юк, тик менә хатыны гына дөнья җүнсезе,—ашатмый, өстен-башын карамый, хатын-кыз назын күрсәтми, имеш. Ул бу сүзләрне нишләптер уртага салып түгел, әле ярты ел элек кенә ире үлеп, ике кечкенә кызы белән тол калган Фәнисә ягына карап сөйли иде. Ял көннәрендә, гел хәсрәт белән генә яшәргә ярамый, бераз ял итеп китәрсең дип авылга, әниләренә дә чакыра башлады дусты. Шундый кайтуларының берсендә күрде Фәнисә Идрисне. Кешеләрне хәсрәт тә якынайта икән. Бу очракта хәсрәт—ялгызлык иде. Сүзне кем сөйләсә—шуныкы дөрес, дигәндәй Фәнисә дә ышанды Ләбибә сөйләгәннәргә, хатынын күреп тә, ишетеп тә белмәгәч, күңеле белән Идрисне яклады, «ярамаслык ир түгел бит, әллә чынлап та хатыны кадерен белеп бетермәде микән соң»,—дип уйлаштыра иде.

Идрис исә хатынын әлләни мактамады да, яманламады да.

—Булган—беткән. Арада җылылык юк иде,—диюдән узмады, бер сөйләшеп утыруларында. Фәнисә моны үзенчә яхшыга юрады. Кайбер ирләр кебек хатын яманлап, узган тормышын ямьсезләп сөйләп йөрми. Күп сүзле ирләрне җене сөйми иде аның.

Хәер, абыйсыннан бигрәк үзе өчен тырышмады микән әле Ләбибә. Хатыныннан аерылгач үзләрендә бер-ике ай гына яшәгән «әйбәт» абыйсын көйләп, юып-пешереп ара башлаган иде ул. Тизрәк кемгә дә булса «төртергә» кирәк. Нигә интегергә тиеш әле ул аның белән? Туган дигәч тә... Ире дә гел тавыш чыгарырга сәбәп итә башлады. Үз тормышының да рәте-чираты юк, бөтенләй ямьсезләнешеп бетәрләр. Әнә, күпме фатирлы ялгыз хатын-кыз! Үзенең дус хатыннары арасында гына да буа буарлык. Берсе белән барып чыкмаса, икенчесен табар...

Ләбибәнең тырышуы җилгә очмады. Фәнисәне абыйсына чыгарга күндерә алды. Фәнисә үзе дә әлләни озак үгетләтеп маташмады, ахры. Бу тотрыксыз илдә ике бала белән таянырлык терәксез яшәүнең җиңел булмасын белә иде ул. Тотрыксыз илнең ирләре дә тотрыксыз булуын гына чамалап

бетермәгән булып чыкты.

«Кеше бәхетсезлегендә бәхет корып булмый»,—дисәләр дә Фәнисә бит кеше ирен тартып алмады, гаиләсен бозмады, ир кеше ялгыз яши алмый, барыбер кемгә булса да өйләнәчәк, өстәвенә ана кадәр үк законлы аерылганнар—Фәнисә үзен шулай юатты. Алай да әнисе белән кинәшләшеп карыйсы итте. "Икенче ир ямаулык кына ул, кызым. Ходайдан насыйп ярын, газиз балаларын ташлаганны сезне ташламас микән сон?" Әнисенең җавабы кыска иде. Аналар алдан сизүчән шул...

Ни хикмәт, кызлары бик тиз үз итте Идрисне, башка гаиләләрдә була торган «үги әти», «синең кызларың»,—дип сөйләшүләр, кагырга тырышулар булмады.

•••

Тормышы күзгә күренеп алга китте Фәнисәнең. Бәйрәме—бәйрәмчә, төне—төнчә, көне—көнчә иде хәзер. Яшьләре өлкәнәюгә таба баруга карамастан туган уртак баланы да: «шулай тиеш булгандыр», дип тыныч кына кабул иттеләр, яхшыга юрадылар.

Фәнисәгә йортка килеп кергәнен юкка чыгарасы килепме, мөмкинлек чыкканга сөенепме, көннәрдән бер көнне Идрис өй салу турында сүз кузгатты. Каршы киләме соң инде Фәнисә! Авыл баласы бит ул, эш кешесе, җир кешесе. Монысын кызларына бүлеп бирерләр—үз әтиләре алган фатир, өйне исә зур итеп, ашыкмыйча салырлар, оныклар белән яшәрлек итеп.

Идрис акчаны начар эшләмәсә дә күп эшне үз көчләре белән башкардылар. Бигрәк тә Фәнисәнең туганнары булышты. «Йә ашарга пешерерсең, Илшатка да күз-колак булырсың»,—дип Рәхимәне дә чакыргалый иде әле. Их, чакырмаган гына булсачы! Йокламаса—йокламасын, ашамаса-ашамасын, үзе өлгергән булыр иде әле.

Өй салу берничә елга сузылса-сузылды—максатка ирешелде. Тирә-күршенекеннән ким түгел, кайбер яклары белән бәлки әле артыграк та булган менә дигән өй җиткерелде.

...Өй урынын карарга килгән көннәрен мәңге онытасы юк Фәнисәнең. Яшел чирәмдә уйланып, бер-берсенә сыенышып, киләчәк турында хыялланып озак утырдылар... Эңгер-меңгер җитеп, җиргә карангылык—төн инә башлаган иде.

—Бу өйнең нигезе безнең мәхәббәткә корылсын,—диде Идрис пышылдап кына... Иң татлы, иң рәхәт, иң бәхетле яратышу кебек тоелды ул Фәнисәгә. Йорт тирәсендә эшләп йөргәндә дә әлеге серле төнне исенә төшереп елмаер иде...

...Шаулатып-гөрләтеп чираттагы Яңа елларның берсен каршы алырга җыелдылар. Җәйгә яңа өйгә дә күчәсе булгач, бу Яңа ел ничектер фатир белән, монда узган тормыш белән саубуллашу кебегрәк килеп чыкты. Бигрәк тә Идрис очынды. Сүзендә өе белән мактану да, горурлану да бар иде. Кунакларны сыйлау белән мәш килгән Фәнисә хәвеф якынлашканын сизмәде дә...

Биреп тә күрсәтә соң хөкүмәт хәзер ялларны! Элек кешеләр әти-әниләренең хәлен белеп, бәрәңге казып, утын ярып килер өчен өстәмә эш сәгатьләре алып эшләсәләр хәзер исә ялны мәҗбүри бирәләр. Ял итә-итә хәтта арып бетәсең.

—Авылга кайтып киләм әле,—диде Идрис Яңа еллар каршылап берничә көн узгач,—өйдә аунап ятып та туйдым.—Фәнисә каршы килмәде. Күчтәнәчләр төяп, тизрәк исән-сау кайтуын теләп озатып калды.

Тик кайтмады Идрис. Исәнлеккә исән иде үзе...

«Әти-әнисе янында озаграк торырга теләгәндер»,—дип баштарак үзен тыныч тотарга тырышты Фәнисә. Ахырда, түземлеге бетә башлагач, күп хатын-кызларга хас булганча эчен бушатыр өчен дусты Рәхимәгә шалтыратты. Рәхимә исә үз чиратында аны юату сүзләре белән күмеп ташлады, Илшатның бит беренче кышкы каникулы дип, үзләренә кунакка чакырды. Баласын Рәхимәләргә озаткач әлеге коточкыч хәбәрне аңа улы Илшат кайтып әйтер дип ничекләр уйлый алсын икән Фәнисә!

—Әни,—диде Илшат, кайткач,—безнең әти хәзер Рәхимә апаларда яшәячәк икән...

Бу хәбәрнең мәгънәсен аңлый алмыйча улына озак карап торды Фәнисә. Ничек инде... Яшәячәк?.. Улы үзе дә бу сүзне әлләни аңлап әйтми иде кебек.

—Булмаганны,—диде Фәнисә,—дөрес аңламагансындыр, улым. Общежитиенең кеп-кечкенә бүлмәсендә үзләре дә чак сыялар, аннан соң нишләп әле әтиең аларда яшәргә тиеш?

—Әти үзе шулай диде,—Илшат бу юлы әтисенең сүзен дәлил итеп китереп.—Безгә килеп йөрерсен, диде.

—Нәрсә була соң бу?—дип уйлады бераз аңына килә башлаган Фәнисә,—бу ни соң? Моңарчы берни дә сизмәде микәнни? Ире белән Рәхимә очрашып йөрделәр микәнни? Нигә? Ни өчен? Алар әйбәт яшәделәр бит. Булмас, кеше турында начар уйлап өстенә гөнаһ алу бу. Алай дисәң, тора салып кеше өенә барып яши башлап та булмый бит. Бала ялгыша булыр, йә шаярткannardыр... Әле кайчан гына бер мәҗлестә ирләрнең хатыннардан китүе турында сүз чыккач:

—Минекеме? Бөтен хатыннардан ирләре китеп бетсә дә минем Идрисем миннән китмәячәк,—дип шапырынган иде Фәнисә. Ул моны шул кадәр ышанып әйткән иде. Зур ышаныч белән, эчке ышаныч белән. Йә Ходам, бер генә хәлне дә бу хәл минем белән булмас дип әйтмә икән...

Кайсыдыр берсе:

—Ирләр алар күчмә кызыл байрак кебек—бүген синдә, иртәгә миндә,—дигәч, дәррәү кычкырып көлгәннәр дә иде әле. Алай да Рәхимәгә шалтыратып карыйсы, улының сүзләрен ачыклыйсы итте Фәнисә. Бала гына бит әле, бәлки, нәрсәне дә булса аңлап та житкермәгәндер.

Трубканы Рәхимә үзе алды. Сөйләшүгә алдан ук әзерләнеп куйган, күрәсең, сүз эзләп интекмәде, каушап та калмады.

—Нигә син генә чит ил машинасында йөрергә, ике катлы шәп өйдә яшәргә тиеш тә, мин тулай торакта интегергә тиеш әле?—диде ул кабаланып, тизрәк әйтеп калырга ашыгып.—Балаларымның киләчәген мин кайгыртмасам, кем кайгыртыр? Бу кечкенә генә бүлмәгә ничек хатын алып кайтсыннар алар?

Идрис өйдә юк иде, күрәсең, Рәхимәнең шактый иркен сөйләшүеннән шулай аңлашыла иде.

—Ул бит минем ирем,—диде Фәнисә чак-көч тын алып,—үзенә шундыйны табарга иде...

—Менә таптым бит инде, кичә синеке иде, бүген—минеке. Шуңа күрә әйтәләр бит, ирләргә ышанма, Иделгә таянма, дип, дөнья түгәрәк бит ул, дустым, үзенә дә кемнәндер килде.

—Безнең бит балабыз бар...

—Безнеке дә булыр. Икене тапканны өченчесен генә табармын. Орлыгы Бохарада түгел, үзебездә генә,—диде хатын астыртын көлеп.

Фәнисәнең бүтән әйтер сүзе дә, ишетәсе килгәне дә юк иде. Ул хәтта—«Идрисне чакыр әле, үзе белән сөйләшим әле»,—дип тә әйтә алмады.

«Бәхет өчен көрәшергә кирәк»,—диләр дә бит, тик ничек итеп? Рәхимәнең ишек төбенә барып егылсынмы? Мәңге бармаячак. Эшенә барып хуҗаларына зарлансынмы? Заманы ул түгел. Күпчелек очракта әле хатын-кызның үзен гаеплиләр, җүнле хатыннан ир китми, янәсе. Кайчандыр Идриснең беренче хатыны турында Фәнисә үзе дә шулайрак уйламадымыни? Дөнья—куласа дигәннәре шушыдыр, күрәсең.

* * *

Мәхәббәтне—нәфрәт, өметне—өметсезлек, сагынуны—ачу алыштыра башлады. Еламыйм, дисәң дә елата, уйламыйм, дисәң дә уйлата шул. Җыр тыңлыйм дисәң—җырлары гел сагыш-сагынудан тора, кешеләр белән аралашыйм дисәң—хатын-кызның сөйләшүе күп вакыт үткән тормыш хакында. Иң кыены ял көннәрендә иде. Иң кыены төннәрен иде. Серле дә, шомлы да, күпме хатын-кызның күз яшьләрен сыйдырган, юатучы да, елатучы да булган төннәр! Сезгә тагын бер ялгыз, кимсетелгән, рәнҗетелгән бәхетсез җан өстәлде. Мәрхәмәтле булыгыз анарга! Көч һәм сабырлык, өмет һәм ышаныч өстәгез!

Ял көннәрендә беркая чыкмас булды Фәнисә. Юган булыр, пешеренгән булыр, ә күңелендә: «Идрис килер дә күрми калырмын, шалтыратыр—туры килмәм», дигән уй иде. Үзләре өйдә юк чакта шалтыратса дип яздырып калдыра торган телефон алып кайтып куйды, аның да әле шнурсызын—трубка гына, төнлә шалтыратса килеп җитә алмам дип янына куеп ятар иде, өйгә килеп керүгә иң беренче эш итеп телефонны карар иде.

Бер көнне эштән кайтып кергәндә улы Илшатның ашыга-ашыга киенеп маташуына тап булды Фәнисә.

—Хәзер әти килә,—диде Илшат,—тау шуарга алып бара.

Атыла-бәрелә чыгып чапкан малаеның өстендә юка куртка булуын бераздан гына чамалаган Фәнисә улы артыннан ташланды. Тау шуу белән мавыгып, бигрәк тә әтисе белән очрашу шатлыгыннан онытылып китеп суык тидереп кайтсын тагын. Утыр аннары ачка койрык чәнчеп. Болай да көч-хәл белән җиткерә.

Подъезд ишегеннән кулына куртка тоткан хатынын күрүгә Идрис кар бураннары туздырып алга ыргылды. Машина артыннан чанасына абына-сөртенә: «Әти, әти!»—дип кычкырып Илшат йөгерә иде.

—Син генә гаепле, син чыкмасаң әти китми иде, син генә гаепле!

Үкси-үкси, тәгәри-тәгәри елаган улын юатырга сүзләр таба алмады Фәнисә, аңа кушылып елый гына алды.

* * *

Үзенең көтү-сагынулары, рәнҗеш-үпкәләре белән мәңге узмас кебек тоелган озын кышлар да үтеп китте. Тик кыш кына узды шул. Ә көтү, көтәсе килү, күрәсе килү бары тик башка төсмер генә алды. Табигатьнең үзе кебек, күңелдәге яра да ел фасылына карап йә төссезләнеп китә, йә киресенчә тагы да ачык төсләргә маныла. Кайчак килеп чыккан хәл белән килешеп, «Язмыштыр», дип уйласаң, икенче бер вакыт «Нигә?», «Ни өчен?» дигән уй өскә чыга. «Оныттым», дип әйтү генә җиңел. Яраткан кешеңне оныту—үткән тормышыңны, үзеңне онытуга тиң бит ул. Аны хәтерләтеп торучы уртак бала булганда—бигрәк тә. Акылы сау, тәне сәламәт кешегә бу мөмкин эш түгел.

Кыш буе яшерен бер өмет яшәде Фәнисәнең күнелендә. Язлар житеп, яна өйләренә баргач Идрис уйланыр, үкенер, акылына килер дип. Ни генә әйтсән дә ул өйнең нигезе аларның мәхәббәтенә корылган бит.

Шимбә көн. Идрис анда булырга тиеш. Мондый матур көнне кыпкысан бүлмәдә ятмас. Күрешерләр, сөйләшерләр, аңлашырлар. Кайчандыр бер тында сулыш алып, керфекләр—керфеккә, иреннәр—иренгә тиеп яткан кешеләр ничек инде сөйләшәсе дә килмәс дәрәҗәдә дошман булып яшәргә тиеш ди. Кияүгә бит аерылып үзенә дошман арттыру өчен чыкмыйсың лабаса!

Идрис барында машинада тиз тоелган араны җәяүләп бара торгач инде караңгы да төшә башлады. Көннәр озыная төшкән булса да һәрнәрсәнең үз вакыты бар, өйләрдә утлар алынып, кичке вакыт якынлаша иде. Фәнисә дә үзләренең өйләрендә ут күреп сөенеп куйды. Йөрәк урыныннан кубып колак төбендә үк каккан кебек. Нәрсә әйтер? «Кайт»,—диярме? Киресенчә үзе әле: «Кайттым мин»,—дип килеп керерме... Тегесе дә аның өе, монысы да анык бит. Кем кайткан да, кем киткән—нигә катлауландырып торырга. Бәлки әле аңлашып тору кирәк тә булмас. Бәлки әле Идрис үзе дә шушы уйлар белән яшидер? Көтәдер. Бер дә уйланмый калмас...

Язгы кичке һава керсенгә тәрәзәләр ачылып куелган. Кухня пәрдәләре үтә күренмәле икән, хәзергә ярап торыр, яши башлагач алыштырырмын дип нәрсә бар шуны элгән иде. Өй эче ачык шәйләнә. «Бусагада туктамыйча түргә узма»,—диләр халыкта. Бераз тын алып, тынычланып алырга кирәк. Өлгерер. Иң мөһиме килде. Идрис тә бирсде.

Ачык тәрәзәдән җыр-музыка ишетелеп китә. Бер адым... тагын бер адым һәм кулы ишек тоткасында... Шулчак таныш шәүләләр күреп Фәнисә катып калды. Идрис үзе генә түгел иде. Йә, Хода! Аның яратып алган өй җиһазлары, савыт-сабаларына хәзер кемдер хуҗа булып, аның ире белән аның өендә... Бер хезмәте, бер көче кермәгән килеш!..

—Мин бит кешенекен тартып алмадым! Ирен дә, өен дә! Нигә минекен алдылар?!

Узып китүче машина эчендәге кешеләр чәче-башы тузгыган, шашкан кыяфәтле кыр буйлап чабулап йөрүче хатынның сүзләрен ачык кына аңламасалар да үз-үзен тотышына карап саташып-адашып йөрүче дип уйлый алалар иде. Сынды Фәнисә. Арыды. Көчле булып, сер бирмәскә тырышып, көтеп арыды. Аяклары тотмас булып, каралып килүче ак кар өстенә сыны катып сыгылып төште. Аңа хәзер барыбер иде.

***

Ни кадәр генә заманны сүксәк, кешеләрне каты бәгырьлелектә гаепләсәк тә дөнья гел начар кешеләрдән генә тормый. Аның юлында да яхшы кешеләр очрарга насыйп булган. Кич йөрергә чыккан егет белән кыз машина белән хастаханәгә илтмәгән булсалар, Фәнисә дә өшепме, үпкәсенә суык тиепме якты дөнья белән хушлашкан булыр иде. Психик авырулар хастаханәсенә керү бәрабәренә булса да исән калды.

...Аңына килгәч тә беркавым үзе белән нәрсә булганын, кайда ятканын аңыша алмыйчарак торды Фәнисә. Өй дисәң—өйгә охшамаган, хастаханә дисәң, тәрәзәдә рәшәткәләр, озын коридор башындагы ишекне ак халатлы кешеләр ачып керәләр, бикләп чыгалар. Гел хатын-кызлардан торган бу бүлмәдә ниндидер моңарчы күрелмәгән хәрәкәтләр бара. Кемдер кычкырып җырлый, кемдер кычкырып көлә, кемдер исә мендәрен бала рәвешенә китереп төргән, яулык бәйләткән дә имезгән кыяфәт чыгарып утыра.

Ниһаять Фәнисә кайда килеп эләккәнсн чамалый, һәм алдагы көннәрдә үзе белән нәрсәләр булганын исенә төшерә алырлык хәлгә килә башлады. Ни хикмәт—курыкмады.

Үзенә таба килүче ак халатлы ханымны күргәч Фәнисә чәчләрен төзәтеп, итәкләрен рәтләп караваты кырына җайлабрак торып утырды.

—Уяндыгызмы? Үзегезне ничек хис итәсез?

—Мин ничек биредә? Бу бит ялгышмасам...

—Әйе,—диде ак халатлы ханым,—сез больницада. Тик сезнең янығызда бернинди кәгазьләрегез-документларыгыз юк иде, безгә кайбер әйберләрне ачыклап, теркәп куярга кирәк,—дип, Фәнисәне үзе белән чакырды.

Үзенең бөтен тормышын—шатлыгын-кайгысын, ниләр булганын, ниләр кичергәнен—беренче ире үлеп ике бала белән тол калганын, икенче ире башка берәүгә китеп инде тагын ялгыз калганын—барсын-барсын сабый чакта мәктәптән кайткач әнисенә сөйләгән кебек сөйләде дә сөйләде Фәнисә.

Дәвалаучы табибә Зәйтүнә Әсгатовнага таныш хәлләр иде болар. Фәнисәнең хәләте аңа үзенеке белән аваздаш кебек тоелды. Ул да кичерде бит хыянәтне. Бәлки әле шушында эшләмәсә, бу хәлгә тарыган кешеләр белән көн дә очрашып тормаса, кем белә, үзе дә шушы хәлдә булмас иде микән! Ләкин ул аңарга бу турыда сөйли алмый иде, юкса аның каршында дәвалаучы табиб буларак көчен җуеп, гап-гади бер хатын-кызга әйләнеп калыр иде.

—Син уйларың белән аны һаман үзеңә бәйләп тотасың, шуңа да оныта алмыйсың. Җибәр син аны. Бөтен яратуыңны улыңа бир, кызларың белән яшә. Син бит ялгыз түгел.

—Бала ирне алыштыра алмый. Хәтерләтә генә ала,—диде Фәнисә. Аның әле тагын: «Әйтү җиңел ул. Сезгәме соң, мине аңлау! Үзегезне әле эшкә ирегез машина белән йөртәдер, кышкы ялны коньяк җылысында кызынып ятып уздырасыздыр, акчасызлыкның да ни икәнен белмисездер»,—дип тә әйтәсе килгән иде дә, тыелып калды, һәрбер әйткән сүзең монда синең файдага булмаска мөмкин.

Зәйтүнә Әсгатовна үзенең авыруларына сак карарга тырыша. Төшенкелеккә бирелеп йөргән кешеләр дә монда килеп эләгергә мөмкин. Тик авыру үзе теләмәсә, үзе ачылмаса никадәр генә тырышсаң да аның эчке дөньясына үтеп керә алмыйсың. Дару-уколлар нәрсә ул! Иң мөһиме—күңел савыксын. Күңелгә шом кереп урнашырга юл калмасын. Үз-үзенә ышаныч булсын. Бәхетнең дә, бәхетсезлекнең дә күп очракта үзебездән торганлыгын, кемдер килер дә мине бәхетле итәр дип яшәмәскә кирәген, үзеннән үзең нык булырга тиешлеген аңлатырга тырыша Зәйтүнә Әсгатовна авыруларына.

—Бәхет капкалары күп булыр. Берсе ябылса икенчесе ачылыр. Ябылганына озак карап торырга ярамый, яңа ачылганын күрми калуың бар—бу Зәйтүнә Әсгатовнаның кайдандыр укыган, авырулар белән сөйләшкәндә генә түгел, инде үзе өчен дә яратып куллана торган канатлы сүзләре иде.

•••

Күпкә тынычланып, савыгып кайтты Фәнисә хастаханәдән. Уйлар да үзләреннән-үзләре таралды диярлек. Кызлары килеп, очрашып торгач, өйдәге тормышы, улы өчен дә ул кадәр борчылмады. Организмны ныгытучы, нервларны тынычландыручы уколлардан да баш тартмады, алдагы тормышы өчен сабак булырлык гыйбрәтле хәлләр дә күреп чыкты. Шөкер, эшендә

дә «тегендә ятып чыккан»,—дип йөз чөермәделәр, ничек эшләсә—шулай дәвам итте. Өендә дә эш белән, күбрәк улы белән мәшгуль булырга тырышты. Кулда эш булганда юк-бар уйга урын калмый. Улына да үзенең тарафыннан игътибар җитмәүдән никадәр кыен булганлыгын хәзер генә аңлады. Бәлки әле Ходай аны Идрис белән нәкъ менә шушы бала тусын өчен очраштырган-кавыштыргандыр?.. Бәлки әле аның бәхете алдагы көнендә нәкъ менә шушы баладандыр... Бәлки әле улы әтисеннән дә уздырып тагын да шәбрәк итеп өй салыр да Фәнисә ул өйнең түрендә генә кадерле әни, кадерле дәү әни булып яшәр... Булмас димә, дөнья бу!

...Мәктәпләрдә укулар башланырга да күп вакыт калмаган. Бушрак чакта кайбер әйберләрен караштырып куярга кирәк. Кызларына рәхәт, апалы-сеңелле үзләре дә барып ала алалар.

Кичен, узган елгы мәктәп киемнәрен барлап—нәрсәләрне янартырга кирәклеген сөйләшеп утырганда сүз уңаеннан гына әйтелгән сымак итеп улы сорап куймасынмы!

—Әни, менә хәзер әти кайтып керсә ни дияр идең?

Бәгырь түрендәге төер үзен сиздереп, төзәлә башлаган яра сулкылдап куйды. Юк икән, үзеңнән качып котылып булмый икән. Алар бала вакытта уйный торган «Аптыратыйммы, тинтерәтимме?» уенына охшаган иде бу сорау. «Әйе», димә, «юк», димә—акка-карага тимә» дип башлана ул уен.

Үткәнгә кагылма, алдагысына кизәнмә. «Әйе», дияргә дә ярамый, «юк», дияргә дә. Ә улы аннан җавап көтә. Соңгы вакытларда үзенең күргән-кичергәннәре аша туган бер генә уен әйтә алды Фәнисә:

—Кадерсез көннәргә калдырма...

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**



Эльвира
Һадиева

## ҺӘМ МӘҢГЕЛЕК ТӘМЕ—ГАДИЛЕКТӘ...

### Яшеренгән

**Яргаланып беткән хәтер—**
**Йөзләр анда,**
**Тик күз һәм... йөзләре—онытылган.**

**Кемдер мыштым гына әйтер:**
**«Йөрәгеңдә, ахры,**
**Миңа урын булмас?» Оныт—тулган!**

**Пошынып та талган күңел,**
**Яшьле күңел**
**Яшеренгән керфек асларына.**

**Дөньям ябык, шакымагыз,**
**Бүген никтер**
**Тирә-юньдә ач җан, бары ачлар гына...**

### Бүтән

**Тагын күпме сорау?—**
**Дәшми көтәм.**
**Йөрәгем дә шул ук,**
**Хыял бүтән...**

**Туфан куркытмый ла—**
**Терәгем бар...**
**Моңым ташый, аңа—**
**Күкрәгем тар...**

**Тагын күпме вәгъдә?—**
**Түзәм, көтәм.**
**Йөрәгемдә—Кояш, ә син...**
**Ә син читтә.**

Эльвира ҺАДИЕВА—*яшь шагыйрә; шигырьләре көндәлек матбугатта, шулай ук «Казан утлары»нда басылып килде. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты факультеты студенты.*

***

Онтылырга вәгъдә биргән ярым,
Сукмагыма нигә чыгасың?..
Син—төннәрдә адашырга язган
Сөюемнең соңгы догасы.

## Әфсен

Күзләр түгел, инде ак кыш булган...
Ул чакларда җанга моң наз катыш тулган.

Әрнер әле җәрәхәтләр, вакыт узсын—
Өметләнеп кенә саташылган.

Хискә кирәкмени нәфрәт угы:
Бу әфсенем йөрәгеңә, тоям, йогыр...

Син китәрсең... кыюлык һәм шифа сорап,
Җан-бишектә калыр шигырь-угыл.

***

Бушады әрнүдән ярсыган болыт та,
Яфраклар битендә яшь калды.
Арынган күккә дә тыныч төн юк, имеш,
Офыкны кытыклый таң, калкып.

Сукмакка үрелгән каеннар күрсенә,
Кизәнеп вакытсыз юлчыга...
Шул каен кызыдай тетрәнгән мизгелем,
Беразга, үтенәм, борчыма...

## Үзгәреш

Дерелдәп куямы болытлар?—
Күз салган сукмактан кар ага...
Оныттым, дисең... Тик, төбәлгән
Үкенеч-укларың ярага.

Кабаттан, тоямын, бу кышлар
Ирешсә кол хисен чыгарыр.
Тезләнмә, кирәкмәс кимсенү,
Мин шул ук, ә йөрәк—югары!

## Ирекле

Яңа гына шыткан гасыр учта яна,
Һәм мәңгелек тәме тама гадилектән.
Югалтасың әкрен-әкрен барын икән:
Читлегеңдә калам, дөнья, җан—ирекә...

Төшкә килеп йөрү инде кирәкмәстер,
Моңсызлардай каты булыйк, йот яшьләрең!
Раббың гына сыендырыр җаннан купкан
Бер кирәксез җырның, беләм, мең яшәрен...



# Ләйсән Фәтхетдинова

## Булыр

*Ат та булыр, тун да булыр—без булмабыз.*

М. Акмулла

**Киенергә тун кирәк.**
**Берәү түгел, ун кирәк!**
**Ә аны элергә—чөй!**
**Чөй кадаклар өчен—өй!**
**Шәл бәйли башларга—җөй,**
**Тавышсыз җырчыга—көй...**
**Мактанырга тун кирәк,**
**Алып булса, ун кирәк!**

**Хәерчегә җан кирәк,**
**Акчалыга дан кирәк.**
**Чирле өчен—сау йөрәк,**
**Ялгыз елгага—тирәк...**
**Хәле барга—эш кирәк,**
**Байга алтын теш кирәк.**
**Биргәннән баш тартучы,**
**«Мә!» диючесе сирәк...**

**...Килер бер көн—киләчәк,**
**Ходай барсын бирәчәк!**
**Башкасы кирәк бит, дип**
**Акылсызлар көләчәк!**
**Байлык, диеп сулмагыз...**
**Бар да булыр, барсы да—**
**Без генә тик булмабыз...**

## Күкләрне кочамын

**Җирләрне гизәмен,**
**Галәмгә очамын.**
**Күңелем канатлы—**
**Җиһанны кочамын.**

**Айларны гизәмен,**
**Йолдызлар күзлимен.**
**Кешеләр җанында**
**Яктылык эзлимен.**

**Күкләрне гизәмен,**
**Диңгездә йөзәмен.**
**Киләсе дулкынның**
**Шаулавын сизәмен.**

**Кош булып очамын,**
**Күкләрне кочамын.**
**...Күңелең киң булса,**
**Киң булыр кочагың.**

## Кешеме ул?

**Үз иленнән көлгән кеше—кешеме ул?**
**Диннән көлү—аңлы адәм эшеме ул?**
**Үз дустыннан көлгән кеше—җанлымы ул?**
**(Кеше була белгән кеше калдымы ул?)**

---

Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА—*яшь шагыйрә; шигырьләре көндәлек матбугатта басылып килә. Балык Бистәсе районы Котлы Бөкәш мәктәбенең 11 сыйныф укучысы.*

Үз гаебен аңламаган—аңлымы ул?
Мактанырга һәвәс кеше—данлымы ул?
Мохтаҗларга ярдәм итмәс—канлымы ул?
Кеше исеменә лаек калдымы ул?

Гомеренең кадерен белмәс—яшиме ул?
Уңга диеп, сулга атлый—яшьниме ул?
Рәхмәт сүзен өйрәнмәгән—ул йөрәксез...
Кеше түгел кеше җирдә—ул кирәксез...

## Бәхет, диләр...

Бәхет диләр, бәрхет диләр,
Диңгезләрдә гиздерә...
Бәхетне аңлый белмәсәң,
Бәхет тә бит биздерә...

Бәхет, диләр, байлык, диләр,
Бәхет, диләр, саулык ул.
Әгәр кадерен белмәсәң,
Бәхет тә бер айлык ул.

Бәхет, диләр, кояш, диләр,
Бәхет—тормыш кояшы.
Күңел күзе күрми икән,
Андыйга соң—ни яхшы?

Бәхет, диләр, урман, диләр.
Кемгә чәчәк, кемгә чүп.
Бер елмаерлык бәхет тә
Кемгә бик аз, кемгә күп.

Бәхет, диләр, бәхет, диләр,
Бәхет—яшәү тамыры...
Тамырларың ныкмы әле,
Әй син, туфрак камыры!—
Кеше...

## Үреләм

Җанымны алсаң да, ризамын,
Гомерем өзсәң дә, карышмыйм!
Син сипкән туфракта тишелгән,
Син чәчкән бөртекле арыш мин...

Тормышым киссәң дә, ризамын,
Сынавың үтәргә карышмыйм.
Мин яшим, мин торам, йөгерәм...
Чапсам да, әлегә ярышмыйм...

Адымым сүтсәң дә, ризамын,
Юлымны өзсәң дә карышмыйм.
Җиреңне яраттым, йә Ходам!
Мин аңа үреләм—ябышмыйм...

...Тик яшәт син безне, әлегә!
...Карадан аклыкны табышыйм!
Җиреңә гашыйкмын, гомергә...
Юләргә, юк ла, мин сабышмыйм.

Син яшәтче безне, Ходаем,
Гомерне вакытсыз ваклама...
Иң изге хыяллар-теләкләр
Алдагы көнгә, дип саклана...

# ХӘРӘКӘТТӘ—БӘРӘКӘТ



«Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Равил ФӘЙЗУЛЛИНның** «Идел-Пресс» басмаханәсе генераль директоры **Ислам ӘХМӘТҖАНОВ** белән әңгәмәсе.

**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** *Хөрмәтле Ислам әфәнде! Хәтерлисездер, 1997 елны, ягъни моннан 11 ел элек матбугатыбыз хәлләре турында әңгәмәләшкән идек, һәм ул әңгәмә журналыбызда матур итеп басылып та чыкты. Сез ул елларда Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министры идегез. Хәзер сез «Идел-Пресс» ААЖнең генераль директоры. Һәр вазифаның үз авырлыгы, үз җаваплылыгы. Мина калса, хәзерге эшегез зурлыгы һәм җаваплылыгы ягыннан элеккегесеннән һич тә ким түгел. Бәлки, артыгракстыр да әле. Сез— Китап дигән зур дөньяның безнең республикадагы короле. «Идел-пресс» полиграфия һәм нәшрият комплексының эшчәнлеге турында укучыларыбызга беркадәр мәгълүмат бирсәгез икән.*

**И. ӘХМӘТҖАНОВ.** "Идел-Пресс" исемен ишеткәч кызык булып китте әле. Чит калалардагы заказчыларыбызның бөтенесе диярлек безне "Идеал-Пресс" дип йөртә, хатларга да шулай язалар. Үпкәләмибез, киресенчә, "Идеал" булырга язсын дигән өмет белән яшибез.

"Идел-Пресс" СССР таркалганчы ук илдәге иң дәү ун нәшрият исемлегендә йөрде. Ә бүгенге "Идел-Пресс"—120 (!) исемдәге гәҗит-журнал, ел саен 9—10 миллионлап китап дигән сүз. Альбом, буклет, дәфтәр ишеләренең исәбе-хисабы да юк. Болайрак әйтеп ялгыштым кебек, өреп тутырылган саннар белән мавыкканыбыз юк анысы, һәр нәрсәнең исәбе дә бар, хисабы да... Юлыбызның дагалы икәнлегенә ишарә рәвешендә бер сан: көн саен 2 миллион сумга якын бәрабәр рухи азык "пешерәбез". Үткән ел 408 миллион сумга җиткән. Чамалыймсыз, начар сан түгел бу! Җитмәсә ел саен 25—30 миллион өстәлеп бара. Төп партнерларыбыз кемнәрме? Иң әүвәл үзебезнекеләрне—Татарстан китап нәшрияты белән "Мәгариф" нәшриятын атап узарга тиешмен. Мәскәүдәге 22 нәшрият әзерләгән китапларда "Казанда басылды" дигән мөһерне күрергә мөмкин. Екатеринбургтагы, Башкортстан, Самарадагы коллегаларыбыз белән мөнәсәбәтләребез нык. Якут телендәге әлифбаны да басабыз, чечен китаплары да безгә ят түгел. Бездә эшләүчеләрнең һәркайсы уч төбендә йөртерлек кеше, зат-пирут йөреп чалбар

туздыручылар бөтенләй юк. Алар булдыклылыгы белән предприятие бәрәкәтле үзгәрешләр кичерә—яңа җиһазлар ала, полиграфистлар әзерли (югары белемле полиграфистларның житешмәве элек-электән булган проблемалар арасында иң теңкәгә тигәне), туасы көннәр хакына фикри җегәр туплый...

Ибен-җаен белеп эшләгән хезмәт кешесенең мәнфәгате һәрчак үзәктә булды. Бүгенгә айлык уртача эш хакы 13 мең 679 сум. Ел ахырына кадәр аның тагын берәр меңгә артачагына һич шигем юк. Әбәтләп алу өчен көн саен утызар сум акча бирелә. Үзебезнең врач, шәфкать туташлары бар. Телисең икән, спорт залында шөгыльлән! Эшкә автобус китерә, автобус кайтарып куя. Һәр җирдә чәчәкләр, ял итә торган бүлмәләрдә аквариум, тутый кошлар... Җан кайнарлыгын салып эшләгәннәргә әйтелгәннәр аз, бик аз әле. Эш кешесе бернәрсәдә дә мохтаҗлык күрергә тиеш түгел—бу безнең өчен доминант идея.

**Р.Ф.** *Илкүләм эзлекле гомумбер идеология булмаса да, рух дөньясы инерт халәт кичерми. Без теләгәнчәме, юкмы, тормыш барыбер дәвам итә. Әнгәмәләшкәннән соң үткән еллар эчендә яшәвебездәге вәзгыять нык үзгәрде. Язучыларның хезмәт нәтиҗәсе булган әдәби әсәрләргә (бу очракта аны китап дип атыйк) дә мөнәсәбәт үзгәрде. Китапны хәзер дә Галиҗәнап Китап дия алабызмы? Сезнеңчә, җәмгыять тормышында Китапның роле ничегрәк хәзер? Бәһасез хәзинәме ул, әллә беренче чиратта, товармы? Сүз, әлбәттә, яхшы китаплар турында бара.*

**И.Ә.** Китап ул борын-борыннан могҗиза булды һәм, иманым камил, киләчәктә дә шулай булып калыр. Китап сине исертергә дә, айнытырга да мөмкин. Утызынчы елларда кино һәм илленче елларда телевидение барлыкка килгәннән соң да "Китапның киләчәге бармы?" кебегрәк сораулар туганлыгын беләм. Белгеч-галимнәрнең ничәмә-ничә еллар дәвамында альтернатив ягулык тирәсендә ду-чат килеп бәхәсләшүләре һәркайсыбызга билгеле. "Бүген-иртәгә" кебегрәк вәгъдәләр хәйран, ә автомобильләр, элеккегечә, бензин "ашый".

Кәгазь китапның киләчәге өметсез дип тәкърарлаучылар белән һушымнан язганчы бәхәсләшергә әзерләп. Электрон китапларны да, аудио китапларны да хурларга җыенмыйм. Әмма, инде әйтеп узганымча, Галиҗәнап Китапны беркайчан да бернәрсә дә алыштыра алмастыр. Кулыңа алуга хисләнә башламагач, геройлары белән кайгырмагач-сөенмәгәч, күңеленә хуш җирләрен кайта-кайта укымагач, шушы да булдымы китап уку! Укый-укый черемгә китеп баруларны, бакчаның күләгәле почмагында кичке тынлыкка сыенып уку ләззәтен аудиокитап алыштыра алыр дисезме? Хаталанмыйк. Минем өчен пунктуациянең нинди булуы да кыйммәт. Ноктолы өтер белән күп нокталарны үз күзләре белән күреп хозурланучылар да бер мин генә түгелдер. Еллар тузанын кага-кага уку тәмен Интернет бирә аламы икән? Дөрес аңлый күрегез, Интернет, электрон китапханәләргә дә күсәк күтәрергә җыенган кеше юк. Аларында мәгълүмати-белешмә әдәбият, сүзлекләр туплансын. Тормыш сынавын узганнары, әлбәттә.

Китапка күпме генә мәдхия җырласак та, китап укудан берникадәр читләшү үзен сиздермичә калмый. Әмма "аһ" орырга, "укымыйла-а-ар" рәвешендә чаң кагарга иртәрәк әле. Рәсәйгә, йә булмаса, татарларга гына хас чир түгел бу. Юккамыни инглизләр: яшьләрнең Шекспирда гамьнәре юк, рухи яктан гарип булып үсәләр түгелме соң алар, дип парламент мөнбәреннән кызып-кызып бәхәсләшәләр. Франциядә француз телен коткару (әйе-әйе нәкъ менә шулай) максатында оешкан гомуммилли комитет эшли. Алманиядә булганда дәүләтнең балаларда китап уку теләген үстерү өчен ел саен 4 миллион евро акча бүлеп бирүен ишеткән идем. Ә американнар бәйге оештырганнар! Ниндинеме? Балаларның китап укып йоклап китү бәйгесен. Галиҗәнап Китапның киләчәге хакында сөйләүче мисаллар түгелмени болар?

**Р.Ф.** *Сезнең кабинетның албүлмәсе стенасында төрле-төрле дипломнар, Мактау кәгазьләре, бүләкләнү турында Указлар эленеп тора. Түр бүлмәдә дә ул призларның сыннары, медаль-билгеләре җитәрлек. Алар хезмәттә ирешкән уңышларның символлары бит инде. Кайсылары аеруча кадерлерәк?*

**И.Ә.** Иң әүвәл диплом, йә булмаса мактау кәгазьләренә кагылышлы бер нәрсә сөйләп узыйм әле. Ел төгәлләнергә берничә ай кала берләшмә-предприятие җитәкчеләре исеменә Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан, хәер, алай гынамы,

кайчагында Кейптаун, Сидней кебек калалардан затлы ялтыравык кәгазьләргә алтын буяулар белән басылган чакыру-тәкъдимнәр "ява" башлый. Сиднейдан җибәрелсә дә урысча язылган булыр алар. Һәркайсында диярлек "игезәк" сүзләр: "Мөхтәрәм фәлән иптәш фәләнов! Сез җитәкчелек иткән предприятие соңгы берничә елда икътисади яктан нык сикереш ясады, илкүләм шөһрәт казанды. Безнең халыкара үзәк Сезне 2007 елның иң яхшы компаниясе дип таный һәм Мәскәүнең Президент-отелендә узачак тантанага чакыра." Утсыз, төтенсез, кинәт ялкын! Күзгә бәрелми генә урталыкта атлап кил дә, көннәрдән бер көнне илкүләм танылу ал әле син! Билләһи, башларың әйләнеп китәр. Тагын бер нәрсәне әйтеп китү зарур. Ялтыравык кәгазьнең икенче ягында вaграк хәрефләр белән диплом белән медальнең, тантанада авыз итәсе шампаньның 2978 еврога төшәчәге күрсәтелгән. Рәсәй акчасына әйләндерсәк 110 мең сумнарга тарта түгелме соң әле бу? Халыкара хезмәттәшлекне үстерү юнәлешендә эшләүче 35 сессия Лондон—Нью-Йорк—Сан-Франциско—Гавай—Токио маршрутын тәкъдим итеп 790.000 (!) сум сорый. Янәсе, алтын орден белән мактау дипломы өчен. Һәм әзрәк арканны кыздырып алу хакына, әлбәттә. Хәләл җефетеңне дә ияртергә ниятләсәң, әлеге бәһане икегә тапкырлап куй. Узган елның соңгы берничә аенда без шуңа охшаш 22 тәкъдим-чакыру алдык. Дан тагарагыннан берәр калҗалы кисәк эләктереп калырга теләүчеләр беткәндер дигән фикердән ерак торам мин. Шулай булмаса, әледән-әле гәҗит битләрендә кемнәрнеңдер "дөньяның иң мәшһүр заты", "Рәсәйнең иң күренекле җитәкчесе" дигән исем алуларга кагылышлы хәбәрләргә юлыкмас идек. Шөкер, итәк астыннан дан сатып ятучылар белән безнең беркайчан да алыш-бирешебез булмады, күптән мондый күз буяуларга ясин чыгылган.

Ә безнең албүлмәдәге диплом-мактауларга килгәндә шуны әйтә алам: аларның берсен дә ифрат зур акчага да сатып алып булмый. Әйтик, "Рәсәйнең мактаулы салым түләүчесе" дигән диплом. Әгәр син салымнарыңны көннекен көнгә түләп бара алмасаң, моның ише бүләкләр хакында хыялыңны җылытып йөрергә мөмкинме соң?! Мәгълүм ки, республика җитәкчеләренең рәхмәт хатларын да сорап алып булмый. Дин әһелләренең дә күзгә төтен җибәреп утырганын ишеткәнем юк. Сабан туйларын оештыруга өлешебез кергән, милиция белән бәйләнеш ныгыган,—дипломнар болар һәм күп нәрсә хакында сөйли. Күптән түгел Рәсәй күләмендә "Нәшрият һәм полиграфия өлкәсендә тармак әйдәүчесе" дигән диплом тапшырдылар. Акча түләп түгел, маңгай тирен түгеп алдык. Соңгысы булмастыр шәт.

**Р.Ф.** *Казансуы буендагы сез һәм без бергә-бергә эшләгән «Идел-Пресс» бинасы төзелгәнгә дә кырык елга якын гомер узды. Сезнең дә гомернең байтак еллары биредә эшләп үтте. Инде без дә олыгайдык, шулай ук, бина да «картайды». «Идел-Пресс» территориясе тирәсендә яңа бина-корпуслар төзү планнары юкмы? Баумандагы Матбугат йортыннан нәшриятлар, редакцияләр кайсы кая таралып беткәч, матбагаларны бер үзәккә туплау уе күпләрдә бар. Бәлки, аларны «Идел-Пресс» тирәсенә җыю кулайдыр? Бу хакта Сез ничек уйлыйсыз?*

**И.Ә.** Матбугат йортыннан башлыйк әле җавапны. Аның төп хуҗалары—китап нәшриятлары шәһәр читенә "башка чыккач", "Мәдәни җомга" гәҗите безгә—"Идел-Пресс"ка "йортка кергәч", аннан килеп, мәркәзебездәге иң дәү китап кибетенә йозак элгәч, менә калса, Бауман урамы гармунсыз авыл, сандугачсыз урман шикеллерәк булып калды. Бер чаты китек аның хәзер. Башкаланың рухи кәгъбәсенә менә торган атаклы баскыч төбендә гөлләрәп гәп коруларны, исемнәре дәреслекләргә кергән каләм ияләренең тәмәке көйрәтүләрен дә күрмисең инде. Баумандагы олы күченешнең шаукымы безнең тарафларга да килеп җитеп, көн аралаш диярлек, озын колаклар аша, кемнәрнедер кушалар икән, кемнәргәдер үз хәлләрен үзләре күрергә тәкъдим ителгән икән ише сүзләрне ишетә башладык. Җае килгәндә, безнең тел төбендә нәрсәләр ятканлыгын белешеп алуларын да әйтим. Әлеге мәсьәләдә ашыгу-каударлану килешмәс, җиде кат үлчәгәннән соң гына кулга кайчы алу хәерле булыр, дидек. Белүемчә, хәзер хөкүмәттә "Идел-Пресс"ны киңәйтүнең берничә варианты карала. Беренчесенең төп идеясе гәҗит-журнал редакцияләре урнашкан ундүрт катлы бина күршесенә анардан да биегрәк икенче бер корпус күтәреп, киләчәктә шәһәрнең төрле почмакларына сибелгән барча редакцияләрне бер түбә астына туплаудан гыйбарәт. Ә хәзерге бина

сүтеләчәкме, дип сорарсыз. Сүтелмәс дип уйлыйм, шәпләп-сипләп яңартылыр, аннары инде мондый бинага хуҗа табылмый калмас. Икенче тәкъдим "Ак Барс банк"ы белән бәйле. Ул төп инвестор (акча чыгымын үз җилкәсенә алучы дип анлыйк) сыйфатында эш итеп, типография ягын элекке "Тасма" берләшмәсеннән бушаган мәйданнарга—"Химград" шәһәрчегенә күчерергә ниятли. Ә редакцияләрнең "Ак Барс банк"ының бүгенге төп бинасына (элеккеге Яшьләр үзәгенә) күчү ихтималы бар. Сезнең белән әңгәмә корып утырган дүрт гектарлы мәйданнарда банк хуҗалыгы булыр дип фаразлана. Бүгенге проектларның берсенә дә соңгы нокта куелганы юк. Бизмәндә дистәләгән коллективларының язмышы. Әйткәнемчә, мондый эштә кабалану кирәкми.

**Р.Ф.** *Әлбәттә, зур хуҗалык җитәкчесенең вакыты бик чикле. Шулай да, Сез, галим-журналист буларак, кайбер әсәрләрне күздән кичерәсез дип уйлыйм. Бүгенге татар әдәбиятында яратып укырлык әсәрләр бармы? Нинди жанрлар Сезгә якын? Гомумән, татар әдәбияты, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында берничә сүз.*

**И.Ә.** Берьюлы биш сорау юлладыгыз, кыскача гына җавап биреп булырмы... Хезмәтем матбугат, китап басу белән турыдан-туры бәйле булганга үзебездә дөнья күргән әсәрләрне хәлдән килгәнчә укып барырга тырышам, кайбер шигырьләрне хәтта куен дәфтәренә дә күчереп куям. Беләбез ки, бүген күп языла, әмма аз укыла торган заман. Һәр укылган әсәр хәтергә уелып кала димәс идем. Үземә тарихи романнар, документаль чыганакларга нигезләнеп язылган мәгълүматлы әсәрләр ныграк ошый. Чын мәгънәсендә матур әдәбият кануннары белән иҗат ителгән мәхәббәт повестьларын да көтеп алам. Яшьлегебездә китаплары кулдан төшмәгән Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, М. Әмир, Ф. Хөсни, Н. Дәүли, М. Мәһдиев, Г. Афзал кебек мәшһүр шәхесләр юлын дәвам итәрлек язучыларыбыз аз түгел. М. Хәбибуллин, Ф. Садриев, Ф. Бәйрәмова, К. Кәримов, В. Имамов, М. Әмирхан романнары нәкъ менә бүгенге укучы өчен һәм киләчәккә атап язылган дип, икеләнмичә әйтә алам.

Һәр үткән гасыр әдәбият тарихына яңа мирас өстәп тора. Ләкин һәр язган әсәр мирас булып кала алмый. Әйтик, узган гасырның 90 нчы елларга чаклы өлешен алып карыйк. Хәтерем ялгышмаса, ул чорда 170ләп татар язучысы бар иде. Күпчелегенең кулдан каләмне төшермәвен беләм. Иҗатлары өчен орденнар алган, мактаулы исемнәр яулаган, Дәүләт премияләренә лаек булган язучыларыбыз күп иде... Кызганыч, без инде ул шәхесләрнең күбесенең исемен онытып барабыз, өебездә сакланган калын-калын китапларын Хәйрия елында авыл китапханәләренә илтеп тапшырдык. Бүген безнең рәсми рәвештә теркәлгән 300дән артык язучыбыз бар. Киләчәк шуларның күпмесен хәтеренә теркәп калыр?

Мине бер тенденция сагайта—тарихи романнар язу модага керде түгелме? (Мин инде милиция хезмәтеннән алып язылган бер генә детектив әсәрне дә үзәккә алып сөйләшә алмыйм, гафу итәрсез, алар бездә басылган "ширпотреб"ны хәтерләтә). Нурихан ага Фәттах исән чагында кайда булган алар? Үсеп җитмәгәннәр—яшьрәк булганнармы? Алай дисәң, тарихи романнар "коеп" торган бүгенге әдипләребез арасында өлкән яшьтәгеләр дә бар. Каләм белән язарлык, цензурасыз, фикер ирегенә ирешердәй кыю заман җитмәгән булган, диярсез. Әйе, килде ул кыю заман. Ә кая соң кыю тарихи әсәрләр? Бөтен булганы игезәкләр кебек охшаш, ханнар ызгышы, бозык гыйшык, рус дәүләтенә яраклашу һәм тиранлык стихиясе белән булган таныш вакыйгаларның компилятив варианты. Күренеп тора ки, материалларның архивларда саклана торган байлыкларга мөнәсәбәте юк, ә зыялы укучы әллә кайчан укып чыккан җиде-сигез букинистик китаптан гына алынган.

Нурихан Фәттахның Сез җитәкләгән басмада узган елның ахырында басылып чыккан "Аклан" романын гына алыйк. Ул төгәлләнмәгән килеш калган... Борын-борын заманда Җир шарында тик бер генә—Аклан иле (Атлантида) дигән ил генә булган, аның халкы безнең борынгы бабаларыбыз һәм алар бары тик төрки телдә генә сөйләшкәннәр. Ә бит роман моннан 40 ел элек язылган. Йә, шул чор өчен кыю фикер түгелме бу?!

Тагын бер тенденция борчый. Матур әдәбият кысрыкланды. Чәчмә әсәрләргә публицистика үтеп керде. Калын-калын романнар үзенең күләмен югалткан очеркларны хәтерләтә. Автор вакыйгаларны тормыштагыча сөйләп чыга да янгыравык исем куя. Ә сурәтләү чаралары, сюжет, образлылык турында бөтенләй оныта. Андый романнар һәм повестьлар тиз ялыктыра. Минем "Таң җиле" (Фоат

Садриев), "Ком сәгате" (Камил Кәримов), "И, кылгам догам минем" (Марат Әмирхан) кебек романнар укыйсым килә.

Авторларыбыз арасында хатын-кызларның күбәюен 90 елларда балкыган сәяси янарышларның унышы дип карарга кирәк. Һәм киләчәк турында житдирәк уйлаганда, кызлар "тудырган" чәчмә әсәрләрдә ир белән хатын арасындагы конфликтларны, Бразилия сериалларындагыча чуалган интригаларны, бер сөяркәнең икенче сөяркәгә оештырган бәрелешләрне генә түгел, ә социаль яктан мөһим булган һәм әдәби эшләнеше матур әдәбият дәрәҗәсенә житкән язмышлар күрәсе килә. Үзәк матбугат, аның телевизион каналлары шыплап тулган байлар "нужасы" белән генә мавыкмыйча, гади хезмәт кешесе турында да тагын язарга вакыт житкәндер, бәлки.

**Р.Ф.** *Сез озак еллар матбугатта эшләгән кеше. Заманында «Татарстан яшьләре» газетасын житәкләдегез, «Социалистик Татарстан»да («Ватаным Татарстан») җаваплы вазифа башкардыгыз. Баш мөхәррир чакларыгыз сагындырамы? Хәзер берәр басманың баш мөхәррире булсагыз, ниләр эшләр идегез? Хезмәттәш буларак, бездәйләргә киңәшләрегез дә бардыр?*

**И.Ә.** Киңәш бирергә бөтенебез оста анисы, ә менә өр-яңа гәҗиткә фатиха биреп, шуның тиражын ике-өч елда 100 меңгә житкереп кара син! Берничә ел элегрәк матбугатның бүгенге хәле турында бәхәс чыккач, күптәнге хезмәттәшем шулай дигән иде. Күзгә бәреп әйткәненә үпкәләмәдем. Ихластыр, киңәш, "рецепт" бирүчеләр байтак, менә шулайрак эшлиләр аны туганкаем, дип үрнәк күрсәтүчеләр юк дәрәҗәсендә. Инде килеп, Сезнең сорауга әйләнеп кайтыйк. Социологик тикшеренүләр шуны раслый: гәҗитләрнең 32—36 процент мәйданы сәяси язмаларга бирелә. Дөнья стандарты—10 процент! Укучы рәсми хәбәрләргә мәйданын кызганмаган басмаларга йодрык күрсәтеп, жан азыгына урынны мул биргән басмаларга өстенлек бирә башлады. Кайбер гәҗитләрнең тиражлары ике-өч елда 30—40 меңгә житүе шул хакта сөйли түгелме соң? Берәү дә рәсми хәбәрләрдән бөтенләй баш тартырга өндәми. Житәкчеләрнең сәяси очрашуларын да бутәнчәрәк язып була бит. Үрнәге дә бар. Моның өчен "Коммерсант" гәҗитендәге А. Колесников язмаларын уку да житә. Иманым камил, рәсми хәбәр шундый рухта языла калса, укучы дүртенче битне онытып, беренче битне күзли башлар иде. Кайчагында проблеманы өйрәнү урынына тырнак астында казынуга тап буласың. Йә язманы күп нокталар белән йомгаклап куялар. Нәтиҗәсен үзең яса, янәсе, ахыргача уйлап бетер! Аннан килеп, укучыга тәти сүздән бигрәк, төгәл сүз кыйммәт. Бертөрле сөйләп, икенче төрлерәк яшәү рәвешен алга сөрүне ул өнәми. Тәти сүз дигәннән гәҗитләребезнең теле ташка үлчим. Кайда телебезнең аһәне, моны, табигый агышы? Журналист елларның итәгенә ябышып түгел, ә аларны үзе житәкләп барырга тиешле. Ә бәлки алган акчасы биш-алты меңнән артмаган журналисттан бүтәнне көтәргә дә кирәкмидер?!

**Р.Ф.** *Үткән ел элек дәүләт канаты астында булган күпчелек редакцияләр «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенә керде, дөресрәге, керергә мәҗбүр булды. Акционерлык, үзегез беләсез, берләшеп, акча арттырып, үзбаш яшәү дигән сүз. Күпчелек редакцияләр, әлбәттә, үз кереме хисабына көн күрә алмый... Газета-журналларда эшләүчеләрнең бу мәсьәләгә җавапка караганда сораулары күбрәк әле бүген. Сездән, Матбугат дөньясын эчтән дә, тыштан да, идеологик һәм икътисади яктан да яхшы белгән, бу эштә «елан аягын күргән» кешедән, ишетәсе килә: бу гамәлләрнең ахыры ни белән бетәр икән?*

**И.Ә.** Дәүләт, байтак вакытлардан бирле, без матбугатка киләчәктә дә ярдәм итәргә әзер, әмма акрынлап чыгымнарның бер өлешен үзегезнең җилкәгә салырга өйрәнегез, дип искәртеп килде һәм килә. Бергәләп уйлашыйк әле: чыгымнарны, дөресрәге, дәүләттән килә торган ярдәм—дотацияне ничек итеп киметергә кирәк? Фикер-тәкъдимнәр күп, хәл итү юлы бер—рекламаны түргә уздырып. Ә игълан-реклама сиңа килергә ашкынып тормаса әгәр? Чөнки ул һәр басма алдында баш ияргә ашыкмый, аны, беренче чиратта, тираж кызыксындыра, бүтәнчәләтеп әйтсәк, реклама ничәләп кешенең күзенә чалыныр, басманың таралу географиясе—калаларамы, авылларамы—кызыксындыра. "Без—яхшы, без—берданбер" дигән шигарь

белән генә аларны үзенә каратуы кыен. Ә тираж мәсьәләсе милли матбугатны сызлатып торган нәрсә. "Татмедиа", дәүләт карамагындагы барча басмаларны бер түбә астына җыеп, гомуми тиражны реклама хуҗасын кызыктырыр дәрәҗәгә җиткерергә ниятләгәндер, дип беләм. Хәзер реклама, барча район-шәһәр гәҗитләрендә дөнья күреп, республика басмаларында кабатланып, 400ләп мең тираж белән дөнья күрә. Аннары, Акционерлык җәмгыяте кредитлар алып, кайсыдыр бер басманы үстерү концепциясен алга сөрергә мөмкин, икенчеләренең кыйбласын үзгәртә ала. Нинди генә яссылыкта карасак та, әлеге үзгәрешләр басмаларны агач атка атландырып калдырмаслар дип уйлыйм. Бигрәк тә милли матбугатны. Милли матбугат, балалар матбугаты, хатын-кызларга адресланган матбугат бик күп илләрдә, шул исәптән, көнбатыш илләрендә, дәүләт тарафыннан финансланып килде һәм килә. Татарстан кебек республикада да милли матбугатка булышлык итү мәсьәләсенә "аннан соң" дигән караш була алмый. Ник дигәндә, сүз, тел мәдәният халык язмышы турында бара ләбаса.

**Р.Ф.** *Сезнең, «Идел-Пресс» коллективының хәйриячелек эшчәнлеге турында еш ишетеп, укып торабыз. Шәхсән Сез үзегез дә, мәктәпләргә, китапханәләргә әледән-әле ярдәм итәсез. Бу җәһәттән туган ягыгыз Буалылар бигрәк тә рәхмәтлеләр дип беләм. «Казан утлары» журналына да шәфкать күзе белән карыйсыз. Безнең яшь авторларның беренче китапларын чыгаруда булышасыз. Коллектив исеменнән рәхмәт Сезгә! Базарча кырыс һәм мәрхәмәтсез заманда миһербанлылык аерым игътибарга, хөрмәткә лаек. «Идел-Пресс»ның хәйрия эшчәнлеге турында без дә язып чыккан идек. Мәрхәмәтлелек акцияләре һаман да дәвам итәме?*

**И.Ә.** Ничек кенә әле! 3 миллион 755 мең сум—узган елда хәйриячелек, иганәчелек юнәлешендә шушы кадәр акча тотканбыз. Китаплар бүләк иткәнбез, үзебезнең хисапка җиде китап бастырып чыгарганбыз, мәктәп-гимназияләргә, балалар бакчаларына булышлык иткәнбез, милициянең терәк пунктын шефлыкка алганбыз, стипендиантларыбызны булдырганбыз, күп балалы гаиләләргә, колониядәге тоткыннарга ярдәм кулы сузганбыз, мәчет-мәдрәсәләрне дә онытмадык. Яшермим, дәрт бар, дәрман юк дигәндәй, бөтенесенә ярдәм итеп тә булмый. Үпкәләүчеләр, ишекне каты итеп ябып чыгучылар да юк түгел. Үземнең андыйларга да үпкәләгәнем юк. Мәҗлес уздырырга сорамый бит, китап бастырырга... Хәер, гозернең дә төрлесе була. Бервакыт миңа Уссури юлбарысларын саклау фонды төзибез дип килделәр. Төзегез, минәйтәм, кем комачаулый соң? Акча юк, диләр болар. Әйтерсең лә Татарстанның үзенең киек һәм кош-кортлары ярдәмгә мохтаҗ түгел!

**Р.Ф.** *Белгән, аралашкан кешеләр, иң әүвәл Сезнең кешелек сыйфатын бәялиләр: ул—егет кеше, ул—булган кеше, диләр. Үзем дә шуңа инанганмын. Менә шул шәхескә 60 яшь тулып килә. Күп күргән, күп кичергән журналист-мөхәррир дә, министр да, зур хуҗалык җитәкчесе дә булган, балалар үстергән, шул ир-егет үзенең үткәненнән канәгатьме? Эх, шуны эшлисе калган, теге вакытта менә болай итәсе булган икән, дигән уйлар килгәлиме?*

**И.Ә.** Килми! Яшермим, абынган-сөрлеккән чаклар да булмыйча калмагандыр. Вакыты-вакыты белән борын да канагандыр, җан да җәя бавы кебек тартылгандыр. Кемгәдер охшап бетмәгән гамәлләр эшләгәнемне дә беләм. Әмма бернәрсәгә дә үкенмим. Димәк, Ходай шулай язган. Бөтенесе шома гына, җайлы-ипле генә тәгәрәсә сагынып сөйләргә ни калыр? Минем өчен шул ачык: байтак елларны сыйдырган гомеремдә йөз кызартырлык гамәл кылганымны хәтерләмим.

Иртәгә—яна көн, яна мәшәкатьләр. Туасы көннәр мәшәкатьләре дә газиз халкым мәнфәгатьләре белән үрелеп барыр дигән өметтә яшим.

# СОҢГЫ ӨЧ ЕЛДА...

Киләсе айда Татарстан язучылары чираттагы XVI корылтайга җыела. Шул уңайдан редакция берничә язучыга түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итте:

**1. Ике корылтай арасында иҗади тормышыбызда Сезне нәрсәләр сөендерде?**

**2. Киләчәктә нинди мәсьәләләргә күбрәк игътибар итү кирәк дип саныйсыз?**

Редакциягә алынган җавапларны урнаштырабыз.



**Мәдинә МАЛИКОВА:**

1. Мин үзем соңгы елларны әдәбиятыбыз өчен уңышлы чор дип саныйм. Язучылар җиң сызганып эшлиләр, яңа әсәрләр дөньяга чыгып тора, «Казан утлары»нда күләмле әсәреңне бастырып чыгарыр өчен елдан артык көтәргә кирәк—чират шактый озын. Димәк, байлык зур дигән сүз!

Укучыларыбыз да күбәйде шикелле, һәрхәлдә мин соңгы вакытта яңа әсәрләр белән кызыксынуның артканын тоям. Халык телевизордан туя башлады, җан азыгын китаптан табарга теләк көчәя. Бигрәк тә яшьләрнең китапка тартылуы куандыра. Егет-кызларыбыз арасында укучылар да күп, каләмле, талантлылары да җитәрлек. Болар безнең киләчәгебезгә өметне үстерә, билгеле.

Ике корылтай арасы шәхсән минем үзем өчен дә уңышлы булды, дип саныйм. «Казан утлары»нда яңа романым дөнья күрде. Өч китабым нәшер ителде: «Югалган якутлар»ның икенче басмасы һәм «Кызыл гөл», «Тылсым. Шәфкать» исемле соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләремне эченә алган китаплар. Алар хәзерге көн өчен шактый зур тираж белән басылды: икенче басма—5 мең, «Кызыл гөл"—7 мең, «Тылсым», «шәфкать» 10 мең тираж белән чыкты.

2. Бүгенге көндә әдәби җәмәгатьчелекне иң нык борчыган мәсьәлә—яңа чыккан китапларны укучыга илтеп җиткерү, әлбәттә. Безнең укучыбыз бөтен илгә сибелгән. Татар авылына барып җитә алсаң, дистәдән артык кына булса да укучыңны табасың. Әмма барлык авылларга да барып җитеп булмый, чөнки язучының төп эше—язу өстәле янында. Башка өлкәләрдәге укучыларыбыз белән очрашу бик сирәк вакыйгага әйләнде. Читтә яшәүче укучыларыбызны без инде югалттык, дияргә була. Язучылар берлеге алар белән бәйләнешләрне торгызу, ныгыту өчен бөтен көчен куярга тиеш, дип уйлыйм. Таланты булган каләм иясе, артыннан этеп тормасаң да, язуыннан туктамас, ә менә аның китабын укучыга илтеп җиткерүдә ярдәм итү—мөмкин эш. Моның өчен Язучылар берлегендә гел шуның белән генә шөгыльләнүче бер бүлек булдырырга кирәк, дип саныйм.

Язучылар белән укучылар арасында элемтә тыгыз булса, иншалла, татар әдәбиятының киләчәге якты булыр, дип ышанам.

**Газинур МОРАТ:**



1. Үтә дә коммерцияләшә һәм маргиналлаша барган җәмгыятьтә милли әдәбиятларга көн итүе дә бермә-бер кыенлаша. Иҗат белән җитештерү тармагын бер шартларга куюю, рухияттән матди керем өмет итү әдәбият-сәнгатьне бөтенләй дә мөшкел хәлгә төшерә. Мондый вәзгыятьтә хәтта буыннар арасындагы чылбыр да шартлап өзелергә мөмкин. Әгәр әдәбиятка талантлы яшьләр килми башласа, андый хәвефнең булуы да бик ихтимал. Хәер, әллә кая ерак китәсе юк, әле узган гасырда гына да Татарстаннан читтә туып-үскән күпме әдип татар әдәбиятына хезмәт итте. Ә хәзерге яшьләр арасында андыйлар, ни кызганыч, берән-сәрән генә күренә. Шул рәвешле, бүген әдәбиятыбызның иң яшь көчләрен, асылда, Татарстанда туып-үскән егетләр-кызлар тәшкил итә. Күрәсез, ил-дөнья буйлап сибелгән милләтебезнең рухият өлкәсендәге потенциаль мөмкинлекләре отыры тарая бара.

Шулай да, шөкер, әдәбиятыбызга әзерлекле, зәвыклы яшьләр килә тора. Һәм, әйтергә кирәк, әлеге процесс соңгы елларда аеруча активлаша төште. Бу җәһәттән бигрәк тә шигъриятебез яшәреп китте. 18-20 яшьлек, яхшы мәгънәсендә акселерат егетләр-кызлар килеп ята бүген шигърият мәйданына. Эльвира Һадиева, Лилия Гыйбадуллина, Рифат Сәлах, Йолдыз Миннуллина, Айдар Җамалиев, Ләйсән Фәтхетдинова, Гөлнара Сибгатова, Илнур Юнысов, Алинә Бикмуллина, Илһам Шәрипов, Лилия Закири, Айсылу Мостафина...—әнә шундыйлардан. Аларның кайберләре инде үз китапларын да чыгарырга өлгерде, Язучылар берлегенә дә тәкъдим ителде.

Талантлы яшьләрне барлап, аларның иҗатын дөньяга чыгаруда «Казан утлары», «Идел» журналлары, «Мәдәни җомга» гәзите, Татарстан китап һәм «Мәгариф» нәшриятлары зур тырышлык куя. Яшьләребезнең иҗади куәсен арттыруда шулай ук «Иделем акчарлагы» кебек әдәби бәйгеләрнең дә шифалы йогынтысы аз түгел, минемчә. Ә инде күренекле шагыйребез Рәдиф Гаташның бу өлкәдәге остазлык хезмәте һәркайсыбызга үрнәк булып тора.

2. Татар матбугатының шыпырт кына акционерлаштырып куелуы турында инде әһле каләм дә, укучылар да белә булыр. Гәзит-журналлар белән хезмәттәшлек итүче авторлар да бу яшертен гамәлиятнең зыкымын тиз арада тоеп өлгергәндер. Ә матбугат ул, үзегез беләсез, әдәбиятның тормыш итү рәвеше. Әгәр матбугатыбыз коммерцияләшеп, акционерлашып бетә икән, әдәбиятыбызны да шундый ук киләчәк көтә. Шуңа күрә язучылар корылтаенда, әдәбият белән беррәттән, матбугатыбызның хәзерге хәле турында да җитди сөйләшү булыр, дип ышанам. Югыйсә, җавапсызлыгы чикләнмәгән җәмгыятьтә яши-яши бөтенләй дә «акционерлашып» бетүебез ихтимал.

**Ләбиб ЛЕРОН:**



1. Сөенечләрдән битәр, көенечләр күбрәк булмады микән, дим әле мин. Бик кыска вакыт арасында гына да гаять зур югалтулар кичердек бит: Наис Гамбәр, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Нияз Акмал кебек асыл иҗатчыларыбыз татар шигъриятен илкүләм танытуда армый-талмый хезмәт иткән Сергей Малышев һәм Роза Кожевникова кебек талантлы каләмдәшләребез бер-бер артлы бакый дөньяга күчтеләр. Алардан берникадәр алдарак кына Илдар ага Юзеевсыз калган идек. Татар әдәбиятына килгән мондый олы югалтулар эзсез генә үтмәстер: аларның юклыгы һәрдаим үзен сиздерәчәк әле.

Сөенечләргә килгәндә... Замана бер алдын, йөз мәртәбә артын күрсәтеп торуга карамастан, татар әдәбияты һаман хәрәкәттә, үсештә, яңарышта. Мине иң куандырганы—сәләтле, иҗади яшьләрнең бер буыны пәйда булуы. Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Айдар Җамалиев, Лилия Гыйбадуллина, Йолдыз, Эльвира Һадиева, Рөстәм Галиуллин, Райнур Әгъләметдинов кебек яшь каләм ияләрен күз унында

тотуым. Аларның барысы да диярлек,»Идел» яшьләр үзәге оештырган «Иделем акчарлагы» бәйгеләрендә катнашып, лауреат булдылар. Мин бу яшьләргә аеруча өмет баглыйм. Ике корылтай арасында иҗатташ дусларым Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Рәдиф Сәгъди, Зиннур Хөснияр, Вакыйф Нуриев һәм Камил Кәримнең, олпат остазларым, күренекле каләмдәшләрем Рөстәм Мингалим, Батулла, Туфан Миңнуллин, Әхсән Баян, Фәнис Яруллин, Лирон Хәмидуллин, Харрас Әюп, Фоат Садриевларның яңа китаплары басылып чыкты. Аларны укып хозурландым. Озаклмый Марат Закир, Ләис Зөлкарнәй китапларын да укып тәэсирләнермен әле, дигән ышанычым бар. Кино сәнгате тернәкләнеп килә, шөкер! Мансур Гыйләҗев, Батулла, Салават Юзеевлар бу өлкәдә азау ярдылар дип беләм. Өлкән язучы-журналист Госман Гомәрнең әсәре буенча «Чия чебене» дигән кинофильм төшереләчәк, дигән күңелле хәбәр йөри. Бирсен Ходай! Балалар драматургиясендә дә алгарыш сизелә: Хәбир Ибраһимнның Буа дәүләт театры сәхнәсендә бер-бер артлы ике спектакле куелды. Шәхсән, минем «Чәпәләй белән Тәпәләй» дигән әкияти пьесам Минзәлә театрында сәхнәләштерелде. «Сынган беләзеге» белән менә ничә ел инде тулы залларны елаткан Рәдиф Сәгъди һәм яшь драматург Илгиз Зәйниевнең дә балалар-яшьүсмерләрне күздә тотып язган әсәрләре—театрларыбыз репертуарында. Шагыйрь Рафаил Газизов «Мәгариф» нәшриятында нәшер ителгән «Бүләгем» исемле китабы өчен балалар әдәбияты буенча дөньякүләм булдырылган иң югары бүләккә—Г.-Х. Андерсен исемендәге Халыкара дипломга лаек булды. Болар сөенечләр түгел мени, ә?! Әлбәттә, сөенечләр! Боларга өстәп, Газинур Морат белән икебезгә узган ел М.Җәлил исемендәге премия бирелүен дә әйтеп үтсәм әле...

2. Проблемалар бар инде ул, бар. Алар иҗатта да, тормыш-көнкүрештә дә хәттин ашкан дигәндәй... Әдәбиятны гына алыйк. Мин үзем—Г. Кутуйның «Рөстәм маҗаралары"н, Г. Гобәйнең «Маякчы кызы»н, Ф. Кәримнең «Разведчик язмалары»н, М. Юнысның «Занзибар—зәңгәр болытлар артында»сын, А. Расихның «Бәхет орлыклары»н, Л. Ихсанованың «Саралан малайлары»н, Р. Хафизованың «Кирлемән»ен, Батулла әкиятләрен, М. Хәсәновның маҗаралы повестьларын, А. Тимергалинның фантастик әсәрләрен укып үскән буын вәкиле. Үзеңдә юкны кешедән таләп итү дөрес тә түгелдер, бәлкем... Шулай да... Бүгенге әдәбиятыбызда хәзерге заман баласы мөкиббән булып укырдай әсәрләр юк дәрәҗәсендә, дип әйтмичә кала алмыйм. Нишләп юк соң андый әсәрләр? Балалар күңеленә ачкыч табалмаудан гынамы бу? Сәбәп нидә? Сатира-юмор өлкәсендә дә хәлебез әллә ни мактанырлык түгел. Ильф һәм Петровның «Алтын бозау»ына, «Уникe урындык» әсәренә, үзебезнең Ф. Әмирхан сатирасына тиңләшерлек әсәрләрне әле дә булса иҗат итә алганыбыз юк. Кем әйтмешли, талант житенкерәмиме, әллә башыбыз бәләкәйме? Проблема тирәндә ята, минемчә. Без сай җирдә йөзәргә өйрәндек һәм шул сай җирдә һаман да йөзгән булабыз. Эчкәрәк керергә, тирәнрәк урында колачларга, төпкә чумып алырга куркабыз. Җаныбызга Курку оялаган, димме—Караңгылыктан да куркабыз, Яктылыктан да. Парадокс: шәп әсәр язарга бик телибез, талант та бар, ничек язарга икәнлеген дә беләбез сыман, әмма... Әйе, безнең белән әлеге дә баягы Курку идарә итә. Минемчә, бөтен проблемаларның башы нәкъ менә шунда: безгә Куркуны җиңәргә кирәк!



**Рифә РАХМАН:**

1. Соңгы елларда драматургиябездә, театр сәнгатендә үземне борчыган бик күп сорауларның һич югы азына булса да халыкның гына түгел, хәтта хөкүмәт җитәкчеләренең дә игътибарын юнәлтә алдым кебек, театрыбызның бүгенге торышы мәртәбәле җыелышларда үзәк проблема рәвешендә күтәрелде. Минем көчкә бастырып чыгара алган кечек кенә язмама каршы күләмле, шакшы телле күләмле мәкаләләр басылды, аңа җавап йөзеннән телетапшырулар оештырылды. Шунысы сөенечле: әдәби җәмәгатьчелек, хәтта талантлы артистлар һәм режиссерлар да аларның "социаль заказ" рәвешендә башкарылганлыгын аңлады; җавап язарга, бәхәскә кушылырга курыксалар да, эшләрендә үзләренә проблема тудырудан тайчынсалар да, һич югы миңа рухи терәк булдылар,

шалтыратып булса да рәхмәтләрен әйттеләр. Рәдиф Сәгъди, Искәндәр Сиражи кебек кыю каләмле журналистлар, сәнгатькәрләр сәхнә, әдәбият һәм башка проблемаларны үткен куйган мәкаләләр белән вакытлы матбугатыбызны җанландырып җибәрделәр.

«Казан утлары» журналы кечкенә генә бәхәсләр клубына әверелеп бара, авыруының, хәлсезлегенең соңгы стадиясенә кергән, икейөзле тәнкыйтьнең җан тәслим кылмавына күпмедер хезмәт итә. Күп кенә газета-журналларның редакторлары тәнкыйть язмасын күрүгә үк, яисә фәлән темага языйм әле дип шалтыратуга ук, барыбер басмыйбыз, дип торган шартларда «Казан утлары» безгә ни дәрәҗәдә кирәк! Кызганыч ки, ул да тәнкыйтькә урынны азрак бирә. Шул ук вакытта аның редакция коллективы үз тирәсенә матур телле каләмгә һәм акыллы фикергә ия авторларны туплавын дәвам итә. Тәнкыйди эчтәлектәге мәкаләләрне бастыра алмаган чорда һич югы әдәби әсәр аша укучы зәвыгын тәрбияләүче вакытлы матбугатка да рәхмәт күзе белән карый башлыйсың икән.

2. Татар тормышында актуальлеге кимегән бер генә мәсьәлә дә булса бар микән? Бигрәк тә Россия сәяси шартларны үзгәртә барган заманда, милли республикаларның теләсә кайсы яктан хокуклары кимегәндә...

Актуальлекнең дәрәҗәсе, әлбәттә, төрле. Әдәбиятта, аның тәнкыйть өлкәсендә дә кичекмәстән хәл ителергә тиешле проблемалар бар. Бүгенге көндә шуларның иң мөһиме: тәнкыйтьнең махсус басмасын булдыру. Әгәр шул хәл ителсә, башка бик күп мәсьәләләрне үз тәртибендә чишәргә мөмкин. Болар—кыю мәкаләләр белән тәнкыйть утына алып, чын мәгънәсендә нәфис әсәр иҗат итә алмаучыларны язучы исемен дәгъвалаудан ваз кичтерү; әдәби-тәнкыйди дебатлар, әңгәмәләр, фәнни бәяләмәләр яисә башка бер чара-юллар аша әдәби дәрәҗәгә, яисә премиягә лаек кандидатураларны ачыклау; Язучылар берлегенең тулырак әдәби елъязмасын алып бару; яшь тәнкыйтьчеләр тәрбияләү һәм башкалар.

Тәнкыйтькә нисбәтле журналны яисә альманахны язучылар, әдәбият галимнәре һәм китапханәләр санынча дәүләт акчасына чыгару артыннан йөрергә иде. Мин, үзем, мәсәлән, анда хәтта хезмәт хакы алмыйча яисә бик шартлы акчага эшләргә дә риза. Мәкаләләр тәмам редакцияләнеп электрон вариантларда китерелә алган заманда аның саннарын бер-ике кеше дә туплый ала. Моны кемгәдер акча түләп эшләтү дә журнал бәясен артык үстереп җибәрер дип уйламыйм. Аны кварталга бер чыгучы басма сыйфатында гына булса да күрәсе килә.

**Юныс САФИУЛЛИН:**



Туксанынчы елларда бөек идеяләргә хезмәт итүче әдәбиятны һәм сәнгатьне "чишендерү" башланды. "Поэт в России больше, чем поэт, театр—больше чем театр" дигән гүзәл канунның тамырына балта чабылды. Чит илләрдәге театрлардан үрнәк алырга чакыру башланды. Социалистик реализмны туздырып (ә бит анда гомумкешелек тудырган файдалы идеяләр дә бар иде), аның урынына беренче итеп эгоизм, комсызлыкны яклаган, әдәп тә оят калмаган әдәбиятны һәм икейөзле, ялганчы, ясалма сәнгатьне күтәрделәр. Режиссерларны тәрбияләүче остазлар да театр кешене тәрбияли алмый, милләт төшенчәсе ясалма нәрсә, тоталитаризм иле тудырган бар нәрсәдән ваз кичик, сәнгать кешене якларга түгел, ә ялган матурлык белән «алдарга» тиеш диделәр.

Әдәбият һәм сәнгать тарихыннан хәбәрдар кешеләр беләләр, менә охшаш чирләр элек тә булгалап торган. Әйтик, театр дөньясында Кәрим Тинчуринның Кутуй кебек футуристлар белән көрәше... Бигрәк тә Крылов мәсәле аша яхшы аңлашыла ул бәрелешнең асылы:

*Талант чиксез шәп булса да,*
*Хәтта халык аңа кайчак сокланса да,*
*Файдасы булмагач илгә,*
*Кирәге бар аның, нигә?*

Әйе, безнекеләргә дә Мәскәү һәм Питерда инде эпидимия төсен үк алган, кешедәге кыргый, түбән инстинктларны ачу, шуларга юл бирү кебек йогышлы

авыру йокты. Безнең яшьләр дә баштарак кеше тормышы турындагы олы дөреслекне әйтеп бирү максатын шәхси тормышның һәр почмагына шакшы кул белән тыгылу, «чишенү, ыштансыз калу»лар белән алыштырырга омтылдылар. Бу авыру кайсыдыр жинелчәрәк, тизрәк үтсә, кайсындадыр озагракка да сузылгалады. Әйтик, Самара шәһәрендә күптән түгел Әлмәт театры гастроленә карата чыккан «Театрдан биздерүче театр» дигән тәнкыйть мәкаләсе шуна мисал була ала. Ә менә Г. Камал театрының баш режиссеры бар вөжүде белән эзләнүләргә чумгангамыдыр «империя грипыннан» тизрәк котылды. Бик тырышканда кемгә дә бәйләнеп була, әмма аның еллар буе артистлар укытуын, унсигез яшьлек драматург тәрбияләп бирүен, ин - иң мөһиме, яна режиссерларны, да үзебездә үстерә башлавын кем кире кага алыр икән? Шулай да, Фәрит Бикчәнтәевнен Марсель абый югарылыгындагы режиссер икәнен танырга теләмәү бар. Ф. Бикчәнтәевнен әүвәлге драматургларнын әсәрләрен дә Мәскәү, Европа тамашачысы сокланырлык итеп куюын ничек күрмәмешкә салышып була икән? Хәер, режиссураның чын көчен аңламаучылар да шактый гына. Әнә, Түбән Новгородтан килгән язучы Т. Миңнуллин әсәре «Дивана»ны карагач «Звезда Поволжья" газетында автор һәм артистларны гына күккә чөеп мактый, ә режиссерның алты ай буе эшләгән эшен бөтенләй күрми... М. Сәлимжанов гомер буе чит илләргә чыгар өчен тартышты, ә Фәрит остазы эшен дәвам итеп театрны инде берничә чит илгә алып чыкты, хәтта Лондонда булдылар. Лондонда Фәрит режиссурасындагы «Телсез күке» әнә инглиз режиссерында да кызыксыну уятты. Шәт, иншалла, татар драматургы әсәре чит ил сәхнәсендә дә куелыр. «Яңа татар пьесасы» дигән бәйгенең дә Фәрит тарафыннан дөньяга чыгарылуын онытмыйк. Аның жюриенда утырганда шуны күрдем, пьесалар елдан-ел яхшыра, бәйге үз эшен эшли. Бу зур өметләр уята. Язучы буларак күңелемә тагын да зуррак өметне Язучылар берлегенең рәисе Илфак Ибраһимов китерде. Ул күпне күрә, күпне эшләргә көче житә. Хәтта мине дә эш белән күмде. Кыска гына вакытта «Акмулла», «Г. Ибраһимов», «Т. Әйди» дигән театральләшкән тамашалар яздырды.

Соңгы елларда Илгиз Зәйниев, Равил Сабыр, Шамил Фәрхетдинов кебек яшь драматурглар берлеккә алындылар. Равил Сабирны 2004 елда конкурска катнашкан чакта ук «Земфира»сы белән хәтерләп калган идек. Һәм менә алар Дәүләт Бәдриев белән бергә талантлы «Хәят» спектаклен тудырып Чаллы театрына уныш китерделәр. Әйе, талантлы һәм чагыштырмача яшь драматургларыбыз янәшәсенә алардан да яшьрәкләрнең өстәлүе драматургияне тагын да куәтләндерә. Шулай ук, яшь һәм әзерлекле театр белгече Нияз Игъламовның үсеп житүен дә драматургиябезгә шифалы жил исә башлады дип кабул итик. Ә бит, әйбәтләп карасың, ул егет тә Фәрит Бикчәнтәевнен алга карап эш итүе нәтижәсендә мәйданга чыкты.

Яшьләр театрының баш режиссеры Ринат Әюпнен эшчәнлеген дә юкка гына мактамыйлар. Гажәеп тыйнак, намуслы, эзләнүчән егет. Традицияләрне бик жимерми генә янартып, яңа исемнәр таба-таба, милләтебезгә тугры хезмәт итә. Әмма ул бүгенге көндә хатыны белән кечкенә генә бер бүлмәле хрущевкада яшәп ята икән... Режиссерлар юк дәрәжәсендә дибез, ә үзебез аларны шундый мескен шартларга куеп тилмертәбез. Аларның хезмәт хакы да бик аз лабаса.

Әлмәт театрына Гали Хөсәенов кебек фидакарь режиссер Ильяс Гәрәевнен килүе дә драматурглар күңелен күтәрерлек вакыйга. Театр аны үз итсә, алар кабат күтәрелер иде. Бик талантлы коллектив бит югыйсә.

Гел күңелне тырнап торган бер нәрсә бар: ул театр белгечләренен сафы нык сирәгәю. Инде Буа театры кебек яна театрлар да туган чорда Рәүф Игъламов белән Назыйм Ханзафаровларның житди аурып сафтан чыгулары театр тәнкыйтен йомшатты. Хәзер спектакльләргә эстетик анализ ясаган рецензияләр аллә нигә бер генә языла. Чын белгечләр булганда, алар театрларны да игътибарда тотарлар, драматургиягә дә зур файда китерерләр иде.

Рәшит
Фәтхерахманов

# МИЛЛӘТ ТЕМАСЫНА ЭТЮДЛАР

## Кайда сез, диссидентлар?

80нче еллар ахыры—90нчы еллар башында бездә диссидентлык модага кергән иде. Диссидентлар, ягъни башкача фикер йөртүчеләр[1] һәркемнең игътибар үзәгендә булды, давыллы, шау-шулы митинглар алардан башка узмый иде. Хәтерлисездер, беренче номерлы диссидент дип ул вакытта Борис Ельцин саналды. Үз вакытында политбюро алып барган сәясәткә җиңелчә генә каршы чыгу сәрхушне Русия тәхетенә матур гына итеп күтәрде дә куйды. Хрущев һәм Брежнев идарә иткән чорларда чит илләргә качкан диссидентлар да бу вакытта, тантана итеп, Ватанга кайтып төштеләр. Әлбәттә, диссидентларны бу дәрәҗәдә иркәләүләр яңа заманда карьера ясарга теләүчеләрнең күзен кыздырмый калмады. Чөнки тегеләр депутатлыкка уздылар, кайчандыр үзләре каршы көрәшкән льготаларда һәм төрле өстенлекләрдә коена башладылар. Бу гына да җитмәде, аларның кайберләре ришвәтчеләрнең алгы сафларына басты. Дөрес, Русия демократиясенең җиңүе өчен намуслы рәвештә көч түгүне дәвам итүчеләр дә булмады түгел. Әмма аларның тавышларын 1993нче елның көзендә Мәскәүдә яңгыраган танк залплары һәм алардан соң булып узган давыллы вакыйгалар тезмәсе акрынлап күмде, диссидентлык модадан чыкты, сайлауларда җиңүне хакимият белән әшнәлек һәм капитал тәэмин итә башлады.

Менә шул диссидентлык «пачутта» булган чакларда безнең кайбер татар зыялылары да, үткәндәге кыюлыкларын искә төшерергә тырышып, пьедесталга күтәрелергә азапландылар. Әмма туксанынчы еллар башында пьедесталга күтәрелү өчен 60-70нче елларда эшафотка менүдән дә курыкмастай батырлык күрсәтү сорала иде шул. Бу кадәресе совет чоры татар зыялысына җитми иде, әлбәттә. Шуңа да күпләр узып киткән совет чорын кире кайтарырдай булып уфтандылар, ләкин соңга калып яндырылган партбилетлар өметләнгән нәтиҗәне бирми иде инде.

Чын татар диссидентын мин үзем бары тик бер тапкыр, 1982 елның октябрендә күрдем. Брежнев үлеп бетмәгән, хакимияткә Андропов килүгә санаулы гына көннәр калган иде. Мин сөйлисе вакыйга иҗатчы яшьләрнең республика семинарында, «Яшьләр үзәге» дип аталган мәгълүм бинада булды. Семинар алдан планлаштырылган сценарий буенча әйбәт кенә башланып китте. Яшь язучыларны, композиторларны, рәссамнарны идеологик яктан эшкәртү максатыннан, берничә лекция тыңлаттылар. Бер яһүд профессорының Тукайның «Милли моңнар»ын сәнгатьле итеп русча укуы истә калган. Шул ук профессор, Көнбатышның черегән идеологиясенең безнең яшьләргә начар йогынты ясау мисалы итеп, Казандагы бер яшьләр төркеменең инглиз флагы күтәреп, инглиз җырлары җырлап йөрүен сөйләде. Тагын биш-алты елдан соң бу идеологиягә бөтен ил белән кочак җәячәгебезне ул вакытта беребез дә күз алдына китерә алмый иде әле.

---

[1] Автор бу сүзнең мәгънәсен җиңеләйтебрәк бирә. Диссидентлар дип кеше хокукларын сакламау, үзгә фикер өчен эзәрлекләү, башка дәүләткә гаскәр кертү һ. б.ны гаепләп СССРда тоталитар режимга каршы чыгучылар аталды. Ред.

Икенче көнне секцияләргә таралыштык: язучылар аерым, композиторлар һәм рәссамнар аерым җыелыштылар. Язучылар секциясен партия өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин җитәкләде. Бу өлегә юньле-башлы бер әсәр дә язарга өлгермәгән булачак каләм ияләренә зур игътибар күрсәтү иде. Секциядә эш үзара фикер алышу тәртибендә оештырылды. Берничә яшь активист (көрәсең, алдан әзерләп куелганнардыр) беркемнең дә кытыгына тими торган шома нотыклар сөйләде. Шулай майлаган кебек кенә барганда, азиат кыяфәтле бер егет торып басты. Бу егетнең сүз алуы түрәләрнең сценариена кертелмәгән иде, ахрысы, каршы өстәлдәгеләр бер-берсенә карашып куйдылар.

—Мин,—диде егет,—күптән түгел генә Ташкенттан күчеп кайттым. Хикәяләр яза идем. Әзер хикәямне тотып Казанда редакциягә бардым. Укып чыктылар. «Шәп хикәя язгансың. Ләкин моны бу хәлдә бастырып булмый, су куш син моңа, су куш»,—диделәр. Икенче редакциядә дә шул ук хәл кабатланды, һәркайда хикәямне мактадылар һәм ахырдан, бастырырлык булсын өчен, су кушарга тәкъдим иттеләр. Шуннан соң мин хикәяне ташлап, әкиятләр яза башладым.

Зал уңайсызланып көлешеп куйды. Ләкин егет туктарга уйламый иде әле.

—Мин Казанга килгәч, тагын бер нәрсәгә аптырадым,—дип дәвам итте ул.— Сездә татар теле бер дә кулланылмый икән.

Һәм ул татар мәктәпләренең булмавы, татарча кинофильмнар төшерелмәве, татар теленең кулланылыш даирәсенең тарлыгы хакындагы милләтпәрвәрләр үзгәртеп кору башлангач кына күтәрергә җөрьәт иткән четерекле мәсьәләләрне берәм-берәм санап чыкты. Егетнең нотыгы залга көчле тәэсир итте. Семинарда утыручы олпат татар язучыларының башлары аска иелгән иде, алар бер сүз дә эндәшмәделәр.

Егеткә җавапны Мусин үзе бирде. Талантлы кеше иде ул, демагогияне хакыйкать итеп тәкъдим итү остасы иде. Аның чыгышыннан мин шуны аңладым: татарларга татарча кинофильмнар гына түгел, татарча спектакльләр дә кирәкми икән. Академия театрына да күбесенчә наушниклар киеп руслар йөриләр икән... һәм башкалар, һәм башкалар. Алгы рәттә утыручы танылган татар язучылары тагын дәшмәде. Мин аларның барысын да хөрмәт итәм. Алар арасында соңыннан милли проблемаларны Бөтенсоюз күләмендә күтәреп шаулатучылар да булды, һәм мин аларны теге вакыттагы дәшмәүләре өчен дә кискен гаепләмим. Дәһшәтле система иңнәреңнән басып торганда сүз әйтү авыр шул ул. Аның каравы, яшьләр әтәчләнде, егетне теге яктан да, бу яктан да чукыды. Болар барысы да рус телләләр иде. Синең телеңнең каһәрле язмышын алар каян аңласын ди. Егетнең сүзен шулай итеп юкка чыгардылар. Ул берүзе иде шул, аны беркем дә якламады. Ләкин тәнәфескә чыккач, кемнәрдер егетнең кулын кысып, җилкәсеннән кагып киттеләр. Нишлисең, бу кадәресе дә кыюлык иде, әлбәттә.

Юк иде ул заманда татар зыялылары арасында диссидентлар, җәмәгать! 90нчы еллар башында үзләрен совет чоры диссидентлары дип тәкъдим итүчеләр—сугыштан соң күбәюче батырлар кебек кенә иде. Чын диссидентлар 70-80нче елларның төрмәләре, сөргеннәре аша узды.

Шул ук 1982 елның язында мин Горький автозаводында булдым. Горький шәһәрендә яшәүче бер ханым поездның плацкарт вагонында үз шәһәрен мактап барды. Берзаман ул кинәт кенә тынып калды да, як-ягына каранды һәм тавышын акрынайтып: «Беләсезме, Сахаров бит бездә утыра»,—диде[2]. Совет чорының атаклы диссиденты Сахаров исемен мин шунда беренче тапкыр ишеттем. Татар язучылары, Аллага шөкер, ул вакытта барысы да ирektә иде.

Дөньяның барышына карыйм да, тоталитаризмның яңадан баш калкытуын күрәм. Сүз ирегe акрынлап кысылып килә, матбугатта дөреслеккә караганда ялган күбрәк. Эфир да «су кушылган» хәбәрләр белән тулы... Мәктәпләрдә укытучыларның бугазына басып партиягә димлиләр. Бу кадәресе тоталитар КПСС чорында да күзәтелмәгән иде. Кыскасы, яңадан диссидентлар заманы җитте, җәмәгать. Кайда сез, сәламәтлекләрен һәм гомерләрен хакыйкать хакына корбан итәргә әзер торучы татар зыялылары? Халыкка бүген сезнең хак сүзегез кирәк!

[2] А. Д. Сахаров 1980-86 елларда Горький шәһәрендә сөргендә була. Ред.

## Татар кызы

*«Тупас... Кырыс!»—диярсең син мине,*
*Ә син аңлый алыр идеңме*
*Аю сыман таза шушы ирне*
*Аягыннан еккан сөюне?!*

Зөлфәт

Бу вакыйга унҗиде-унсигез еллар тирәсе элек булды. Торгынлык еллары белән шау-шулы үзгәртеп кору чорының очрашкан мәле иде, ахрысы. Казанга бара торган кичке электричкага утырып юлга чыктым. Кыш иде. Урамда төн дисәң дә ярый. Төнге шәһәр яны поездларында кеше аз була. Аларда шундырмы шомлы тынлык хөкем сөрә. Ул тынлыкны кайвакытларда берәр исерек хулиганның тәртип бозуы яисә яшүсмерләрнең үзара тәпәләшүләре өзәргә мөмкин. Минем үземнең, мәсәлән, үсмер малайлар төркеменең үзара мөнәсәбәтләрен ачыклаган вакытка тап булганым бар. Шунысы яхшы: алар гадәттә чит кешегә игътибар итмиләр, үзара гына «аңлашалар». Мондый «аңлашу»да инде, әлбәттә, йодрык аргументы төп рольне уйный.

Бүген мин вагонда ялгызым диярлек. Дөрес, аргы баштарак шыпырт кына утырган тагын бер-ике пассажир бар. Менә аларның берсе, урыныннан кузгалып, миңа таба атлый башлады. Аю гәүдәле, көрәк куллы, күзендә нур әсәре юк. Туп-туры минем янга килеп көрәк кулын сузып күреште дә авыр уфылдап каршыга утырды. «Син мине тыңларсыңмы?»—дип башлады ул сүзен. Тез буыннарының калтырануын сиздермәскә тырышып, тыңларга әзер икәнлегемне белдерәм. Мондый очракта тыңламау үз-үзеңә хәтәр хөкем чыгаруга тиң булуы бар. Юлдашым шактый яшь күренсә дә, ике бала атасы икән инде. «Балалар яныннан китеп барам,—диде ул, йодрыкларын әрнүле кысып. Күзләрендә тирән сагыш чагыла, шул сагыштан бугай, сызланулы рәвештә йөз сызыклары җыерыла, әрнүле газап, газаплы әрнү бөтен тәненнән бөркелгәндәй булып китә.— Хатыным техникумда укый минем, читтән торып. Беләсеңме, менә шул гулять итә. Ачыктан-ачык, бөтен кеше алдында. Баштарак сизмәдем. Хәзер бөтенесе дә бетте. Аңлыйсыңмы, татар кызы бит ул... татар кызы!» Аю гәүдә соңгы сүзләренә бөтен җан сызлавын салып әйтә, төйнәлгән йодрыклары тез өстендә уйнап-уйнап ала. «Их, төкерер идем мин аңа. Балалар җәл. Менә бүген дә өйгә кайттым, ишек бикле, балалар әчтә ач утыралар. Тәрәзәдән карап йөрдем-йөрдем дә, китеп барыш менә».

Шактый күп еллар узгач та шушы ирнең газаптан кыйшайган йөзе күз алдымнан китми, «Татар кызы бит ул... татар кызы!..»—дигән сүзләре һаман колакта яңгырый. Безнең менталитет татар кызы саф, тыйнак, мәхәббәттә турылыклы дип формалашкан иде. Ул елларда да бу рәвешле фикерләү, тормыш моның киресен инде бер генә тапкыр исбатламаса да, милләт кызларының күптәннән килә торган асыл сыйфатлары үзенә күрә бер символик образга тупланып, күп күңелләрдә яши иде әле. Һәм безне дә яшәтә иде, ахрысы.

Бүген без татар кызларының «досуг» оешмаларында төнге сменада эшләвенә күнегеп беттек шикелле. Дөрес, ак яулыклы, озын итәкле татар кызлары да хәзер аз очрамый. Уңнан да, сулдан да боларга да тәнкыйть ява. «Татар кызы болай киенергә тиеш түгел, татар кызы түгел, түгел...»—дип үзләренең гарип фикерләрен газета битләренә менгерә кайбер абруйлы авторлар. Чынлап та, нинди булырга тиеш соң ул?! Татар кызын шәригать кануннарыннан арындырып, иркле итү идеясен беренче тапкыр бөек әдип Фатих Әмирхан күтәреп чыкты шикелле. Әдәбиятта башлап татар кызына декольте күлмәкне дә шул киертте төсле. Шуннан соң татар кызы ирләр урынына урман кисте, юллар төзеде, бүсере чыкканчы җир сөрде,. Боларга кем гаепле иде? Сорау ачык килеш кала.

## Цивилизацияле халык

Себергә мин бер генә тапкыр сәяхәт иттем. Юлга чыкканчы ук кисәтеп куйдылар: Екатеринбургка кадәр юлың тыныч булыр, теге ягына чыккач, сак бул, анда тынычлык күрмәссең, диделәр. Сүзләре рас килде. Урал башкаласына

кадәр плацкарт вагонда тынычсызланырлык берни дә юк иде шикелле. Үзебезнең татарча сөйләшүләр дә ишетелгәли, исерек йөзләр дә күренми диярлек, проводница хатыннар да, пассажирларга хезмәт үк күрсәтмәсәләр дә, кайнаган су һәрвакытта диярлек бар: үзең ясап чәй эчәргә була. Рәсәйдә шуннан артыгына өмет иткән дә юк инде аның.

«Свердловск—Приобье» поездына күчеп утыргач, хәл үзгәрде. Көндезен чагыштырмача тыныч иде әле. Иң әүвәл күзгә ташланган яңалык: биредәге халык бер-берсен әйбәт үк белә булып чыкты. Болар, күрәсең, вахтага йөреп эшләүчеләрдер. Кичкә таба вагонда хәлләр акрынлап «куера» барды. Аек йөзләр сирәгәйде, шау-шулы сөйләшүләр җәнҗаллы талашларга күчеп китkәләде. Карта уены, исерек оргияләр... Кайсы проводник та кайсы пассажир икәнлеген аерып булмаслык иде. Һәм берәү дә йокларга җыенмый иде, ахрысы. Йөрәктәге шомны басарга тырышып, бераз черем итеп алдым. Газаплы төн үтте, иртә җитте. Обь елгасына якынлашкан саен, пассажирлар саны кимү сәбәпле, вагон бушый һәм тынычлана төште. Әмма җирәнгеч кыланышлар туктап ук бетмәгән иде әле. Боларны мин, күрәсең, өнәмәвемне чыраема чыгарып күзәткәнмендер. Сәрхуш булса да, акылын җуеп ук бетермәгән бер рус егете яныма килеп утырды. Мин кичтән үк үземнең Татарстаннан икәнлегемне әйткән идем инде. «Син,—дип миңа эндәште егет,—борчылма. Сез татарлар бит—Европа, цивилизацияле халык. Безнең табигатьне син аңлый алмассың. Без—кыргыйлар инде". Егетнең күз карашы сагышлы иде. Рус кешесе авызыннан милләтемә карата мондый бөек бәяне беренче тапкыр ишетүем иде.

## Татар тәкъдире

Казандагы танышлардан берәүнең улын армиягә алдылар. Беренче чечен сугышының башланган еллары иде бу. Рус империясе аз гына йомшарып торганнан соң, ике башлы каракошның яңадан милләтләр тәненә тырнакларын батырып, җелекләрен суырырга талпына башлаган чаклары. Армиядә татар егетләрен бик хәтәр кыйныйлар икән, җитмәсә, чечен сугышына җибәрелү дәһшәте дә җанны бимазалый. Егет тәртипле, инсафлы гаиләдән, тик әтисе вафат инде. Яклау сорап хатларны әнисенә яза. Ә әни кеше бик үткен хатын. Хәер, мондый хәлдә әти кеше булса да, әллә ни майтара алмас иде. Солдат әтиләре комитеты юк бит. Аналар комитеты исә ул елларда бик актив. Егетнең әнисе дә күп уйлап тормый, Чиләбе якларында, «учебка»да булган улы янына китә. Туп-туры часть командирына кереп, улын хәрби хезмәтне үтү өчен Казанга җибәрүләрен таләп итә. Тегесе, әлбәттә инде, ризалашмый, уку-өйрәнүне «бишле»гә генә тәмамласа, улыңны үзе теләгән җиргә җибәрәчәкбез дип, алдап-йолдап котылмакчы була. Егет тә төшеп калганнардан түгел, шәһәр малае бит, биредәге шартларда татар малаена «бишле»гә уку мөмкин түгеллеген командирның йөзенә бәреп әйтә. Татарларга гына түгел, Татарстаннан килгән рус егетләренә дә көн юк икән частьта. Шулай итеп, Татарстанның суверенитет өчен тыйнак кына көрәше армиядәге ватандаш егетләрнең башына гөрзи булып төшә икән. Чистайдан алынган рус егете дә әнә татар хатынына ялына, минем турыда кайтып әнигә генә әйтегезче, тик ул мине моннан килеп йола алмас инде, бик юаш бит дип өзгәләнә икән. Әни кеше улына киемнәр дә алып килгән була. Улын увольнениегә алып чыгып китә. Чыгуга киемнәрне алыштырып, берничә чакрымдагы станциягә җәяүләп элдертәләр болар. Арттан машина тавышы ишетелүгә кар көртенә чума идек, дип сөйләделәр соңыннан. Мең газап белән Казанга кайтып егылалар. Кайтуга хәрби комиссариатка барып хәлне аңлаталар. Казанда акыллы хәрбиләр эшләгән, күрәсең. «Күршеләрегезне кисәтегез, частьтан эзләп килсәләр, Чиләбегә киткән иде, кайтмады әле, дип әйтсеннәр, үзегез берәүгә дә ишек ачмагыз,»—дип өйрәтеп җибәрәләр. Нәкъ шулай эшлиләр дә. Чиләбе хәрбиләре килеп, ишек төбендә озак кына кыңгырау чылтыратып торалар да, күршеләрнең ишекләрен ачтырып, алар белән сөйләшәләр һәм кайтып та китәләр. Егет шуннан Казанда хезмәт итә башлады. Хәрби хезмәтне ошатып, өч елга контракт та төзеде әле. Өенә кайтып йоклап, гарнизонга хәрби хезмәткә генә бара иде. Тик мондый бәхет озакка сузылмады, аны тоттылар да Чечняга командировкага җибәрделәр, тәкъдирдән котыла алмады. Контракт төзелгәч, баш тартып булмый шул. Аллага шөкер, исән калды тагын.

## Марилар

Участок хастаханәсендә терапевт булып мари кешесе эшли. Бик тә таләпчән, авыруны дәвалауга фидакарьләрчә бирелгән табип. Русчасы әйбәт, йөз-чалымда да милли үзенчәлек сизелми, кыскасы, әйтмәсәләр, рус кешесе дәвалый дип йөрер идем. Беркөнне палатага мари агаен салдылар. Монысының, татар авылында туып-үскәнлектән, татарчасы да яхшы ук, үз телен дә онытмаган, кирәк булса, русча да сукалый. Иртәнге обход вакытында мари табип мари пациент янына килеп утырды һәм болар үз телләрендә сөйләшеп киттеләр.Йә, Хода! Йөзләреннән нур агыла, гәпләре җылы, ягымлы, карашлары мөлаем, самими! Табиптагы бу кадәр кечелекне, пациентны олылауны моңарчы күргәнем юк иде. Бөтен палата, тын калып, телләрен аңламаса да, боларны күзәтте. Кешенең игелеклелеген саклыйм дисәң, теленнән аерма икән. Ана телен онытучылар—бәхетсез, аны кирәккә санамаучылар—ахмаклар, оныттырырга тырышучылар—ерткычлар, дигән фикергә килдем мин бу ике марига карап.

## Такта һәм без

Без инде суверен булдык дип аякны нык басып йөргән чаклар әле. Дөрес, татар эстрадасында дәүләтчелегебезне «сувенир дәүләт» дип сүз уйнатучылар да булгалады. Әмма шәһәрләрдә урам исемнәре язылган такталарның хаталы булса да русчасы астына татарчасын куя идек инде. Хәтта Комлев урамына да «Мөштәри» дип татар исемен кушуга кадәр барып җиттек. Менә шул урамның 14нче йорты каршында язучы Марат Закирны көтеп торам. Бинаның диварына «Татар язучылар йорты» дигән такта куйганнар. Ә менә русчасын әллә кирәк дип санамаганнар, әллә онытканнар (хәзер анысы да бар инде).

Урамнан яшь кенә бер хатын үтеп бара. Йорт янында туктап, русча: «Монда ни язылган?»—дип сорады. Мин язуны татарча укып бирдем. Хатын үз теленә тәрҗемә итүне таләп итә. «Дом татарских писателей»—дидем мин. «Ник русчасы юк аның?»—ди теге, ярыйсы ук кыза башлап. Мин никтер җавапка сүз тапмыйм. Ул арада хатын Президент Шәймиевнең астыртынлыгы һәм мәкерлелеге, татарларның хәйләкәрлеге, Казанда русларга шартларның яшәп булмаслык икәнлеге турында ярсулы һәм нәфрәтле нотык та тотып алды. Баштарак мин дә бу хатынга нәфрәтләндем. Хәзерге акылым белән соңга калып булса да уйлыйм: сокланырга кирәк булган икән аңа. Әгәр татар үз телен шулкадәр дә изүгә шулай нәфрәтләнә белгән булса, телебез мескен хәлгә калыр иде микән?

## Тамырларны эзләү

1947 елдыр бу. Әтинең сугыштан кайткан вакытлары. Бу турыда мин, әлбәттә, ишетеп кенә беләм. Күп гаиләләр сугыштан улларын, әтиләрен каршы ала алмый. Ә минем әби бер улын озатып ике егет каршылаган. Кайтканда әтигә үзенең милләтен ачыклый алмыйча интеккән бер егет ияртә. Документлары буенча рус икән теге, ләкин рус булуы белән һич кенә дә килешәсе килми ди. Балалар йортында үскән ул. Тамырлары кайдан икәнлеген хәтерләми, ләкин татар нәселеннән булырга тиешмен дип әйтә ди. Менә шулай әтигә ияреп татар авылына кайтып төшкән дә (бәлагә тарыганнарны ияртеп кайту гадәте үлгәнче бетмәде әтинең), татарча өйрәнеп бездә яшәп тә яткан әле бераз. Әмма сугыштан соңгы авыр еллар бит. Татарның үзенең ничек итеп булса да башын алып авылдан качарга дип йөргән вакытлары. Әлеге егет тә каядыр китеп югалган. Татар оптом руслаша башлагач, ниятеннән кайтмадымы икән ул?

Тагын бер мисал. Мәскәүдән авылга бер егет кайтып йөри. Чибәр генә үзе, башына түбәтәй киеп мәчеткә дә килгәли. Әтисе чыгышы белән шушы авылныкы. Инде мәрхүм. Егетнең күз карашы уйчан, моңлы, йөзендә безнең өммәт кешесенә генә хас булган нур да бар. Татарчасы ташка үлчим генә, күп нәрсәне аңлап та бетерми бугай. Ләкин тамырларга тартылу көчлегә охшаган. Йә ахшамнан, йә йәсигътан соң, Аллаһка башларны сәҗдәдә игәч, үз яшьләре тирәсендәге Нияз белән ислам нигезләрен өйрәнеп калалар. Русча сөйләргә туры

килә инде моңа, нишләтәсең. Хәер, иманга кайткан егетнең телен табуга да өмет бар. Иншаллаһ, татарлыгын да онытмас, телен дә өйрәнер. Татарча сөйләшеп тә, татарлыгын оныткан милләттәшләр дә җитәрлек бит әле.

## Эстоннар

Эстоннар бер миллион тирәсе генә икән. Безнең татардан әллә җиде, әллә егерме тапкырга азрак булып чыга. Болар үзләренең төгәл саннарын беләләр инде. Шуларның бер кыйпылчыклары аерым авыл булып Россиядә, Краснодар крае тирәсендә яшәп ята ди. Затлы яхшы коттеджлар, һәркайда чисталык, телләре эстонча, киемнәре милли. Ә безнең татар... Киемнәре театрда, теле...

## Адашканга юл бармы?

*Нәфрәт кисәгедәй*
*Тешен кыскан кисәү,*
*Сонгмилар калка.*
*Калка әллә ничәү...*
Мөдәррис Әгъләмов.

Әфганстаннан совет гаскәрләре чыгарылуның унбиш еллыгын без әле күптән түгел генә билгеләп үттек. Вакыт яраларны акрын гына дәвалап килә, күп нәрсә онытылып бара. «Данлыклы совет сугышчылары»ның бу илдә күрсәткән батырлыклары турында коммунистик пропаганда уйлап чыгарган мифлар да шулай итеп акрынлап тарих тузаны астында күмелә башлады. Сиксәненче елларның урталарында татар театры сәхнәсенә «Зөлфия» исемле спектакль менгән иде. Социаль заказ буенча иҗат ителгән бу тамашаны телевидение аша да күрсәттеләр. Хәтерлим әле, без, торакның бер бүлмәсендә яшәүче өч студент, телеэкраннан шуны тамаша кылып утыра идек, бүлмәгә курсташ кызларның берсе янына килеп йөри торган «әфганчы» егет килеп керде. Экранга текәлеп күпмедер карап торды да: «Егетләр, юкка вакыт әрәм итмәгез, тоташ ялган бу,»— дип чыгып та китте.

«Әфганчы» егетләр әфган хәлләрен искә алырга яратмыйлар. Тик шулай да «шуравилар» кайвакыт, күңелләрен бушатырга теләгән чакларына туры килгәндә, пропаганда буяуларыннан азат булган ялангач хакыйкатьне дә әйтеп ташлаштыргалыйлар. Мондый чакта гадәттә хакыйкатьнең шәрәлеге «каз тәне» чыгарырлык, аркадан кырмыскалар йөгертерлек була. Бервакыт шулай ике «әфганчы» егет исерек совет солдатларының ничек итеп танк пушкасыннан ату ярышы оештырып уйнаганнары хакында сөйләделәр. Берниндн максатсыз, бары тик азгын күңел таләбенә буйсынып кына, алар як-якка, хәтта тозәп тә тормыйча, снаряд арты снаряд җибәргәннәр. Аларның бу «шаярулары» төнге тынлыкта йокыга талган әфган авылына кыйбатка төшкән: йортлар җимерелгән, хатыннар һәм балалар һәлак булган.

Без Җир шарының төрле почмакларында урнашкан, төрле милләт вәкилләре яшәгән Хатынь, Сонгми, Орадур кебек авылларның фаҗигаләре турында укып үстек. Совет шагыйрьләре бу ерткычлыкларга нәфрәтләнеп йөзләгән ярсулы шигырьләр иҗат иттеләр. Евгений Евтушенконың "Хотят ли русские войны?" шигыре кайчандыр ничек популяр иде! Икейөзле Көнбатыш цивилизациясе тарафыннан соңгы елларда гына варварларча җимерелгән Гыйрак һәм Әфгандагы торак пунктлар фаҗигасе хәзер ни рус, ни француз шагыйрьләрен илһамландырмый, канга баткан чечен авыллары һәм шәһәрләре хакында да музалар дәшми.

Ләкин сүзем бу хакта түгел иде бит. Темага этәргеч биргән вакыйга моннан берничә ел элек рамазан аенда авыл мәчетендә булды. Ул елны, гыйлемле яшь егетләргә ияреп, мин дә җәмәгать белән укылучы тәравих намазына йөри башлаган идем. Ясигъ намазы вакыты инде кергән иде. Без мәчеттә икәү генә. Тагын килүчеләр булмасмы дип азаннан соң бераз көтеп утырырга булдык. Намазга басарга дип торганда гына, ишектән таныш булмаган бер егет килеп керде. Кул биреп күрешкәннән соң, ул мине мәчет коридорына чакырып чыгарды. Егетнең әйтәсе сүзе бар икән һәм ул аны, күрәсең, очраган бер ке-

шегә сөйләп йөрергә теләми иде. Инде чалара башлаган чәчем ышаныч уятты, ахрысы, серен миңа ачарга булды ул. Чынлап та, авыр иде бу сер. Әгәр дә гыйбрәт алырлык әһәмияте булмаса, мин аны язып та тормас идем. Егетнең исемен һәм туган-яшәгән урынын әйтми калдырганга, персонажыма моның начар шаукымы тимәстер, шәт.

—Мин,—диде егет, сүзен башлап,—тыела алмыйча эчәм. Яратып йөргән кызым да күптән кияүдә инде, өйләнгәнем дә юк.

Мин яңа танышымны юатырга, тормыштагы бөтен авыр хәлләрдән чыгу юлы барлыгына ышандырырга тырышам.

—Әле иң әһәмиятлесен әйтмәдем,—диде егет моңа каршы һәм миңа бераз сынап карап торганнан соң сүзен дәвам итте.—Минем... кеше үтергәнем дә бар. Суеп. Берне генә дә түгел.

Мин әллә ышанып ук бетмим, әллә сүзнең мәгънәсе баш миендәге тиешле урынга барып җитми, йөзем үзгәрешсез кала. Бу тынычлыгымны танышым үз файдасына кабул итә.

—Әфганстанда хезмәт иттем мин. Шунда әсирлеккә төшкән мөселманнарны суярга туры килде.

Бармаклары белән минем бугаз төененнән тотып күрсәтә дә дәвам итә:

—Менә моннан пычак тыгып җибәрә идек тә актарып чыгара идек. Каннары чәчрәп китә иде. «Аллаһу әкбәр,»—дип үлделәр барысы да. Инде хәзер миңа нишләргә?—ди ул, моңлы күзләрен миңа төбәп.

—Тәүбә итәргә дә намазга басарга,—дим мин, башка җавап тапмагач.—Аллаһ—кичерүче. Иншаллаһ, кичерер.

Ул вакытта әле җавабымның дөреслегенә үзем дә ышанып бетми идем. Ләкин әңгәмәдәшемнең газаптан җыерылган йөзе бераз язылып китүенә карағанда, аңа бу сүзләр уңай тәэсир итте кебек. Бары тик берникадәр вакыттан соң гына мин Вәхши атлы гарәпнең тарихы белән таныштым һәм теге вакыттагы җавабымның дөрес булуына инандым.

Мөселманнарның каферләр белән Өхед тавы янындагы сугышында мәҗүсиләр ягыннан торып сугышучы Вәхши дигән кол пәйгамбәрнең (с. г. в.) абыйсы Хәмзә ибне Абдул Моталлипны арттан сөңге ыргытып үтерә. Вәхшинең сөңгесе пәйгамбәребезнең яраткан абыйсын үтәли тишеп, эченнән чыга. Вакытлыча җиңүгә ирешкән мәҗүсиләр соңыннан мөселманнарның үле гәүдәләрен мәсхәрәлиләр. Вәхшинең хуҗасы Хәндә исемле хатын Хәмзәнең эчен яра һәм бавырын чәйни башлый. (Мәгълүмат Ибәд-ар Рахмән җәмгыяте тарафыннан эшләнгән «Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы» дигән китаптан алынды) Вакытлар үтү белән Вәхшидә күңел газаплары башлана һәм ул, исламга килергә ниятләп, Аллаһның илчесенә хат яза. Исламият тарихында Вәхшинең икеләнүләр белән тулы хатларына җавап рәвешендә Аллаһтан иңгән Коръән аятьләре билгеле. Аларда сүз адәм баласына тәүбә итеп исламга килү юлларының беркайчан да ябык булмавы хакында бара. Кем идең син, мәҗүсиме, коммунист-атеистмы, эчкечелек һәм зина баткаклыгына төшеп баттыңмы, имансызлыгың белән башка төр җинаятьләр кылдыңмы, адашканга туры юл һәрвакыт бар, ул - Раббыбыз тарафыннан безгә җибәрелгән Коръән юлы. Бары тик ихлас бул да тәүбәгә килергә онытма, гөнаһларыңнан ваз кич, аларны кабатлама.

Боларны язуымның максаты шулдыр: еш кына безнең замандашларыбыздан кайберәүләр, тәкәбберләнеп, фәлән мәчетнең имамы элек коммунист иде, мин шуның артыннан намазга басыйммы дип, үзләренә исламга юлны бикләп куялар. Коммунистик томаналык елларында без барыбыз да адашуда идек. Адашканга туры юлны эзләү хәерледер. Ә инде бәндәләр кальбендә ни барын белүче Аллаһтыр. Без инде күпме генә бәндә җанына үтеп кереп, аны тикшерергә, бәһаләргә яисә хөкем чыгарырга тырышсак та, бу безгә бирелмәгән. Бәс, шулай булгач, имамнарның хәлен дә Аллаһка тапшырыйк һәм үз кальбебездәге тәкәбберлектән котылу юлларын эзлик. Тәкәбберлек—Иблисне хурлыкка төшергән һәм тәүбәдән читләштергән сыйфат.

## «Йонлач кул»мы, ришвәтме?..

Без, элеккеге совет гражданнары, бер-берсенә капма-каршы һәм дошман булган ике системада яшәү «бәхете»нә ирештек. Көнләшерлек һәм кызыгыр-

лык «бәхет» түгел бу. Системаларның икесе дә адәм баласының табынуга булган ихтыяҗын эксплуатацияли. Нәрсәгәдер «кол» булу һәм табыну - кешелекнең табигый омтылышы, коммунизм аны үзенчә, капитализм исә үзенчә файдалана. Төптәнрәк уйлап карасаң, бу ике системада яшәү бер үк киемнең бер очракта сул ягын, икенчесендә уң ягын әйләндереп кию белән бер. Шуңа да системаларның берсе дә кешегә табигый тынычлык һәм рухи үсеш бүләк итә алмыйлар, һәр ике очракта да тормыш адәм баласының деградациясе, шәхеснең таркалуы белән тәгәлләнә. Бары тик гомуми агымнан читтә калуга һәм табыну объектын дөрес сайлауга ирешкәннәр генә стресларсыз яшәп, фани дөнья белән тыныч саубуллаша ала. Таныйк: мондыйлар үтә сирәк очрый.

Коммунистик режим кумирлар тудырып, шуларга гыйбадәт кылуны алга сөрә иде. Югары урындагы җитәкчедән пот ясап, тормыштагы четерекле мәсьәләләрне шул хәл итә дип ышанып яшәү юлбашчыга ярарга тырышу, ничек булса да аның яхшы мөгамәләсенә ирешергә омтылуга китерә. Тыштан гына булса да «өстен зат»ка мәхәббәтеңне белдерү, аңа һәрдаим тәлинкә тоту, дошманнардан донос һәм анонимкалар язып үч алу, көнчелек һәм астыртынлык—коммунизмда шәхес деградациясенең төп билгеләре... Адәм баласының мондый түбәнлекләргә төшүе миллионнарның ГУЛАГ лагерьларына ябылуы, сәламәт килеш психиатрик хастаханә корбаннарына әйләнүе белән тәгәлләнде. Шуңа да большевистик режимда «хакыйкать эзләү» кыйбатка төшә иде. Мондыйларга ике генә юл бар: йә сәяси тоткыннар өчен махсус лагерьларда зек буласың (мондый лагерьлар Горбачев «перестройка»сының беренче елларында да бар иде әле), йә тиләләр йортының пациентына әвереләсең. Шуңа күрә донос төсендәге имзасыз хатлар коммунизмда иң үтемле көрәш чарасы булып санала, югарыдагы җитәкченең сиңа мөнәсәбәте тормыштагы урыныңны, җәмгыятьтәге рейтингыңны билгели иде.

Коммунистик торгынлык елларында шуңа да кешенең абруен билгеләү өчен «блат» дигән сүз кулланыла башлады. «Аның блаты бар»,—дип әйтү кешегә кызыгып һәм хөрмәт белән карарга мәҗбүр итә, чөнки «блаты булганнар» белән танышлык үзе дә яртылаш блат дигән сүз, «минем блатым бар» дигән гыйбарә мактану, тормышта «урын»ың бар икәнлеген белдерү өчен кулланыла. Блат бар нәрсәне лә хәл итә дип исәпләнелә: вузга керү, карьера ясау, машина алу, затлы тауарларга ирешү, коммунизмның соңгы елларында исә трусик йә оекбаш алу кебек «мәсьәләләр» дә танышлык хисабына тормышка ашырылалар, шуңа да акча икенче планда йөри. Йөз «Жигули»лык акчаң булса да, блатың булмаса, машинага тиенүең икеле.

Блатның иң югары дәрәҗәсе булып «йонлач кул» санала. Бу инде иң югары урындагы җитәкчеләрнең протекциясеннән файдалану дигән сүз. «Йонлач кул» төрмәдәге пахан кебегрәк инде ул, җылы урын һәм башка коммунистик «мафиозилар»дан кагылгысызлыгыңны гарантияли. Блаты булганнар белән еш очрашырга туры килсә дә, «йонлач кул» белән бәйле бер генә истәлек сакланып калган.

Сиксәненче еллар башында пединститутка, безнең факультетка укырга кергән ике йөздән артык студент арасында озын толымлы, тыйнак кыяфәтле бер кыз бар иде. Шәһәр мохитенә килеп эләккән башка авыл кызларыннан аермалы буларак, ул толымын кистереп, кыяфәтен station алай кисәк кенә үзгәреп китмәде. Болай «аһ» итәрлек үк чибәр булмаса да, күрәсең, тышкы кыяфәтендә ниндидер бер үзгә сөйкемлелек булгандыр, курсташларыннан берсе, тыйнак һәм чибәр генә егет, аңа игътибар итә башлады. «Миңа шундый озын толымлы кызлар ошый», - диде ул бервакыт ачылып китеп һәм берничә тапкыр аның «озын толым» белән сөйләшеп торганы да күренде. Ләкин мөнәсәбәтләр шул сөйләшеп торудан узмады кебек, егетебез кызга ничек тиз якынайган булса, шулай ук тиз ерагайды да. Ихтимал, кызның эчке дөньясында егетне ераклашырга мәҗбүр итәрлек ниндидер ямьсезлек тә булгандыр, ул кадәресе безгә караңгы.

Студентлыкның беренче айлары акрын гына үтә торды, «озын толым» башкалардан бик аерылып тормыйча гына лекцияләргә йөрде, чәчрәп чыгу, коллективта үзеңә аерым урын дәгъвалау кебек сыйфатлар аңа ят иде, ахрысы, хәтта бөтен кеше ишетерлек итеп сүз сөйләгәне дә булмады. Болай бик йомыкый да түгел иде кебек ул үзе, бәлки, аның безгә тыйнаклык булып тоелган сыйфаты

үзен башкалардан өстен саный торган яшерен тәкәбберлек кенә булгандыр. Күпмедер укыгач, тыйнак кыз үзгәрде, лекцияләргә сирәгрәк йөри башлады, бераздан аның ялгыш юлга басуы турында имеш-мимеш, гайбәтләр дә ишетелгәли башлады. Андый кызлар булгалый, лекцияләргә йөреп, зачет-имтиханнарын тапшырсалар, алар укуларын уңышлы гына дәвам итәләр. Нык үскән социализм җәмгыятендә кызларның һәм егетләрнең тотнаксызлыгы инде алай кискен гаепләнми, вак-төяк гайбәтләр сөйләнелә дә онытыла иде. Безнең «озын толым» исә факультетның комсомол комитетында тикшерүгә куелды, чөнки ул икенчеме, өченчеме курсларда дәресләргә йөрүдән бөтенләй диярлек туктады. Башка кимчелекләргә күз йомылса да, дәресләргә бөтенләй үк йөрмәүне гафу итеп булмый иде: кулга диплом алу өчен имтиханнар тапшыру кирәк бит. Шулай комсомол комитетының активисткалары очып кунып юлдан язган «тыйнак кыз»ны тәрбиялиләр, яныйлар, куркытырга тырышалар.«Озын толым» исә аларны гадәтенчә тыныч кына тыңлап тора. «Тәрбия сәгате» күпме баргандыр, ахырдан кызыбыз бер җөмлә белән бөтен комитетны телсез итте. «Сез барыбер мине берни эшләтә алмыйсыз, чөнки минем «йонлач кул»ым бар»—диде ул. Комсомол лидерлары, «йонлач кул»га каршы нинди карар чыгарырга да белмиләр, аптырауларын факультетның партком секретарена җиткерәләр. ишеткәч, ул да авыр гына көрсенә: «Аһ, шул «йонлач кул»ы турында сөйләп йөрмәсә иде ул»,—ди дә тына. Мәсьәлә шуның белән ябыла. «Йонлач кул»га аркалану толымлы кызны кая кадәр алып барып җиткергәндер, анысын хәтерләмим, соңгы курсларда ул факультетта күренми иде шикелле.

Социалистик вуз тәмамлаган безнең буын хезмәт юлын капиталистик җәмгыятьтә дәвам итте. Кыйммәтләр алышынды, табыну объекты үзгәрде, һәркемгә мәгълүм: хәзер инде ул—акча, мал, байлык. Танышлык белән генә нәрсәдер хәл итү нык кыенлашты, күп очракларда бөтенләй мөмкин дә булмый башлады, "блат" сүзе дә кулланылыштан акрынлап төшеп калды. Туксанынчы елларның икенче яртысында мин, бик үтенеп сорагач, танышлардан берсенең кызын югары уку йортына урнаштырырга омтылып карадым. Вуз профессорлары белән мәсьәләне хәл итәргә тырышу катлаулы булып чыкты, кызның сәләтлелеге һәм аның конкурстан төшеп калуы гаделсезлек булачагы турындагы дәлилләремне колак яныннан гына үткәреп: «Метафоралар белән сөйләшмә, күпме түлисез?»,—дип мәсьәләне кабыргасы белән куйдылар. Ришвәт галиҗәнапләре инде хакимлекне үз кулына тәмам алып бетергән, намусны акчага алмаштыру гадәти күренешкә әйләнгән иде. Бу хурлыклы, нәтиҗәсе коточкыч булган "педагогик ришвәт"кә татар әхлагы да киртә була алмады, мондый сатулашулар безнең милли телдә дә бик матур бара икән!

Әлеге вакыйгадан соң миңа тагын бер-ике тапкыр югары уку йортына керүдә ярдәм сорап мөрәҗәгать итеп карадылар. «Ришвәт алмыйм һәм бирмим, арадашчы да булмыйм»,—дигән катгый җавaптан соң мондый үтенечләр тукталды. Бүген инде вуз конкурслары ачыктан-ачык «акча янчыклары конкурсы» дип атала, укырга кергәндә ришвәт бирү кирәклеге берәүне дә гаҗәпләндерми, «акча барысын да хәл итә» дип исәпләнелә.

Вузга урнашу күмәк психозга әйләнде, белеме бармы-юкмы, сәләтлеме, түгелме, бала уку йортына урнашсын—әти-әнинең төп хыялы шуңа әйләнде. Югарыдагы җитәкчеләрнең ел саен коррупциягә һәм ришвәткә каршы сугыш игълан итеп торулары хәлне аз гына да уңай якка үзгәртмәде һәм үзгәртәчәгенә ышаныч та аз. Танылган юмористларның берсе прокурор турындагы миниатюрасын сөйләп кеше көлдереп йөри бит әле. Аның кыскача эчтәлеге болай: прокурор җинаять эшен япты, чөнки тикшерә торгач, җинаятьнең очы прокурорның үзенә барып чыкты. Ришвәт белән көрәш тә шуңа охшаганрак: ришвәтчеләр ришвәтчегә каршы көрәшә һәм нәтиҗәдә, билгеле, инде ришвәтче җиңеп чыга. Мәгариф системасындагы ришвәтчелекне туктатырга тырышып, бердәм дәүләт имтиханы да кертеп карадылар, нәтиҗәсе—өметсез. Имтихан ришвәтчелекнең һәм күз буяуның спираль буенча үсешен генә китереп чыгарып төсле. Моны Мәгариф министрлыгының рәсми сайтындагы аналитик язмалар да раслый. Шул ук сайтта нинди «хезмәт» өчен күпме түләргә кирәклеге хакында мәгълүматларны да табарга була, мәгариф системасындагы рэкетның масштабы белән дә таныша аласың.

Ә болай үзе ришвәтчелекне киметү өчен артык зур акыл да кирәкми төсле.

Әйтик, ришвәтчелекнең иң үзәккә үткән ике тәренең тамырына балта чабу өчен дәүләт күләмендә бер карар кабул итү дә җитәр иде. Илнең армиясен профессиональ нигезгә күчерү турындагы карар мәгариф системасындагы ришвәтне туксан тугыз процентка, ә хәрби комиссариатлардагы ришвәтне 100 процентка юкка чыгарыр иде. Чөнки күзе-башы тонган яшьләр вузга ашкынуның нигезендә рус армиясендәге вәхшилекләр ята. Шул вәхшәттән улын коткару өчен актык сынык ризыгын бирергә әзер бүген әти-әниләр. Мондый ажиотаж үзеннән-үзе психоз тудыра һәм аңа кызлар да кушыла. Бу психозны соңгы унбиш елда гөмбә кебек үрчегән уку йортлары һәм аларның туктаусыз артып торучы яңа факультетлары да канәгатьләндереп бетерә алмый. Ә менә вузлар саны бернечә тапкыр ким, чыгарылыш класс укучылары артыграк булган 1983-87 елларда хәл бөтенләй башка иде. Күп факультетларда конкурслар юк кына түгел, тиешле сандагы студентлар төркемен җыю да кыенлашкан иде хәтта. Моның сәбәбе дә бар иде, билгеле. 1983 елның язында студентлар өчен «отсрочка» дигән нәрсә бетерелде һәм вуз эскәмиясеннән армиягә ала башладылар. Ләкин бу ысулны бүген кулланырга ярамый. Чөнки ул хәрби комиссариатлардагы ришвәтләр санын һәм күләмен кискен арттырачак. Бүген армиядән котылу өчен алтмыш мең тирәсе түлиләр имеш. (Бу акчага хәрби комиссариат компьютерындагы мәгълүматны үзгәртү, сәламәтлек буенча армиягә яраксыз дип табу кебек «хезмәтләр»не сатып алып була диләр) Элекке саклану министры Иванов та әнә, Россия армиясе—эшче-крестьяннар армиясе ул, дип рәсми рәвештә игълан иткән иде. Бу һич кенә дә эшче-крестьян балаларында патриотлык көчле дигәнне аңлатмый, аларның кесәсе сай дигән мәгънәне генә бирә.

Армиядә хезмәт итү тәртибен үзгәртер өчен саклану министрлыгындагыларга һәм депутатларга күпме төртергә кирәк икән? Ә болай армиядәге «бабайлык» турында чаң сугып матбугат хәрби комиссариат коррупционерларының кесәсен калынайтуга гына хезмәт итә. Профессиональ армиягә күчүгә нәкъ менә комиссариат хезмәткәрләре теше-тырнагы белән каршы. Язын-көзен алтын алма өлгертә торган агачны кисәргә җүләрмени алар!

Эчке эшләр министрлыгы, үз хезмәткәрләрен ришвәттән аралау өчен, аларны тәкъдим ителгән ришвәт күләмендә акчалата бүләкли икән. Инде бернечә милиционер шундый бүләкне алганнар да: кайсы квартирлы булган, кайсы акчалы. Тик моннан соң иң куркыныч җинаять эшләрен дә «җинаять составы юк» дип ябудан туктауга бик өметләнмик әле. Намуслы милиционерлар ришвәт тәкъдим итүчеләрне якаларыннан сөйрәп китерделәр дә ди. Ләкин «албастылар» моңа барыр дигән ышаныч аз. Башларына тай типмәгән бит аларның. Берәү дә ришвәт алмый башласа, тәкъдим итүчеләр дә бетәчәк, һәм, димәк, ришвәт тәкъдим итүчене «сатып» бүләк алу да тукталачак Шуңа да юл хәрәкәте инспекторлары һәм башка хокук тәртибен саклаучылар дәррәү рәвештә ришвәттән баш тартырлар дип ышанырга ярамый. Бары тик ришвәтне сораучылар да, тәкъдим итүчеләр дә саклык чараларын көчәйтәчәкләр һәм ришвәт тегермәне тагын да кызурак әйләнә башлаячак. Чөнки ришвәт малга табынуны байрак итеп күтәргән капиталистик системаның табигый, профессиональ чире ул.

Фәридә
Хәсәнова

# ШИГЪРИЯТТӘ СӘЙДӘШ ЯШИ

*...Бөекләргә таянабыз.*
*Тормыш белән бәхәс чыгып,*
*үзебезне яклаганда,*
*аклаганда,*
*яман сүздән сакланганда...*

Г. Морат

Хәзерге поэзиядә татар халкының гыйбрәтле язмышлы тарихи шәхесләренә багышлап язылган әсәрләрнең күбәюе күзгә чалына. Әйтик, соңгы көннәрдә генә Р. Харисның сирәк талант иясе Рәшит Ваһаповка багышланган «Жырчы» поэмасы аерым китап булып дөнья күрде. Шагыйрьләребез шулай ук Б. Урманче, С. Сәйдәшев, С. Садыйкова, И. Шакиров һ. б. бөекләрне әдәби образга әйләндерүдә бик теләп иҗат итәләр. XX гасыр ахыры һәм Яңа гасыр башындагы шигърияттә бигрәк тә Тукай образын сурәтләүгә аерым игътибар бирелә. Шунысы күңелгә ятышлы: шагыйрьләрдән Тукай образы өстен чыкса, аның янәшәсендә композитор С. Сәйдәшев тә урын ала. Хәзерге татар шагыйрьләре даһиларны исән чакта ук хөрмәтләп калырга омтылалар дип уйларга нигез дә бар. Мәсәлән, Гәрәй Рәхимнең Илһам Шакировка багышлап язылган бер шигыре болай яңгырый:

*Алар безнең, яңа бу заманның,*
*Иң алдынгы сәнгать батыры—*
*Шигърияттә—Тукай,*
*Музыкада—Сәйдәш,*
*Сәхнәләрдә—Илһам Шакиров.*
*Син аларны,*
*Син аларны тыңла,*
*Ваклыклардан әгәр ялыксаң.*
*Яшәүләре—бик тә гади, тыйнак,*
*Сәнгатьләре—бөек, халыкчан.*

Әсәрне кемгә дә булса махсус багышлап язу—дөнья әдәбиятында киң таралган күренеш. Бу жанрга беренчеләрдән булып латин поэзиясендә Гораций мөрәҗәгать итә. Низами, Сәгъди, Сервантес, Мольер кебек әдипләрнең дә бу жанрны үстерүдә өлеше бар. Багышламалар рус әдәбиятында XVIII гасырда рус классицизмы вакытында ук күзәтелә, ә татар әдәбиятында багышламалар, мәдхия һәм мәрсия формасында булып, XIX гасырда күпләп языла башлый. Гали Чокрый исемле шагыйрьнең 500 мәрсия язганы билгеле.

Соңгы елларда гына Лена Шагыйрьҗан, татар халкының күренекле шәхесләренә багышламаларын туплап, «Сагынмаклык» исемле җыентык чыгарды. Әлеге җыентыкта урын алган шигъри һәм чәчмә әсәрләр, истәлекләр, халыкның мәдәният-сәнгать өлкәсендә эшләп, халык тарафыннан танылуга ирешкән зыялы катлам вәкилләре турында. Әлеге шәхесләрне шагыйрә бөеклек, чисталык, яктылык символы итеп сурәтли, әмма идеалга омтылу, аның чынбарлык белән туры килмәвен дә яшереп

тормый. Л. Шагыйрьжан бөек шәхесләрнен анында, тормышында булган каршылыкларга милли-фәлсәфи күзлектән карап бәя бирергә омтыла.

Ркаил Зәйдулла да бер төркем шагыйрьләргә «багышлаулар»ын «Мәгарә»дә бастырды. Мөхәммәт Мирзаның хәтта Хәсән Туфанга охшатып «Улыма», «Кызыма» дигән багышлауларына кадәр бар. Аның иҗатында жырчы Әлфия Афзаловага багышланган поэма да күзәтелә, Салават та читтә калмаган. Ә менә язучы-галимнәргә Рөстәм Мингалим игътибарлы. Аның багышлаулары формасы буенча башкалардан бераз аерыла, аларда юмор хисе «бәреп тора». Илдар Юзеев та 30 лап шигырен багышлаулар тупламасында бирә. Аның багышлаулары мәдхия һәм мәрсиягә тәгәл бүленгән, шигырь юлларына салынган хис-фикер ике төрле аңларга юл калдырмый. И. Юзеев багышлаулары башкорт һәм татар халкының күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренә юлланган булуы белән дә үзенчәлекле. Кыскасы, татар әдәбияты «Багышламалар» үсешен кичерә, дип нәтиҗә ясау да хата булмас.

Ә менә Ренат Харис иҗатында мәшһүр шәхесләргә багышлап язылган әсәрләр «Исәндәдер...» дип аталган аерым бер циклга берләшә. Әлеге цикл үз эченә егермеләп шәхескә багышламалардан гыйбарәт. Шигырьләр арасында язучылардан М. Кәрим, С. Хәким, Ә. Еники, Г. Бәширов, И. Юзеев, Ш. Анак кебекләр, композиторлардан А. Ключарев, Р. Яхин, С. Садыйкова, Н. Жиһанов, И. Мәжитов, М. Яруллин, Р. Ахияровалар күзәтелсә, рәссамнардан Х. Якупов, Ф. Хәсьяновалар урын ала. Шагыйрь жырчыларга да сүздән һәйкәл коя белә. И. Шакиров, В. Ганиева, И. Газиев кебек шәхесләр шигырьләрдә кабатланмас бизәкләр белән истә кала.

Р. Харис, гомумән, сәнгать әһелләренә, сәнгать өлкәсенә гомер буе игътибарлы булуы белән аерылып тора. Бу гади кызыксыну гына түгел. Юкка гына шагыйрь: «Иң беренче хыялым композитор булу иде»,—дип әйтмидер. Шагыйрьне сәнгать дөньясындагы зәвыксызлык күренеше борчый. Шуңа да ул «Тоныкйолдызлар» исемле поэмасын иҗат итте.

Ә бүген сүзебез хәзерге татар шагыйрьләре иҗатындагы Сәйдәш образы турында булыр. Р. Харис иҗатында «Сәйдәш яры» исемле поэма белән бергә «Сәйдәш» шигыре дә күзәтелә. Әлеге шигырьдә шагыйрь Сәйдәш музыкасын халык күңеленең мәгърур моңы дип атый, һәм ул моңның, кеше сынына әверелеп, Казан урамнары буйлап, уйчан гына, тын гына йөреп торуы турында яза.

Поэмага килсәк, анда Сәйдәш үзе турыдан-туры катнашмый. Әлеге зәңгәр күзле, сихри тавышлы образ уналты яшьлек чибәр кыз Бибисара күзаллавындагы истәлекләр аша бирелә. Поэманың исеме—шушы кызның кушаматы. Үзенә музыкадан дәресләр биреп, пианинода уйнарга өйрәткән укытучысы, яшь егет Салих Сәйдәшевкә гүлеп гашыйк булган кыз әнә шундый матур кушамат эләктерә: «Сәйдәш яры».

Туташның йөрәгендә бер күрүдә сөю уты кабызган егет ул чакта әле гади бер музыкант кына була. Шагыйрь Сәйдәшнең турыдан-туры портретын һәм характерын күрсәтми, шулай да Буа кызының жылы истәлекләре һәм авторның әледән-әле композиторның зәңгәр күзе белән моңлы музыкасына әйләнеп кайтуы геройның тышкы кыяфәте дә, характеры да үтә уңай булгандыр дип уйларга урын калдыра. Әсәрдәге романтик хис нәкъ менә шул «зәңгәр» сүзенә барып тоташкан шикелле тоела башлый, хәтта бу сүз матурлык символы гына түгел, моң мәгънәсен аңлатуга ук дәгъва иткәндәй була. Әлеге символ бер җирдә «йөрәкнең зәңгәр күзе тәрәзләрдән истәлекләр эзен эзли» рәвешен алса; икенче җирдә «уйларның зәңгәр күзе һәр Сәйдәшкә бәйле өйгә мәрмәр такта эләр өчен урын эзли»; өченчесендә «кызның күзләрендә зәңгәр упкынлы Салих» чагылып китә; ул да булмый, Салих күзләрендәге зәңгәрлек бүлмәне тутыра. Автор әсәрдә үзе дә зәңгәр гөмбәзен кара болыт капламавына шатлана. Кыз, Сәйдәш белән саташып, төн уртасында пианинода уйный башлагач, «төнге тәрәздә зәңгәрлек яктырып тора башлый». Тагын да килеп, Сәйдәш күзләрендәге зәңгәр нурның кыз күзләрен зәңгәрлеккә төрүе, кызның Сәйдәштән аерылгач, башкача очратмаган «жылы зәңгәрлеге» кебек сүз-сурәтләр күзәтелә.

Поэмада Сәйдәшнең кыз мәхәббәтен кире каккан вакыттагы халәте символик-драматик мәгънәгә ия. Музыкага өйрәнгән Буа кызы композиторның үзенә дә якын

була башлый, ләкин арада Сәйдәш күңеленә алданрак кереп урнашкан Казанның Бибисарага охшаш тагын бер кызы бар. «Сәйдәш яры» әлеге җавапсыз мәхәббәт халәтендә егетнең «зәңгәр күзләреннән алсу сүзләр эзләп» карый, аның күзләренә яшь тула, шул яшьле күзләрдә «моңлы зәңгәрлек чайкала» башлый...

Мондый да күркәм шәхескә, егет асылына гашыйк булмау мөмкин түгел. Шуңа да кызның хыялый, матур, саф булып, сагыш катыш Сәйдәшкә соклануы гомер буе саклана. Р. Харисның поэманы оештыручы вакыйга итеп, ике яшь кешенең романтик һәм драматик мәхәббәт тарихын алуы шул сәбәпле хуплана да. Җырлап торган күпме сүз-сурәт, мәгънә, хис-тойгы сыйган драматик «Сәйдәш яры» поэмасының үзәгендә әнә шул илаһи көчкә ия мәхәббәт тора. Поэмага борчылу, кайгыру, дулкынлану, киеренкелек хисләре хас.

Малай чактан гармунга үрелгән Р. Харис өчен дә С. Сәйдәшев гади кеше генә түгел. Поэмада автор образы да зур әһәмияткә ия. Ул бөек шәхеснең үз Туган җире белән бәйле истәлекләренә сак каравы белән аерылып тора. Шагыйрь: «Тукай хаклы: үлгәч кенә татарда даһи дан эчә»,—дип язса да, үзенең талантлы кешеләргә игътибарлы булуы, хөрмәт белән каравын һәрдаим сиздереп тора. Р. Харис поэманың башына «Салих Сәйдәшев Буада» дип куя. Бу сөйләнәсе вакыйгаларның кай тирәдә баруын искәртү, Сәйдәш мәхәббәтенең географик киңлекләренә дә ишарә буларак кирәк. Автор шигърияттне каяндыр читтән, ерактан, башка тормыштан эзләми, теманы үзенең яшәгән җирлегеннән ала. Шуның өстенә Р. Харисның үзенең дә Буа егете булуын истән чыгармыйк. Шунлыктан, авторның төп вакыйганы, үзәк образларны сурәтли-сурәтли туган якны, балачакны, яшьлекне сагыну хисләренә, күңелендә йөрткән матур истәлек-хатирәләргә бирелеп китүе бер дә гаҗәп түгел.

Салих Сәйдәшевнең туганы Д. З. Саинова-Әхмәрова истәлекләрендә композиторның Буа төбәге белән бәйле биографиясе болай искә алына: «1917 ел—революциянең кайнаган елы. Салих тормышында да үзгәрешләр башлана. Халык мәгарифенең өяз бүлеге чакыруы буенча театр артистлары белән ул Буага бара. Анда беренче мәртәбә музыкаль коллективларны, түгәрәкләр һәм оркестрларны оештыру, туплауга юнәлдерелгән сәләте тормышка аша. Яшь булуына карамастан, кыска гына вакыт эчендә ул музыка студиясе, оркестр туплый, чуаш, татар хорларын оештыра һәм җитәкли, фортепьянода уйнау дәресләре бирә, концертларда, спектакльләрдә катнаша. Мондый актив эшчәнлеккә аннан соңгы елларда да ия була. Зыялы һәм үз яшьтәшләре арасында инде танылып өлгергән яшь, чибәр егет, мөгаен, байтак кызларның йокысын калдыргандыр. Бу еллар иҗади хезмәт тормышына керү белән бергә яшьлек мавыгулары чоры булып та кала. Мәшһүр язучыбыз Әмирхан ага Еники үзенең «Гөләндәм туташ хатирәсе» дигән әсәрендә Салих Сәйдәшев тормышының бу чорын гаҗәеп матур сурәтли». *(Салих Сәйдәшев: Композиторның тормыш һәм иҗат юлы.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.—Б. 46).*

«Сәйдәш яры» поэмасының да беренче юлларыннан ук автор күңеленең җилкенүе, моңга төренүе сизелә. Моның да хикмәте бар. Поэмадагы автор һәм сурәтләнгән герой образы, вакыйгаларны сөйләүче һәм Р. Харис үзе дә—моң дәрьясында йөзгән кешеләр. Шуның өстенә бер шикләнүсез укучы автор белән шагыйрьне бер үк шәхес итеп кабул итә, гәрчә әдәбият теориясе аларны аерып караса да. Ә моң моңга тартыла инде ул! Сәйдәш кадәр Сәйдәшнең шагыйрь туган ягына килеп, үзеннән соң гомер буе сагынып сөйләрлек матур истәлекләр калдыруы кәгазь битләрендә урын алырга тиеш иде, әлбәттә.

Шулай итеп, автор укучыны Сәйдәшкә бәйле хатирәләр агымына алып кереп китә. Шагыйрь укучысын Сәйдәшкә бәйле һәрнәрсәнең халык бәгыренә тоташуын, һәр хатирәнең чиста, фәкать чиста булырга тиешлеген искәртә. Яшьлеге Сәйдәш исеменә тиеп киткән хатынның картлыгын да автор нәфис итеп сурәтли. Әсәрдә Р. Харис Сәйдәшне мәхәббәт мәсьәләсендә тотнаклы, әдәпле итеп сурәтләүгә ирешә. Әсәрдә Сәйдәш чолгап алган даирә дә тасвирлана . Әлеге поэмада татарның күп кенә шәхесләре атала: монда Бакый Урманче да, Нәҗип Җиһанов та күзгә чалына, Җәлил дә күренеп ала, Фәйзи Биккенинны да күрү насыйп була. Поэма барышында Р. Харис Сәйдәшне гел «үзенеке итеп бетерә». Ул, Буаның географиясен барлап, табигый байлыкларын да онытмый. Зөя елгасы, Бикмураз, Түбән Наратбашы,

Б. Урманче туган Кул Черкене, Р. Харисның Казмасы, Кильдураз күренеп торган Шәриф Хөсәеновның «Өч мунча» авыллары поэмада урын ала. Шагыйрьнең:

*Татарстан урамнарын*
*укчә белән шакый-шакый,*
*татар халкы тарихына*
*ничә Сәйдәш, ничә Бакый,*
*ничә Җиһан, ничә Җәлил*
*атлый бүген сиздермичә?!—*

дип язган юллары бүген дә яшьләр арасында талантлар барлыгына ишарә итә. Бу талантлар Татарстан урамындагы Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында булмас микән дип уйларга да урын кала хәтта...

«Сәйдәш яры» XX гасыр ахырында (1998) язылган поэма. Инде бу вакытта татар әдәбияты, Т. Галиуллин әйткәнчә, «икенче жылыныш» кичереп өлгергән, 90 еллардагы вакыйгалардан соң милли үзаңы үзгәрә башлаган; милли тарихны, татарның талантлы шәхесләрен барлау чоры бу.

Ә менә Равил Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасы 1978-80 елларда ук язылган. Әдәбиятта зурдан ук алып әйтерлек үзгәрешләр дә юк, жәмгыятьтә дә «үзгәртеп кору» башланмаган, бу дөньядан киткән сәнгать әһелләрен «йолдыз»га әйләндерү дә юк, «торгынлык» дип аталган чор бу. Менә шул вакытта Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасы языла. Шагыйрь поэмасы язылганнан соң да Сәйдәштән «китми». Аның Мәскәүдә композиторның 100 еллыгын бәйрәм итү кичәсендәге чыгышы да «Татар дөньясында гасыр башына (XX гасыр) охшаш революцион үзгәрешләр бара. Димәк, яна Сәйдәшләр кирәк!»—дип тәмамлана. Р. Фәйзуллинның «Бер рәсемгә карап» дип исемләнгән «Сәйдәш»не язу истәлеге дә бар. Әлеге мәкаләсендә автор үз әсәрен уйлану-монолог дип атый, укучының әсәр исеме астындагы «Силуэт» төшенчәсенә дә игътибарлы булуын сорый. Белгәнебезчә, әлеге төшенчәнең Татар теленең аңлатмалы сүзлегендәге икенче мәгънәсе «әйбер-объектның бик ерактан караганда яки караңгыда әз-мәз генә шәйләнә торган күренеше, рәвеше, сызымтасы» мәгънәсен бирә.

Шуны да билгеләп үтү дөрес булыр, әсәрдә Сәйдәш һич тә «шәүлә генә» булып чыкмаган. «Сәйдәш яры»нда романтик Сәйдәш белән очрашсак, «Сәйдәш» тә композитор образы фәлсәфи-реалистик буяуларда ачыла. Поэмада мәшһүр композиторның әти-әнисе, жизнәсе, беренче хатыны Валентинага булган мәхәббәт тарихыннан гыйбарәт биографик моментлар белән дә танышабыз. Шулай да поэмада информация бирү өстенлек ала дип раслау дөрес булмас иде. Әсәрдә Сәйдәш кенә түгел,

*Җилләр генә, ахры, бу җиһанда*
*ничек тели—исә шулайга,*

дигән кысаларга куып кертелгән, «максат биеклеген алырга омтылган» татар интеллигентының гомумиләштерелгән образы да «карап тора». Әлеге образ илдә башланган үзгәрешләргә сизгер, тик «яңаның кыска «тамыры!» дип уйласа да, аларны кабул итә; тукталып уйланып ала; талант юлы турында гыйбрәтле язмышны башкаларга да ишеттерергә тели.

«Сәйдәш» поэмасында вакыйга Казан һәм Мәскәү, Оренбург шәһәрләрендә бара. Р. Фәйзуллин тарихи фактларны нигез итеп ала. Монда татар театры тарихы, татар халкының талантларга бик үк сакчыл булмаган карашы, гомумән, һәр вакыйгага Вакыт категориясеннән чыгып фәлсәфи бәя бирү күзәтелә. Поэма пролог һәм эпилогтан тыш, тагын унбиш бүлекне эченә ала. Һәр бүлек татар халкының драматик язмышын чагылдырган эпиграфлар белән башланып китә. Әсәрдә тарихилык көчле, татар милләтен бердәм итеп күрү хисе көчле. Поэманың әле «үзгәртеп кору» башланганчы ук язылганын (1980) искә алсак, Сәйдәшнең, шагыйрь сүзләре белән әйткәндә, «конъюнктура сандугач»лары ишәеп, композиторның «интеллектуальный

закуска» корбаны булуына шик калмый. Гомумән, Р. Фәйзуллин композиторны татар халкының сирәк очрый торган зыялысы итеп сурәтләүгә ирешкән. Әлеге поэмада татарның күп кенә билгеле шәхесләре турында мәгълүмат бирелгән. Андыйлардан Ш. Әхмәров, Ф. Әмирхан, М. Вахитов, Г. Кариев, З. Яруллин, К. Тинчурин, В. Мухина, М. Мозаффаров, Н. Жиһанов, Ф. Яруллин, Ф. Туишев, К. Мотыйгый исемнәре телгә алына. Әсәргә Казанның күп кенә тарихи урыннары килеп кергән: Ташаяк ярминкәсе, Шамил йорты, Евангелийский (хәзерге Татарстан) урамы, «Кольцо» тирәсендәге «Балык базары», Бакалтай болынлыклары, Мәскәүдәге Казан вокзалы.

Поэма үзе дә зур күләмле, масштаблы әсәр. Юкка гына Т. Галиуллин аны шигъри романга якын тора дип билгеләп үтмәде. «Сәйдәш» поэмасы интеллектуаль поэзия әсәре. Поэмада чарланган фикерләр күп очрый. Шундыйлардан: «һәр мескенлек түгел тыйнаклык»,—дигәнен Яңа гасырда даһи булмаганнарга да истә калдыру артык булмас. Шагыйрь Сәйдәшне фаҗигагә китергән сәбәпләрнең берсе хатын-кыз икәнен искәртә, ләкин бу үтә дә интим өлкәдә җәелеп сурәтләргә теләмәвен белдереп, объектив сәбәпләрне шәйләргә дә урын калдыра. Автор Сәйдәшнең үзенә тартып тору сәләтенә соклана, «сирәк арасыннан сайлап алынган бер гәүһәр ул» дип билгели. Поэма үзәгендә «талантлы кешедән никадәр таләп итсәң, шулкадәр үк хөрмәт ит» принцибы ярылып ята. Р. Фәйзуллинның әлеге шигъри юллары бәхәс формасында язылган, риторик сораулар, әйтеп бетермәүләр күплеге белән дә аерылып тора:

*Эше гел гүзәлме? Чиксез мәллә*
*Үзен зурлата алу кодрәте?*
*Гел алай ук түгел... Хикмәт, ахры,*
*Талантының табигатендә.*
*Шәхес булып яшәү рәвешендә,*
*Сөйләшүендә, һәр гадәтендә,*
*Кешеләргә ягымлылыгында,*
*Дөньяга мөнәсәбәтендә...*

Ике поэманы чагыштырып караганда, географик кинлек кенә түгел, ә сурәтләнгән образның яше дә әһәмияткә ия булганын тоясың. Р. Хариста Сәйдәшкә унсигез яшь тирәсе булса, Р. Фәйзуллинда аның, үсмер һәм танылган вакыты чагыла.

Сәйдәш—ике әсәрдә дә бер үк төрле, саф, тыйнак, зыялы, күркәм кешеләрнең берсе. Җаны музыкада яшәгән кеше ямьсез, сөйкемсез була да алмыйдыр ул. «Андый кешегә дөнья әшәкесе, фани дөнья гайбәте йога алмый»,—дип исбатлый авторлар.

С. Сәйдәшев образын Марсель Галиевтә дә очратырга була. Сәйдәшне ул бер эссесында телгә ала. Әлеге авторның С. Сәйдәшев турында уйлану нәтиҗәсе буларак язылган «Соңгы аккорд» исемле шигыре дә бар. Шигырьдә хәзерге заман музыка сәнгатенә ironияле карашны да тоярга мөмкин.

*Ялгыз булмә:*
*Соңгы дигәнне ишеткәнгә мәллә*
*Стенада сөенеп көлә,*
*Тураймакчы булып бөкре шәүлә?!*

«Чын музыка язу өчен яфракларның яшел кан тибешен тыңлый алу, яңгыр шавын, болытлар күкрәвен ишетү, бураннарның җебен-җепкә аера белү сорала», дип яза М. Галиев.

«Яшел яфрак»тан алган моң детале Кадыйр Сибгатуллинның 1985 елда язган «Безнең моңнар» шигырендә дә күзәтелә.

*Яшел бөре булып агыла моң,*
*яшел яфрак булып ярала,*
*сары яфрак булып җиргә ята,*
*кар бөртеге булып тарала,*—дип язган иде ул.

Сәйдәш образы К. Сибгатуллинның «Ленин мемориалы» шигыренә дә килеп керә. Шигырьнең исеменнән аңлашылганча, монда сүз үз вакытында Сәйдәш һәйкәлен салу өчен халыктан акча җыю турында бара.

Р. Фәйзуллин поэмасында да Сәйдәшкә һәйкәл салынмауга борчылу белдергән юллар бар. Бүген исә ул һәйкәл Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты алдында басып тора.

Һәйкәл мәсьәләсе Зөлфәтне дә борчыган икән. Шагыйрьнең Ф. Шаляпинга һәйкәл куюу унае белән язылган шигыре «Арьяктан хәбәр» дип атала. Шагыйрь бөек рус җырчысын асыл тавыш иясе дип атый. Автор аның тавышын тыңлаганда, Тукай булып күрсенә дә, туфрактан Сәйдәш нуры сирпелгәнен сизеп ала. 1999 елда язылган шигырь татар җирендә Сәйдәш тә, Шаляпин да газиз икәнлеген искәртә.

«Йөрәген былбыл чаккан» Зөлфәттә «Былбылның канат җилпеше» исемле 2004 елда язылган шигырь дә бар. Шагыйрь биредә талантларга күктән индерелгән илаһи көч турында уйлана.

*Адәмнәрне сайлап, нигәдер,*
*Иҗат моңы, моң иҗаты өчен*
*Былбылның бер хисен биргәндер...*

Ә Сәйдәштәге моң дөньяны тетрәтсен һәм былбыллар гына ишетә торган тавышларны ишетсен өчен бирелгәндер, дип яза шагыйрь. Әлеге илаһи халәтне Зөлфәт «Сәйдәш балкышы» шигырендә дә дәвам иткән кебек була. Сәйдәшне сурәтләүдә эпитетларны бер дә кызганмый шагыйрь. Ул аны «серле таң кошы», дип тә, «табигатьнең үзеннән килгән сихри дулкын» дип тә, «язмышыбызның асылы» дип тә зурлый. Ахырдан:

*Сәйдәш үзе—тоташ музыкадан*
*Коеп куйган һәйкәл шикелле!*—дип соклана.

С. Сәйдәшев образы шигырь, җыр, поэма, хикәя генә түгел, баллада жанрында да чагылыш таба. Биредә Зиннур Мансуровның «Сәйдәш ялгышы» исемле әсәре күз алдында тотыла. Шомлы буран күренеше. Табигатьтә пәри туе, хәтта фәрештәләр фанфарага бии. Авыл йорты. Анда олуг кунак бар. Кунак алдында «Хәйям сые» куелган. Кунак борчыла, аның күңеле тыныч түгел. Буран эченнән ул К. Тинчурин тавышын ишеткән кебек була... Шомлы табигать күренешен шагыйрь илдәге сәясәт китереп чыгарган ыгы-зыгыга тиңли. Монда 1929 елда милләтчелектә һәм Совет властена каршы агитация алып баруда гаепләнеп, гаилә башлыгы Шиһаб Әхмәровның кулга алынуы; Сәйдәшев өчен көнкүреш проблемалары тулы билгесезлек башлану; 1930-31 елларда зур әсәрләрнең язылмавы, музыка өлкәсендәге каршылыклар; Сәйдәшнең иҗат эшчәнлегенә 10 ел тулу көнен уздыргач та, композиторны тормышның хисапсыз сикәлтәләреннән коткарып килгән «Кәрим ага»ның кулга алынып, атып үтерелүе кебек фаҗигалар күз алдында тотылгандыр дип уйларга нигез бар. Шулай итеп, З. Мансуров кыска гына шигырендә Сәйдәшне фаҗигагә илткән сәбәпләрне күрсәтүгә ирешкән. Әлеге шигырь, әзерлекле укучыга юнәлтелеп, бик тыгыз, төгәл, үтемле фикере белән аерылып тора:

*...Ап-ак кардан Сәйдәш бара төсле,*
*Тартып бара кара роялен...* ,—дип тәмамлана ул.

З. Мансуров шигырен укыгач, күңел янадан Р. Фәйзуллин поэмасына әйләнеп кайта.

*...Дуслар... Уендашлар... Шешәдәшләр...*
*Сердәш булып йөргән көндәшләр...*
*Һәрчак булган, һәм бар, булачаклар—*
*Туып кына торсын Сәйдәшләр!—*

дип кисәтә татар илендәге талантларны шагыйрь. Ә менә Нияз Акмалның «Талант» шигырендә, гәрчә анда Сәйдәшкә мөрәҗәгать итү бөтенләй булмаса да, әйтелгән фикер нәкъ менә аңа атап язылган кебек тоела.

*Аш табагы уртак иде табында,*
*Күз йомганчы бушаттылар табакны.*
*Аңа гына бер йотым да калмады.*
*Һәм әйттеләр:*
*«Түзәр, ул бит талантлы!..»*

Шулай да, минемчә, Сәйдәшнең фаҗигасен ачып бетерә алган әсәр юк әлегә. Һәр шагыйрь аның теге яки бу ягына гына якын килә. Күбесе аның тормышын ал да гөл итеп, моңына сокланып кына яза. Бу нисбәттән И. Юзеев трагедиясе аерылып тора, билгеле. Ләкин ул да нигездә ике яклап кына тасвирлый: К. Тинчуринны югалту һәм сәяси заказ буенча талантны рухи яктан үтерү.

Татар театрында Сәйдәшев белән бергә эшләгән Б. Гыйззәтуллин болай яза: «Көннәрдән бер көнне театрга штатны кыскарту турында боерык килеп төште. Баш режиссер Ш. Сарымсаков, режиссерлар Г. Йосыпов һәм Х. Уразиков, директор Н. Гайнуллин һәм мин партком секретаре Б. Гыйззәтуллин парткомда җыелдык. Без болай уйладык: Сәйдәшевнең эш хакы барлыгы 89 сум. Мондый зур дәрәҗәле кешегә бу акчаның әлләни әһәмияте юктыр, дидек тә, кыскартып куйдык. Үзе каршы килмәде. Күпмедер вакыттан соң без аның белән Радиокомитет янында очраштык. Ул учын ачты да ике айдан артык вакыт эчендә музыкасын тапшырган өчен алган гонорарын—42 сумны күрсәтте. Сүзсез диалог шактый озакка сузылды. Мин шунда гына нинди хата ясавыбызны аңладым». Тиздән гонорарлар да туктала, чөнки радиодан аның көйләрен бик сирәк тапшыра башлыйлар. *(Д. Ж. Саинова-Әхмәрова. Салих Сәйдәшев.- Казан: Татар. кит. нәшр.,2001.-Б. 164).*

Бөек композитор тормышында моннан башка фаҗигаләр дә күп булган. Яраткан хатынының баладан үлеп китүе, икенче, өченче хатыныннан да уңмау, яраткан улы Эмильне югалту һ. б. лар.

Хәзер Сәйдәшкә мөрәҗәгать итмәгән шагыйрь юктыр. Роберт Әхмәтҗаннын да «Сәйдәшкә» исемле шигыре бар. Шагыйрь композиторны «алтынланган каен чуклы симфоник көздә зәңгәр күзләре белән зәңгәр күккә карап, ак болытлардан аккан моңга сокланып торган» мизгелдә күрә. Сәйдәш үзенә 100 яшь тулган көннәрендә кайтып килсә, беренче булып кемгә кул бирер икән дип уйлана автор. Сәйдәшнең тине юклыгын, аңа көндәш булырлык талант булмавын да искәртә. 2001 елда язылган бу шигырьдә дә Сәйдәшкә һәйкәлнең әлегә халык йөрәгендә генә салынуына борчылу бар.

«Хезмәтеннән тәм табу, «Бишбүләк» китергән уңыш улы Эмиль туу шатлыгы белән кушылып китә. Соңыннан билгеле булганча, бу улын ул барыннан да артыграк ярата. Анарда музыкага сәләт күреп, музыкаль белем бирү белән шөгыльләнә башлый. Ул зур канәгатьләнү белән гаиләсен яраткан Кызыл Байракка, дачага, табигатькә, Иделгә алып бара.

Һәр талант иясенең яраткан урыны була. Сәйдәшев өчен, мөгаен, мондый урын Кызыл Байрак булгандыр», дип яза Д. Саинова үзенең истәлекләрендә. Шагыйрә Бикә Рәхимова композитор биографиясендәге менә шул фактны «Моң иясе» исемле шигъри юлларга кертеп җибәрә. Автор ярсып аккан Идел өстендә Сәйдәш моңнарын сизгән кебек була, бу моңнарда шагыйрә әрнү, әрем ачыларын тоеп ала. Б. Рәхимованың «Сәйдәш портретына карап уйлану» исемле җыры да бар. Шагыйрә үзенең соклану хисләрен «татарның асыл табышы» метафорасына сыйдыра. Өченче бер шигырендә Б. Рәхимова Сәйдәшкә үзе теләп бәхет кошы кунгандыр дип фаразлый. Аннан соң, «моңсар» эпитетын кулланып, Сәйдәш үзе татар халкы тарихында бәхет кошы сыман бер күренеш дигән нәтиҗәгә килә. Шуны да искәртү урынлы булыр, гадәттә, башка шагыйрьләр «моңсар» эпитетын Сара Садыйковага карата куллана иде.

Шагыйрә Флера Тарханованың да Сәйдәшкә багышлап язган шигыре бар.

Шагыйрә композиторның даһи әсәрләренә соклана, «халык бәгыре»ннән төшкәнгәдер, бу җырлар башка дәверләрдә дә яшәрләр дигән өметтә кала. Ә Роберт Миннуллинның «Шәрык биюе» шигырендә бию музыкасы бәгырьләргә кагылган чөй, йөрәктәге җөйгә тиңләштерелә. Көй тыңлаганда ерак татар тарихына кадәр барып җителә. Ә Самат Шакир шигыре Латвия соборында органда яңгыраган «Шәрык биюе»ен тыңлаганда туган хисләрне чагылдыра. Тыңлаучылар, төрле милләт кешеләре булып, Сәйдәш көен «татарның Бахы» дип кабул итәләр. Шәрык моңы агылганда, мең төрле асылташ кебек җемелдәп, ефәккә төренгән яшь кызлар биегән кебек була. Шигырь соклану катыш тантаналы пафоска корылган һәм кызыксынып укырлык әсәр булып чыккан.

Һәр шагыйрь Сәйдәшкә үзенчә якын килә, аның яңадан-яңа сыйфатларын табуга ирешә. «Сәйдәшев, хәтта ирләр компаниясендә дә, чыгырыннан чыкканны өнәмәгән; андыйларны, үзе үк бераз уңайсызланып, «Шаяртма!» дип, яраткан сүзе белән туктата торган булган. Сәйдәшев авызыннан чыккан бу сүз «Тукта!» дигәнне аңлаткан һәм аның лексиконында ул, иң якыннарына гына әйтелә торган «Бәгырь» сүзе кебек үк киң мәгънәгә ия булган» (Д. Саинова).

Кешенең барлык хисләре, кичерешләре бергә тупланган йөрәк символын аңлата торган «бәгырь» сүзенең шагыйрьләрне иҗатка аеруча дәртләндерүен таныырга кирәк. Әлеге сүз Р. Хариста «Сәйдәш—үзәгемдә, бәгыремдә, кыл уртада», «бәгырьне изә» буларак кына кулланылса, З. Мансуров Сәйдәш лексиконындагы тылсымлы сүзне К. Тинчурин образына әйләндерә. Дөресен генә әйткәндә, бу сүз нәкъ менә ана күбрәк туры килә дә.

*Гарасатта йөрәк гаҗизләнсә,*
*ала иң югары нотаны...*
*Бәргәләнеп буран ятьмәсендә,*
*әллә бәгырь... Кәрим ятамы?!*

Әлеге «бәгырь» сүзенә Роберт Әхмәтҗанов та игътибар итә. Сәйдәшнең башкаларга мөрәҗәгать итеп әйткән сүзен үзенә карата куллана:

*Килче, бәгырь,*
*Йөрәк мәйданында*
*Тиңең дә юк,*
*Юктыр көндәшең.*

Әлеге «бәгырь» сүзе Мәхмүт Хөсәеннең 1993 елда язган «Сәйдәшне озатканда» исемле шигырендә дә күзәтелә. Сәйдәшнең үлеме турында ишеткәч, ул язган маршны тыңлагач, хәтта «таш бәгырьләр» дә чыдамады дип яза шагыйрь. Шигырьдә Сәйдәшне соңгы юлга озату күренеше тасвирлана. Шагыйрь гади халыкның да, республикада исемнәре билгеле шәхесләрнең дә «күзе дымлы, ирennәре дерелди...» дип яза. Сара Садыйкова Сәйдәшнең хәер-догасын искә төшерә, А. Ключарев тирән кайгыга бата, Заһид Хәбибуллин тын гына «Сагыну»ын уйный, рояльдә Рөстәм Яхин сыктый, Мансур Мозаффаров сызлана. Ә Казан урамнары халык ташкынын сыйдыра алмый, транспорт туктала. Әхмәт Фәйзи сенелесенең истәлекләреннән күренгәнчә, Казанда Тукайны гына шулай күмгәннәр. Нури Арсланов, композиторны күмеп кайткач та, «өзелгән кыл, сынган саз» сүз-сурәтләре белән матәм шигыре яза. Шуннан соң шигърияттә шактый вакытка тынлык урнаша.

М. Хөсәендә дә, Р. Хариста та, З. Мансурда да Сәйдәш образына «кергәндә» фикерне буран, кар символлары аша белдерү сизелә. М. Хөсәен Сәйдәшевне соңгы юлга озаткан вакыттагы табигать халәтен җемелдәшеп җиргә яуган, җилдә уйнап очкан карлар, болыт арасыннан монсу карап торган кояш аша сурәтләп бирсә (С.Сәйдәшев белән хушлашу 21 декабрьдә була), Р. Хариста да вакыйгалар кыш, буран, кышның язга таба авышкан бер мәлендә күзәтелә. Күрәсең, шагыйрьләр тышкы дөнья салкынлыгын Сәйдәшнең җылы музыкасы белән җылытырга телиләр. Ә З. Мансуров, алдан әйтелгәнчә, шәхес-табигать параллельлеге белән генә

чикләнеп калмыйча, хәл-әхвәлне сәяси планда яктырта.

Сәйдәш лексиконындагы тылсымлы сүз 1995-2001 елларда Илдар Юзеевны «Бәгырь» исемле трагедия язарга этәрә. Шагыйрь иҗатында Сәйдәш образы аңа кадәр дә күзәтелә. 1997 елда язылган «Татар моңы» поэмасында шагыйрь аны парольгә «әйләндерә». Дөньякүләм танылу юлында:

*Безнең пароль—Җәлил!*
*Безнең пароль—Сәйдәш!*—дип белдерә ул.

Шагыйрьнең «Фәтхерахман» поэмасына да Сәйдәш килеп керә. Ачлык-ялангачлык кагылып үткән М. Яруллин, Ф. Яруллиннарны шагыйрь «Зәңгәр шәл» качкыннарына тиңли. Шагыйрьнең «Күз яшьләре» шигыренә дә Сәйдәш килеп кергән. Башка телдә сөйләшкән, чит кавемнән кәләшләр алган яшьләргә И. Юзеев «җаннарында Тукае, Сәйдәше булмаган» буын итеп карый. Шагыйрьнең икенче бер шигырендә Тукай Салихның уйнавын тыңлап хозурлана, «без китсәк тә бу җиһанда Салих Сәйдәшләр кала», дип юана.

Ә «Бәгырь» шигъри трагедиясендә XX гасырның 30 елларында булган вакыйгалар урын алган. Әсәрдә илдәге сәясәтнең татар халкының ике зур талантына китергән фаҗигасе сурәтләнә. К. Тинчурин хатыны Заһидә ханым истәлекләреннән күренгәнчә, әдип Сәйдәшне нык хөрмәт иткән, аңарга карата туганнарча мөнәсәбәттә булган. Кайчакларда ул: «Мин йөзем орлыкларын сибәм, ә Салих аларны ала да бриллиантлар ясый»,—дип әйтә торган булган. Дөрестән дә, алар арасында тыгыз иҗади хезмәттәшлек хөкем сөргән. «Тинчурин, драмаларын Сәйдәшев өчен язып, аның иҗатына төп азыкны бирә. Ә Сәйдәшев, үз чиратында, актер үз роленә кергән кебек, бу пьесаларга кереп китеп, андагы характерлар, персонажлар белән бергә яшәп, кабатланмас музыка тудыра һәм шуның белән спектакльнең икенче авторына әйләнә»,—дип яза Д. Саинова.

И. Юзеев трагедиясе Сәйдәшнең юксынуы белән башланып китә. Әсәрдә ике талантның кара урманда учак ягып, «Зәңгәр шәл» өчен музыка эзләүләре үзе үк символик мәгънәгә ия, чөнки «Җир өсте» шомланып калган. Ләкин бөекләргә карурманда да ялгыз калу язмаган булып чыга. Алар янына сынчы Сәйяр белән балерина Гөлнара килеп җитә. Тинчурин Сәйярне шымчы буларак кабул итә. Моңа нигез дә бар: ул төшендә үзеннән Сәйдәшне көчләп алып китүләрен күргән. «Качкыннар җыры» менә шундый халәттә туа. Әсәрдә «Зәңгәр шәл»нең премьерасы куелу күренеше бирелә. Халык әсәрне, Сәйдәшевне, Тинчуринны бербөтен итеп күрә. Символик зәңгәр шәлне Заһидә иненә салалар. И. Юзеев бу өч шәхеснең бөтен фаҗигасен шул бер җөмлә аша әйтеп бирүгә ирешкән. Салих Тинчуринны эзли. Ә ул качкын киемендә пәйда була. Сәяси тоткыннар, сүзләрен бераз гына үзгәртеп, «Зәңгәр шәл»дәге «Качкыннар җыры»н җырлыйлар. Әсәрдә репрессиягә дучар булган гаилә тормышы, читкә тибәрелгән Заһидә Тинчурина образлары бар. Трагедиядә Сәйдәш ачынып сорый:

*Ни өчен сүз осталарын*
*Тоталар зинданнарда?*
*Иҗат эше җинаятьме?*
*Ни гаеп бар аларда?*

Үзләрен Яңа дус дип тәкъдим иткән шымчылар җавап та бирә:

*Шагыйрьләр иректә йөргәндә—*
*Тәхет өчен куркыныч.*
*Телен һәм кулын бәйләсәң,—*
*Хуҗа-юлбашчы тыныч.*

Салих үзенең иректә калу сәбәбен аңлый алмый интегә, бергә эшләделәр, бергә яшәделәр. Ул хәтта үзенең урынын Кәрим янында, төрмәдә итеп күрә башлый.

Ләкин Сәйдәшне алып китүче һаман күренми, юкса профессиональ эшчәнлегенә карата урынсыз тәнкыйть тә житәрлек, эшеннән дә кыскарталар. Ә кулга алмыйлар да алмыйлар. Сәбәп бик гади икән бит. Хакимият кешеләре дә жыр ярата икән. Тик ул жырның сүзләре алар ишетергә теләгән сүзләр булсын. Поэмада кеше анында һәм тормышында булган каршылыкларның иң югары ноктага житүе күрсәтелә. Шәхеснең чарасызлыгы әсәрне укучыда киеренке хис тудыра. И. Юзеев биредә аерым татар интеллигенты трагедиясен халык трагедиясе дәрәжәсендә күтәрә алган. Поэмада үткен сатира, сарказм сизелә. «Халык дошманнары»ның йөзен ачкан кешеләргә «Сәйдәш маршы»н уйнап бүләк тапшыру, Казанда «репрессия планы»н планнан тыш арттырып үтәү, яшьләрнең, Сәйдәш музыкасына биеп, әлеге «жиңү»не бәйрәм итүләре—болар барысы да сәнгатьчә югарылыктагы уйланып-борчылып көлү чагылышы булып тора.

Трагедиядә сәнгать кешеләреннән дошман эзләү мотивы киң чагылыш тапкан. Бу дулкынга Сәйдәш һәм Тинчурин сыннарын эшләгән Сәйяр да эләгә. Аның «Жан дуслар» дип исемләнгән сыны сәяси хата буларак бәяләнә. Тоткыннар белән төрмәләр тула, анда урын бетә. Төрмәләрне яна тоткыннар өчен бушату башлана: Тинчурин да, Сәйяр дә юк ителә. Сәйдәшкә дә якты көн бетә, кульязмалар яндырыла:

*Көемне дә тентиләр.*
*«Сүзләреңнән аерылгач,*
*Даһига тиң син!»—диләр.*

Шулай да трагедия оптимистик рухта тәмамлана. «Зәңгәр шәл» янадан сәхнәгә менә. Янадан Заһидә Тинчурина иненә Булат тарафыннан Зәңгәр шәл салына. Кара урман яктыра.

Менә без күләмле өч зур шигъри әсәр күрдек. Һәр әсәр Сәйдәшне яна яктан ачуга юнәлдерелгән. Өч әсәрдә дә бер идея хөкем сөрә: ул да булса, тугрылык идеясе. Татар әдәбиятында борынгы чорлардан, Кол Галидән бирле килгән тугрылык. Ата-ана, сөйгән яр, дус, туган жир, яраткан хезмәт, халыкка тугрылык. Ә бездән— талантларга кадер. Бу унайдан Эльмира Шәрифуллинаның «Шәхес белән халык таныла» исемле шигыре искә төшә. Халык һәм талант төшенчәләрен бербөтеннең ике ягы итеп карый ул. Халык булса, талантлар да табыла. Талантны кадерләгән халык үзе дә дәрәжәле була.

*Мәртәбәгә, дәрәжәгә куеп,*
*Күрә белсәң, әгәр күңелен—*
*Яшәтәлсәң, ул да яшәтәчәк,*
*Данга күмеп, халык гомерен,*

—дип яза шагыйрә.

Сүзебезне Татарстанның халык артисты Ш. Монасыйпов фикерләре белән йомгаклыйк. Ул бөек остазы турында менә ниләр яза: «Халыкның мәхәббәтен һәм ихтирамын С Сәйдәшев кебек үк бер генә татар композиторы да казана алмагандыр, мөгаен. Аның якты-кояшлы, жанга якын, сихри музыкасы безнең йөрәкләргә шулкадәрле тирән һәм нык үтеп кергән ки, ул үзенең рухи кыйммәте белән бөек Тукай шигъриятенә тиңләштерелә ала. С. Сәйдәшев музыкасын тынлаган чагында аның гаҗәеп матур аһәңен, рухи дәртен, күңелләргә яшәү көче бирүен сизмичә калу мөмкин түгел. С. Сәйдәшевнең даһилыгы менә шунда чагыла да инде».

# ЭНҖЕ БӨРТЕКЛӘРЕН ТЕЗГӘН УЛ...

Элегрәк концертларда үзәкләрне өзеп ала торган бер чыгыш була торган иде. Ул—татар халык көйләреннән тезмә. Оста гармунчы яки баянчы халык җәүһәрләренең иң кәттәләрен сайлап, берсеннән икенчесенә күчә. Жаннарны айкап, күзләргә яшь китереп моң агыла. Шул моң тирбәлеше хәтта аңлатып та бетереп булмый торган көчле тәэсире белән күңелләрне гаҗәеп бер сихәт ләззәтенә төрә.




Салисә Гәрәеванын «Йолдыз янгырлары» китабын кулыма алып укый башлагач әнә шундый халәт кичердем. Укыйм, укыган саен укыйсы килә. Укыган саен үземне сокландырган юлларын кәгазьгә терки барам. Баксаң, мин инде һәрбер шигырьдән юллар гына түгел, строфалар, өзекләр күчерәм икән:

*Күкләрнең бар көтмәгәндә мине*
*Таңга калдырганы:*
*Ява кинәт утлы яңгыр булып*
*Йолдыз яңгырлары!*

Бу юллар—китапка исем биргән «Йолдыз янгырлары» исемле шигырьдән. Ахыры исә:

*Соклануздан бу илаһи мәлгә*
*Балкый бәгырьләрем...*
*...Йолдыз яңгырыдай яусын илгә*
*Якты шигырьләрем! —*

дип тәмамлана.

Салисә Гәрәеванын шигырьләре, чынлап та, якты шигырьләр. Алар сокланудан: табигатькә, матурлыкка, батырлыкка сокланудан; Ватанын, туган төбәген, кешеләрне яратудан яралганнар. Эчкерсез соклану һәм эчкерсез яратудан.

Менә ни өчен ягымлы, якты булып туган алар!

Әгәр, дип уйга калдым мин, күчереп язган «энҗе бөртекләре»нә карап, әлеге өзекләр көй халәтендә булып, шул көйләрдән тезмә уйнарга туры килсә? Ничә тезмә туар да, тезмәләрне башлау өчен иң беренче итеп кайсыларын куярга мөмкин булыр иде?

Шагыйрә үзе китапны алты бүлеккә бүлгән. Һәр бүлек, эпиграф кебек итеп куелган берәр строфалык яки икешәр юллык шигырь белән башланган. Ә бүлек эчендә шушы эпиграф кочагына лаек дип табылган «асылташлар» тупланган.

*Учларыма алам кош баласын, —*
*Куркытамдыр, бәлки, анасын?*
*Җир шарын да, кош баласы итеп,*
*Учларыма килә аласым... —*

ди шагыйрә «Учларымда Җир шары» исемле шигырендә.

Салисә Гәрәева иҗатында Туган җир, Туган ил, Ватан төшенчәсе бик калку, бик кадерле итеп сурәтләнә. Шуңа күрә аны бер бүлеккә генә сыйдырып та булмыйдыр. Бу тема, китапның буеннан-буена сузылган кызыл җеп кебек, башка бүлекләргә дә бик табигый рәвештә барып керә һәм үзен аклый.

*Җир һәм Күкләр сүзсез-өнсез генә,*
*Бер-берсенә сеңеп, тартылып,*
*Бар моңнарын гүя үткәрәләр*
*Минем кайнар йөрәк аркылы!*

---

Салисә Гәрәева. «Йолдыз яңгырлары». Татарстан китап нәшрияты, 2006.

Шагыйрь йөрәге дөрестән дә кайнар, шагыйранә нечкә хисле.

*Мин бәхетле — яратам мин! Шуңа күрә*
*Күкрәгемдә якты, кайнар кояш йөртәм.*

Йөрәге урынында кайнар кояш йөртүче, Күкләр хәбәрен үзе аша үткәреп җирдәшләренә җиткерә белүче Салисә Гәрәева дигән шагыйрә кем ул? Нинди токымнан, кайсы яклардан?

«Йолдыз янгырлары» китабы безнең бу сорауларыбызга да тулы җавап бирә.

*Ерак җирдә: — Син кайдан? — дип сорасалар,*
*Горурланып: — Минзәләдән, Тулбайдан! —*
*дим.*

Димәк, шагыйрә тумышы белән Минзәлә районы Тулбай авылыннан.

*Әткәм рухы илһам бирә һаман да,*
*Ак кулмәктән төшләремә кергәләй.*
*Олы тормыш үткән, Герман җирләрен*
*Гизеп кайткан гаярь әткәм — Хан Гәрәй!*

Авылларында «Хан» кушаматы алган ата кешенең шигырь сөрешендә җитмеш төрле һөнәргә ия булуын, ягъни унике ел мәдрәсәдә белем алган Хан Гәрәйнең Коръәнне шаулатып укый, тальянда гөрләтеп уйный белүен; аз сүзле, житди, сабыр кеше икәнлеген дә һәм башка сыйфатларын да ачыклый алабыз.

*— Кем булдың соң әле, төсмерләмим,*
*Мотаһарә димме рәвешең?*

Монысы инде шагыйрәнең газизләрдән газиз әнисе. Шулай ук укымышлы буын, мулла нәселеннән. Балаларына Утыз Имәни шигырьләрен яттан сөйли торган Ана.

*Без ой тулы җиде бала үстек —*
*Җиде агач кашык биеттек.*

Менә шул Ык дулкыннарын колачлап, Сәрмәт чишмәсеннән су эчеп, Тулбай яланнарында каз куып йөргән, бер-берсенә пар аккошлар кебек тугрылыклы — олы мәхәббәт белән яшәүче ата-ана тәрбиясендә үскән кыз буйга җиткән. Үзе дә ана булу бәхетен татыган.

*Йөзебезнең нәсел сызыкларын,*
*Холыкларны, хата, өметне*
*Мирас итик газиз балаларга:*
*Ана булу — безнең бөеклек!*

Шагыйрьнең дөньясы киң, күңел күзе күпне күрә. Ул үзе лирик герой — Шаһинә: мәхәббәт алиһәсе дә, назлы хатын, бәби имезүче Ана, әнисе итәгенә башын куйган бала да. Әмма ул җир кешесе тормышы белән яши. Шуңа күрә һәммәбезгә хас югалту-сагышлар аны да читләтеп үтә алмый.

*Мин килгәнче газиз әнкәемне*
*Борчымагыз, явар яңгырлар.*
*Әнкәм туфрагына коелыр өчен*
*Күз яшьләре дигән яңгыр бар.*

Шагыйрь язмышы — шигырьдә. Хикмәтле дә, шәфкатьле дә, хисле дә, көчле дә. Шагыйрә иҗатыннан укучы үзенең сөенечен дә, көенечен дә таба ала.

*Җиткерделәр:*
*Сагынасың икән,*
*Үкенәсең икән һаман да...*
*Мин үкенмим, чөнки синең йөзең —*
*Сине күрми үскән баламда!*

Балачак аланнарына һәм яшьлек елларына җин сызганып эшкә керешкән батыр да, булдыклы да, ихлас та хатын-кыз язмышы кушыла. Шул язмышы Минзәлә кызын байтак еллар илдән читтә яшәтә. Шигырьләрнең исемнәреннән үк күренгәнчә: «Казакъ даласында», «Троицк», «Алматы», «Грузин иле», «Магниткада», «Чиләбе», «Златоуст», «Урал — минем кырыс язмышым» һәм башкалар, һәм башкалар — аның гомер дәфтәренә теркәлгән төбәкләр. Ул төбәкләргә, ул үткән һәр сукмакка, Урал иленең карлы-бозлы юлларына шигырь яңгырлары явып калган.

Менә шундый шигъри автобиография... Әмма ул дәвам итә. Әлеге китапта да яна исем-атамалар дисеңме, үзенчәлекле һөнәр ияләре, үзгә йолалар, дөнья буйлап сибелгән кардәшләребезнең көн-күрмеше турындагы бай мәгълүмат — укучы өчен бик тә кызыктыргыч шагыйранә образлар!

*Руда иле, металл, күмер иле,*
*Атом иле минем Уралым!*
*Таңга калып кеше хезмәтенә,*
*Аркылыга-буйга урадым!*

Чынлап та, яратып яши якташыбыз Уралда.

Милләтебезгә хас булган, сыйфат— тырышлык белән, бөтен күнелен, бөтен көчен биреп эшли. Өлкә радиокомитетында редактор буларак туры эфирда «Дулкын», телевидениедә (шулай ук туры эфирда) «Чишмә» тапшыруларын алып бара. Чиләбе өлкәсен аркылыга-буйга гизеп, Курган, Свердловск, Төмән, Киев һәм башка шундый төбәкләрдәге радиация дозаларын эчә-эчә йөреп, бай материал туплап, җирле халык яратып тынлый торган радиоочерклар, ике телдә дә камил эшләнештәге кызыклы тапшырулар әзерли. «Дуслык» һәм «Туган як» газеталарында җаваплы сәркәтип булу; Муса Җәлил исемендәге әдәби берләшмә оештыру, соңыннан шул берләшмәне җитәкләү; армыйталмый татар әдәбиятын пропагандалау, хисапсыз күп очрашулар...—җәмгысы утыз ел! Аз вакыт түгел. Җирле халыкның никадәр генә зур мәхәббәтен казанса да күңеле һаман үзенең Татарстанын сагына. Ахыр чиктә сихри Тургаяк, Чибәркүлләр дә, мәрмәр ярлы Миасс елгалары да, шифалы дала кымызлары да тотып кала алмый аны. Ашкынып, канатланып газиз Ватанына, ата-баба җиренә, туган туфрагына кайта.

*И мөкатдәс Тукай эзле җирем!*
*Әнкәм сеңгән газиз туфрагым!*
*Еллар аша үтеп сирәгәйгән*
*Киң күңелле әйбәт дусларым! —*
*Сезгә дәшәм: эзлим җылы кул,*
*Илдән читтә бәхет булмый шул!*

Бай тәҗрибә туплаган, тирән белемгә, фәлсәфи фикерләүгә ия шагыйрәбез, ниһаять, үз өендә. Тамырларында күркәм тыйнаклык, булганына шөкер итү.

*Ни кичерсә гавәм, миңа да шул —*
*Артыгын да бирмә, кимен дә!*
*Чит илләрдә мине тубәнсетмә*
*Һәм килмешәк итмә илемдә!*

Менә шундый теләк-дога аның күңелендә. Әмма шагыйрәнең кайнар йөрәге тегендә дә, монда да үзе белән. Күңелендәге көчле гражданлык тойгысы ил гаме, халык мәнфәгате турында уйлау аны һичбер вакыт, һичбер нәрсәгә битараф калдыра алмый. Тарих яралары туктаусыз йөрәген әчеттерә. Кайтаваз булып, Күкләр сулкылдавын хәтерләткән шигырьләр туа.

*Дошманнардан тазартылган ил кырында*
*Күрдегезме гади солдат каберләрен?*
*Каберләрдә мәңгелеккә ятып калды*
*Кыз солдатлар-кардәшләрем, бәгырьләрем...*

Кыйбласын югалткан хәят, бөек яшәү кануннарының җинаятьчел рәвештә бозылуы, эшчән милләттәшләребезнең күндәм, буйсынучан, карусыз булуыннан явызларча файдалану вакыйгалары нинди генә намуслы кешенең йөрәген тетрәтмәс икән?

Көньяк Уралның «Маяк» берләшмәсендәге фаҗига Чернобыль фаҗигасеннән күпкә алда, күпкә куркынычрак була. Әмма атом-төш шартлавының яшерен сер итеп сакланырга тиешлеге, астыртын сәясәт күпләрне ак үлемгә дучар итә.

*Яңгырады «Маяк»ның казасы,*
*Кабатлап японнар афәтен:*
*Шул шартлау эзенә — нәкъ каза эзеннән!*
*Наратлар утырткан йөз хатын.*

*Суларда эрегән агудай,*
*Иссез дә, төссез дә бу үлем!*
*Яшь нарат утырткан хатыннар*
*Калдылар туфракка күмелеп.*

«Бу кансыз дәүләтнең беләбез тарихын: хисапсыз бинахак корбаны!»— ди шагыйрә җан авазы белән, туктаусыз кабатланып торган тарихи яраларга үзәге өзелеп.

Кеше гомеренә аяусыз һөҗүм. Шомлы хәлләр, трагик язмышлар, психологик киеренкелек... Шагыйрә йөрәгеннән ургылып чыккан көчле оран—шушы гаделсезлекләргә каршы кискен көрәш ул.

*Русиядә сугыш тынганы юк:*
*Гел кан ага, гомер киселә...*
*Чечня дисәң, «200»ле санлы*
*Шомлы табут төшсен исеңә!*

Җир иминлеге, кешелек дөньясы өчен йөрәгең авыртып кайгыра белү. Кайгыру гынамы соң? Сызлану, әрнү, чиргә сабышу! Чынлап та, кем әйтмешли, Җир ярылса—нәкъ менә шагыйрь йөрәге аша, шагыйрьнең йөрәген ярып үтәдер ул фаҗига!

*Ятимнәрнең әче, канлы яше*
*Кем йөрәген телмәс, тамганда?!*
*Иң куркыныч яшьләр — ирләр яше,*
*Көлгә калып Ватан янганда,*
*Халык яше хәтәр аннан да!*

Салисә Гәрәеваның кыйбласы нык. Бервакытта да, бер җирдә дә ул үзенең татар баласы икәнен онытмый. Каләме туган җиренә, теленә, гореф-гадәтләребезгә булган мөнәсәбәтен иң җылы хисләр белән анлата.

*Карталарда уч төбедәй генә*
*Минем тыйнак Татарстаным!*
*Ул охшаган чигү урнәгенә*
*Сафьян читек теккән Остаңың!*

Яисә:

*Туган телем — якты уйлар теле,*
*Куанычым, яшем, дәртләрем.*
*Йөрәгемдә йөртәм әнкәемнең*
*«Балам!» диеп өзелеп әйткәнен!*

«Йолдыз яңгырлары» — саллы китап. Анда йолдызлар яктылыгы да, яңгырлар шифасы да муллан. Тагын да мөһимрәге, китапны укып чыккач, бер генә шигырь турында да «монысын нигә төшереп калдырмады икән», дигән уй тумый. Һәркайсы үзенчә яктыртып, үзенчә җемелдәүче, күз явын алырдай камил эшләнешле энҗе бөртекләре алар!

Гомумән, Салисә Гәрәева шигырьләрендә ясалмалылык, белер-белмәс теманы ачарга алыну юк. Аларның һәркайсында пөхтә форма: ритм-рифма төгәллеге, табигый агым, аһәнле эчке яңгыраш, эчтәлеккә тәңгәл чагыштырулар, сокландыргыч детальләр, шигъри образлар, ихласлык! Шул ук вакытта логик эзлеклелек.

Көчәнмичә, зур осталык белән иҗат ителгән мондый чын, житлеккән шигырьләр, табигый ки, зур талантка ия булган шагыйрь каләменнән генә туа ала.

Тирә-юнендәге гүзәллекне искиткеч сизгер тоя белүче шагыйрә иҗатыннан бик күп китерергә мөмкин булыр иде мондый матур мисалларны. Гомумән, аның шигъриятенә әнә шул тоя белү «хужа» дияр идем. Хәтта шигъри форманы сайлау да шул хис-тойгының үзенә йөкләнгән шикелле. Кайсына нинди калып яраклы ягъни. Нәкъ менә шуңадыр да, оста тегүче тарафыннан жиде кат үлчәп, буй-сынына килешле итеп тегелгән кием кебек, эчке халәтенә тышкы җисеме ятып, ярашып тора аның шигырьләренең.

Кыскасы, китапта шигырь тукымасына салынган материал гаҗәеп бай, шул ук вакытта укучы өчен кызыклы һәм зәвыклы да. Кайбер очракларда билгеле бер эзлеклелектә бирелгән шигырьләр бер-берсен тулыландыра, башлаган теманы дәвам итеп, мәгънәви баета бара. Ә кайчагында өр-яңа табышы белән шаккатыра, шатландыра. Мәсәлән, эшче темасы, тимер кою романтикасының бөтен тирәнлеге белән ачылуы да татар әдәбиятында сирәк күренеш. Кыскасы, Салисәнең иҗат офыклары шулкадәр киң ки, мина калса, аның каләм җиле кагылмаган бер генә тема да, бер генә очрак та юк шикелле.

Талантлы шәхесләргә яшәү, иҗат итү бервакытта да җиңел бирелмәгән. Минзәлә кызының да сыгылган чаклары булгандыр. Әмма китапта күз яше юк. Киресенчә, «Горурлыгым каты корычтан!» дип кистерә ул. Теләсәнинди давылны да җиңә алырлык көченә таяна.

*Ялганнарны җаным күтәрәлми —*
*Турыдан бәр! Суксын яшене!*

Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, шагыйрә Салисә Гәрәева үткән юлы, кылган гамәлләре, талантлы иҗаты белән, шигырендә әйткәнчә, үзенә чын мәгънәсендә һәйкәл куйган.

*Авыр яшим. Әмма шигырьләрдән*
*Көмеш һәйкәл салдым үземә!*

Сүземне халык авыз иҗаты җәүһәрләреннән тезелгән тезмәләрне юксынудан башлаган идем. Гаҗәп хәл, аларны алыштырырлык тезмәләрне шигъри энҗеләрдән дә тезеп була икән бит.

Каләмдәшем Салисә Гәрәеваның «Йолдыз яңгырлары» җыентыгына тупланган якты шигырьләре шуны дәлилләде.

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА**

Аяз
Гыйләҗев

# ГОМЕРНЕҢ БЕР ЕЛЫ

КӨНДӘЛЕК СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

**20 октябрь, 1993 ел, Переделкино**

Ниһаять, тормышның табигый үсеш кануннарын гариплөндереп бозган, адәм асылын үз файдасына үзгәртергә маташкан явыз Ленинның иң актыккы үтенече тормышка ашачак: җәсаден әнкәсе янындагы тын урынга күчерәчәкләр. Беләм, әле моның белән генә Җир шары Ленин афәтеннән котыла алмас, әле ул һәм аның тәгълимате төртеп-күмеп калдырган миналар тоташ чылбыр булып берөзлексез шартлап ярылып торачак. Ә-ә-ә! Казанда, үз тирә-ягымдагыларны санап чык, бөтенесе «ленинизм чумасы» белән чирләгән җаннар. Ленинизм—"возвратный тиф"ның иң авыр, җаннан һич китмәс бер формасы. Кайчан исә бер Ил башына яңа диктатор калкып чыга икән, ул, әлбәттә, Ленин-Сталин алымнарына борылып кайтачак. Әле җир чак-чак күтәреп торган бу авыр йөк вак-вак кисәкләргә таркалып уалганчы йөз, йөз илле ел үтәчәк. Рәсәйдә каршылыклар бер чакта да бетәчәк түгел, каршылыклар яшәү кырын уңдырышлы итеп ашлап торачак һәм нәкъ әнә шул кырда диктаторлар шытып чыгачак та инде. Кичә телевизор каршысында утырабыз. Профессор Друзин, Николай Тряпкин, тагын берничә ак баш. Ленинның гәүдәсе күчерелеп, аның тирәсендә сырышкан тигәнәк-мәетләр Кремль диварларында калмаячак, дигән хәбәр яңгырагач сөмсерләре коелды! Бөекләрнең мәетләренә дә тынгылык юк! Христофор Колумбның гәүдәсен кайлардан кайларга күчереп йөртмәгәннәр. Сталин бу юлы да Лениннан калмый. Аны кая куярлар икән? Гөрҗиләр алып китәме? Шулай булыр, мөгаен. Югыйсә Мәскәү зиратларында аңа тынлыктан өлеш чыкмас. Ельцинның көр тавышы яңгырый башлады. Кая кадәр барып җитәр. Әлегә күңелем белән мин аңа ышанам, кылган гамәлләрен аклыйм. Бөтен тирә-ягым, танышларым, очраклы юлдашларым аңа ләгънәт укый, "Рәсәй Американың кисәкчәсенә әйләнде, хәзер илдә бара торган барлык үзгәрешләрнең җитәкчесе Америка!" дип кабатлыйлар. "Ельцин диктатор!" дип куркыталар. Моңарчы йомшаграк булды шул диктатор дигәнебез! Әгәр ул көчен сиздерсә, дилбегәне кулыннан ычкындырмаса, мәми авыз булмыйча коммунистлар өеренең котырынуына чик куйса, илдәге буталыш бу дәрәҗәгә килеп җитә алмас иде. Коммунистлар Икенче Бөек Октябрь Фетнәсе аша властька килеп җитә яздылар бит, Ходаем... Телевизор тынды, радио сүнде, Мәскәүдә мәхшәр!

Тагын ниләр күрсәтәсең бар икән, и дөнья!

Төнәген кичке чәйдән соң йортыбызның ишегалды сукмакларына йөрергә чыктым. Ике ел инде үз тирәбездә генә уралам, ихатадан ары чыгарга аяк тартмый. Этләрдән куркам—усалландылар, машиналардан шүрлим—күбәйделәр, адәмнәрдән сагаям—күпчелеге ятлар—һичберсен аңлап, кабул итеп булмый. Чит ил машиналары шау-шусыз, шым гына шуып киләләр дә кычкырып саңгырау колакны да яралар.

Чыкса-ам—җил! Җил,җил,җил! Кышны ашыктырып тынны буып килүче аяусыз җил. Бәйдән ычкынган, Рәсәй икътисады сыман шашынган, чаба хәзер, чаба, аны тыяр көч калмаган, урман куелыгына бәреп керә—май йомарламын тураган үткер пычак кебек тишеп кенә чыга! Кичә радио-телевизорлар: "фәлән вакыт-

*Ахыры. Башы 1нче санда.*

тан капитализмда яши башлыйбыз", дип тантаналы тавышлар белән илгә яңа игълан тараттылар. Шуны күздә тотып социализмда келпеп утырган багана башы лампочкаларын чепи күзле, мунча ояларына гына яраган утларны яндырдылар. Кара, тар сукмаклар куе караңгылыкта эрегәннәр. Сагаеп кына атлыйм югыйсә, алай да абындым. Ничек чәчрәп барып төшмәдем дә, ничек күзлегемне ватмадым! Булыр иде бер кәмит! Иелеп карыйм, капшап табам, шактый юан каен шартлап сынып сукмакка аркылы төшеп яткан. Мин узасы юлга женнәр чыгарганмы? Җил, җил, җил...Урманның кара шавы колакка сыймый, выжлый, куркыта... Әз генә тынган арада күктән самолетлар шавы коела, сизәм—самолетлар да канатларына төяп тавыш ташыйлар.

Илне аркылы-торкылы бүлгәли торган, бүленгән кисәкләрне бер-берен̦ә каршы котырта торган яман аяклы хәбәрләр колакны киле сабы белән төя, күкрәк читлегенә кугәргән тимердән кыршаулар суга. Җил, җилкәй җитез аяк! Нигә андый уйларымны алып китеп башымны җиңеләйтмисең? Кай тарафлардан иссәң дә син миңа дәһшәтле шикшөбһәләр, тышауланган уй-гамь ияртеп киләсең?! Тыңлачы, күрче, таныш агачлар арасыннан кысыла-кысыла чыккан кара җилнең бусы нәкъ Казан тирәсеннән исеп килде бугай?! Мине уртада калдырып бөтерчектәй бөтерелде, зыр-зыр әйләндерде. Аллакайгынам, очыртып алып та китте! Очам, очам! Себеркегә атланган убырлы карчыкмыни! Карыйм, түбәндә татарның бишеге Казан! Әнә, татарның сәяхәтен йомгаклый торган утрау—Яңа Бистә зираты. Шәһәрнең кара шәмнәрен учына җыйган Бишбалта. Төзелеп бетмәскә салынган ваемсызлык һәйкәлләре—кунакханәләр. Зәһәр исе китмәскә сеңгән мәшһүр ертык Болак. Җир белән Күкне ялгап масайган тәкәббер җил мин чалны тузан өермәседәй бөтереп болгый...



*Түбән Камада "Җидегән чишмә" кичәсендә Азат Зыятдинов белән. 1984 ел.*

Сабый чакта өлкәннәр, әби-бабайлар безне ни-нәрсәгә өйрәткән?! Тормыш сабакларын ни дип авызландырган. Беренче нәүбәттә тыйнаклык-басынкылык сеңдергәннәр. Көн туса: "иелгән башны кылыч кисми!" дип тәкърарлаганнар. Янәсе, безләргә юашлык кына килешә, татарны шул гына бизи, дигәннәр. Бер без генә, сугыш алды балалары гына түгел, гасыр буена шул кагыйдә татарга ябышып яткан. Без, мәсәлән, идарә итү фәне барлыгын, арадан сайлап алып зирәкләрне шул мөһим фәнгә өйрәтергә, шул рәвешчә дөнья күтәргә кирәклеген уйлап та карамадык. Икътисад кануннарын бик яшьтән танып белергә кирәк, дип безгә берәү дә әйтмәде. Беркатлылык татар гадәте, бул юаш, хәйләсез, бүген син—ишәк, иртәгә—йөк аты. Тормыш безгә нык сеңдергән төп фән әнә шул иде. Җитәкчеләр, югарыдагылар кайдадыр чит кырларда үсә дә... аларны безнең түргә кылыч тактырып китереп утырталар. Күргәнебез шул, инанганыбыз да шул булды.

Тормыш шартлары, нужа бабай, хәерчелек тә шушы, кеше җанын какшата торган кануннарны татарга өстәп, сеңдереп килгәннәр. Бер мисал:мин урта мәктәпне сугыш беткән елны, кырык биштә тәмамладым. Унҗиде яшьлек егет! Характерның бөреләнеп чәчкә аткан чагы! Унынчыга, ата-бабамнар яшәгән төбәккә Сарманга ике ел күтү көткәннән соң килдем. Төннәр айсыз, көннәр дөм караңгы булса да яшьлек үзенекен ала, Минзәлә елгасы ягасында атауда кичке уеннар булгалый. Мин дә атауга төшәм, читтән-читтән гөр килеп биеп-җырлап йөргән кызлар көтүенә карап торам. Уенга кермим, биюгә катнашырга базмыйм. Аягыңда сусәргән мыеклы чабата, күттә сидрәп беткән түбә ямаулы чалбар, иңдә агарып-юкарып беткән иске солдат гимнастеркасы... Ничекләр кыеп уен уртасына янып торган кыз-кыркын арасына керәсең? Кызлар бөтен барлы-

гымны, шигъри күңелемне йотып алсалар да мин, серле кыяфәт алып читтәрәк булырга тырышам, аккан су, ай урагы, яр буе бизәкләре таллар белән серләшкән булам. Серләшәм дә! Мескенлек—геннардан озак еллар дәвамында бик авырлык белән китә торган сыйфат ул. Бу сыйфат татарның үзәгенә үткән, бәгыренә төшкән. Син ул әшәке йогынтыдан арынып, бер арата гына өскәрәк менәм дисең... тормыш барыбер изүеңнән эләктереп ала. Әтиеңне кимсетәләр, мәсхәрәлиләр... Анаң бичара кара язмыш тәгәрмәчләре астында кала. Авылдашларыңның, кардәш-ыруларыңның зар-моңнары туктаусыз сиңа агылып тора. Кай якка карама—хәерчелек, юклык, бөлгенлек. Күңелеңне өзмәс авыр моң баса!..

Һәммәсе алдында да син—көчсез, син—чарасыз. Җан тартыша, күңел үсми.

Шулай яшәлде, мин бик озакларга кадәр әнә шул җәрәхәтләрдән арына алмадым. Әле хәзер дә начальниклар ишеген кыяр-кыймас кына кагам. Йомышым ни тәҗел булганда да алар катына барып баш ияргә базмыйм. Улларымда да шул ук сыйфатлар бар. Бигрәк тә олы улым Искәндәр кыюсыз, басынкы. Нәбәрә-оныкларым да шулай булмас дип кем әйтә ала?!

Каһәр суккыры, балаларга бүтәнчә тәрбия биреп тә булмый бит! Тәрбия—ата-ана теләгенә буйсынып кына нәселдән-нәселгә күчә торган гамәли сыйфат түгел, нишлисең: башны ташка орасыңмыни!.. Хәлбуки, балалар,татар сабыйлары, идарә итү фәне белән бик иртә кызыксына башларга, нидер беләргә, туктаусыз өйрәнергә кирәклеген аңларга бурычлылар. Урыс: "простота—хуже воровства!" дип тиккә генә үз балаларына тукып киләме?.. Оялчанлыкны, басынкылыкны, буйсынуны безнең канга буыннан-буынга сеңдергәннәр. Берзаман тарих әзрәк кенә үзгәреп, татарның да күзе-колагы, теле вә теше барлыгы билгеле булгач, милләт хадимнәренә ихтыяҗ туды. Буш урыннарга беренче чиратта әрсезләр, ачарбаклар, тәмле тамаклар менеп утырды. Коммунистик мәктәптә сабак алган, аякланган кадрлар иде болар. Бүтәнчә тәрбия мәктәпләре булмагач шул явызлык мәктәбе шәкертләре Татарстан белән идарә итә башладылар. Башта җыйнаулашып Мәскәүнең күнегелгән җырларын җырладык, әле безнең тавышларны күмәк җырда гына ишетергә мөмкин иде. Торабара тормыш күмәклек арасыннан солистларны таләп итте. Табигать үзенекен итә, милләт түренә омтылган кичәге коммунистлар да сагаеп кына, як-якларына каранып булса да үз тавышлары яралганын сиздерделәр. Һәм шушы ике-өч ел дәвамында ил-көн каршысында абруй да казанып өлгерделәр. Мин Минтимер Шәймиевне күз алдында тотам. Аның Мәскәү кубызына биергә бик үк теләмәгәнен шуннан әйтәм, Мәскәүнең карагруһ шовинистлары шактый нык талкый башладылар егетне! Үз этләребез дә күздән ычкындырмадылар, нәни генә чатагы сизелсә дә арттан да алдан да типкәләделәр. Тәүге хөрмәтне Минтимер сабырлыгы белән казанды. Төрле яктан ябырылган әнчекләргә сәлам бирмәде, Мәскәү белән арадашлыкны уңай дәрәҗәдә саклады, федераль шартнамәгә имзасын салмады. Иплә кенә җөмһүриятнең хокукларын, бәйсезлеген саклады. ГКЧП көннәрендә ул беренче тапкыр абынды. ГКЧПның ялгыш кына өскә калкуын без ап-ачык белеп тордык, чәнчелеп төшәсен юрадык. Мин: "бер атна торыр", дидем. М. Шәймиев тирәсендә әзерлекле политологларның булмавы аны хаталандырды дип уйладым мин. Алга таба җөмһүриятнең икътисады ныгуы, нефть табышлары, 1992 елда Татарстан кырларыннан алынган көтелмәгән уңыш Шәймиевкә нур өстәде. ГКЧП онытылды, яисә онытылып торды, татарларның рәсми лидерларына кыюлык килде. Үз-үзен тотышына, кыяфәтенә, тавышына, без моңарчы татарда күрмәгән олпатлык килде. Күңелем белән мин аның "Ил агасы" булып җитешүен күрдем, сөендем!..

Менә тагын октябрьдә коммунистларның чираттагы фетнәсе күтәрелде. Рәсәй язмышы кыл өстендә калды. Татарстан—илләр арасында Рәсәй белән иң тыгыз бәйләнергә мәҗбүр булган ил! Татарстан өчен Казанда кемнең, кайсы төркем вәкиленең хуҗа булып утыруына караганда Мәскәүдән нинди җилләр исүе дә мөһим шарт. Тормыш шундый кысан шартлар тудырып ныгыткан ки, Мәскәүне кемнәр үз кулында тотуы безнең киләчәкне дә билгели. Әгәр 3-4 октябрь көннәрендә Руцкой-Хасбулатов-Макашовише коммунистлар җиңгән булса...Татарстанның үз билгеләнү хокукы, милли үсеш тирәсендәге хыяллар, җөмһүриятнең бәйсезлеге иртәнге томан сыман тарала да бетә иде! Кайсы якка борылып баксаң да Татарстан язмышы Мәскәүдә нинди хөкүмәт утыруга тыгыз бәйләнгән. Хуш, Мәскәүдә фетнә. Фетнәчеләр җиңәсенә тулысынча

ышаналар. Руцкой: "Очучылар—минем кулда, әфганнар мине яклый, чекистларның күпчелеге мине яклый", дип юкка гына әйткәнмени? Иң төпле дәлил шул булыр...

Мәскәүдә чуалышлар! Илгә мәгълүм шәхесләр һич көтмәгән борылышлар ясап куеп гаҗәпкә калдыралар. Ил башларыннанniләр өметләнеп көтсәк тә, ахыр чиктә, без барыбыз да коммунистик агулы тәрбия сеңгән куркыныч кешеләр. Ак йортны саклаучылар да, саклаучыларга каршы корал алганнар да адәм җанын кызганып тормаганнар, кырганнар да кырганнар. Үлүчеләрнең төгәл санын ике як та киметә, дөнья җәмәгатьчелеге белмәслек дәрәҗәдә тырышып-тырышып яшерә. Иң мөһиме шул иде: 3-4 октябрьдә Мәскәүнең Ак йорт алдында Татарстанның барыр юлы вә киләчәге хәл ителә иде... Ә Татарстанның үзендә нiләр булды?..Шым..берни дә булмагандай булды... Якутларның лидеры Николаев фетнә башлануга ук Мәскәүгә, Ельцин янына килеп җиткән дип сокланып сөйләделәр... "Авызың пешсә, салкын суны да өреп кабасың", дип әйтеп калдырган бабайлар... Урысның күт астына су керсәме?.. "Урыс бунтыннан Ходa сакласын!" дип Пушкин әйтеп калдырганмы?.. 3-4 октябрьдә Ленинның, аның фетнәчел кануннарының, ул төзегән дәһшәтле-канлы империянең соңы килде. Дөрес, әле коммунистлар тиз генә бирешмәс, алар җир астыннан да агуларын чәчеп ятачаклар. Адәм балаларының иң зур бәхетсезлеге шунда, алар инде күмелгән, череп таркалган мәетләргә дә баш орырга, аларның исемнәрен түрдә тотарга яраталар. Иң зур җинаятьләр кылган явызлыкларның каберләрендә чәчәкләр үсә, адәм улларының миләрен сөремле торган куркыныч чәчкәләр... Әле коммунистик илләр күпме... Фидель явызлар бар... Әле Рәсәйнең үзендә ленинизм белән агуланып мәңгегә акылга килә алмаслык миллионнар бар. Алай да, Ленин тәгълиматы какшаган чор. Җир шары иркен сулыш алырга әзерләнгән тарихи чор...



*Татарстан Язучылар берлеге йорты ишегалдында Мөхәммәт Мәһдиев белән. 1993 ел.*

Татарның итәге юешләнеп бозга ябышып катарга гына тора аның... 3-4 нче октябрьдә, берни белмәгән-күрмәгән булып кыланып йөреп, без суверенлыкка торган юлыбызга таш канатлары өйдек. Кайчан канатларны алып ташлап юлны аруландырырбыз? Кем чистартыр татарның барыр юлын?

Хатирәләремнең шушы кадәресен егермеләрендә язарга тотынган идем, бүген 23 числода йомгаклап куям.

### 23 октябрь, 1993 ел, Переделкино

Соңгы көннәрдә нык кына суытты, төннәр айлы, һава саф, салкынча, рәхәт. Рәшат белән Миләүшә килеп ике кич кунып киттеләр. Равил Фәхретдиновның ике улы бар, икесе дә өйләнгән. Йортларына уңган киленнәр төшкән—Равилнең өч оныгы, өч малае бар! Кулыннан бер дә төшерми икән малайларны! Равил йорты—игелекле йорт, нәселе нык, димәк ул ашлы нигездә өч татар үсеп килә... Мин дә кызларымнан канәгать. Тик алар өчесе дә татар егетләренә кияүгә чыгып, татар кавемен дәвам итәрләр дип кем раслый ала? Сайлау хокукы егетләрдә. Әнә ич, Алмаз энекәш, олы кызы Әлфиянең кияү таба алмавына әрнеп: "Инде насыйбы чуваш булса да риза, чыксын гына иде!" дип әйтеп салды...

Бүген иртәдән бирле кар ява. Күзгә рәхәтлек, җиргә аклык, күңелгә сөенеч алып килә торган Переделкино кары. Мин өченче катта, карның талгын гына утырып, сабыр гына агачлар куенына коелганын күзәтергә яратам. Дөнья күз алдында үзгәрә. Дөньяга мөнәсәбәт үзгәрә. Килгән шәпкә сөенеп, очынып, ку-

ана-куана эшкә ябышкан идем. Иртәләрен җилдәй очып йөрим, адымым җиңел, Казандагы сыкраулар беттеме әллә? дип куанам. Өч әйләнәм, өч ярым, ярәнгә дүрт әйләнергә җыенам. Пәнҗешәмбе көн иртән шәп-шәп атлап киттем дә, йөрим, йөрим, түгәрәкне ике үттем, өченчегә борылып йортка таба килә идем, кинәт әлләни булды. Гәүдәм эреде дә акты. Йөрәк тә авыртмый, тигез генә типкән сыман, тирләмәдем дә, ә атлап булмый. Аяклар җирдән аерыла алмый, гәүдә авыр, үземә-үзем хуҗа түгел. Кая ул өченче түгәрәккә тәвәккәлләү! Беседкаларның берсенә кердем дә, култыксага таянып ял итәм. Кәеф кырылды, күңел коега төшеп китте. Шактый басып моңаеп тордым. Күңелнең караңгылыгын куарлык, эшкә дәрт иңдерерлек ник бер уй килсен башыма! Диабет астыртынявыз тез астына китереп типтеме? Монда диета белән исәпләшеп торып булмый, әндри әбәденә тәгаенләгән баллы-төче күмәчләрне дә ашарга туры килә, творогка да шикәр сибәләр, бәрәңгене калдырасың икән, көне буе ач йөрергә туры килә. Ашала инде, тәмугка кертәсен белсәң дә тамакны җиңеп яки алдап булмый. Шул сынык күңел белән күп вә тиз йөрергә дә куркып, менә ике-өч көн адымнарны санап, гәүдәне төз тотып, яраланган киек сыман ихатадан читкә чыгарга куркып йөрим. Күтәрелеп карыйм, шәп-шәрә каеннарның югарыга үрелгән очлары, дәү-дәү себеркеләр булып, күкне себерәләр, ары-бире тоташтан чайкалалар. Эх, искәрмәс күңел түренә утырган хәсрәт юшкыннарын себереп ыргыта торган бер кодрәт булса иде! Шул көннән повестька тотынган да юк әле. Кичә-бүген көндәлегемне алга этәргән булам... Уйладым—менә мин язам, көн-төн уйладым, уйлардан котылмак юк. Кемгә хаҗәт хәзер мин язганнар?.. Татар укучысы кайчанга кадәр булыр?.. Безнең аз санлы бүгенге укучыбыз с о ң г ы   т а т а р л а р түгелмени?.. Ун еллардан соң, егермедән татарча укучы булырмы?.. Каян килер ул? Аны кем әзерләр? Менә радио аша турыдантуры элемтә дигән тапшырулар бара. Сорау бирәләр, наданнарча гына булса да әлегә кызыксыналар. Ни аяныч:ник арада бер яшь кеше сорау биреп үз буынының барлыгын белдерсен! Менә ни суыта минем күңелне! Рахмай Хисмәт кебек: "Рудольф Нуриев, Софья Гобәйдуллина, Роальд Сәгъдиевләр татар булганнар...Татарлар алар—безнең куанычларыбыз!"—дип үз-үземне алдап утырыйммы?.. Беренчедән, ул санаган мөгтәбәр затлар бер чакта да татар булмаганнар, алардагы татарлык—ай-һай! Аннары, юк икән, нигә ялган юанычлар эзләп, күрәләтә бер-беребезне алдыйбыз без?!

**25 октябрь, иртәнчәк**

Көннәрне бутаганмын, ахрысы, кичә егерме дүрте булган ләбаса! Мин "кайтырга фәлән көн калды!" дип санап маташам. Кичә кышның чыны булды, көне буе кар яуды. Кичен футбол: кар ерып "Спартак", "ЦСКА" егетләре туп кудылар. Футбол җене кагылганнар юк, бер башым тамаша кылдым. Бүген эшкә кайтырга вакыт җиткәндер. Байтак симерттем ялкауны! Казанда Литвин ыжгырып көтеп торадыр! Менә эшлекле кеше! Совет заманында туып, совет чорында яшәсә дә еврейлыгы һич китмәгән Литвинның! Мәсьәлә кайсы чорда яшәвеңдә генә түгел, кемнең тамырларында нинди геннар төягән кан агуында! Татарның генфонды бозылып беткән шул. Менә нәрсәдә хикмәт!

Миңа да, мин бичарага да, Бикчура ханнан ук килә торган нәсел җепләренә терәк булган геннарны уятырга бик вакыт! (Әгәр соңармаган булсам!!!!!)

Килгән төшкә Ямил—сыткы сагыз ябышып, кич саен: "әйдә, берәр чәркә тотыйк инде!" дип коткы салып йөрсә дә эш агачым җимеш бирә башлаган иде. Шуннан берара әлләни булды. Баш каядыр тәгәри, туктап торса зыр-зыр әйләнә, болай да чак эләгеп торган уйлар, көчле җил тараткан мәкинәдәй, очып югалалар. Юк кына нәрсәләргә дә дикъкать игелә шул. Путевканың соңгы ике көне буталып, Мәскәүдән шалтыраталар: "Сезнең бүлмәгә алтысында Барнаулдан берәү килә",—имеш. Юк нәрсә, бүлмәләр буш диярлек, урын табылыр иде, ә ятасың—шул искә төшә, уянасың—тагын шул инә чокчый җанны!.. Ниһаять, аны да хәл иттек. Шуннан соң, Ходаның хикмәте, эшем гөрләп китте. Бара! Менә өч көн—нык кына һәм нәтиҗәле язам. Повесть героеның үзенчәлекләре ачыла бара, характеры табыла. Әле беркемнең дә исеме ачыкланмаган. Җәлладның татар булуы эчне тырный тырнавын, ул чынбарлыктан да тәмам качып, котылып булмас шул. Исемнәр әдәби әсәрдәге кешенең асылына ярашып, берегеп торырга тиеш. Әсәрнең герой исеме аның хәрәкәтенә, ритмына ярашмаса, атла-

ган саен телне көрмәкләндерә. Ә палачка нинди исем кушарга? Үземә җайсызлаган берәүнең исемен кушыйммы әллә? Килешмәс, бигрәк күзгә кылчык булып кадалып торган исемнәр.

Ямил "Наш современник" журналының 2,3 саннарын калдырып киткән иде. Үткән төндә Борис Можаевның "Изгой" исемле романын укыдым. Журналның тенденциясе куркыныч, ул урыс күңелендә ватанпәрвәрлек уятырга тырыша. Урыс үз тарихын, үткәнен вә бүгенгесен, сугышларда җиңүләрен, батыр солдатларын телгә кертә икән, шунда ук аның теленә "татар" сүзе эленә. Нинди сүзләр белән генә каһәрләми журнал татарны! Шигырьләрендә исемнәре атап әйтелмәсә дә туксан процент татарлар каһәрләнә. Ай-һай, журнал үгетләре белән генә, урысның кара төркем булып тупланган әдипләре сүзе белән генә, иманын югалткан урыс милләте яңарыш чорына барып керә алырмы? Мин Югары курсларда укыганда, семинарларның берсендә: «һәр милләтнең үсеш юлы бар, туа ул, үсә, тамырлана, чәчәк ата һәм һәлак була", Х1Х гасырда үзенең иң биек ноктасына менгән урыс милләте бу гасырда һәлак булачак", дип чыгыш ясаган идем. Партбюрога чакырып алып арт сабагымны укытмакчылар иде, партиясез икәнемне белгәч куып чыгардылар. Можаев чын әдип, алган темасын белеп, тирәнтен актарынып, югары сәхнәгә меңгереп яза...

Эрнест Сафонов Югославиядән бер повесть язган. И яратмый инде мөселманнарны! Мөселман кыргый да, вәхши дә, сасы исле шакшы да. Татар-башкорт арасында яшьли яшәгән бу кешечек элгәре татарлар, мөселманнар хакында яхшы ният белән хөкем чыгара торган иде, хәзер үзгәргән. Чыны кайчан иде: элекме—хәзерме? Адәмнәр ашыгып-ашыгып битлекләрен алыштыра торган чак!

***

Бүген егерме тугызы, берсекөнгә Нәкыя килә. Аны көтәм. Мондый да мәрхәмәтле октябрь булыр икән! Унбишенә кадәр Казанда ае белән табигать бәйрәме булды. Монда да, җил болытларны селки-селки кар бөртекләрен иләп ала да, ялтырап ягымлы кояш чыга. Һава таза, әле салкын патша тәхеткә менеп җитә алмады. Алама тунын сөйрәп тәхет аягы тирәсендә мыштырдап йөри. Кичә алдан һич уйламыйча "Кар ява, кар" исемле хикәя яза башладым. Бәхетсез, бичара, гарип Петрович белән очрашып сөйләшү миңа нык тәэсир итте. Менә ул арып, хәлдән таеп, иске себеркесен кочып йортыбыз баганасына сөялеп тора. Болдырга чыгып баскан тук, симез, иркә Мәскәү маржалары этләрнең танавын үбәләр, мәчеләрне сыйпый-сыйпый ашханәдән алып чыккан көтлитләр белән сыйлыйлар. Ә сиксән яшьлек бичараның күз яшьләрен берәү дә күрми. Үзем дә моңарчы күрмәгәнмен, белмәгәнмен. Картлыкта адәмнең күзләре бәхетсезлекләрне җетерәк, ачыграк күрә башлый.

Милли аң үсеше хак сүзләр, тарихи дөреслек белән беркетелмәгән совет әдәбиятына иртәгә мөнәсәбәт ничек булыр?.. Әле яшәү мәйданыннан китеп бетмәгән, көймәнең койрыгын кулларыннан ычкындырырга уйлап та карамаган, бүген битлекләрен оста гына алыштырып яшәп килгән татар большевиклары, үткән чорның зарарлы, ярлы әдәбиятыннан да нәкъ үзләренә файдалы, киләчәкләрен тәэмин итә торган гыйбрәтләр табып алып шуны чәйнәмәсләрме?.. Иман алыштыру, кабатлап әйтәм, берчакта да ансат булмаган, әмма яңа заманга безнең кебек җимерелеп, ватылып килеп кергән халык тарихта булдымы икән?.. Иман алыштыруны җиңелгә санап, бүгеннән: "халкыбыз уянды, ул бүтән!" дип сөрән салучылар нык хаталаналар. Һәм ул хаталарның кая илтеп җиткерәсен уйлап карау юк. Кинәт уяту өчен чамасыз олы көч, җир тетрәтерлек вакыйгалар кирәк. Булырмы алда андый вакыйгалар, табылырмы андый бинийһая үлчәүсез көч?..

Рәсәй яңа конституция кабул итәргә әзерләнә, аның төрле вариантлары җаваплы кешеләрнең миен черетә. Әлегәчә мәгълүм булган проектларда "самостоятелная республика Татарстан" дигән мәгънә юк. Ярый ла Президент Шәймиев ипле генә басып торып, егылмыйча Татарстанны яклый алса! Ярый ла Ельцин җәнаплары безне аңларга омтылып караса! Чаллыярны инде коралланган, инде тешләрен кайрап үткерләгән башсыз җитәкчеләре яшьләребезне котыртып утка алып кермәсә! Татарстан мисалында Рәсәй империясенең тагын бер кат, инде бик озакка таралып китүе бар! Свердловск "Урал республикасы" дип үзен игълан итте. Тарихта булган ич, кенәзлекләр булган, тагын шул чор әйләнеп кайтмасмы?.. Чөнки шул кадәр зур, иләмсез, котсыз дәүләт үз санын

үзе күтәреп тора алмый шикелле.

Бездә ул кадәр сизелми иде, Мәскәү чынлап торып капитализмга кереп бара икән! Төрле катлауларның, бер-берсенә һич охшамаган төркемнәрнең юлы нык аерыла, моны күрү өчен әлләни вакыт та кирәкми. Берәүләр—хап та хоп халык авызыннан миллионнарны тартып алып, капитализмга, аның җылы түренә үтә алганнар, кыйммәтле чит ил машиналарында җилдертә. Машиналарның тизлеге арткан, әкрен кыймылдасаң, хәзер изеп-таптап китәчәкләр. Иң кызыгы шунда ки, тиз барып, куелган кагыйдәләрне бозсаң да куркыныч янамый, ГАИ егетләре дә долларның, марканың, фунтларның бәясен нык үзләштергәннәр. Тәртип бозасың икән—долларга атланып сират күперен теләгән кадәрле үтеп чыгасың... Капитализмга беренчеләрдән булып коммунистлар партиясенең өлгер вәкилләре барып керде. Алар әзерлекле, идарә итү, урлау тәҗрибәләре җитәрлек, иң мөһиме—алар бердәм, хуҗалыкның кайсы тармагына борылсалар да элеккеге әшнәләрен, атаклы карак-бурларны, тәмле ашарга яраткан фирка әһелләрен, КГБ ялчыларын, оста каракларны табалар. Караклар каракның исен ерактан сизә!.. Илдәге мал—элеккеге партия тарафдарлары кулында.

Аларга кызыгып карап, көнләшеп, җае килгәндә бу кучеш чоры каракларының җанын кыюдан да чирканмаган икенче төркем бүтән сукмактан уза. Мәскәүлеләрнең чиреге, килгән кунакларның яртысы бәләкәй арбаларга күчкән. Арбалар, арбалар, арбалар... Безнең күз "уф алла" арбаларына авыл юлларында күнеккән. Гадәттә ул чак арбаларында утын, печән, бер-ике капчык бәрәңге була иде. Ә капитализмның бүгенге көн шома сукмаклардагы арбаларынданиләр барын җир йөзендә кылынган гөнаһларны санап барырга көчләре җиткән фәрештәләр дә санап, исәпләп-хисаплап бетерә алмас иде. Алып сатарлар, маклерлар, мал юллаучылар, кыстаучылар, алдаучылар, теләсә кемне сугып егып өскә калкырга тырышкан бөкеләр, ирләр, хатыннар, беләтләр, угрылар, тәнсатарлар—һәммәсе дә бар бу бәләкәй арбалар салган яңа заманның тар сукмакларында. Мал арбаларга гына сыймаган, шытып килгән капиталистның куллары буш түгел, уңынасулына дәү-дәү буаз букчалар эленгән, иңөсләре дә буш түгел, биленә дә уннарча капчык-янчыклар асылган. Бау белән биленә тагылган арбасын сөйрәп, бөтен якларына асылган бөкреләрен чайкалтып чаба Рәсәй балалары. Хәзер шәһәрләрдә йөкле хатыннар бөтенләй күренми диярлек, хатыннар шикле, өйрәнелмәгән капитализм дөньясына яңа гражданнарны катнаштырып җибәрергә ашыкмыйлар, көтәләр. Күрәм, ике метрга якын буйлы, куна җилкәле бер хатын килә, адымнар шәп:лап та лоп атлый... Ходәвәндәм: йөкле ич бу! Кендек тирәсе бүрткән, җәелгән, калкынган. Шулай дип уйлап бетермәдем, йөкле дигән хатыным, каршысына килеп чыккан баһадир кебек ирне бер якка чөеп җибәрде. Баксаң, бәбиле корсак дигәнем, ниндидер мал төргәге икән!

Метро. Керү-чыгу. Адәмнең бичара балалары, яңа тормышка ашкынган уллары Днепрогэс буасы булып бөяләләр, төрткәләшеп, эчтән генә бер-берсен сүгеп, каһәрләп торалар да, ниһаять, буа ерыла. Ташкын тау-тау дулкыннарын ияртеп эскалаторга кереп китә. Элгәре халык уллары эскалаторның бер ягына сеңеп, сул ягын ачалар иде, ашыкканнар, тизлек яратучы яшь-җилкенчәк эскалатор тизлегенә сыешмыйча араталарга җәлт-җәлт басып аска йөгерәләр иде. Хәзер... Капчыклар, төеннәр, таулар арасыннан таракан да үтеп китәрлек түгел, җитү чәче майланып култык астына төшеп җиткән, үтүкләргә ярамый торган торба чалбар кигән бер әрсез аска төшәм дип алга ыргылган иде, ә дигәнче күздән югалды, шактый вакытта тегене әрекмән колакларыннан сөйрәп чыгардылар, капчыклар арасына кысылган икән бичара. Тыны бетеп танавы канаган әрсез үсмернең.

Менә мин—алтмыш биш яшьлек карт, чемоданнарымны сөйрәп, көчкә-көчкә тын алып Казан вокзалының перронынннан үтеп барам. Йөкчеләргә эш кимегән, һәркемнең диярлек кулында үз арбасы. Мин оялып арба алмаган идем, юньсез...

Кая барам мин бүген? Нәрсә йөртә мине?.. Уй дәрьясыннан качып котылмак юк. Казанда җанымны белгән уйлар, күңелемне иңләгән фикерләр берсе дә юлда төшеп калмады, һәммәсе, һәркаюсы аксаклый-туксаклый ияреп баралар. Әдәбиятның язмышы ничек булыр... Менә шул борчый мине! Безнең яшьтән үк партиягә җаннарын тапшырган картларыбыз бер тамчы да үзгәрәчәк түгел: Г. Бәширов, Р. Ишморат, С. Батталлар үзгәрә аламы?.. Аннан соңгы буын вәкилләре коммунистик сандалларга чүкелеп, коммунистик тормыш шар-

тларында сугарылган кешеләр. Ленинизм—ябышкан идея, аның моделе бик гади—"күз күреп җиткән офыкларда сине оҗмах көтә!" Бүген ни булса да түз, чыда, киләчәк бәхетең өчен бүгенгеңне корбан ит! Сүзнең көчен, бөтен куәтен, исерткеч тәмен бары тик коммунистлар гына белеп бетерде. Без барыбыз да, акыллы гына сүзләр ычкындыра алган Салих Батталлар да Ленин идеяләренең җимергеч чүкече астында калып аңнары изелгән кешеләр... Без шушы җитмеш ел дәвамында татар халкының асыл иманын җимерергә өзмәс булышып килдек. Газетларда укыдым, Брежнев Украина хуҗасы Щербицкийдан: "Якындагы биш елда Украина урыслашып бетәме?" дип сораган. "Бетәчәк!" дигән Щербицкий. Табеевтан шулай дип сорамаганнармы алар? Усмановтан? Әлбәттә, сораганнар һәм һичшиксез безнең юлбашчыларыбыз да "Урыслашу тәмамланачак!" дип үрә катып, зур тантана вә ышаныч белән җавап биргәннәр...


*Хатыны Нәкыя белән. 1996 ел.*

Хәзер халкыбыз ике төркемгә бүленәчәк, байлар вә ярлылар катлавы барлыкка киләчәк. Киләчәктә бу аерма тагын да тирәнәячәк һәм аерымлык мәңгелек канунга әвереләчәк. Ярлы булырга туганнарны баета алмый торган замана килә. Байлар тагын да баеп ярлылардан күпкә өскә менәчәк. Бу җәмгыятьнең какшамас үсеш законы. Байлар татар булып калырмы, әллә алар үзләренә файдалы бүтән юл сайларлармы? Кайсы төркемгә хаҗәт булачак татар әдәбияты? Кем укыр татар телендә?.. Җитмеш еллык сыналган әдәбият хәзинәләрен тоташтан яндырырга, көл итәргә туры килерме?.. Большевизм чорында өстен саналган темаларга берзаман мыскыллау, көлү башланачак.

**7 ноябрь, 1993 ел, Переделкино.**

Бүген монда соңгы көн. Иртән юлга төеннәрне барлый башласак... ха-ха-ха! Ничекләр автобуска керербез дә, ни хәлләр итеп метроны узарбыз. Ярый ла Мәскәү хәвеф-хәтәрсез генә озатса... Кичә большевиклар өндәүләр күтәреп, чәчкәләр тотып үзләренең мәңгелек аталары Ленин янына килеп сәламнәрен тапшырдылар. Бүген мәркәз милициясе сагайган, Кызыл мәйданда хәрәкәт, коммунистлар җыйнала!

Кичә ишетелгән ике хәбәр сабырларны да аяктан екты, Ельцинга азмы-күпме ышаныч баглаганнарның да өмет шәмнәрен сүндерде. Беренчедән: "Президент сайлауны уникенче июньгә билгелибез, чигенү дә, чигерү дә булмаячак!" дип белдерде. Яраннары аның бу көтелмәгән адымын акларга, төрле сәбәпләр табарга тырышып, аяк астында убылган балчыкны цементларга азаплансалар да моңарчы аңа ышанып килгәннәр дә егылды. Шуңа өстәмә, Рәсәй хәрбиләре "Россия атом-төш коралын беренче башлап куллану хокукын үзендә калдыра", дип белдергәннәр.

Парламентның сулга каерылганын күрә торып бернинди төпле чара табалмавын, гамьсез битарафлык саклавын аңлаганнан соң мин беренче тапкыр Ельцинга ышанычым какшавын язып үткән идем инде. Дөрес! Мин сарык түгел, аның да гап-гади бер урыс икәнен күрә килдем, ләкин... кем алыштырыр Ельцинны? Коммунист-фашист Хасбулатов белән Руцкоймы? Макашов өреме? Җүләрләр йортыннан ычкынган Жириновскиймы?.. Алар белән чагыштырганда Ельцин күңелемә якынрак тоела иде. Хәзер, адым саен үз сүзеннән кире кайтуы, вәгъдәсезлеге белән аңа булган ышанычым нык какшады. Коммунистлар партиясен хөкем итеп, хурлык баганасына кадаклыйсы урында, ул аларга ирек, мөмкинлек юлы ачып, өндәп сайлауларга алып кереп бара. Тиешле имзаларны иң әүвәл, беренче булып һәм сан өстенлеге белән нәкъ коммунистлар җыйды. Мәскәүдә чыга торган фәләстин гәҗите "Зюганов президент булачак!" дип тантана белән белдергән иде, хак булып чыгар шикелле! Әйткән сүзен җиренә җиткерә алырлык ныклык юк икән Ельцинда. Шәймиевнең фетнә ва-

кытында Мәскәүдән читтә йөрүендә дә бер-бер мәгънә табарга була! Әгәр иртәгә Ельцин чәнчелеп барып төшә икән—Шәймиевнең йөзе ак!

**13 декабрь, 1993 ел, иртәнчәк**

Соңгы атна шик-шөбһәләр чытырдап ябышкан кием итәген сөйрәп йөреп үтте: сайлауларны көттек. Депутатлар, хөкүмәт әһелләре авыз тутырып: "сайлауга барып йөрүнең файдасы юк!" дип игълан иттеләр. "Яңа конституция проекты милли җөмһүриятләрнең мөстәкыйльлек идеясен санга сукмый, без, элеккедән дә яман хәлдә: Казан губернасы булып кына калабыз", дип күпчелек милләттәшләребез гайрәтләнеп, кыюланып сөрән салдылар. Сәяси төркемнәрне җитәкләгән лидерлардан иң батыры Вл. Жириновский булып чыкты. Ул, һич читенсенмичә, икеләнмичә: «Әйе, илдә урысның өстенлегенә ирешергә, аны мәңгелеккә ныгытырга кирәк... Әйе, сугышсыз яшәп булмый, дөньяның иң җитди мәсьәләләрен бары тик өченче бөтен дөнья сугышы гына хәл итәчәк... Әйе, без җылы океаннарга барып чыгарга тиеш... Әйе, Кытай, Төркия, Һиндстан кебек илләрне бары тик Рәсәй генә акылга утыртырга тиеш... Әйе, алда шундый икътисади шартлар туачак әле, Балтыйк буе илләре, Урта Азия илләре "безне урыс канаты астына алыгыз, зинһар!" дип ялынып киләчәк...» дип белдерде. Тайчынып тормады, урысның сиксән биш проценты уйлаганны бик яхшы белгән, ачыклаган, үзләштергән Жириновский үзенең кара максатын, шуңа ирешү юлларын, иманын чак кына да яшереп тормады, үзенең урысның күпчелегенә таянганлыгын белеп эш йөртте. Узган сайлауларда аның партиясе 6 миллион тавыш алган иде. Мин бу араларда "властька Жириновский киләме?" дип куркып йөрдем. Марксизм һәм фашизм—славян халыкларына, урысларга иң ятышлы, иң уңай идеологияләр. Басып алу, буйсындыру, илләр, халыклар язмышы белән уйнау—урыс милләтенең иң яраткан, иң хозур шөгыле! Ленин халыклар белән үзенчә уйнаган, халыклар—сычкан, Ленин усал, астыртын, яшькелт күзле Мырауҗан булган. Рәсәй киңлекләрендә булып узган, тегe яки бу күләмдә милләтләрне урыслаштыруга күп көч сарыф иткән әтәм-сәтәм илбашларын санап тормыйм. Күңелсез вә ямьсез эш булыр иде болары!.. Алдан бер нәрсәне искәртик:милләтләр язмышы белән усал "шаярган" илбашы артыннан ук, аның эзләренә басып ук икенче бер илбашы тумый, ул беренче кылган гамәлләрне саннамаган, тәнкыйтьләгән булып та кылана. Явызлар арасында, әлбәттә, урталыкта, бераз йомшаграк, милләтләрнең әткәсе булып уйнаучы шәп-шәп артистлар булып үтү зарур. Брежнев, Андроповлар шундый кыланчыклар иде бугай. Еллар үтте, илбашлары алышынды, милләтләр тутырылган капчык, ниһаять, Ельцин хәзрәтләре кулына төште. Ул берара капчык бавын бушатып, әчкә, караңгы тынчулыкка әз-мәз тын һава җибәрде. Татарлар да сулыш киңәйтеп, сөйләшер хәлгә килделәр. Рәсәйдәге милли кысынкылыклар чак кына онытылып торды дияргә булды. Ләкин Ленин-Сталин, тарихның иң бөек явызлары, үз тәгълиматларын дөньяда раслар өчен милләтләр узасы юлларга куркынычлы, дәһшәтле миналар тыгып-тутырып куйганнар иде инде. Әфганстанда совет армиясе калдырган миналарны тазартып бетерер өчен мең ел кирәк дип саныйлар! Совет солдатларының кермәгән тишекләре, үтә алмаган ярыклары калмаган дигән сүз!..Җир шарында совет системасы борын тыкмаган, үзенең агуын чәчмәгән бер почмак та калмаган шул, калмаган. Тарих мәйданына алда чыгачак лидерлар әнә шул билгеләнгән сәгате-минуты килгәнне көтеп ятучы җимергеч көчләргә, ленинизм миналарына гына таяналар. Миналарның урыска һәр даим ярдәм итәчәген белә Вл. Жириновский! Шуңа күрә ул урыс явызлары көткән сүзләрне көчәйтеп, сулышын киңәйтергә әзерләнгән милләтләрнең маңгаена гына чәпи!.. Аннары... Сталин явызлыгы әз-мәз онытылды, җимерелеп бетмәгән вә бетәчәге дә юк, ленинчылар Ленин-Сталин гамәлләрен тагын бер кат алга манып аңгыра адәмнәрнең күзен сукырайталар. Ленинизм белән фашизм һәрвакыт кулга-кул тотынышып яшәделәр. Һәм бүген тагын бер мәртәбә аларга якты көн килде:кичәге сайлауларда иң зур күпчелекне Жириновский өерә алды. Рәсәй сайлаучыларының 26 проценты фашистлар лидеры Жириновскийга тавыш биргән. Әле бу процентка ничә миллион бәндә кергәнен белдермәделәр... Икенче урында хөкүмәт җитәкчеләренә тавыш биргән «Выбор" өерә бара. Жириновскийның уңышларын күреп "Выбор"ны беренче урынга күчерәләр дә, Владимир Вольфович икенче булып кала... өченче урында коммунистлар...

Зюганов, Умалатова һәм башкалар... Элеккеге, кичәге сайлаулардан чыгып, ышанып әйтергә була: өченче сайлауларда Жириновский "сайлаулар" дигән уеннарда вакыт уздырып маташмас, раз-два... һәм тәхеттә!.. Әле фашизмның Рәсәйдә ачыктан-ачык, надан гражданнар да абайларлык хәлдә, күренгәне юк, әмма ләкин бер нәрсә мөһим:хәзер фашизмның аягүрә басар сәгате сукты!.. Рәсәйнең бөтен халыклары, җөмһүриятләр, шул исәптән Башкортстан, Чуашстан кебек эре төбәкләр дә кичә буар елан тамагына үз ихтыярлары белән кереп чумдылар... Дуамал чеченнар аерылып калды да... Татарстан "сайлауларга бойкот" ясады. Бусы Мәскәү сүзе. Башта "Татарстан халкының җиде проценты сайлауларга килде", диделәр. Соңра сайлаучыларның "унике проценты тавыш бирүдә катнашты", дип чирканып кына әйтеп куйдылар...

Жириновский—26 процент.

Унике процент татарлар сайлауда катнашкан. Бу ике сан алда бик зур мәгънәгә ия булачак әле!.. Татарстанга карап сагайган, колагын шомарткан Мәскәү дә бу санны онытачак түгел. Чеченнәргә ни, алар урыска каршы чыгып тәгәрәп йөрсеннәр, Мәскәү кичерәчәк аларны. Дөнья күтәреп каршы чыгачак түгел. Татар язмышының чынлыгы авыр, кичә радиода Төркиядә яшәүче бер өлкән татар чыгыш ясады. "Кардәшлек" дип аталган тапшыру Төркия татарларына багышланган иде. "Без кайгылы халык", диде татар. Язмыш бер чакта да тулаем бүтән халыкларның ихтыярына гына буйсынмаган, теге яки бу күләмдә язмышлар хәл ителгәндә милләтләрнең, аерым алганда татарларның да үз урыннары, дәрәҗәләре бар икән. "Кайгылы халык" икән, моңа гел-гел бүтәннәр генә гаепле ме?..

Менә сайлауларга катнашмадык...

Бүген мин татарлар авызыннан сүз көтәм, йомгак сүзләренә мохтаҗ минем күңелем. "Җиңдекме?" "Җиңелдекме?" Ни әйтерләр безнең хөкүмәт әһелләре? Милли лидерлар нинди йомгак ясый? Оттыкмы? Оттырдыкмы?

Бүгеннән Рәсәй язмышында олы борылыш ясала. Кыяр-кыймас көйрәп яткан яңа рух—шовинизм кичәге бәрәкәтле сайлаулардан соң үзенең ал битлеген салып ыргытачак бит! Жириновский яшереп тә тормады, сайлауларга ай кала элек үк: "әле мин һәммәсен дә ачып бетермим, менә, сайлаулар үтсен, без үзебез теләгәннәрнең һәрбарчасын ачып салырбыз!" дип янамадымыни?!

"Сайлауладан соң Рәсәй күкрәгенә таралган татарларның язмыш шартлары" хакында миннән башка берәр кеше әрнеп уйлыймы бүген?! Нигә мин ашыгыч эшемне ташлап кәгазь-машинкам белән генә серләшәм? Эндәшер кешем калмадымы?

Эшемне ташлап, дидем дә... авырткан кулымны сызлаган маңгаема терәп уйга баттым. Эшләрем муеннан, эшләрем тезелеп тора. Алар кулында чыбыркы, каулыйлар алар мине, тышаулыйлар да яралар. Занкиевның 20 табак романын беренче майга өлгертергә кирәк. Нур Гайсинның 16 табак җыентыгыннан нидер рәтләргә, сипләргә вакыт. Литвин белән язарга тотынган повесть бер атлый да, ике адым артка чигенә. Мин кызыгып, янып уйлыйм: бу эшләр өстемә таш булып яумаса мин бүген үземне ничегрәк хис итәр идем икән?! Җиңел яшәр идемме?.. Беләм, сизәм, акча өчен бөтенләй юк эшләр белән маташам. Беләм, язганнарым беркемгә дә кирәк түгел. Безнең язучылар «халкым өчен", "халкыма!" дигән купшы шома сүзне үлеп яраталар. Ә мин?! Бармы минем халкым?! Мохтаҗмы ул минем сүземә?! Ай-һай! Гомумән, бармы ул татар халкы?! "Юк ул!" дияргә базмыйм... Әнә ич, сайлауларны кире кагарга дигәндә шактый нык бердәмлек күрсәттек. Ләкин мин бу адымның (кабатлап әйтәм!) җиңүме, түгелме икәнен өзеп кенә әйтә алмыйм. Бер нәрсәне беләм: без шактый катлаулы, дәһшәтле юлдан бара башлыйбыз. Бүген милләтнең сынала торган чоре!..

Уйлар сынык-санык...Уйлар ышкы йомычкасы сыман вак. Уйларыма үзем хуҗа түгел. Офыкта Жириновский... Җиңүче—ул.

**25 декабрь, 1993 ел, Казан.**

Таңнан торып Нәкыя белән ярминкәгә чыгып киттек. Муллык. Муллык! Шөкер! Ит-ашлар эскерт булып өелгән, бәрәңге төягән дию пәриедәй машиналар мәйданга тыгызланып тулган. Яшелчәләргә карап күзләр камаша; Буа, Кукмара районнары килгән. Казан халкы акчаны санап тормый, ризыкларны батманы

белән алалар. Мин бер читтә, кап-кара куштан машина чыгарган әче тотенне иснәп Нәкыянең бәрәңге алып чыгуын көтәм. Тышы вә эче кара машинага кәттә-кәттә киенгән ике кеше кереп утырдылар. М. Гафуриның алтын базлары хуҗаларын тасвирлаган күренеш исемә төште. Болар Рәмиевләр янында!.. Нинди ерак безнең аралар, арада упкын, болар—татар булсалар да бер чакта да мине аңлар түгелләр. Якын араларда миңа "халык язучысы" дигән исем ябыштырырга ниятлиләр, диләр. Имеш, указга култамга да салынган инде. Ә мин, алтмыш алты яшьне тутырып килгән аксакал, күрә карау күзләрем белән урамнан карлы сукмак эзләп, чана тартып ит-бәрәңге, бавыр алып кайтам... Район хуҗаларының нинди иркенлектә яшәп, байлык диңгезләрендә коенуларын уйлыйм...

Алдарак язасы сүзләргә кайтыйм әле! Бу арада күңел гел сынык, гел төшенке булды. "Ел азагын хәтереңнән чыгарма!" дипме, 24 ендә, көндезгә унбердә, кан басымым күтәрелде. Сул яктан маңгай чатнап-чатнап китә. Элегәрәк басым уйнаганда мин сәбәбен эзләп таба торган идем, бу юлы һич очына чыга алмыйм, очына чыга алмаганда күңелгә курку катыш каушау керә... Күрше Фәридә ханым кереп басымны үлчәде. 180/110. Мәктәптән Нәкыяне чакырып кайтардым. Ул кайткач тынычлана төштем. Идарә утырышы билгеләнгән иде, бармадым, бара алмадым. Соңыннан бармавыма сөендем: күп кешеле, ыгы-зыгылы утырыш булган!.. Соңра гадәттәгечә, төрле почмакларга чәчелгәннәр дә башлары күпереп тубал булганчы чөмергәннәр...



*Г. Тукай музеенда, Г. Ахуновның тууына 75 ел тулу уңаеннан уткәрелгән очрашуда. 2000 ел.*

Сайлаулар узды, демократ дип ат алган төркем: "Ни булды? Сайлауларда ник җиңелдек? Нихәл итеп фашист Жириновский алга чыкты?" дип, үзара мыштым гына талашалар, гәҗит-журналларны, телевидениене сүгәләр. "Халык Жириновскийны яклап түгел, хөкүмәт әгъзаларын кабул итмичә тавыш бирде. Бу бик очраклы хәл!" дип, тагын бер тапкыр халык күзенә ком сибеп маташалар. Сайлау нәтиҗәләренең сәбәпләрен ачыклау өчен комиссияләр төзегән булып кыланалар. Беркем дә: "Әйе, урыс халкының күңелендәгеп, ниһаять, Владимир Вольфович азагынача ачып салды. Бу ачыш кирәк иде. Бу мәсьәлә моңарчы битараф урысларны да уятачак һәм үзәккә тартачак!" дип әйтми. Ә Жириновский, үзе сайлаган вә үзен җиңүгә китергән куркыныч юлыннан бер карыш та тайпылмыйча Австриядә «частный кунакта» ята, шәраб эчә, мунча керә (телевидениедән анысын да күрсәттеләр!) һәм дөньяны атом бомбалары белән коендырырга, ул гына җитмәсә әле эшләнеп бетеп кенә килүче яңа коралны да кулланырга вәгъдә биреп, бөтен кешелеккә кыю рәвештә яный, өркетә. "Әгәр буйсынмасагыз... әгәр мин билгеләгән юлдан бармасагыз... бер милләткә дә, бер илгә дә рәхим-шәфкать юк!" дип секунд саен кабатлый...

Безнең сайлауларда катнашмавыбыз Җиңү дип игълан ителде. Җиңү булуы да бик ихтимал. Татарстан урыслары да бу юлы татарлар белән бер сафка баскандай иттеләр. Яңалыкмы бу, әллә уен гынамы? Урысның кайсы тармагы безгә тартылды? Авылларммы? Алай дисәң, авылда урыс калды микәнни? Нигә авылда чиләнсен ул, урыс Рәсәй киңлеге калаларына тартылды һәм барган бер җирендә җирле халыкны кол итеп эш башына менеп утырды. Хәзер менә Урта Азиядән, Кавказдан, бүтән төбәкләрдән күпме урыс куылып кайта. Бу олы сүзне истә тотыйк:куылып! Моңарчы урыс куып йөртә иде, теләсә иле-иле белән халыкларны өерләп куа иде, бүген урысны куалар. Һәм нигездә яшәгән илләрендә баш булып торган урыс куылып кайта. Явызлана белгән, изәргә оста, тәмлетамак урыс кайта... Алар хупламыймы Жириновскийны! Татар-башкортны Монголиягә куам ди икән, ул бары тик үз кәефенә яраштырып кына кумый ич безләрне, ул, әнә шул җайлашкан төбәкләреннән кузгатылган дүңгәләкләр

өчен дә тырыша лабаса! Гасырлар дәвамында куып күнеккән, канына өстенлек, әрсезлек сеңгән урыс-улак берәр заман шушы куылышларга риза булып тора алырмы?.. Ай-һай!..

Яши-яши гыйбрәтләр арта... Әле кайчан гына Ельцин ягына авышканын сиздермәгән, Кырымда арка җылытып яткан өчен Шәймиевкә әллә нинди гаепләр тагарга әзер идем... Бу хакта язып-теркәп китмәдемме икән, көндәлек бик өзек-өзек, торымнан-торымга гына языла, язганнар истә калмый, буталчык дөньяда зиһеннең бөтенлеген саклап тотып булмый. Хәзер Шәймиевнең зирәклегенә сокланам. Парламент явызлары Хасбулатовларны терәп аттырып, кичәге үз адәмнәрен үтертеп, кан коеп Ельцин дөньяга үзенең күләгәсен ачып күрсәтте. Шактый явыз, кансыз, чын урыс икән ләбаса ул!.. Аның шушы атыш адымнарын хуплап үзем дә үземә бүтән төрлерәк итеп карадым. Хасбулатовның кемлеген әллә кайчан белә идек ләбаса!.. Аның властька үрләве хакында бер генә сөйләшмәдек, хатларымда да ошбу фикерем чагылыш тапкандыр! Шул чакларда Хасбулатовны, аның иярченнәрен авызлыклау, тәхеттән бәреп төшерү берни тормый иде. Ике ел тынып-куркып яшәде дә корал телгә килгәч кенә Ельцин дә гайрәтләнде. Сизгәнме боларны Шәймиев, юкмы, иллә мәгәр бүген аның йөзе ак, ул канлы бәрелешкә кулын тыкмады. Илбашына сабырлык килешә шул!..

Беркөн Рәшат кереп үз күзәтүләре белән уртаклашты әле. Медицина институтының хәзерге дүртенче курсы гына студентларга охшаган, әле бу буыннан, бу потоктан кемдер, файдалы кеше чыгуын көтәргә, өметләнергә була, ди... Аннан соңгы өч курс... Онытма: болары инде хәзер өскә калыккан сары күбек, заманны авызлыклаган байларның сөекле балалары икән! Алдап-юлдап, ришвәт биреп сынауларны вафасыз үтеп китә алган, өске катларга арт ишектән үтеп йөрергә гадәтләнгән яңа заман хуҗаларының балалары... Наданнар, һавалылар, байлар, чамасыз тәкәбберләр... Бер сурәт басылган иде гәҗиттә. Мәктәп. Уку классы. Мескен генә, фәкыйрь генә бер укытучы. Уртада танавын югары чөйгән бер маңка сарык утыра. Шул нәҗес капчыгы янәшәсендәге кызга: "Фи-и, миңа атна саен сагыз алырга да аның получкасыннан артык акча бирәләр!" дип хәлфәсен мыскыл итә... Әле шул буын вәкилләренең дә үсеп җитеп ил башына менеп утырасы бар ич. Әлегә безнең арттан калкынган һәр буын үзе белән өметсезлек, адәм баласының иң түбәндәге инстинктларын гына алып килә. Аны безнең һәм бездән алдагы буыннар өметсезлек баткагында, сасыда һәм быкырдыкта тәрбия итеп үстерәләр. Шуннан чыгып әйтәм: Рәсәйдә бер чакта да ипле хөкүмәт, демократик гадел кануннар өстенлеге була алмас!.. Элек мин балаларны кая да булса чит илгә җибәреп, алардан аеры яшәү хакында уйлый да алмый идем, хәзер исә икеләнәм:таба алырмы алар илдә бәхет!? Без нужа чөмереп авылда аякланган буын вәкилләре авырлыкларны күтәрә алдык, бездә әрсезлеккә караганда түземлелек күбрәк иде. Түздек! Ә алар? Чит илләрне күргән, мондагыны иртә аңлаган хөр күңелле егетләр өзмәс чәчәк аткан ахмаклык дөньясына гел-гел риза булырлармы?!

Декабрьнең иң зур вакыйгаларыннан: Рөстәм Яхин вафат булды. Татарның без белгән, без кабул иткән, без яшәгән чор татарының соңгы композиторы. Әнвәр Бакиров белән чордаш булсалар да ул татарның йомарланган җылы җаны биеклегенә бер чакта да менеп җитә алмады. Яшь ягыннан Рөстәм белән Әнвәр тиң булсалар да халыкның аңын, моңын, кайнар җанын бер дәрәҗәдә кабул итә алмадылар. Рөстәм үз чоры татарларының җанын бөтен тарафтан аңлап, табигать көчләрен заманча эшкә җигеп, татар күңел дөньясының бердәнбер хуҗасы булды. Уфалы Рим Хәсәнов вакыт-вакыт аның бәрәкәтле дулкыннарында тибрәлеп, татар күңеленә китмәс җылылык өстәп торгалады... Әмма Рөстәм Яхин соңгы ун-егерме елда бердән-бер бөек милли композиторыбыз иде. Рөстәм татарның җан сакчысы, күңел биеклегенең төгәл үлчәү бәрәмлеге иде. Глинка әйткән: "без музыканы тудырмыйбыз, аны халык тудыра, без аранжировать кына итәбез", дигән. Соңгы чирек гасырда татар милләте шулкадәр җимерелде ки, аны татар дип атау да кыен, аның милли төп сыйфатлары уңды, югалды, алмашынды. Рөстәмнән соң килә торган композиторларга үпкә дә юк сыман, алар үз чорының җимешләре... Рөстәм Яхин белән татарларның йөз еллык, мең еллык нурлы тормышы, җылы җанлы татар моңнары китте. Сәйдәш—Яхин, алар арасындагы мәйданны хаклы рәвештә билгәгән Мансур Мозаффа-

ров, Заһит Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключаревлар китте. Рөстәм яшәгәндә, аның моңы шушы буын дулкыннарында өстенлек иткәндә, ошбу мәшһүр затлар да татар күңеленең тоткасы булып торалар иде. Рөстәм Яхинның вафатына атап Марсель Галиев искиткеч тирән мәгънәле мәкалә язды, татар дөньясында Рөстәмнең нинди урын тотуына хак бәя бирде.

Кичә, ягъни егерме дүртендә, Тинчурин театрында Исламия Мәхмүтованың юбилеен үткәрдек, илле яшь тулган икән. Бөтен Казан купты, моңарчы бер генә татар артисткасының юбилее да болай зур күләмдә, халыкның ихлас мәхәббәтен кузгатып узганы булмады шикелле. Ярата икән татар Исламияне! "Оештырган, оештырганнар!" дисәләр дә чынлык бүтәндә:милләт сөйкемле, ягымлы балаларына үтә мохтаҗ икән. Һичнинди арттырусыз әйтелгән мактау сүзләре, ихлас котлаулар Исламиянең бүгенге татар сәхнәсендә беренче дәрәҗәдә торган артистка икәнлеген раслады. Һич бүтән уйларга бирелмичә рәхәтләнеп, сафланып Исламия тудырган рәхәт һавада кинәнеп утырдым. Сәхнәгә дүртәү мендек: мин, Туфан, Илдар вә яшь драматург Данил Салихов. Җылы сүз дә әйтергә тырыштык. Татарстан, Казан, бөтен районнар тузгыган иде. Исламияне чәчкәләр белән күмделәр, олы-олы бүләкләр тапшырдылар. Исламия кичәсенә тамаша кылырга килгән халыкның күбесе кара болыт булып урамда калды. Кертелгәннәренә театрда урын җитмәде. Депутат значоклары кадаган кәттә-кәттә ирләр, баштанаяк затлыга төренгән таза-таза татар апалары урын табалмыйча сөрлегешеп йөрделәр. Без—Туфан белән янәшә диярлек—мыек астыннан гына көлеп утырдык. Хәер, мыек Туфанда гына иде. Яшә, Исламия!



*Уңнан сулга: Искәндәр Гыйләҗев, Камал театры директоры Шамил Закиров, Аяз Гыйләҗев, Рәшат Гыйләҗев, Камал театры администраторы Кадим Нуруллин. 2001 ел.*

Егерме җидесендә шушы ук залда Равил Фәйзуллинның юбилей кичәсе. Аңа да татар әдәбияты күгендә якты йолдыз булып балкырга язсын! Исламия кичәсе Фәйзуллинныкына катышып китте.

***

Ул арада миңа "Халык язучысы" дигән исем тактылар. "Йәгез, бер дога!" романы басылып чыгу уңаеннан журнал хадимнәрен чакырып, аларда нык кына банкет ясадым, Зәйдән Фалес Вәлиев килде, бүләк итеп миңа "Темп" телевизоры тапшырды. Күңелле генә чәйләдек-мәйләдек. Шуннан Ярулла дусларыбызда Яңа елны каршыладык. Режим һәр тарафтан бозылды, ватылды, вакытында ашау, рәтле йокы күргән юк, урамнарда хәл алып йөреп булмады, боз, бозлавык. Яшь кенә көчле адәмнәр дә очып-тәгәрәп китәләр, чыксам курка-курка гына басам... Кыскасы, әле бу көннәрнең тәнгә вә җанга кунган бәрәкәтле һәм бәрәкәтсез тәэсирләре ачык ук түгел.

Бүген, икенче гыйнварның иртәсендә, торып утырдым да көндәлегемне, хат-рецензия ише вак-төякләрне караштырдым. Шушы көннәрдә аларны төпләтеп, китап итеп җыештырып куясы иде. Алда көтеп, һәр таңымны сагалап торган тәҗел эшләрне искә төшерергә дә, санарга да куркам! Ходам ярдәмче булсын, югыйсә үзем генә ерып чыга торган түгел.

Надир
Дәүләт

# ЕРАК КӨНЧЫГЫШТАГЫ ТАТАР-БАШКОРТЛАРГА НИ БУЛДЫ?

## Кереш

Руслар, Идел-Урал өлкәсендә яшәүче татар-башкортлар һәм Русиядәге башка азчылыклар Кытайның төньяк өлкәсе Маньчжуриягә XIX гасырның ахыры, XX гасырның башларында килеп урнаштылар. Бу халыкларның Маньчжуриягә, аннан исә Кытайның башка өлкәләренә, Кореяга һәм Япониягә таралуы өчен беренче чиратта икътисади һәм икенче чиратта сәяси сәбәпләр да бар иде. Беренче сәбәп 1898 елда Көнчыгыш Кытай Тимер юлын (ККТ) салуга керешү, икенчесе исә 1917 елда Русиядә инкыйлабның киң колач алуы иде. Инкыйлаб йөзменләгән эшченең, авыл халкының, хәрбиләрнең, хәлле кешеләрнең, интеллигенциянең һ. б. корбаннарының башта Маньчжуриягә, соңрак исә башка Ерак Көнчыгыш өлкәләренә китеп сыенуына сәбәп булды. Маньчжурия һәм Ерак Көнчыгышның башка өлкәләрендә бәлки дә 50 елдан азрак яшәүләренә карамастан, руслар һәм башка азчылык халыклар үз диннәрен, телләрен һәм мәдәниятләрен саклап калу ягыннан шактый уңышлы эшчәнлек башкардылар. Чөнки туган җирләренә кире кайтулары турында хыялланмадылар да...

Маньчжуриядә руслар янә күплекне, татар-башкортлар исә азчылыкны тәшкил иттеләр. Ягъни чит илдә дә шулай ук руслар белән бергә эшләделәр, аларның мәктәпләрендә белем алдылар. Бары тик уртак булмаган гыйбадәтханәләре—чиркәү һәм мәчетләр аерым иде (алары да бөтен җирдә дә юк иде). Татар-башкортлар либераль руслар янында фашист яисә коммунист карашлы русларның йогынтысыннан да котыла алмадылар. Хәтта үз хакимиятләре астында тотучы Япония, Маньчутиго (Маньчуко) яисә Кытай хакимлекләре, Русиядән килгән качкыннар булганлыктан, аларны рус дип кабул иттеләр. Кыскасы, өлкәдәге рус басымчылыгы, рус йогынтысы, рус мәдәниятенең изүче үзенчәлеге, балаларны ассимиляцияләү, яшь нәселләрне үз мәдәниятләреннән ераклаштыру, үз милләтеннән читләштерү күренеше Ерак Көнчыгышта да дәвам итә килде. Бу проблемаларга тагын үз мәсьәләләрен Япония, Маньчутиго яисә Кытай хакимнәренә аңлату авырлыгы да кушылды. Икенче төрле әйткәндә, яшәү өчен көрәш бары тик икътисади өлкәдә генә түгел, куркынычсызлык өлкәсендә дә, мәдәни, хәтта дини өлкәләрдә дә шактый фидакарьлек таләп итте.

ККТның төзелүе Русия ватандашларына яңа офыклар һәм мөмкинлекләр ачты. Бу алар өчен эш—киләчәк иде. 1890 еллардан соң рус милләте вәкилләренең саны зур тизлек белән артты. Мисал өчен, 1893 елда Шанхайда бер генә Русия ватандашы булса, 1904 елда инде бу сан берничә меңгә, 1929 елда исә 13 меңгә якынлашты. 1930 елларда Шанхайдагы рус колониясе 20 меңнән артты.

1899да Харбинда 14 мең рус ватандашы бар иде һәм бу санга 5 мең тимер юл сакчысы керми иде. 1905 ел азагында бу сан 40 меңгә, 1907дә 48870кә иреште. 1916 елда 68500 рус ватандашыннан 34200е рус, 5 мене яһүд, 2500е поляк иде. Калганнарының күпчелеге ихтимал төрек-татар иде. 1917 елда Харбин халкының саны 100 меңгә, руслар саны исә 40 меңгә житкән иде. Харбин шәһәренә килсәк исә, 1920 еллар белән Маньчжурия Япония тарафыннан яулап алынган 1931 ел

арасында Русия ватандашларының саны 150дән 200 меңгә житте. Ләкин «Харбин Таймс» хәбәр итүенчә, бу сан 70 меңгә тиң. Моның 30 мене Харбинда яшәүчеләр. Соңгы биш елда (1929-1934) 7.223 туу, 6.117 үлү һәм 2.500 өйләнү акты билгеләнгән. Ләкин икътисади һәм сәяси тотрыксызлык өйләнүче парлар санын 1930 елдагы 620 дән 1933 елда 367 парга кадәр киметте.

Руслар японнарның Квантун армиясенең 1932 елда Харбинга керүен шатлык белән каршы алдылар. Японнар аларны Совет басымыннан саклар да, яхшырак яшәү шартлары тудырыр дип өметләнгәннәрдер. Токионың стратегиясе Маньчжуриянең җирле халкын идеологик тәэсирдән азат итү иде. Японнарның ярдәме белән барлыкка китерелгән Маньчутиго хакимияте дә мөстәкыйль дәүләт оештыру теләге белән янды.

Япония белән Советлар Союзы арасында сугыш чыгу ихтималы исә японнарның качкын руслар арасыннан яшерен шпион-агентлар әзерләү һәм аларны Советлар Союзына җибәреп мәгълүмат туплау эшчәнлегенә керешүенә сәбәп булды. Ләкин японнар бу агентларга да ышанмый иделәр. Мәсәлән, Тиентсин шәһәрендәге Рус антикоммунистлар комитеты лидерларының кайберләре чыннан да рус күчеп килүчеләре арасына индерелгән агентлар иде.

Совет армиясе 1945 елның 9 августына Маньчжурия белән Кореяны яулап алды. Яулап алынган өлкәләрдә яшәүче барлык иске рус ватандашлары автоматик рәвештә «дошман эшчәнлек алып баручылар» дип игълан ителде. Алдан ук әзерләнеп куйган исемлекләрдә НКВД (сонрак КГБ исеме белән атала башлады) һәм СМЕРШ Рус Ак армиясендә яисә Япония армиясендә хезмәт иткән 10 мең кешене төрле гаепләре өчен хөкем итеп, Себергә җибәреп хезмәт лагерьларына яптылар. Совет пропагандасына ышанган 3 меңләп руска 1947 елда совет паспорты бирелде, һәм алар Тиентсин портына иң якын булган Находкага җибәрелделәр. Ләкин вәгъдә ителгәннәрнең берсе генә дә үтәлмәде. Киресенчә, алар ябык хезмәт лагерьларына озатылдылар, бер өлеше исә атып үтерелде. Исән калганнары 1956 елда, Хрущевның Сталинны гаепләве һәм аның чорындагы эшчәнлекнең туктатылуы нәтиҗәсендә бу җәзадан котылдылар. Ләкин 1948 елның апрелендә Маньчжурия белән Кореяда Совет басымы юк ителгәннән соң бу Совет терроррыннан ничек булса да котыла алган яисә Совет басымы астындагы өлкәләрдә яшәмәүче рус мөһаҗирләре Сеул, Шанхай һәм Гонконгка сыенып дөньяның төрле илләренә качу юлын таптылар.

1949 елның октябрендә Кытайда хакимиятне үз кулына алган коммунистлар исә өлкәләрдәге мөһаҗирләрнең йә Кытай ватандашлыгына күчүләрен, йә булмаса илдән чыгып китүләрен таләп иттеләр. Әлбәттә, илдән чыгып китүчеләргә үзләрен кабул итәрлек башка бер ил табып, виза алулары җитди бер киртә иде. Халыкара мөһаҗирләр оешмасы мондыйларны вакытлы рәвештә Филиппинның 7 чылбырлы утраудан барлыкка килгән Тубабао (Тубуаи) утрауларыннан Гуйанга һәм Самараска урнаштырды. Качкыннарның күбесе бу утрауларда бик авыр климат шартларында виза көтә-көтә берничә елга калдылар. Ахыр чиктә бу качкыннар АКШ, Канада, Австралия һәм Төркия кебек дәүләтләр тарафыннан кабул ителделәр. Кытай ватандашлыгына күчүче яшьләрнең хәле исә Советлар Берлегендә яшәүчеләрдән әллә ни аерылмады. Гәрчә хезмәт лагерьларына ябылмасалар да коммунистлар режимыннан гадел һәм яхшы мөнәсәбәт тә күрмәделәр.

## Төрек-татарлар[1] күпләп яшәгән шәһәрләр

Русиядән Маньчжуриягә һәм аның аша ерак Көнчыгышның Корея, Кытай һәм Япония кебек илләренә эмиграция дулкыны XIX гасырның соңгы ике елында Көнчыгыш Кытай Тимер юлының төзелүе белән бергә башланды. Башта тимер юлны төзүдә катнашу яисә бу төзелеш тудырган сәүдә мөмкинчелекләреннән файдалану максаты белән килүчеләр Патша Русиясендә 1917 елгы инкыйлаб кабыну нәтиҗәсендә шул җирләрдә иммигрант буларак калырга мәҗбүр булдылар. Руслар

[1] "Төрек-татарлар» термины Идел-Урал буендагы татар, башкорт кебек төрле төрки халыкларны бер атама белән белдерү өчен XX гасырның башында кулланыла башлады. Большевиклар инкыйлабыннан соң куллануы тыелды. Башка мәгълүмат табу өчен карагыз: Nadir Devlet «XX yьzyilda Tatar1arda Milli Kimlik Meselesi», Бюллетень, LX. – № 227 (апрель, 1996), 191-202 б.

белән бергә Русиянең башка азчылыклары, шул җөмләдән татарлар да шул ук язмышка дучар булдылар. Баштарак килүчеләр тимер юлда эшләү яисә сәүдәгәрлек итү максаты белән килсәләр дә, берникадәр вакыттан соң яннарына гаиләләрен китереп кечкенә колонияләр барлыкка китерә башладылар. Большевиклар инкыйлабыннан бай булу яисә башка сәбәпләр аркасында качучыларга Кызыл Армиягә каршы сугышкан һәм җиңелгән Ак Армия вәкилләре дә килеп кушылды. Нәтиҗәдә иммигрант колонияләре тагын да зурайды. 1919 елда ККТ Маньчжурия станцияләре белән Харбин арасында поезд сәфәрләре туктатылгач, бу маршрут тирәсендә урнашкан башка халыклар кебек төрек-татарлар да эш мөмкинлеге булган Харбин, Чангчун кебек шәһәрләргә күчеп урнаштылар. Безгә мәгълүм булганча, Маньчжуриянең төньягыннан көньягына кадәр сузылган Маньчжурия (шәһәр), Хайлар, Цицихар, Харбин, Ченчюн (Чангчун-Синзин), Гирин (Кирин), Мукден (Шенйанг), Аншан, Даирән (Дальний/Далиан), Чинтинфу, Пограничная, бүгенге Кореяның Фусан (Пусан), Сингишу (Синуижу) белән Кеижо (Сеул); Кытайның порт-шәһәрләре Тиентсин һәм ин зур шәһәре Шанхай; Япониянең Токио, Йокохама, Нагойа, Осака, Кобе, Киото, Кумамато, Мийазаки, Тайкуйу, Сасджима, Одавара, Куруми, Мийакунуджи, Шимба кебек зур һәм кечкенә шәһәр һәм шәһәрчекләрендә, хәтта юл буендагы станцияләрендә дә киң бер территориядә Русиядән күчеп килгән татарлар яши иде. Шул кадәр киң аланга таралуларының бердәнбер сәбәбе—яшәү өчен мөмкинлекләр тудыру иде. Беренче килүчеләр Русиянең Европа өлешендә урнашкан Пенза һәм Тамбов губерналарындагы вак сәүдәгәрләр иде. Болар Маньчжуриядә ККТ юлы буенда төрле кибетчекләр ачып сәүдәгәрлеккә керештеләр. Берничә ел эчендә эшләрен көйгә салган кайберләре гаиләләрен дә үз яннарына күчерде. Шул рәвешле дини һәм милли ихтыяҗлар төрле җәмгыятьләр оешуына, мәктәп һәм мәчетләр ачылуына сәбәп булды. 1917 октябрь инкыйлабыннан соң сәүдәгә сәләтләре барлыгы электән үк билгеле булган төрек-татар башта Хайлар белән Харбин кебек шәһәрләрдә урнашып сәүдә итә башласалар да, соңрак Корея белән Япониягә дә таралганнар. Гомумән, йон, тире, комач һәм кием-салым белән сәүдә итәләр иде[2]. 1900нче еллардан 1938нче елларгача алар төзегән яки арендага алган мәктәп белән мәдрәсәләр саны 18гә ирешә. Шөбһәсез ки, татарларның саны бөтен җирдә дә бер үк түгел иде, шуңа күрә җәмгыятьләрнең эшчәнлекләрендә дә төрлелек бар иде. Маньчжуриядә татарлар иң күп санда Харбин шәһәрендә урнашкан иделәр. Ерак Көнчыгыштагы татарларның саны турында төгәл генә бер мәгълүмат булмаса да, 10-15 мең тирәсендә дип фаразлана. Ләкин бу күчүләр аеруча икътисади авырлыклар һәм сугыш куркынычы арту белән кими башлады. Шул сәбәпле бу сан 1945 елларда 5 меңгә кадәр төште дигән карашлар бар.

Идел-Уралдан төрле вакытларда һәм бигрәк тә инкыйлаб кабынгач, Себердәге Колчак армиясенә кушылып Манчжуриядә, биредән Кытай, Корея һәм Япониягә сыенганнар арасында байтак солдат, офицер, ваклы- эреле сәүдәгәр, дин эшлеклесе, зыялы бар иде.

## Гаяз Исхакыйның мәйданга чыгуы һәм Идел-Урал төрек-татарлары хәрәкәте

XX йөз башында хәзерге татар әдәбиятының үсешенә бик зур йогынтысы булган Мөхәммәд Гаяз Исхакый (Иделле) (1878—1954) үз илен ташлап китәргә мәҗбүр булганчыга кадәр, 1897—1918 еллар арасында хикәя, роман һәм пьеса жанрларында 29 әсәр иҗат итә. Сәяси карашларын халыкка тагын да ачыграк аңлату максатыннан чыгып журналистика эшчәнлегенә дә керешә. Гаяз Исхакыйның журналистика эшчәнлеге бары тик мәкаләләр язу белән генә түгел, үз газеталарын чыгару һәм алар белән җитәкчелек итү рәвешендә дә алып барылды. «Тан», «Таң йолдызы», «Ил», «Сүз», «Безнең ил» кебек газеталар чыгарды. Үзе 1917 елның ахырында Уфада ирекле сайлауларда демократик рәвештә оештырылган «Эчке Русия һәм Себер

[2] P. Sorokin, «Russian Tatar Emigrй Communities in East Apia»? CESS 2004 Конференциясендә ясалган чыгыш, 116.

[3] Гаяз Исхакый. «Ерак Шәрык юлы мәсьәләләре», Яңа милли юл, № 12 (Берлин 1934), 3 б.

мөселман төрек-татарларының Милләт Мәҗлесе» әгъзасы буларак сайланган һәм бу Мәҗлес тарафыннан кабул ителгән «Идел-Урал дәүләте»н оештыру проектына һәрвакыт катнашып килгән. Бу проект Идел елгасы белән Урал таулары арасындагы территориядә яшәүче төрки халыклар—татар, башкорт һәм чуашлар белән бу өлкәдәге төрле фин-угыр кабиләләренең уртак бер дәүләтен барлыкка китерүне күз алдында тота иде. Менә шул хыялыннан Гаяз Исхакый гомеренең соңгы сулышына кадәр баш тартмады. Җанын коткару өчен үз илен ташлап китәргә мәҗбүр булды. Ләкин анда көрәшче рухы үлмәгән иде һәм шул сәбәпле ул мөһаҗирлектә дә буш тормады, 1928—1939 елларда Берлинда нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналын чыгарып ул көрәшүен дәвам итте. Ерак Көнчыгышта аның бу карашын яклаганнарның бер өлеше Советларның цилиндры астында изелделәр. Башка сүзләр белән әйткәндә, сәясәт корбаны булдылар. Гаяз Исхакыйның Идел-Урал дәүләте фикере Мирсәет Солтангалиевнең «Туран дәүләте» кебек хыял булып калды.

Исхакый Ерак Көнчыгыштагы ватандашларын милләтче карашлары тирәсендә туплау максаты белән Маньчжурия һәм Япониядә татарлар күпләп яшәгән шәһәрләргә дә барып йөрде. Бик танылган язучы, журналист һәм сәясәтче Гаяз Исхакыйны күреп калу бөтен кеше өчен дә чиктән тыш вакыйга һәм сөенү-җанлану чыганагы була иде. Аңа багышлап кичәләр үткәрелгән, Зөләйха, Җан Баевич кебек әсәрләре сәхнәләштереп күрсәтелгән.

Бу Гаяз Исхакыйның Ерак Көнчыгышка әүвәлге килүләре генә түгел иде... «Эчке Русия һәм Себер мөселман төрек-татарлары Милләт Мәҗлесе»нең солых комиссиясе әгъзасы буларак акча җыю максаты белән Себернең Иркутск шәһәренә килгән Гаяз Исхакый 1919 елның урталарында Харбинга кадәр барып җитә[4].

Гаяз Исхакый 1933 елның октябрендә икенче килүендә[5] Токиода тагын бер татар мәшһүре казый Габдерәшит Ибраһим (1857—1944) яши иде. Күпкырлы шәхес, ул да 1908 елда беренче тапкыр Япониягә килгән иде, ләкин ул вакытларда Япониядә татарлар белән күрешүе турында һичбер нинди мәгълүмат юк. Аның икенче килүе исә Исхакыйдан берничә атнага иртәрәк, 1933 елның октябрендә иде. Японнарны ислам диненә күчерү кебек утопик хыяллар белән килгән иде Габдерәшит казый бу якларга. Үзе исә зур кызыксыну тудырган, япон матбугатында да исеме чагылыш тапкан иде. Үз көче ярдәмендә берникадәр эшчәнлек алып бара алса да, 76 яшьлек кешенең озак вакыт һәм зур эшчәнлек алып барачагын көтү дә дөрес булмас иде. Аны Төркиядән бу ерак җирләргә китерүче иң төп сәбәп исә Төркия җөмһүриятендә ислами фикерләрен таратуы өчен җирлек таба алмавында иде. Бу ислами фикерләр татарлар арасында инде таралган булу сәбәпле, Рәшит казыйдан аларны өйрәнүдә бик файда юк иде. Шул сәбәпле Рәшит казый японнарны өйрәтү эшенә керешкән иде. Гаяз Исхакый исә татар җәмгыятендә яңа бер милли дулкынлану хисе тудырды. Гаяз Исхакый ни дәрәҗәдә милләтче булса, Габдерәшит Ибраһим һәм аны монда чакыручы Токио җәмгыятенең мөдәррисе һәм имамы Корбангали дә шул дәрәҗәдә исламчы иделәр. Ягъни бу капма-каршы полюсларның каршылыкка килүләре котылгысыз иде. Корбангалинең Гаяз Исхакыйны үзен тәхетеннән бәреп төшерә алырлык һәм иң аз дигәндә дә икенче планга күчерәчәк бер шәхес итеп кабул итүе чынлыкта нигезсез түгел иде. Моннан тыш Корбангалинең чыгышы белән башкорт булуы һәм Русиядә чакта җәдитчеләр белән булган ызгышлары, бәлкем, Идел-Урал идеясенә каршы чыгуы өчен җитәрлек сәбәпләр иде. Көтелгән хәл озакламый чынга ашты.

Башта Токио җәмгыяте тарафыннан бик дустанә каршы алынган Гаяз Исхакый «Ерак Көнчыгыш Идел-Урал төрек-татарлары хәрәкәте»нең планнары белән таныштыра башлавы булды, фронтлар аерылды, ямьсез күренешләр дә булып алды.

Корбангали һәммә кеше тарафыннан яратылган һәм ышанылган шәхес түгел иде. Бигрәк тә деспотча хәрәкәтләре һәм үткәне белән байтак кешедә ризасызлык

[4] Nadir Dev1et, 1917 Ekim Ihtilali ve Tırk-Tatar Millet Meclisi, (Istanbul: Цtbken Nasriyat 1998), 300 b.
[5] "Turko-Tatar Leader Visits Mainichi P1ant (Ayaz Ishaky Busy Organizing Turkish Peop1e of Eastern Area)», The Osaka Mainichi, (10.08.1934).

тудыра иде. Шул сәбәпле дә, әле Гаяз Исхакый Токиога килмәс борын, 1931елда унлап гаилә Корбангали һәм аның оешмасы белән мөнәсәбәтләрне өзгәннәр иде. Гаяз Исхакый җанландырган яна карашлар исә Корбангалидән кубучылар санын күбәйтәчәк иде.

## Ерак Көнчыгыш Идел-Урал татар мөселманнарының корылтае (Мукден, 4-14 февраль, 1935)

Озак вакытка сузылган тырышулардан соң Маньчжурия (Маньчутиго) империясенең зур шәһәрләреннән КҚТ юлы буенда Харбин-Чангчун шәһәре һәм Дальний порты арасында урнашкан Мукденда бер корылтай уздыру мөмкинлеге тудырылды. Мукден, анда яшәүче татарлар санына караганда бик уңышлы ук булмаса да, Кытай, Маньчжурия, Корея һәм Япония шәһәрләренә чагыштырмача якын булу сәбәпле, корылтай урыны итеп сайланылгандыр, күрәсең. Тагын бер сәбәп итеп монда русларның аз санда булуы һәм япон хакимиятенең корылтай өчен бу җирләрне унайлы дип санавын билгеләп үтәргә дә мөмкиндер. Ничек булса булсын, 1935 елның 4 февралендә Ерак Көнчыгышның дүрт ягыннан да делегатлар Мукденга килеп җиттеләр. Корылтайда делегат булып 40 шәхес катнашты[6].

Мукденда «Ориенталь Отель»дә сәгать икедә ачылган Корылтайда Мукдендагы Япония генераль консуллыгы аркылы Япония императорына һәм Маньчжурия Финанслар Банкы аркылы Маньчжурия императорына рәхмәт сүзләре белән телеграммалар җибәрелде. Моннан тыш Төркия, Иран, Әфганстан, Гарәбстан, Мисыр хөкүмәтләренә һәм Маньчжуриянең Хсинган губерниясе башлыгына корылтайның максат-бурычлары язылган телеграммалар сугылды[7].

Менә шул рәвешле 1935 елның 4 февралендә кичке сәгать тугызда Гаяз Исхакый катнашында Габделхак Ногманның Коръәннән кайбер аятьләрне укуы, моны дин һәм милләт юлында шәһит киткәннәргә багышлавы белән корылтай ачылды. Соңрак корылтайны алып баручы идарәчелек иданы һәм сәркатиплек әгъзалары сайланды.

Унбер көн дәвам иткән (4-14 февраль) Корылтайда шактый гына мәсьәлә каралган һәм шактый гына карар да кабул ителгән иде. Бу җыелыш Ерак Көнчыгыштагы төрек-татарларга аерым бер җанлылык һәм рух бирә. Корылтайдан соң Мукден җәмгыяте делегатлар өчен кичә үткәрә. Бу кичәдә дә чыгышлар ясала. Чит ил кунаклары өчен япон, инглиз телләренә тәрҗемәләр ясала. Ерак Көнчыгышның төрле өлкәләреннән килгән кырыкка якын делегат катнашкан Идел-Урал төрек-татарларының корылтаена зур игътибар бирелүе матбугатта чыккан хәбәрләрдән, җибәрелгән тәбрикләү телеграммаларыннан һәм катнашкан чит ил вәкилләреннән аңлашыла[8]. Корылтайга япон хакимиятенең төрле вәкилләре дә катнаштылар, Япониядәге Иран, Әфганстан, Мисыр кебек мөселман илләренең рәсми вәкиллекләреннән дә котлау телеграммалары килгән, җирле Кытай һәм Маньчу мөселман зыялылары да элемтәгә кергәннәр, һәм аеруча, Идел-Урал сәяси хәрәкәте үзе әгъза булган Прометейның әгъзалары—украин һәм грузин милләтләре вәкилләре корылтайда шәхсән катнашып, хәтта котлап чыгышлар да ясадылар.

## «Милли байрак» газетасы (1935—1945)

Үзәкнең һәртөрле эшчәнлеген халыкка ирештерү, Ерак Көнчыгыштагы татарларга үз тарихлары белән бәйле мәгълүматлар, хәбәрләр бирү һәм аларны бер-берсеннән хәбәрдар итү максатыннан чыгып 1935 елның 1 ноябрендә Мукденда «Милли байрак» газетасы нәшер ителә башлады. Мукденда гарәп шрифтлы нәшрият булмаганлыктан, газета кулдан языла һәм таш басма технологиясе ярдәмендә күчерелеп таратыла иде. Кулдан язылып басылып килсә дә, никадәр генә булмасын,

---

[6] Беренче Ерак Шәрык корылтае, Яңа милли юл, № 86 (3), (1935), 4 б.

[7] "Session For Tatars Held (National Conference Opens At Mukden And Is To Continue For One Week)", The Kobe Mainichi Daily News, (5.02.1935).

[8] "Turco-Tatars Plan Far Eastern Parley (80 Delegates From Various Societies to Meet at Mukden, Feb. 4", The Osaka Mainichi, (17.01.1935); Мусульманам предложено избрать новое правление, Заря, (16.03.1935).

башта чыгымнарны Әхмәд Вәли (Мәнгәр) һәм Хәйрулла Ибраһим бертуганнар үз өсләренә алдылар. Нәшрият бары тик газеталар басу белән генә түгел, мәктәп өчен дәреслекләр чыгаруы белән дә әһәмиятле иде. Ике ел ярым үткәннән соң Хөсәен байның да зур матди ярдәме белән матбага булдыру өчен кирәкле акча җыелды. Ләкин бу юлы гарәп шрифтын табу мәсьәләсе килеп чыкты. Соңыннан болар да Төркиядән китерелде. Шул рәвешле, «Милли байрак»ның 1918 ел 8 апрельдә чыккан 117нче саны газетаның үз матбагасында басылган беренте саны булды[9].

Газетаның язу эшләре мөдире итеп бер үк вакытта Мәркәзнең сәркатибе вазифасын үтәүче Ибраһим Дәүләткилде билгеләнде. Гаяз Исхакый Европага кайтканчы, ягъни 3-4 ай дәвамында, баш мәкаләләр язып, Рокыя Мөхәммәдиш исә башка мәкалә һәм хәбәрләрне әзерләп бу тиражы кечкенә, ләкин тәэсире шактый көчле атналык газетаны чыгару өчен көрәштеләр. Газета нөсхәләренең бары тик Ерак Көнчыгыш өлкәләренә генә түгел, Финляндия, Алмания, Мисыр һәм Гарәбстанның кайбер шәһәрләренә кадәр барып җитүе бу вакытлы матбугат органына шактый зур игътибар булуын күрсәтеп тора.

Газета белән бәйле тагын да реаль мәгълүматларны бу газетада шәхсән эшләп килгән Рокыя Мөхәммәдиш (Дәүләткилде) хатирәләреннән табарга мөмкин[10]:

«1935, 1нче ноябрь минем өчен тагы бер борылыш ачты. «Милли байрак» гәзитәсе чыга башлады. 4 сәхифәлек, атналык, гарәп хәрефләре белән басыла. Башта кулдан язылып, фото ысулы белән басыла. Ибраһим әфәнденең кул язмасы матур булганга, аңа гәзитәне язарга кушалар. Мин язмаларны барлыйм, үзем дә язам, корректорлык вазифасын да үтим. Безгә гәзитә эше дә йөкләнгәнгә, Гаяз абзый безнең мәгашны арттырырга кирәкле тапты. Без 165әр иена ала башладык.

Исемдә калмаган, ничә саны кулдан язылып чыгарылгандыр. Төркиядән кечкенә агач тартмада хәрефләр килде. Хәрефләр, нокта, өтерләр һәм башкалар бераз генә булганга, кирәк кадәре үрчетәсе бар. Башта мөһерләр ясаучы бер кытай хәрефләрне агачтан кисеп ясады, шуннан соң кургаштан хәрефләр коелды. Махсус котылар (тартма, кап—ред. иск. ) ясатылды.

Мансур Арсланбәк исемле буйдак бер милләттәшебез хәреф җыючы эшен үз өстенә алды. Гәзитә басылып чыккач, өчәүләп аны тарату эшен башкарабыз.

Гаяз абзый безне гәзитә чыгару эшенә өйрәтеп, 1936 ел март аенда Европага кайтып китте.

Мансур әфәндегә ярдәмче итеп кытай үсмерләрен алдык. Алар тиз арада хәреф җыярга өйрәнделәр.

Гәзитәдән башка мәктәпләребез өчен дәреслекләр дә чыгара башладык: «Әлифба», «Беренче уку китабы», «Хисап».

Бу эшләрнең барысы халкыбызның үз акчасына барлыкка киләләр иде. Япон рәсми даирәләре безнең милли хәрәкәткә рөхсәт бирүен бирделәр, ләкин матди ярдәм итмәделәр.

Гәзитәне япон цензурасыннан уздыру эше дә Ибраһим әфәнде тарафыннан башкарыла иде. Ул берәр япон студентын яллый, гәзитәнең материалларын япончага телдән тәрҗемә итеп бара, студент яза. Ахырда студент язганнарын укый, Ибраһим хаталарын төзәтә. Кайбер вакытларда Ибраһим әфәнде мәркәз эшләре белән Мукденнан китеп торган вакытларда, гәзитә эчтәлеген мин русчага күчерәм дә, цензорга барам.

Кайбер язманы цензор уздырмый, ашыгыч бер рәвештә яңа бер нәрсә язарга туры килә.

Күп вакытта читтән язмалар килми. Үзебезгә гәзитә битләрен тутырырга туры килә. Гаяз абзыйдан килгәндә безгә бәйрәм була. Ләкин 1939да аңардан язмалар килү туктады. Баш мәкаләдә үз имзам—«Рөкыя Мөхамәдиш», «Үтәмеш», «Илсөяр» имзалы язмалар барысы да минем җилкәдә.

Ничек яза алганмын—хәзер, үтерәм дип куркытсалар да, әйтә алмыйм, һәрничек булса да милли гая нигезендә язмалар иде. Гаяз-абзый миңа язган хатларында минем мәкаләләрне яхшы, дип яза иде.

---

[9] Mahmut Tahir: "Milli Bayrak Matbaasi" Kazan, sayi 18, (1976), 20-21 б.

[10] Rukiye (Muhammedis) Devletкildi, (зеv. Beril Devlet) Hayat Yolumun Izleriden, (Mьnih 1983), 12 б.

Хәрбиндән Хөсәйн Габдүш күп кенә хикәяләрен «Милли байрак»ка юллый иде. Сәяси мәсьәләләргә кагылмый иде.

Хөсәйн Габдүш бик сәләтле журналист һәм әдип иде. Аның язмалары рус эмигрант басмаларында да чыга иде.

«Милли байрак»ка даими эшкә килергә бик тырышып димләп карасак та - килмәде. Вакыт-вакыт ул эчкелеккә бирелеп тәмам эштән чыга торган булганлыктан Мукденга күчәргә разый булмады. Ул артист һәм бай тавышлы җырчы да иде. Үз истигъдадына кин алан булмау аркасында бу зат мөһаҗирәттә әрәм булды. Аның атасы-анасы булмаган, бер бай тәрбиясендә булып мөһаҗирлек бәхетсезлегенә эләккән.

Мансур Арсланбәк безнең белән берничә ел эшләгәннән соң, Хайларга барып өйләнде. Ахырда Төркиягә китеп, Анкарада бер кыз, ике улын үстереп, шунда вафат булды. Үлгәнче мина хатлар язып торды. Мәрхүм яхшы күнелле кеше иде. Аллаһның рәхмәтендә булсын!

Тукайның егерме бишенче сәнгать елына һәм Гаяз Исхакыйның кырык еллык әдиплек хезмәтенә багышланган журналлар чыгардык. Матбугатта сирәк булса да, сонга калулар була иде. Гадәттә 4 битле булып чыккан «Милли байрак» мөһим сәбәпләр белән 8, 12, хәтта 16 бит булып чыкканы да булды. Девизы исә укучыларына түбәндәгечә эндәшү кебек иде:

«Милли байрак» кыйбласы үз илен ирекле итү, үз илен дошман кулыннан коткару, бәйсез булу, төрек-татар милли байрагын ирекле Идел-Уралда хөр җилкендерү... Чит илләрнең бөеклеге, халыкларының төрлелеге эчендә аптырап калган ватандашларыбызны милли юлга бастыру өчен тарихтан башлап кем булуларын өйрәтергә тиешбез. Син бүген мескен, аптыраган бер хәлдә калган мөһаҗир булсаң да, син тарихы бөек бер халыкның баласы. Синең үз илең, үз туган туфрагың бар[11].»

Алты ел эчендә 284 сан чыкты һәм девизыбыз һич үзгәрмәде. 1935 елда Мукденда үткәрелгән Беренче корылтайда кабул ителгән карарлардан читкә тайпылмадык. Табигый ки, газета бары тик милли хәбәрләрне генә яктыртып калмады, дөньядагы үсеш-үзгәрешләр турындагы хәбәрләрне дә укучысына җиткереп торды. «Милли байрак» Идел-Урал төрек-татарларының үткәннәрен яктыртучы һәм шул ук вакытта киләчәгенә дә кагылышлы мәкаләләр дә бастырды. Төрек-татарларның мәсьәләләреннән тыш Төркистандагы, Кавказдагы, Себер, Кырым һәм Балканнардагы төрекләрнең хәле, табигый ки, Төркия Җөмһүриятендәге үсеш-үзгәрешләр газетаның төп темалары иде. «Милли байрак" Ислам дөньясындагы халыкларга игътибар бирергә тырыша иде. Азия халыклары белән кардәш булганлыкларыннан, алар белән дә төрле килешүләр үткәрелде. Кыскасы, төрекчелек һәм исламчылыкка таянып, Идел-Уралның бәйсезлеге өчен көрәштән гыйбарәт иде. Газета халыктан җыелган акча хакына чыгып килде».

Гаяз Исхакый Ерак Көнчыгышта ике елдан күбрәк торганнан соң, 1936 елның март аенда Европага кайтуында анда бәлки инде элеккеге күтәренкелек калмаган иде. Ул зур эш башкарган—шактый гына татарны мәдәни, дини һәм сәяси гөмбәз астына җыйган һәм, иң әһәмиятлесе, даими бер басманың («Милли байрак»ның) дәвамлы чыгып килүен булдырган иде. 1935-38 еллар арасында «Милли байрак» газетасында аның 41 мәкаләсе басылган иде[12]. Һәм дә 1939 елның август аенда Берлинда Гаяз Исхакый үзе чыгарган «Яңа милли юл» журналының Алманиянең Польшаны яулап алуы, ягъни сугыш башлану сәбәбе белән ябылуы аркасында, Советлар Союзы чикләреннән еракта яшәүче татар-башкортларның бәлки дә бердәнбер даими басмасы булып «Милли байрак» атналык газетасы калган иде. Хәбәрләшү чараларының бүгенге кебек тизлекле һәм алга киткәннәре (телефон, Интернет) булмавы күз алдында тотылган вакытта, бу даими басмалар диаспорадагы татар-башкортларның илләре, үз җәмгыятьләре турында туган телләрендә хәбәрләрне ирештерә алырлык бердәнбер чара иде. 1928 елда чыга башлап 1939 елда нәшер ителүдән туктатылырга мәҗбүр булган, «Яңа милли юл»ның тиражы турында мәгълүматлар юк, бәлки бер мең йә дә азрак күләмдә иде. «Милли байрак»

[11] Милли байрак дүртенче елына керде / Яңа милли юл. – № 128 (12), (1938), 334 б.

исә уңышлы елларда, ягъни 1935тән алып Ерак Көнчыгышта сугыш башланган 1941 елга кадәр 500 тираж белән чыгып килде, 1941 елдан соң 400гә кадәр төште, сугыш шартларында почта хезмәте аксый башлаган елларда исә (1943-1945) тираж 30 данәгә кадәр кимегән иде.

1940 елның 1 ноябрендә «Милли байрак» бишьеллыгын каршы алды. Бу вакыйгага багышланган сан 4 бит белән түгел, төгәл 16 бит булып чыкты. Ләкин газетаны чыгарып килүче Рокыя Мөхәммәдиш һәм Ибраһим Дәүләткилдене бер кешедән башка беркем котламады. Чынлыкта исә газета Рокыя Мөхәммәдишнең җилкәсендә иде. Газетадагы Төркия белән бәйле хәбәрләр Истанбулда чыгып килгән «Җөмһүрият» газетасыннан файдаланып әзерләнә иде. Ләкин 1940 елның августыннан соң бу газета Мукденга килми башлаганнан соң, Төркия турында хәбәрләр кимеде. Рокыя Мөхәммәдиш газетасы аксамасын өчен 1935-1940 еллар арасында бары тик бер тапкыр гына ялга китә алды[13]. Газетаның язмышы шулкадәр дә Рокыя Мөхәммәдишкә бәйле иде ки, бик сирәк булса да, мәсәлән, 1940 елның ноябрь аенда ул ике атна грипп белән авыру сәбәпле газетаның бер саны чыкмаган, соңга калган иде[14].

Һәм Ибраһим, һәм Рокыя (Мөхәммәдиш) Дәүләткилделәрнең[15] эшчәнлекләре аркасында 1945 елның август аенда кулга алынган «Милли байрак»ның 440 саны бернигә дә карамастан чыгарылган иде. Язылучыларның күпчелеген Финляндия, Эстония, Польша, Алмания һәм Төркиядә яшәүче татарлар тәшкил итә иде, Согуд Гарәбстаны һәм Һиндстанга берәр нөсхәсы җибәрелә иде[16].

## Икенче корылтай (1941)

Беренче корылтайдан соң Маньчжурия, Япония һәм Кытайдагы җәмгыятьләрнең зур бер өлеше Милли Мәркәзнең күзәтүе астында эшчәнлекләрен дәвам иттеләр. Ләкин аз өлеше Милли Мәркәзнең күзәтүеннән еракта калган иде. Ерак Көнчыгышта яшәүче төрек-татарларның саны кими башлагач, фараз ителгәнчә 15 мең түгел, 5-6 мең тирәсендә калган булса кирәк. Корылтайның үткәрелү вакыты 10 көнгә кичектерелергә мәҗбүр булды, һәм, ниһаять, 1941 елның 28 августында Икенче корылтай кабат Мукденда үткәрелә алды. Европада дөрләп янган, соңрак Ерак Көнчыгышта 1941елның 7 декабрендә Япониянең кушылуы белән тагын да дәһшәтләнгән Икенче Бөтендөнья сугышы зур икътисади һәм сәяси авырлыклар тудырды. 1938, 1939, 1940 елларда корылтайның үткәрелүен тыйган японнар бу юлы үзләре үк Корылтайның үткәрелүен телиләр, шул сәбәпле Маньчутиго хакимиятеннән виза алу мәсьәләләрен хәл итүдә шактый зур ярдәм күрсәтәләр. 1935 елның февраль аендагы Беренче корылтайда 41 делегат катнашкан булса, бу юлы 26 делегат катнаша алды[17]. Үткәрелгән сайлауларда Үзәк рәисе итеп Әхмәтшаһ Гыйззәтулла, диния комитеты рәисе итеп Габделкәрим Рәхим, сәркатип итеп кабат Ибраһим Дәүләткилде сайланды. Белем бирү һәм тәрбия комитеты рәисе итеп исә Рокыя Мөхәммәдиш һәм финанс эшләре комитеты рәисе итеп Салман Аити сайланды[18].

## Йомгак

1898 елда Маньчжуриядә Көнчыгыш Кытай Тимер юлы төзелә башлау белән Ерак Көнчыгышка руслар Русия империясенең башка төрле этник төркемнәре белән бергә татар-башкортларның да 1920 елларга кадәр бу җирләргә күчүләрен

---

[12] Ahmed (Mahmut) Tahir. Ayaz Ishakinin "Milli Vol" ve "Milli Bayarк"taki Vazilarnin Konulari, Muhammed Ayaz Ishaki Hayati ve Faalieti (100. Dogum Yili Dolayisiyla), (Ankara 1979), 118-120 б.

[13] Рокыя Мөхәммәдиш Гаяз Исхакыйга 1940 елның ноябрендә җибәргән хаттан.

[14] Рокыя Мөхәммәдиш Гаяз Исхакыйга 1941 елның 6 феврендә җибәргән хаттан.

[15] Икесе 1943 елның 17 октябрендә өйләнештеләр.

[16] Протокол Допроса, № 1.68, 5.9.1945 (Рокыя Дәүләткилдегә йөзбашы Королевның 11.00–15.00, 15.00-18.00 һәм кабат 23.30га кадәр алып барылган сорау алуы).

[17] Икенче корылтайга катнашканнар. // Милли Байрак. – № 277, август, 1941).

[18] Протокол Допроса N 168, 5.9.1945...

күрәбез. Ләкин Маньчжурия (сонрак Кытай хакимиятеннән аерылып Япония канаты астында барлыкка килгән Маньчутиго), Корея (бу җирләр дә 1910 елда Японияга кушылды), Кытай һәм Япония дүртпочмагында һәм ин азында 25-30 төрле шәһәр, шәһәрчек, авыл яисә станцияләрдә яшәүче төрек-татарлар, бер җирдә саннары күбәю белән, дини һәм милли үзлекләрен саклап калу өчен мәчетләр, мәктәпләр һәм оешмалар булдыру эшчәнлегенә керештеләр.

30нчы елларның башында дөнья икътисади кризиска керде. Бу да бөтен илләрнең бердәм рәвештә сугышка әзерләнүенә китерде. Ерак Көнчыгыштагы һәм Һинд Кытаендагы илләрнең күбесе японнарның кызыксыну аланына кергән, Япония Корея белән Маньчжурияне һәм Кытайның төньягын кулына төшергән иде. Икенче яктан Кытайда да коммунистлар һәм милләтчеләр арасында көрәш бара иде. Боларга өстәп тә Европада Икенче Бөтендөнья сугышының кабынып китүе, шунда ук Японияңең АКШ белән, соңрак АКШның союздашы СССР белән кораллы көрәшкә керешүе сәбәпле районндагы тынычсызлык, икътисади авырлыклар һәм иминлек проблемалары тагын да артты.

Татарлар арасында Ерак Көнчыгышны беренче булып ташлап китүчеләрнең берсе Мәркәзнең эшчәнлегенә шактый зур катнашы булган эшмәкәр Әхмәд Вәли Ибраһим (Мәнгәр) (1891-1978) булды. Ул эшләре начарлана башлауга, 1938 елның 2 февралендә гаиләсе белән бергә китте[19]. Башкалар да алардан үрнәк алдылар. Ләкин илдән малларын алып китәбез дигәндә җирле хакимият корган киртәләргә тап булдылар. 1939-40 елларда яшәү бик кыйммәтләнде, инфляция үсте, хәтта азык-төлеккә кытлык барлыкка килде. Шикәр кебек ризыкларны табу авыр иде. Шул сәбәпле балалар да, олылар да тиешле ризыкларын алмый иделәр[20]. Сугыш шартларында чит илләрдә белем алучы балаларга да акча җибәрү мөмкин түгел иде. Мөмкинчелек чыгу белән чит илләргә китүчеләр турындагы хәбәрләр һәр җирдән дә ишетелеп торды. Мисал өчен, араларында Мәркәзнең диния комитеты әгъзасы Габдрәхман Мостафа да булган Кобе җәмгыятеннән 25 кеше 1941 елның 19 февралендә илне ташлап киттеләр[21].

Инде аңлашылганча, Икенче корылтайдан соң Ерак Көнчыгышта яшәү шартлары бик үк яхшы түгел иде, киресенчә, сугыш икътисади кыенлыклар тудырды. Эшсезлек, ризык кытлыгы, боларга иминлек мәсьәләләре дә өстәлә иде. Япония тарафыннан яуланган Кытай шәһәрләренә һәм шулай ук Япония шәһәрләренә дә АКШ тарафыннан бомбалар яудырыла иде. Советлар Союзы союздашлар рәтендә булганлыгыннан, Маньчутиго һәм Японияга куркыныч төньяктан да яный иде. Нәтиҗәдә көтелгәннәр чынга ашты, 1945 елның 10 августында Совет армиясе Маньчутигога (Маньчжурия) керде. 1945 елның 14 августында исә Япония императоры Хирохито (1901-1989) Японияңең җиңелүен игълан итте. Шул рәвешле, Ерак Көнчыгышның шактый җирләрендә Японияңең хакимлеге көчен югалтты. Японияда һәм ул яулаган Кореяда—АКШ, Маньчжурияда Совет хакимияте урнашты.

Бу хәл шактый антисовет оешмаларның һәм Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының мәркәзе, аңа бәйле булган җәмгыятьләрнең бетүен аңлата иде. Бары тик Мәркәз кенә түгел, Мәркәзгә бәйле булган оешмалар да тәэсирлелеген югалттылар. Маньчжуриягә совет армиясенең керүе белән яла ягу, әләкчелек механизмы эшли башлады, һәм шул вакытта бер төркем шәхесләрнең күп вакыттан бирле совет шпионары булуы да ачыкланды. Совет армиясе Мукденга керү белән, беренче эшләре итеп Мәркәз әгъзаларын берәм-берәм кулга алдылар. Шул рәвешле, Мәркәз рәисе Әхмәдшаһ Гыйззәтулла (Гыйззәтуллин), сәркатип Ибраһим Дәүләткилде, нәшрият комитеты рәисе Рокыя (Мөхәммәдиш) Дәүләткилде, казначее Салман Аити беренчеләр булып кулга алындылар. Чангчун (Синзин) оешмасыннан исә рәис Гыйльман белән сәркатип Әмрулла Аги, Харбиннан рәис Хәбибулла Салаев белән Хөсәен Ибраһимов, Хайлардан Әсат Агеев һәм без исемнәрен белә алмаган кайбер шәхесләр дә ябыла. Токио имамы Корбангали исә сөргенгә җибәрелгән Дальний шәһәрендә кулга алынды.

[19] Сафия Әмрә. Әтием, Ахмәтвәли Мәңгәр – Хәтирәләр, (Казан: Гасырлар авазы нәшрияты 1997), 37 б.

[20] Рокыя Мөхәммәдиш Гаяз Исхакыйга 1940 елның 8 ноябрендә җибәргән хаттан.

[21] Рокыя Мөхәммәдиш Гаяз Исхакыйга 1941 елның 6 февралендә җибәргән хаттан.

1945 елның 20 сентябрендә кулга алынган Рокыя Дәүләткилде төрле сорау алулардан соң[22] 10 елга иркеннән мәхрүм ителде.[23] Кулга алынганда авырлы булган, берникадәр вакыт үтү белән баласы кулыннан тартып алынган[24], төрле хезмәт лагерьларында чиләнгәннән соң, Себердә үзе кебек үк җәзага хөкем ителгән иренең сөрген җирендә аның белән бергә өстәмә биш еллык җәза күргән Рокыя Дәүләткилде 1961 елда гына азат ителсә дә, совет органнары алдында таплы булып калды. Ләкин 1992 елның 22 апрелендә хаксыз рәвештә хөкем ителүе, сәяси изүгә дучар булуы турында игълан ителде.[25] Ләкин бу аклану бик соң булды, чөнки ул инде 1989 елның 10 декабрендә Казанда үлгән иде. Ибраһим Дәүләткилде, хезмәт лагерьларында саулыгын шактый югалтса да, ун елдан азат ителде. Биш ел дәвамында Себердә бер дәүләт фермасында көтүче булып эшләде. Матди яктан авыр хәлдә булса да, хатыны янында иде. Сөргеннән соң туган шәһәре Петропавловскка кайттылар. Аның рәсми органнар тарафыннан аклануы да 1992 елның 30 июнендә чынга ашты[26]. Ләкин ул инде 1967 елның 21 апрелендә үк Петропавловскта үлгән иде. Мәркәзнең рәисе, Ибраһим Дәүләткилде белән бергә хөкем ителгән Әхмәдшаһ Гыйззәтулланың язмышы безгә мәгълүм түгел. Исән калган булса, безгә ишетелер иде. Язмышның ачы көлүе: Ибраһим һәм Әхмәдшаһка каршы шаһит булып, рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, мәшһүр имам Корбангали чыгыш ясаган[27]. Югарыдагылар кебек кулга алынып хөкем ителгәннәрдән Әмрулла Агинең котылуы һәм 1965 елда Төркиядәге гаиләсе белән кавышуы мәгълүм[28].

Маньчжуриягә Совет армиясенең керүе һәм җәмгыять хакына эшләүчеләрнең берәм-берәм кулга алынуы төрек-татар халкына шок тәэсире ясады. Идел-Урал девизы көн тәртибеннән алынды.

Югарыда күрсәтелгән сәяси үзгәрешләр аркасында Ерак Көнчыгыштагы татарларның күбесе бу җирләрне ташлап киттеләр. Шул рәвешле Ерак Көнчыгыштагы татар диаспорасының тарихы да азагына якынлашты. Үзләреннән соң ташлап калдырылган мәчет һәм мәктәп биналарының күбесе юк булдылар. «Милли байрак'' һәм башка басмаларның нөсхәсен табу да инде мөмкин түгел. Ерак Көнчыгыштагы төрек-татарларның тарихын тәфсилләп язу исә мөмкин әле, һәм бу кирәкле, файдалы эштер.

Ерак Көнчыгыш егермедән артык шәһәр, поселок, авыл яки станция үзәкләрендә урнашкан төрек-татарлар бирегә ярты гасырдан азрак кына яшәсәләр дә, үз гыйбадәтләре өчен мәчет, уку-укыту эшләре өчен мәктәп һәм социаль тормышны тәртипкә салу, ярдәмләшү өчен оешмалар төзү сәләтен күрсәттеләр. Соңыннан 10-15 мең тирәсе генә булган бу кешеләр, йә арендага[5], йә сатып алган биналарда дини вазифаларын үтәделәр, балаларына туган телдә башлангыч белем бирделәр, бәйрәм җыелышлары, милли кичәләр оештырдылар. Шулай итеп, 45 ел эчендә меңләгән укучы туган телен, тарихын, әдәбиятын һәм динен өйрәнде. Мин таба алган 21 оешма, 18 мәчет һәм 15 башлангыч мәктәбе булган Харбин, Хайлар, Кобе һәм Токио кебек шәһәрләрдә хәтта зур җәмигъ мәчетләре дә салына. Шулай итеп төрки-татарлар үз диннәрен, мәдәниятләрен һәм милли үзлекләрен сакларга тырыштылар.

---

[22] Протокол Допроса...

[23] Протокол судебного заседания 5 января 1946 года; Определение №2-607 Коллегии Верховного Суда Союза ССР. Заседание от 19 марта 1946 г. Кассационная Девлет-Кильди Рукия.

[24] 2003 елның 8 октябрендә Русия телевидениесе "Культура" каналында Рокыя һәм кызы Фәридә турында алты серияле бер документаль фильм күрсәтте. Монда гаиләнең башыннан үткәннәре, аеруча хезмәт лагерьлары чоры һәм аннан соңгы вакыйгалар тасвирлана. Режиссер Марина Разбежкинаның эшләү еллары ахырында төшерелгән бу фильмы «История моей семьи» дип атала. Өстәмә мәгълүмат алу өчен карагыз: http://www.tvkultura.ru/products.cfm?prd=1043

[25] Заключение по уголовному делу Девлет-Кильди Рукия. 28 апреля 1992 года, г.Чита.

[26] Заключение по материалам уголовного дела апх. № Н-18725. 30 июня 1992 г. 13/9-1357 92. Весновская Г.Ф.

[27] Шунда ук.

[28] Әмруллаһ Аги. Мәрхәмәтле һәм милләтпәрвәр кешебез. Ахмәтвәли Мәңгәр — Хәтирәләр, (Казан: Гасырлар авазы нәшрияты, 1997), 80 б.

Бу хәл ватаннарыннан китүдән соң ярты гасыр яисә бер гасыр вакыт дәвам итә, сонрак исә азчылыкны тәшкил иткән бу җәмгыятьләр ассимиляцияләнә яисә яшәгән җирләрендә интеграциягә дучар була.

**I таблица**

ЕРАК КӨНЧЫГЫШТА ОЕШТЫРЫЛГАН ҖӘМГЫЯТЬЛӘР

1) Харбин төрек-татар дини һәм милли җәмгыяте (ТТДМЖ) [Идел-Урал төрек-татар мәдәнияте җәмгыяте: ИУТТМЖ][1]
2) Пограничный станциясе ТТДМЖ
3) Маньчжурия станциясе ТТДМЖ
4) Хайлар мөселманнар милли идарәсе [ИУТТМЖ][1]
5) Хун-хул-ди ТТДМЖ
6) Ил-дуга авылы ТТДМЖ
7) Чанчунг (Синзин) ТТДМЖ [ИУТТМЖ][1]
8) Даирен [ИУТТМЖ][1]
9) Мукден ТТДМЖ [ИУТТМЖ][1]
10) Тиенсин ТТДМ идарәсе [ИУТТМЖ][1]
11) Шанхай ТТДМЖ [ИУТТМЖ][1]
12) Гирин ТТДМЖ [ИУТТМЖ][1]
13) Тумен [ИУТТМЖ][1]
14) Кэй-зео (Сеул) ТТДМЖ [ИУТТМЖ][1]
15) Пусан ТТДМЖ
16) Токио Мәхәллә-и Исламиясе
17) Токио [ИУТТМЖ][1]
18) Кобе ТТДМЖ [ИУТТМЖ][1]
19) Нагоя ТТДМЖ [ИУТТМЖ][1]
20) Кумамото ТТДМЖ [ИУТТМЖ][1]
21) Сингишу (Антунг) ТТДМЖ [ИУТТМЖ][1]

**II таблица**

| ИСЕМЕ | КЕШЕ САНЫ* | МӘЧЕТ/ДАТА* | ЗИРАТ | МӘКТӘП* | УЛ ЕЛГЫ УКУЧЫ САНЫ* |
|---|---|---|---|---|---|
| Харбин | 500 | 1905 Төзү | | 1905 | 2 |
| | 2.000 | 8.10.1937 Мең ел мәчете | 500 | 1918 | 150 |
| Пограничный станциясе | 200-250 | 1920-1940 аренда | | 1920 | 25 |
| Маньчжурия станциясе | 500 | 1904-1935 | | 1920 | 10-15 |
| Хайлар | 1.200 | 1906 Бина алынуды | | 1906 | 100 |
| | | 1925, 400 кешелек | 700 | 1919 төзү | 72 |
| Хун-хул-ди | 100 | 1920-1943 аренда 1943 төзү | | 1920 | 5-10 |
| Ил-дуга авылы | 100 | 1920-1945 төзү | | | |
| Си-Тоу-Хидце станциясе | 150-300 | 1935 төзү | | 1935 төзү | 5-10 |
| Чанчунг (Синзин) | 250 | 1932-1945 аренда | | | |
| Мукден | 200 | 1923 аренда | | 1923 аренда | 5-10 |
| Даирен | 100 | 1925 ? төзү | | | |
| Тиенсин | 120 | 5.8.1928 төзү | | 1928 | 5-10 |
| Шанхай | 200 | 1922 аренда | | 1935 аренда | 10-15 |
| Гирин | 70 | | | | |
| Кэй-зео (Сеул)) | 100 | 1926 бина | | 1926 | 5-10 |
| Пусан | 50 | 1923 аренда | | | |
| Токио | 800 | 1925 аренда | | 1925 аренда | 10 |
| | | 12.5. 1938 төзү | | 1937 | 25 |
| Кобе | 600 | 1923 аренда | | 1923 | 15-20 |
| | | 11.10.1935 төзү | | 1935 | 20-30 |
| Нагоя | 50 | 1935 төзү | | 1925 | 10 |
| Кумамотоо | 50 | аренда | | | |
| БАРЛЫГЫ* | 7.540 | | | | |

[1] 1934тән соң исеме үзгәргән җәмгыятьләр

* Бу саннар төгәл түгел, саннарда 20-30% ялгышу мөмкинчелеге бар.

Рәшит
Ягъфәров

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТАМАША СӘНГАТЕ

Татар халкы тамаша ярата. Анын бу сыйфаты тирәннән, ерак гасырлардан килә. Галимнәр күрсәткәнчә, безнең бабаларыбыз борынгы заманнарда ук карнаваллар, мәйдан тамашалары уздыра торган булганнар. Археологлар тарафыннан табылган истәлекләр арасында моңа ишарәләр бар. Әйтик, борынгы Болгар шәһәре урынында алып барылган археологик эзләнүләр вакытында биюче парлар рәсеме төшерелгән тукыма кисәкләре табылган. Ә инде төрки халыкларнын уен-тамаша традицияләренә күз салсак, аларда бу сәнгать аеруча алга киткәнен күрербез.

Әзәрбәйҗан һәм төрекләрдәге «Карагөз театры», үзбәкләрдәге «кызыкчылар» иҗаты турында зур хезмәтләр язылган, бу тема җентеклэп өйрәнелгән. Әмма татарлардагы мәйдан театрлары, халык тамашалары турында мәгълүматлар аз сакланып калган. Моның җитди сәбәбе дә бар. Халык тамашалары, маскарад, мәйдан театры корулар шәһәр мәдәнияте белән бәйле. Ә татарларда шәһәр мәдәнияте XVI гасырда Рус гаскәрләренең Казан һәм башка шәһәрләрне алуы, аларның шәһәрдән куылуы сәбәпле, бик зәгыйфьләнгән, шул исәптән шәһәр мәдәниятенең бер формасы булган халык театры да үсүдән туктаган, онытылуга дучар ителгән. Бу тамашалар турында халык телендә аерым гыйбарәләр генә сакланып калган. «Кәмит», «кәмит күрсәтү», «Ат кәмите», «кәмитчеләр» кебек сүз һәм гыйбарәләр, күрәсең, халык тамашалары гөрләп торган шул заманнардан ук киләләрдер.

Нәрсә соң ул халык тамашасы яки халык театры? Аның төп сыйфаты нәрсәдә? Бу сорауга фольклорчылар һәм сәнгать белгечләре тарафыннан җавап бирелгән. Традицион яки импровизация рәвешендә корыла торган, һәм телдән башкарыла торган тамаша һәм күренешләрне халык драмасы диләр. Атаклы фольклорчы В. Гусев, мәсәлән, халыкның драматик иҗатын ике төркем: чын театр формасы рәвешенә кергән һәм театр күренеше булып оешып җитмәгән төркемнәргә бүлә. «Чын театр формасы» дип санаганнар арасына ул фәкать фольклор текстларына нигезләнгән һәм традиционлык, телдән-телгә күчеп йөрү, күмәк иҗат җимеше булу, импровизацияләнү кебек үзлекләргә ия әсәрләрне кертә. Ә «театр күренеше булып оешып җитмәгән»нәр арасыннан барлык драматик рәвеше булган йолаларны, йола уеннарын һәм драматик уеннарны түгел, ә аларның кеше гамәлләре художестволы образ аша гәүдәләнеш тапкан урыннарын һәм өзекләрен генә халык театры үрнәкләре дип саный.

Н. Савушкина исә халык театры төркеменә театраль гәүдәләнеше булган, фольклорга хас үзлекләргә ия барлык тамашаларны, көнкүреш пьесаларын, күренешләрне, диалогларны, эпик һәм лирик әсәрләрдәге һәм йолалардагы театраль элементлар төсмерләнгән барлык эпизодларны кертү ягында тора. Бу фикерне башка бик күп театр белгечләре һәм фольклорчылар да хуплыйлар. Без дә, Н. Савушкина фикерен хуплап, халык театрынын жанр офыкларын шулай киңәйтебрәк алу ягында.

Татар халкынын да, башка халыкларныкы кебек ук, бай драматик иҗат хәзинәсе бар. Ул халкыбызнын календарь һәм көнкүреш йолаларында, йола

фольклорында, халык уеннарында чагылыш таба. Халык ижатының экиятләр, бәетләр, җырлар, такмаклар, такмазалар, әйтешләр, алдавычлар жанрына кергән күп кенә әсәрләрендә драмалаштыру, драматик ижат төре үрнәкләре белән очрашабыз. Шулай ук чын мәгънәсендә халыкның театр сәнгате үрнәге дип күрсәтерлек, билгеле бер сюжеты булган драматик тамашалар, күренешләр дә бар. Кыскасы, татар халкының драматик хәзинәсе, славян халыкларына хас героик темага багышланган зур күләмле халык драмалары булмаса да, шактый бай булып төсмерләнә.

Халыкның күңел ачу тамашаларыннан берсе–«Аю биетү». Бу төр тамаша татарлар яши торган төбәкләрдә XIX гасырда булган әле. Аю биетүчеләрнең язмышы турында бәетләр дә чыгарылган һәм алар беркадәр матур әдәбиятта да чагылыш таба. Әйтергә кирәк, тамашаның исеме «Аю биетү» дип аталса да, чынында исә ул төрле сәнгать төрләре катнашкан, театрлаштырылган кәмит булган. Авылдан-авылга күчеп йөрүче труппада кимендә 5-6 кеше булып, алар арасында музыка коралларында уйнаучылар, тамашаны алып баручы сүз остасы–кәмитче дә йөргән. Кыскасы, бу тамаша аю биетү белән генә чикләнмәгән, ул чын театр тамашасы төсмерен алган. Мәшһүр татар журналисты, Г. Тукай замандашларының берсе Вафа Бәхтияров үзенең истәлекләрендә аючылар турында менә ничек язып калдырган: «Аючылар авылга килер алдыннан, авыл куштаннары, аксакаллары, авыл яшьләре атларга атланып, җигүле атларга утырып аларны авылдан берничә чакрым чыгып каршылый торган булганнар. Аючылар авылга кергәндә, барабаннарын кагып, думбра сугып, такмаклар әйтеп керә... Бөтен авыл аякка басып, яңа күлмәкләрен киеп, бәйрәмгә хәзерләнгән кебек каршылый торган булган...

Шуннан соң авылның уртасында яки читендә мәйдан ясап, шул мәйданга авыл халкын җыйнар өчен, барабан суга, быргы кычкырта торган булганнар. Халык җыелып җиткәч, аючылар аюларын думбра сугып, төрле такмаклар әйтеп биетәләр, курайчылар курай уйный, җырчылары курайчыга кушылып төрле җырлар җырлый, такмакчылар думбра сугып, хатын-кызларны, бигрәк тә яшь килеңнәрне шаяртып, алардан көлеп-чәнчеп такмаклар әйтә торган булганнар.

Аю биетеп йөрүчеләр 5-6 кеше, алар арасында курайчы, думбрачы, җырчы, такмакчы, көлдертүчеләре булган. Уен беткәч, араларыннан берсе тамашачылардан акча, йомырка, бүләк сөлге, яулык җыеп йөри...» *(М. Әхмәтжановның шәхси архивыннан.)*

Бу истәлегеннән соң В. Бәхтияров шул чакта кәмитче тарафыннан сөйләнә торган «Унмаган килен» дигән юмористик бәетнең кайбер өзекләрен дә китереп уза.

Аю биетү тамашасы һәм аның традицияләре татарларда XIX гасыр ахырларында инде югалган булырга тиеш. Чөнки безнең гасыр башларында һәм соңрак чорларда «Аю биетү» тамашасының булуы турында язма, басма чыганакларда һәм истәлекчеләрендә телгә алынмый.

«Аулак өй» уеннарында шулай ук драматик иҗат төрләренә, театрлы тамашаларга да урын бирелә. Алар да борын заманнан килгән театр тамашалары кую традициясен дәвам итеп килә. Әйтик, татарлар яши торган байтак якларда кич утырулар вакытында «Сәвәнәй» булып уйнау бик популяр булган. Мәсәлән, Актаныш районы Иске Кормаш авылында туып-үскән, пенсиядәге укытучы Әхәт абый Сафәргалин 1912-13 еллардагы кич утырулар һәм «Сәвәнәй» уйнауны түбәндәгечә искә төшерә: «Аулак өй»ләр вакытында бер сүзгә оста кеше «Сәвәнәй» булып киенә иде. Туның, бүреген әйләндереп кия, тиредән кисеп мыек ябыштыра яисә мыекны корым буяп ясый. Шул рәвешчә йә хәерче, йә дәрвиш халәтенә керә. Тел белән теш арасына бер чыра, чөй кыстырып, телен бозып сөйләшә. Кулына таяк тотып аулак өйдәгеләрнең хәлен сорашкан булып, төрле кызык сүзләр сөйләп, яшьләрнең күңелен ачып йөри». Моңа охшаш «Сәвәнәй» дигән бер тамашаны Минзәлә районы Шыгай авылында фольклорчы Н.Ибраһимов та язып алган. Аерма тик шунда гына: «Сәвәнәй» бу якта камырдан ясалган битлек ясап кигән була һәм ул карап торышка куркыныч персонаж итеп киендерелә.

Курган өлкәсе Сафакул районы Карасу авылында «Аулак өй»ләрдә күңел ачу өчен киендерелә торган көлкеле персонаж «Озын кеше» дип атала. Аны болай киендерәләр: «Озын кеше» буласы уенчы учын алга куеп һәм кулларын беректереп югары күтәрә. Ана одеял ябалар һәм күтәрелгән кулга яулык бәйлиләр. Ул шулай озын бер кеше кыяфәтенә керә. Кич утыручылар ягына чыгып, һәрберсе белән бил бөгеп исәнләшә, кеше көлдереп йөри».

Кич утыру, «Аулак өй»ләрдә «Никах уку» дигән юмористик тамаша уйнала торган булган. Эчтәлеге түбәндәгечә: никах укучы «мулла» түргә менеп утыра. Кыз белән егет мулла каршына килеп: «Мулла абзый, безгә никах укы әле!» диләр. Мулла абзый: «Ерактан өйләнәсеңме, якыннанмы?»–ди. Егет: «Ерактан, мулла абзый, ерактан»,–дип җавап бирә. Мулла абзый «Алайса, ерактан башлаем»,–ди дә, китә укып:

*Әгүзебилләһи мин сиңа әйтим,*
*Бисмилласын әйтеп тормыйм, башлыйм.*

«Мулла» шул җирдә юмористик такмаза әйтә дә, түбәндәгечә тәмамлый:

*...Минем никах шул гына,*
*Садакаңны суз гына.*

«Нардуган» кичләрендә дә өй эчендә тамаша кору традициясе яшәп килгән. Нугайбәк керәшеннәрендә шундый өй театрларын оештыру турында М. Глухов түбәндәгечә яза:

Берәү: «Әйдәгез, авыл буйлап әйләнеп керәбез»,–дип тәкъдим итә. Тәкъдим кабул ителү белән «гастрольләргә» әзерлек башлана. Беренче булып кем йортына керергә карар кылуга карап, кирәк-яракны әзерлиләр. Яшьләр төрле сәер киемнәр киялəр, йорт хуҗасы танымасын өчен, төрле төстәге битлекләр ясыйлар, кем нәрсә эшләргә тиешлеген билгелиләр (гадәттә, өйгә кергәч нинди дә булса сюжетлы комедия уйнала). Барысы да әзерләнеп беткәч, билгеләнгән йортка юнәләләр...

Йорт хуҗасы ишекне ачарга да өлгерми, өйгә, шау-гөр килеп, төрле битлекләр кигән һәм кулларына камчылар, тукмаклар, ясалма кылычлар һәм башка әйберләр тоткан бер төркем яшьләр кереп тула. Килеп керүгә, исәнлек-саулык та сорашып тормастан, алдан әзерләнгән уен башлана. Мондый уен-спектакльләрнең эчтәлеге уйнаучыларның зирәклеге һәм йорт хуҗасы тормышының үзенчәлегенә бәйләнгән була. Уйнаучылар йә «адашкан юлчы» ролен башкаралар, йә бөкре кызларын кияүгә бирә алмыйча, яки азгын малайларын өйләндерә алмыйча азапланучы кодалар булып уйныйлар, йә булмаса ярминкәдән кайтучы кырыктартмачы булып кыйланалар».

Драматик уеннар татар халык сәнгатенең иң зур өлешен алып тора. Билгеле булганча, уен башка төрле тамаша төрләреннән функциональ яктан аерылып тора. Ул әле карап узган театрлы тамашалардан үзенең тотрыклы сюжетка ия булуы белән аерыла. Уенда киенеп-бизәнеп образга керү юк, шартлылык көчле. Уен—күңел ачу чарасы һәм ул бер үк вакытта берничә мәртәбә кабатлап уйнала ала. Уеннарның максатлы идея-художество юнәлеше дә ачык булмый. Болар—уеннарны халыкның көнкүреш драмаларыннан аерып торган үзлекләр.

Хәзер басма чыганакларда һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор фондында драматик нигезе булган йөздән артык уен бар. Аларның якынча өчтән икесе балалар репертуарында яши. Ләкин аларны балаларның иҗат җимеше генә итеп санау дөрес булмас иде. Чөнки тарихи яшәеш дәвамында халык репертуарында әсәрләрнең бертуктаусыз зурлар репертуарыннан балалар мохитенә күчү процессы бара. Ышаныч белән әйтә алабыз ки, хәзер безнең кул астында булган «бала уеннары» дигәнебез кайчандыр зурларның «байлыгы» булган. Аларның эчтәлегеннән, образларыннан да моны белүе читен түгел. Әйтик, уеннарыбыз арасында «Хан» персонажы кергән уңлап уен бар. Аның классик варианты Нәкый Исәнбәтнең «Балалар фольклоры» китабында басылган. Шулай ук «Тукран бабай», «Убыр әби», «Карак» персонажлары кергән уеннар да байтак. Безнеңчә, бу персонажлар кайчандыр халыкның

көнкүрешендәге театрлы тамашаларынын, халык драмаларынын образлары булса кирәк. Мөгаен, алар, олылар репертуарында халык драмалары таркалып югалганнан сон, балалар репертуарына кереп калгандыр.

Күренекле әдәбият белгече һәм тарихчы Г. Газиз үзенен бер хезмәтендә татарлардагы халык драмалары турында түбәндәгечә язган иде: «Драматик (ягъни диалоглы, кара-каршы әйтешә торган) әсәрләр булса да, алар халыкта күбрәге шамакай уеннары, «Алырмын кош–бирермен кош», «Күктә, күктә ниләр бар?» уеннарында әйтелә торган сүзләр шикелле генә нәрсәләрдер. Мондый уеннарнын тагы да тәрәккый итә төшкәннәренең Анатолида, госманлыларда һәм хәзерге кыргызлар арасында сакланып калуы борынгы заманда монын көчле бер әдәбият вә сәнгатьнен нәфисәи тармагы булганлыгын күрсәтәдер». Бу–1932 елда әйтелгән сүзләр. Әлбәттә, ул елларда, әле уен һәм театрлы тамашаларны барлау эше ныклап башланмаган чорда, бу сүзләрнен әйтелүе табигый. Әмма әлеге фикерне хәзер әйтеп булмый. Чөнки хәзер фольклор фондларында халыкнын драма әсәрләре дип санарлык байтак әйбер тупланып өлгерде. Шундый драмаларнын берсен, «Сәвәнәй» дип аталганын күрсәтеп узыйк. Аны 1971 елда Иркутск өлкәсе Чуна районы Кулиш авылында Хәтирә апа Мусинадан Д. Миннуллин язып алган.

Драматик күренеш кич утыру вакытында уйнала торган булган. Эчтәлеге болай: иң башта аркасына мендәр куеп, башына бүрек кигезеп Сәвәнәй әбине киендерәләр, анын кулына таяк тоттыралар. Ул өй алдына чыга да ишекне шакый. Өйдәгеләр: «Керегез!»–диләр. Сәвәнәй әби керә дә, һәрберсенә: «Мина жеп эрләргә килегез!»–дип әйтеп чыга. Берсе дә бармый. Әби икенче мәртәбә килә–берсе дә бармый. Өченче мәртәбә килеп: «Ашка чакырырга киллем»,–дигәч, барысы да «бара». Сәвәнәй әби боларны ашатмыйча «Эшемә килмәдегез, ашыма килдегез»,–дип, куып чыгара.

Күренгәнчә, бу әсәрнен драматик күренешләргә хас сюжеты һәм композициясе, идея-эстетик эчтәлеге бар. Анда халыкнын әхлакый карашлары да ачык чагылыш таба. Шулай ук «Шамакай», «Ике сукыр» дип аталган драматик күренешләрдә дә халыкнын театр сәнгатенә хас үзенчәлекләре ачык күренә. Аларны чын-чыннан «халык драмалары» дип атарга мөмкин.

Татар халкынын халык театры репертуарында мәдрәсә шартларында туган һәм шунда уйналган әсәрләре бар. Без бу әсәрләрне башлыча Г. Толымбайский һәм Г. Лотфи истәлекләре буенча беләбез.

Г. Лотфинын язуы буенча, мондый уеннар Кышкар мәдрәсәсендә бик данлы булган. Аларны «шашу» уеннары дип атаганнар. Н. Ханзафаровнын фикере буенча, «шашу» уены Урта Азиядәге халык музыкантлары башкара торган «шашмаком» дигән музыкаль циклга ияру рәвешендә барлыкка килгән. Бу исемне безнең якларга Бохарада укыган шәкертләр «алып кайтканнар».

Г. Лотфи язганча, Кышкар мәдрәсәсендә Таип исемле шәкерт аеруча осталык күрсәткән. Ул җәнлек, кошлар тавышына охшатып авазлар чыгару гына түгел, татар байларынын көлкеле образларын да күрсәткән. Бер татар баенын рус телен вата-җимерә телефоннан сөйләшүен, приказчикларын сүгүен, байнын асрау кызына күз төшерү күренешләрен бик оста итеп тасвирлый торган булган.

Мәдрәсә театрлары турында Г. Толымбайский да тәфсилләп яза. Ул үзенен «Мәдрәсә калдык-постыклары» дигән мәкаләсендә кайбер «спектакльләр»нен эчтәлекләрен дә тасвирлап уза. *(«Татарстан» журналы, 1930, N 6-7.)*

Андагы театр тамашаларынын төп образлары–муллалар, шәкертләр һәм крестьяннар. Вакыйгасы исә мәдрәсә тормышында була торган хәлләргә корыла яки аларга пародия рәвешендә оештырыла. Шулар арасында «Мулла» дип аталган театр тамашасы бигрәк тә үзенчәлекле. Г.Толымбайский бу тамашанын конкрет «драматургик» текстын бирмәсә дә, анын эчтәлеген анык тасвирлаган:

Авыл кулаклары, куштаннары берәр шәкертне, яисә хәлфәне үзләре мәхәлләсенә муллалыкка сорарга киләләр. Аны күрергә һәм беркадәр сынамакка да булалар. Баш дамелла белән сөйләшкәч, ризалашкач, хәлфәнен, шәкертнен үзе янына керәләр. Шул чагында мәдрәсәнен хәлфәләре мондый бер нәрсә коралар: муллалыкка сорала торган шәкертне ничек булса да тегеләргә зур итеп,

галим итеп күрсәтергә кирәк. Менә шушы теләкне ныклап эшкә ашыру өчен теге мулла була торган шәкерттән–хәлфәдән әллә кайда карт, зур булган хәлфәләр тоталар да чалма, чапаннар киеп, тегеләрдән сабак өйрәнергә керәләр. Билгеле, әле монда үзләре зур, яисә карт булу гына житми, өйрәнергә кергәндә китаплар да зур һәм калын булырга тиеш...

Мулла булачак шәкерт, билгеле, үзен бик эре тота. Үзеннән җавап өйрәнергә кергән карт хәлфәләргә: «Шуны да белмисез, хашәпләр!»–дип кенә җибәрә. Хәтта этәчләнеп кайберләренә сугып та җибәрә. Чөнки мужикларны алдан ук куркытып куярга кирәк. Шуннан инде теге кулаклар үзләренә мулла булачак кешенең галимлегенә хәйран калып кайтып китәләр икән.

Шулай ук Г. Толымбайский тасвирлаган «Хәзрәт белән крестьян», «Мулла малае» дигән «спектакльләр» дә шундый комик эчтәлектәге әсәрләр.

Кыскасы, татар мәдрәсәсе элек-электән халык драмаларының туу һәм яшәеш урыны булган. Соңрак бу шартларда үзешчән спектакльләр куела башлаган, импровизацияле тамашалардан һөнәри театрга беренче адымнар шушы мохиттә ясалган.

Татар халкының драматик иҗатын күздән кичергәндә бер үзенчәлекле күренешкә игътибар итмичә булмый. Ул–җырга корылган, сюжеты диалог-җырлар аша ачыла торган музыкаль драма тамашалары. Бу әсәрләрне М. Мәһдиев «лирик драма» үрнәкләре дип атаган иде. Күренекле фольклорчы И. Надиров хезмәтләрендә дә бу төр әсәрләр анализланды һәм алар әйтеш жанрына якын торган әсәрләр итеп бәяләнде.

Безнең уебызча, М. Мәһдиевнең бу әсәрләргә карата әйтелгән билгеләмәсе отышлы һәм, чыннан да, аларны «халыкның лирик драмалары» дип атау урынлы булыр. Андый әсәрләр халык репертуарында шактый һәм аларның байтагысы әле хәзерге көннәргә кадәр (үзешчән сәнгатьтә) аерым лирик драма, «халык опереттасы» үрнәкләре булып сәхнәләрдә башкарылып килә.

Шуларның классик үрнәкләреннән–«Җизнәкәй» әсәрен күрсәтергә була. Халык репертуарында бик күп вариантларда йөрүче бу кара-каршы әйтешү рәвешендәге юмористик җыр, мөгаен, бик озак вакытлар мәйдан тамашалары, җыен, ярминкәләрдә кәмитчеләр, брамат артистлар тарафыннан җырланып йөргән, шомарган булырга тиеш. Чөнки бу җырның поэтик камиллеге шулкадәр югары дәрәҗәгә җиткән ки, мондый дәрәҗәгә әсәр бары тик озак вакытлар халык репертуарында актив кулланылышта йөргәннән соң гына ирешергә мөмкин.

Түбәндәге строфаларда бу бигрәк тә күзгә чалынып тора (ритмикасына, рифмасына, яңгырашына игътибар итик):

*—Тәрәзәдән нигә бактың, җизнәкәй?*
*—Яшь йөрәккә ут яктың, балдызым-ялгызым.*
*—Тау башында дүрт казык, җизнәкәй,*
*—Бер үпкәннән юк язык, балдызым-ялгызым.*

Шулай ук «Хан кызы», «Башмагым», «Чибәр егет», «Кемгә бирим кызымны», «Әнкәй, башым бик авырта» кебек җырлар да халык репертуарында лирик драмалар төсендә тамаша сәнгате үрнәге буларак яшәп килгәннәр. Бу традиция үзешчән сәнгатьтә 1950 елларга кадәр яшәп килде һәм хәзер дә аларны театраль миниатюра рәвешендә башкару очраклары бар.

Әйтергә кирәк, халык арасында йөргән бу лирик драмаларның сюжетына нигезләнеп чын музыкаль комедияләр иҗат итү очраклары да билгеле. Әйтик, 1920 елларда Х. Ибраһимов «Башмагым» дигән халык лирик драмасы сюжетына нигезләнеп шул исемдә пьеса, ә Т. Гыйззәт һәм Җ. Фәйзи музыкаль комедия иҗат итәләр. Ул комедия халыкның яраткан әсәренә әйләнә.

Кыскасы, халык репертуарында туган драматик иҗат әсәрләре, халык тамашалары, халык драмалары алга таба милли драматургия, һөнәри театрның үсеп китүенә дә этәргеч көч биргән.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Аю Көйдергән авылы

Татарстандагы авыл атамаларына гаҗәеп төрлелек хас һәм алар арасында көтелмәгән мәгънәгә ия булганнары да бар. Шушындый авыл атамаларының берсе—Аю Көйдергән.

Аю Көйдергән авылы Апас районында, үзәге Апастан 36 чакрым ераклыкта урнашкан.

Аю Көйдергән авылы XVIII йөз чыганагында искә алына һәм анда 75 йомышлы, 9 керәшен татары яшәгәнлеге күрсәтелә. Христианлаштыру сәясәте вакытында авылның берничә кешесен көчләп чукындырганнар. А. Артемьев китабында да бу авыл телгә алына. Авылдагы 77 хуҗалыкта 276 ир-ат һәм 248 хатын-кыз көн иткән, мәчет эшләгән. 1898 елгы җыентыкта авылда татарлар һәм руслар яшәгәнлеге күрсәтелә. К. П. Берстель хезмәтендә бу авылда 1020 рус кешесе яши дип әйтелә.

Авыл оешу турында түбәндәге ривайәтне сөйлиләр.

Бик күптән, моннан йөзләрчә еллар элек хәзерге Татарстан җирләренең Зөя елгасы буена, Кайбыч урманнары итәгенә төрле кабилә, төрле ыруг кешеләре күчеп килгән. Күченүчеләр арасында Багыш, Бигеш, Тәүгилде, Тутай, Шәмәк, Балтай, Дәвеш, Караборнаш, Бураш, Кормаш, Үтәмеш, Сатмыш, Барыш, Даныш, Каратай, Ишем, Бортас, Әҗем исемле бабалар булган. Алар үзләренең нәселдәшләре, яраннары белән бергә шушы төбәкләрнең тынычрак, җайлырак почмакларына нигез корганнар һәм шунда вак-вак авыллар булып урнашып калганнар. Заманнар үтү белән, бу авыллар һәм җир-суларның барысын да диярлек шул бабалар исеме белән атап йөртә башлаганнар.

Мәгълүм ки, Апас районының көньягыннан Чирмешән исемле бер елга ага. Борынгы ривайәтләрдән аңлашылганча, шул елганың югары агымындагы бер борылмасына Багыш исемле бер баба килеп, беренче нигез ташы салган.

Аның нәселдәшләреннән Бигеш һәм Мәмәт бабалар исә Багыш баба торагының (хәзерге Багыш авылының) көньяк-көнбатышында исемсез бер кушылдык су буенда—кара урман эчендә төпләнгәннәр, йөзәр еллык карт имәннәрне аударып, ышна ачып, игенчелек белән көн итә башлаганнар. Билгеле, әлегәчә кеше аягы басмаган куе урман эчендә кыргый җәнлекләр, аю, бүреләр дә күп булган. Аюларның берсе Мәмәт бабаның умарталыгына үчеккән. Ул, һәр килүендә берәр умарта оясын урталай аерып, балын ашап китә икән.

Мәмәт бабайның тол карчыгы Гөлнар әби, бу бәладән котылу өчен, хәйлә уйлап тапкан: буш умарта оясына бал сылаган да шуны тирә-күршеләр булышлыгы белән коры салам өеме эченә урнаштырып куйган.

Умарталыкка ияләнгән әлеге аю төнлә белән, бал исен сизеп, салам өеме астына кергән. Шуны гына көтеп торган кешеләр, аюның кергән урынын томалап, өемгә ут төрткәннәр. Бал ялап рәхәткә тиенгән аю ялкын эчендә

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

көеп, пешеп харап була язган һәм, көч-хәл белән генә качып киткән. Шуннан соң инде ул да килмәгән.

Бу хәбәр, әлбәттә, тиз арада тирә-күрше авылларга таралып өлгергән. Алар Гөлнар әбинең зирәк акылына хәйран калганнар, бу авыл кешеләренең ничек итеп аюны көйдергәнлеген кызыклы бер әкият итеп сөйләп йөргәннәр. Шушы вакыйгадан соң Мәмәт бабалар нигез корган бу торак урынны «аю көйдергән авыл» дип (соңрак «Аю Көйдергән» дип), ә авыл урнашкан инеш буен Аю Көйдергән елгасы дип атап йөртә башлаганнар.

Ләкин авыл утырган инеш буе тагын бер яктан бик тынгысыз булып чыккан. Идел яры белән Алатыр арасын тоташтыра торган олы юл авыл яныннан ук уза икән. Юлаучылар Бигеш бабалар торагына тынгы бирмәгәннәр. Өй саен кереп, хуҗаларның пешкән икмәкләрен ашап, азык-төлекләрен алып китә торган булганнар.

Авыл кешеләренә, бабаларның иске нигезен ташлап, бүтән бер тынычрак урынга күчеп китүдән башка әмәл калмаган. Язгы көннәрнең берендә Бигеш, Мәмәт бабаларның оныклары яңа нигез салу өчен җайлырак урын эзләп, исемсез бер инеш буена килеп чыкканнар.

Инеш, Аю Көйдергән елгасы белән бер үк юнәлештә агып, Чирмешән елгасына коя икән. Бөтен тирә-юне кара урман. Инешнең аргы як ярындагы калкулыкта түбәләре күккә сузылган карт имәннәр үсеп утыра, куе урман эченә моң таратып, тау битеннән чишмә сулары челтерәп ага икән.

Ләкин инешнең аргы ягына—чишмәле тау сыртына кичеп чыгарлык түгел. Язгы ташу әле басылмаган, инеш суы да үз эзенә төшмәгән. Ул әле болганчык, шуңа күрә аның кайсы җире кичеп үтәрлек сай икәнен белеп булмый, бераз сабыр итәргә, инеш суының чистарып-тонып җиткәнен көтәргә кирәк. Ил картлары моны күзәтеп торуны Сәйкә бабага тапшырганнар.

Менә көтелгән көн дә килеп җиткән. Сәйкә баба: «Су кайтты, инеш тонды!»—дип хәбәр иткән. Сәйкә бабаның бу җылы сүзе, телдә еш кабатлана торгач, «Томбы»га әйләнеп, исемсез инешнең мәңгелек атамасына әверелгән (Аю Көйдергән халкы бу инешне хәзерге көндә дә Томбы дип атап йөртә).

Бабалар, тонык сулы сай инешне кичеп, тау битенә менгәннәр. Ә аның итәгендә берсеннән-берсе тигез ераклыкта (әйтерсең, араларын адымлап билгеләгәннәр) өч чишмә бар икән.

Бабалар яңа нигез өчен урынны шунда сайлаганнар һәм чишмәләрне, җирле сөйләшкә хас булганча, беренче кизләү, икенче, өченче кизләү дип атаганнар.

Беренче кизләү сукмагының уң ягына—Сәйкә баба, сул ягына аның улы Минкә нигез салган. Ә икенче, өченче кизләү сукмаклары буена башка бабалар нигез корган.

Бабалар эшне булдыра алган кадәр кызу тотканнар. Күченү мәшәкате дә зур булмаган. Чөнки иске нигездәге каралты-кураларны, яртылаш череп ингән өйләрне сүтеп азапланасы, яңа нигезгә күчереп җәфаланасы юк. Анда да урман күккә үрелеп үсеп утыра бит. Кис тә аудар гына!

Салынасы өйләрнең тәрәзә уемнарын каплар өчен карындыклар да кул астында гына. Сәйкә бабай карчыгы Бәсәбикә әби, аның замандашлары Тулганай һәм Тансылу әбиләр аларны алдан ук әзерләп куйганнар.

Яңа нигезгә күчүчеләр иске йортта бик күп иске-москыларын калдырып киткәннәр, ләкин авылның элекке атамасыннан аерыласылары килмәгән: борынгы бабаларның җылы истәлеге итеп, зирәк акыллы Гөлнар әбиләренә хөрмәт йөзеннән, яңа нигезне дә Аю Көйдергән дип атаганнар (Апас районының Чуашстан белән чиктәш көнбатыш почмагындагы кечкенә генә бу авылны хәзерге көндә дә шул мәзәккә тартым һәм әкияткә охшаш маҗаралы исем белән атап йөртәләр).

Бабаларнын иске нигезендә бары тик җимерек каралты-куралар, ишелгән бүрәнәләр генә утырып калган. Алар кайчандыр Бигеш бабалар, Айбикә әбиләр нигез корган, Мәмәт бабалар белән Гөлнар әбиләр гомер сөргән борынгы заманнарнын өнсез тарихын искәртеп, узган-барганнарның күңеленә шом һәм сагыш салып торганнар.

Бу вакыйгалардан соң исәпсез еллар, сансыз көннәр узган. Ләкин борынгы бабаларның оныклары аларнын төп йортын онытмаган, нигез ташлары гына таралып яткан иске авыл урынын Иске йорт дип атаган. Авыл халкы хәзерге көндә дә бу төбәкне «Иске йорт» дип йөри.

Аю Көйдергән авылының табигате бай, авыл үзе дә төшеп калганнардан түгел. Урамына килеп кергәч үк матур манзара ачыла. Йортлар буялган, төзек, каралты-куралар да тел тидергесез.

Без авыл аксакалы Гыйлфан абый Зыятдиновны эзләп таптык һәм авыл турында сөйләвен үтендек. Гыйлфан абый сүзен авылның элекке урам исемнәреннән башлады: авылда Югары, Икенче, Олы, Урта, Аскы, Каенсар урамнары бар икән. Соңгы җитмеш ел эчендә алар яңа рәсми исемнәр белән алыштырылсалар да, халык элекке исемнәргә хыянәт итмәгән, яңа атамаларны әйләнешкә кертмәгән, әби-бабалар теләндә йөргән атамаларны кулланган.

Авылда ышна басулары күп. Таһир бабай, Вәчкә, Габдерәхим бабай, Минкә бабай ышналары—бу шәхесләр ачкан басулар. Бабалар зур көч куеп, калын кара урманнан чәчүлек җирләр яулап алганнар. Югарыда язылган исемнәргә Төбәк, Үрәкәш, Күл басуы атамаларын да өстәргә мөмкин.

Авыл яны табигатенә Үрәкәш, Кәҗәләр һәм башка таулар ямь биреп тора. Елга-ермак, кизләү-чишмәләр, күлләр авыл тирә-юнен сырып алган. Шунысы кызганыч, күлләрнең күбесе беткән, елга-инешләрнең дә суы кими. Саескан, Чәрәш, Элми бабай күлләре хәзер кипкән, сагынып сөйләргә исемнәре генә калган. Аларның кешедән ярдәм ала алмыйча бетүләре көн кебек ачык. Югыйсә, бу җирләр суга бай бит. Моның шулай икәнлеген Төпсез күл яисә Дингез күзе атамасы алган су чыганагы күрсәтеп тора. Гадәттә, мондый атамалы урыннар җир асты суларына бай була.

Бу авылда чишмә-кизләүләргә игътибар зур. Аларны Гыйлфан абый Зыятдинов карый һәм чистарта. Йорты артында ул бик матур алма бакчасы үстергән. Алма бакчасыннан түбән якта төрле-төрле агачлар утыртылган икенче бакча үсә. Бу агачлар ишелеп килә башлаган бик зур чокырны (Чүп елгасы башына) туктату өчен утыртылган. Алар чокырга зураерга ирек бирмиләр, ишелүен туктатканнар. Гыйлфан абый агачларны койма белән әйләндереп алган. Урамга да агачлар утырткан, аларны да киртә белән тоткан. Атау кизләве дип аталган ике кизләүнең тирә-юнен кеше яллап тоттырган һәм әйләнәсенә үзе агачлар утырткан. Аның мондый күркәм гадәте зирәк булып үсеп килә торган оныкларына күчәр, күчми калмас.

Авылда хәзер башлангыч мәктәп, балалар бакчасы, кибет эшли. Йортларга үзәкләштерелгән газ кертелгән, юлга асфальт түшәлгән.

Авыл зиратының да тәрбия күргәнлеге күзгә ташланып тора. Чардуганнар һәм ташлар төзек.

## Балтай авыллары

Атамалары составына «балтай», берәмлеге кергән авыллар Апас районында урнашкан. Урта Балтай авылы район үзәге Апастан 19, Каратун станциясеннән—7, Тәтештән—55; Югары Балтай авылы Апастан—22, Тәтеш пристаненнән—58; Түбән Балтай Апастан—17, Каратуннан—5, Тәтеш пристаненнән—55 чакрым ераклыкта утырган.

Балтай авыллары шактый борынгы чорларда барлыкка килгән. Балтай

авылының өчесе дә Казан ханлыгы чоры документларында искә алына. Археолог-галимнәр Урта Балтай авылы янында борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле тимер һәм бронзадан ясалган сугыш кораллары һәм авыл хуҗалыгы дирбияләре тапканнар.

Д. А. Корсаков белешмәсендә Урта Балтай авылынды 73 йомышлы, 2 керәшен татары, Югары Балтайда 67 ясак түли торган, 13 йомышлы татар, 12 дворовый кешеләр яшәгәнлеге билгеләнә. А. Артемьев хезмәтендә күрсәтелгәнчә, Чирмешән суы янына утырган Түбән Балтай авылының 68 хуҗалыгында 217 ир-ат һәм 194 хатын-кыз яшәгән, авылда бер мәчет эшләгән. Урта Балтайдагы 136 хуҗалыкта исә 454 ир-ат, 419 хатын-кыз исәпләнгән, бер мәчетләре булган. Югары Балтайда барлыгы 75 хуҗалык булып, 247 ир-ат һәм 261 хатын-кыз гомер иткән, авылда бер мәчет булган. 1898 елда басылып чыккан хезмәттә Югары Балтай, Урта Балтай һәм Түбән Балтай авылларында татарлар яши дип күрсәтелә. К. П. Берстель китабында Югары Балтайда—789, Урта Балтайда—1186, Түбән Балтайда 659 татар кешесе яшәгәнлеге искәртелә.

Нажия Борһанова мәгълүматларына күрә, Югары, Урта һәм Түбән Балтай авыллары халкы июнь уртасында күршедәге Зур Бакырчы, Кече Бакырчы, Кара Борнаш, Чиргү, Каратун, Колчык, Көлкәш, Чирмешән, Чәтбаш, Коллар, Шәмәк, Күкшем, Тутай, Аксу, Дәүләки, Багыш халкы белән Кушкапка җыены бәйрәм иткән. Бу бәйрәм Урта Балтай белән Түбән Балтай арасындагы болында үткәрелгән. Бәйрәмгә туганнар, белеш-танышлар күп җыелган. Ярышлар, күнел ачулар булган, кәмитләр ясаганнар. Болынга керә торган урынга ике катлы итеп капка да ясап куйганнар. Бу җыен бәйрәме турында өлкән яшьтәге авыл аксакаллары бик сагынып, кызыктырырлык итеп һәм яратып сөйлиләр.

Балтай атамасы килеп чыгуга карата халык хәтерендә шушындый легенда сакланган. Имеш, Балтай исемле картның өч улы булган. Карт елга буйлап өч чыра агызган да, әйткән: «Чыралар туктап калган җирләргә өч улым урнашып, авыл корыр»,—дигән. Беренче чыра тукталган җиргә олы улы авыл корган. Ул авыл Югары Балтай булып киткән. Уртанчы улы икенче чыра туктаган җиргә урнашкан. Ул авыл Урта Балтай дип аталган. Кече улы өченче чыра туктаган җиргә төпләнгән. Ул урында Түбән Балтай авылы барлыкка килгән.

Балтайлыларны электән үк «кәгазь башмаклылар» дигән кушамат белән атаганнар. Бу кушамат кимсетә торган түгел, киресенчә, балтайлыларнын мәдәниятле булуын раслый. Алар бәйрәмнәрдә кеше арасына чыкканда чабата кимәгәннәр. Урта Балтайда сарык карынын эшкәртеп аяк киемнәре ясаганнар. Алар бик җайлы, ләкин суда кәгазь кебек җеби торган булган. Бәйрәмнәрдә халык шушы аяк киемен кигән, шул сәбәпле Түбән Балтай халкына «кәгазь башмаклылар» кушаматы ябышып кала.

Урта Балтай авылында XIX йөз ахырында—XX йөз башында бер катлы итеп яртысы таштан салынган мәдрәсә бинасы бар.

1896 елда салынган мәчеттә имам-хатыйблар булып Минһаҗетдин Мөхәммәтвәлиев (Указ 1875 елнын 19 июлендә бирелә) һәм Әхмәтҗан Мөхәммәтвәлиев (Указ 1896 елнын 18 сентябрендә бирелә) эшләгән. Алар мәхәллә мәдрәсәсендә укыталар да. 80 укучысы булган бу мәдрәсәдә укыту кадими ысул белән алып барыла.

XX йөз башларында бу мәдрәсәдә Габдрахман Таһир улы Таһиров (1907—1984) укый. Ул Ленинград дәүләт университетының иран филологиясе кафедрасы укытучысы, гарәп, фарсы төрки һ. б. көнчыгыш телләре буенча галим, филология фәннәре докторы булган.

Балтай авылларының өчесе дә әле һаман шактый мул сулы Чирмешән

елгасы буена утырганнар.

Урта Балтай авылы тирә-юнендә географик берәмлекләр шактый. Исемнәре дә матур һәм аһәнле.

Корширмә чокыры Чирмешәнгә кушыла. Авылдан бер-ике чакрым ераклыкта Кара урман урнашкан. Аның яныннан Зирекле суы ага.

Чирмешән суы ярында күлләр дә байтак. Шәмәк, Көлкәш, Югары Балтай, Аю Көйдергән, Балтай һ. б. күлләре Урта Балтай авылының географик мохитен тәшкил итәләр. Балтай күле хәзерге вакытта беткән инде. Урта Балтай авылы янындагы калкулыкта көтү йөртәләр. Куаклык бетә.

Авыл тирә-юнендә кизләүләр дә байтак. Газиз, Ирәзән, Фәсхетдин, Түбән Балтай, Мулла кыегы, Сәйфулла кизләүләре әлегә исән. Ләкин аларга игътибар җитәрлек түгел. Урта Балтай авылы элек Сәйфулла кизләве янында урнашкан булган. Борынгы төп һәм иске зират Сәйфулла кизләве янында. Ирәзән кизләве урыны да шундый ук. Сәйфулла исемле кешене үтереп шул чишмә янына китереп куйган өчен чишмә шундый исем алган дип сөйлиләр.

Авыл янында сазлыклар да күп булган, ләкин алар хәзер кибеп беткәннәр. Чөнки урманнар киселә, агачлар утыртылмый.

Урта Балтайда Урта, Кытай, Саз, Кантур урамнары бар.

Авылларның өчесендә дә манаралы мәчетләр салынган. Урта Балтай авылында XIX йөз—XX йөз башларында төзелгән мәдрәсә бинасы 1669 номеры белән «Татарстан Республикасы: тарих һәм мәдәният һәйкәлләре» дип аталган китапка кертелгән.

Авылның бер ягына урнашкан зиратны Зәен зираты дип йөртәләр. Бу зиратка иң беренче булып Зәен исемле кеше күмелгән, исеме шуннан килә икән. Зиратны авыл халкы карап, чистартып һәм тәрбияләп тора.

Авылда мәдәният йорты, урта мәктәп, элемтә үзәге, медпункт, кибет, китапханә эшли.

Халык үзәкләштерелгән газ яга, юллар асфальтланган.

Олы буынга игътибар зур Караучысы һәм ярдәмчесе булмаганнарны күршеләре карап тора, ташламыйлар.

Түбән Балтай авылының да утырган урыны матур.

Авылда чишмәләр шактый. Берсе зират янында чыкканга күрә Зират чишмәсе дип атала. Икенчесе авылдан ярты чакрым чамасы читтә урнашкан. Басуда булганга күрә аңа исемне Кыр кизләве дип куйганнар. Чишмәләрне авыл халкы карап һәм чистартып тора.

Түбән Балтай авылында мәктәп юк һәм балалар Урта Балтай авылына барып укыйлар. Авылда элек мәктәп булган, аның ишегалды урынында агачлар әле дә үсә. Мәктәбе булмаса да, бу ятим агачларны халык Мәктәп бакчасы дип йөртә.

Авыл зираты каралган, тирә-ягы тотылган.

Балтай авылларының өчесе дә матур гына көн итә.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Д

**ДӘРДЕМӘНД** (псевд., чын исеме-фамилиясе Закир (Мөхәммәдзакир) Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев) (23.11.1859, Оренбург губ. Эстәрлетамак өязе Җиргән а. — 9.10.1921, Оренбург өлкәсе Орск ш.), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, алтын прискалары хуҗасы. 1862 елда гаиләләре б-н Орск өязе Юлык авылына күчеп киләләр. Анда әтиләре 1869 да алтын приискасы ача. Булачак шагыйрь авыл мәдрәсәсендә, аннары Орск һәм Муллакай авылы мәдрәсәләрендә белем ала. 1880-81 дә Истанбулда яши, төрек телен һәм әдәбиятын, китап бастыру эшен өйрәнә. Абыйсы Шакир (Мөхәммәдшакир) б-н аңа әтиләреннән мирас булып 20 прииск кала. 1906 дан башлап алар Оренбург ш.ндә «Вакыт» (нашир булып Д. тора) газетасын, 1908 нең 10 гыйнварыннан «Шура» журналын чыгара башлыйлар. 1909 да «Вакыт» типографиясен ачалар (1918 нең февралендә яңа хакимияткә тапшырыла). 1906-1912 елларда әлеге басмаларда Д.нең 40 лап шигыре дөнья күрә (1913 елдан соң да шагыйрь язуын дәвам итә, ләкин беркайда да бастырмый). 1906 да Д. Оренбург губернасыннан 1 нче Дәүләт Думасына депутат булып сайлана (мөселман фракциясендә тора), 2 нче, 3 нче чакырылышларның сайлаучысы (выборщигы), Оренбург шәһәре управасы, конституцион-демократлар партиясенең Оренбург бюросы әгъзасы була. «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен оештыруда катнаша. Хәйрия эше б-н шөгыльләнә: мөселман хәйрия җәмгыяте, мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте, мохтаҗларга ярдәм һәм ятимнәрне тәрбияләү комитеты әгъзасы була; абыйсы б-н бергә үз хисапларына берничә студентны чит илдә укыталар, мәчет-мәдрәсәләр төзетәләр, аларны китап, дәреслекләр б-н тәэмин итәләр һ.б., Юлык авылында китапханә ача. 1917 дән соң приискаларын дәүләткә тапшыра (абыйсы 1914 тә вафат була), чит илгә китми.

Д.нең беренче басылып чыккан шигыре — «Үткән көннәр» (Р.Фәхретдинның «Әсма» хикәясенә кергән). Ул башка шигырьләр дә яза (аларның берничәсе 1902-03 тә «Тәрҗеман» г-тасында басыла), татар теленә төрек шигырьләрен һәм хикәяләрен тәрҗемә итә («Каргалының Сибгатулла хаҗига мәктүб» (1884) шигыре генә сакланган). Үзенең поэтик карашларын Д. «Каләмгә хитаб» шигырендә билгеләи:

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,*
*Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.*
*Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,*
*Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!*

Аның иҗатының тональлеген һәм тематикасын әдәбият галимнәре «моңлы уйлар», «бабалар кабере янында күңел зары», «килеп кичмешләр әхвален бәян итү» дип билгелиләр. Д. лирикасында Шәрекъ традицияләре өстенлек итсә дә, тулаем алганда Шәрекъ һәм Гареб традицияләренең тирән синтезы күзәтелә. Бу күренеш 20 йөз башы татар поэзиясенә гомумән хас (мәс., Г.Тукай, С.Рәмиев, С.Сүнчәләй иҗатларына). Д. поэзиясендә бу синтез поэтик фикерләү нечкәлекләрендә үзен нык сиздерә, мәс., табигать күренешләрен төсләргә төреп тасвирлауда импрессионизм йогынтысы бар («Сеңеп жиргә...»). Бу синтез шулай ук татар шигыренең строфикасы яңаруында да («Кораб», «Кыш көннәре», «Ятам кай чакларны моңлап...», «Бу — ул...»), фәлсәфи-стилистик эзләнүләрдә дә сизелә. Дөньяны галәм масштабы киңлегендә күзәтү Д. иҗатында, бер яктан — Рудаки һәм Гомәр Хәйям фәлсәфә лирикасына, икенчедән, Гёте поэзиясенә килеп тоташа («Без», «Яз» һ.б.). Халык иҗатына мөрәҗәгать итеп, шагыйрь строфика һәм стиль өлкәсендә яңа ачышлар ясый («Видагъ», «Бүзләрем маналмадым»). Д.нең пейзаж лирикасы пантеистик оптимизм б-н сугарылган («Яз», «Бу — ул...»).

Социаль гаделлек темасы Д. иҗатының үзәгендә тора. Ул аны төрле аспектларда куя. Халык һәм хөкемдар проблемасын ул традицион яссылыкта хәл итә. Гаделлекнең нигезен ул хөкемдарның гадел булуында күрә. Идеал итеп Д. Библия һәм Коръән персонажы, борынгы яһүди-христиан һәм мөселман дөньясында зур абруй казанган — Сөләйманны (христианнарда һәм яһүдиләрдә — Соломон) ала. Хөкемдарның чын бөеклеге, Д.нең күзаллавында, аның гади кешене кайгыртуында чагыла. Тормыш мәгънәсенә һәм галәм серләренә шагыйрь табигать гармониясе аша төшенергә тырыша. Аның пейзаж лирикасы үзенең киң колачы һәм реалистик төгәл, автор һәм лирик геройның рухи һәм хисси якынлыгы, ритм, интонация, строфика һәм

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

структура ягыннан төрлелеге б-н 20 йөз башы татар поэзиясенең кабатланмас күренеше булып тора.

Күренешләрне Д. гомумиләштерә, романтик сурәтләү чараларын файдалана. Ләкин аның поэзиясендә реалистик төгәллек үрнәкләре, детальләштерү алымнары, табигать күренешләрен биргәндә эзлекле динамика да бар.

Шагыйрьнең бурычы турында Д. дөнья әдәбиятының бөек гуманистлары рухында болай дип яза:

*Караңгы төн исә якын-ераклар,*
*Хәзин кальбемне вакла — як чыракълар:*
*Гарибләр, шәм-чыракъ күргәндә юлда,*
*Дисеннәр: бер заман бар булган ул да...*

(«Кыйтга»)

Д. иҗатын өйрәнгән кайбер галимнәр (Г.Халит) аның поэзиясендә фатализм өстенлек итә дип исәпләделәр. Мондый рух, мәс., Д.нең «Кораб» шигырендә үзен сиздерә:

*Шаулый диңгез...*
*Җил өрәдер...*
*Җилкәнен киргән караб!*
*...*
*Кайсы юллар,*
*Нинди упкын*
*Тарта безне җан сорап?*

Әсәрнең катлаулы, метафорага нигезләнгән теле урта гасырлар татар шагыйре Котбка барып тоташа.

Башка татар зыялылары (Г.Ибраһимов, Г.Камал, Г.Тукай) социаль-эстетик идеал эзләгәндә, милләт өчен тарихи юнәлешләр турында уйланганда шулай ук кораб образына мөрәҗәгать итәләр. Кешелек язмышы турында уйланганда бу образга Көнбатыш-Европа философы А.Шопенгауэр да мөрәҗәгать иткән. Д.нең «Кораб» шигыре шагыйрьнең милләт язмышы өчен борчылуын чагылдыра. Үзенең кискен драматизмы, образлар тыгызлыгы, яңа строфикасы, экспрессив хисчәнлеге б-н «Кораб» шигыре Д. иҗатында гына түгел, бөтен татар поэзиясендә күренекле урын алды. Гомумән, котылгысызлыктан чыгу юлларын шагыйрь кешенең рухи үлемсезлегендә һәм мәңгелек мәхәббәт хисендә күрә («Хәят»).

Әсәр.: Дәрдмәнд шигырьләре. К., 1929; Сайланма әсәрләр. К., 1959; Агарган кыл. Поседевшая струна. К., 1999.

Әд.: Халит Г. Концепция мира и истории в поэзии Дердменда // Портреты и проблемы. К., 1985; Саяпова А.М. Поэзия Дардменда и символизм. К., 1997; Гайнуллин М. Татар әдипләре. К., 1978; Хисамов Н.Ш. Дәрдемәнд // Казан утлары. 1989. № 12; Дәрдемәнд. К., 2003.

*Н.Ш.Хисамов.*

**ДӘҮЛӘТШИН** Камил Салихҗан улы (31.5.1935, Кызыл Армия, хәзерге Чистай р-ны Иске Роман а.), әдәбият белгече, филол. фән. канд. (1972). Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1970-72 елларда СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли, 1972 дән Башк. ун-тында (2003 тән проф.) укыта. Хәзмәтләре борынгы һәм урта гасырлар татар поэзиясе тарихына, Р.Фәйзуллин, Р.Харисов, Р.Мингалим, Ф.Яруллин иҗатларындагы дәвамчылык проблемасына, Башкорстан татар шагыйрьләре (М.Вафин, Р.Идиятуллин, М.Нәзиров, С.Рәхмәтуллин h.б.) әсәрләренең стилистик үзенчәлекләренә карый. Мәүла Колыйның поэтик мирасын текстологик һәм әдәбият белеме кануннарыннан чыгып өйрәнде. Югары уку йортлары өчен укыту программалары, укыту-методик әсбаплар авторы.

Хезм.: Туган як шигърияте: индивидуаль стиль һәм поэтик образлылык мәсьәләләре. Уфа. 2002; Борынгы татар әдәби мирасы. Мәүлә Колый хикмәтләре. Эстәрлетамак. 2002.

Әд.: Булатова Д. Бәллүр // Тулпар. 2004. № 4.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Айрат Арслановка 80 яшь

Айрат Гәрәй улы Арсланов 1928 елның 10 апрелендә Башкортстанның Бүздәк районы Ахун авылында туа.



Мәскәүнең театр сәнгате институтын тәмамлаганнан соң озак еллар буе Татарстан радиосында, аннары Татарстан телестудиясендә диктор булып эшли. 1962-63 елларда—Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында—артист.

Айрат Арсланов татар халкына барыннан да элек радио-телевидение, аннары инде эстрада артисты буларак, сәхнәләрдә Галиҗәнаб сүзне фәһемле итеп яңгырата белгән шәхес буларак билгеле. Ул сәнгатьтән, музыкадан, шигърияттән башка яши алмыйдыр, мөгаен. Сәхнә түренә чыгып Тукай, Җәлил, Туфан һәм бүгенге көн шагыйрьләре иҗатыннан үрнәкләр укый башладымы, залда гаҗәеп тынлык урнаша, сүзләр-интонациядән хасыйл булган могҗиза башлана. Халык йотлыгып тыңлый, шигърият моңнарына бирелә. Мәһабәт гәүдәле, чем-кара чәчле, төз басып торган бу шәхесне элек-электән Татарстаннан ерак җирләрдә дә яхшы беләләр. Тыныч, тыйнак, йөзеннән нур чәчеп торган кеше. Аны сәхнәдән һәрчакны “Афәрин!” дип, көчле алкышлар белән озатып калалар.

Ул үз гомерендә нинди генә бәйрәм кичәләрендә, концертларында чыгыш ясамагандыр. 26 апрель көнне без барыбыз да М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры мәйданына—сөекле шагыйребез Габдулла Тукай һәйкәле каршына җыйналабыз. Әлеге очрашуларда Айрат Арслановның чыгыш ясамый калган чагы, ай-һай, булды микән? Ул яңгыраткан шигъри юллар һәркемне фәлсәфи уйлануларга этәрә, яшәү кадерен белергә өйрәтә.

2007 елны Татарстан китап нәшриятында “Айрат Арсланов” дигән китап-альбом нәшер ителде. Анда хөрмәтле артистыбызга карата замандашларының истәлекләре, аның үзенең сүз сәнгате турындагы уйланулары, фоторәсемнәр урын алган.

А. Арсланов—Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Бөтенсоюз нәфис сүз осталары конкурсларында җиңүче.

Сүз—безнең рухи байлыгыбыз, милли мирасыбыз, гамьле яшәешебез. Галиҗәнаб сүзгә, аны миллионнар йөрәгенә җиткерүчеләргә алга таба да хәерле юл!

**Альфрет ӘБДРӘШИТОВ** эше.

## Равил Шәрәфигә 70 яшь

Аны барысы да яхшы беләләр...

Шулай да иң элек аның биографиясендәге кайбер сәхифәләрне күздән кичерү урынлы булыр.

Равил Шиһап улы Шәрәфиев (Равил Шәрәфи) 1938 елның 5 апрелендә Балык Бистәсе районынын Олы Солтан авылында дөньяга килә.

Мәскәүнең Щепкин исемендәге театр училищесын тәмамлаганнан соң 1961 елдан— Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты. Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәләт премиясе лауреаты.



*Равил Шәрәфиев Фәнис Яруллинның "Әнә килә автомобиль" драмасында Тимерҗан ролендә (уңда).*

Гаиләдә бер кыз, бер малай үстергәннәр. Кешеләрнең гадел, тәртипле, ихлас булуын хөрмәт итә. Хоббие, үзе әйткәнчә, "Хөббениса"сы—жиздән эшләнгән ишек тоткалары коллекциясен туплау. Музыкада кумирлары—Чайковский, Штраус, Сәйдәшев; әдәбиятта—Достоевский, Тукай, Такташ, сынлы сәнгатьтә—Делакруа, Тропинин, Зарипов.

Болары—коры, статистик мәгълүматлар.

Ә бит сәхнә артисты—барыннан да элек эш кешесе, образлар иҗат итүче. Равил Шәрәфи—беренче чиратта комик артист. Аның хакында "гримсыз артист" дигән сүзләрне дә еш ишетергә туры килә. Исемеданы үзенең персонажларына, бигрәк тә халыкчан рухлы Хужа Насретдин исеме белән тәңгәл тора диярлек.

"Шәрәфи! Гажәп бит, шушы исем татар халкында мөстәкыйль бер янгырашка ия. Артистлар күп, халык аларны төрле рәвештә ярата, ә менә Шәрәфинең популярлыгы беркемнекенә охшамаган. Халык сәхнәдәге Шәрәфине тормыштагыдан һич кенә дә аерырга теләми. Ул аны берьюлы (тоташтан) кабул итә..."

Театр белгече Дания Гыймранова артист амплуасындагы төп үзенчәлекләрнең берсен хаклы рәвештә әнә шулай бәяли.

"Юмор картаймаска ярдәм итә",—ди Р. Шәрәфи. Бу—яшәү халәтенең, күңелнең мәңге яшь калу сәләтенә ия булуы хакында әйтелгән сүзләр.

Шунысын да искәртик, аның белән аралашкан, аны якыннан белгән дуслары комик артист Равил Шәрәфинең тормышта житди, гамьле, фәлсәфи фикерле кеше икәнлеген әйтәләр.

Ул сәхнәдә дә, тормышта да үзенең абруен югалтмый. Замана үзгәрешләре аның холык-фигылен килеш-килбәтен бер дә үзгәртә алмас шикелле. Ул тамашачыны көлдерү өчен "уйнамый", ә бәлки геройларының асылына эчке бер әзерлек белән үтеп керә. Кыскасы, татар сәхнәсенең күркәм традицияләрен күркәм дәвам итүче артистыбызга юбилей мөнәсәбәте илә алга таба да күңел хөрлеге һәм иҗат уңышлары телибез.

**Рашат НИЗАМИ**

## Мөнир Мазуновның тууына 90 ел

Шагыйрь Мөнир Мазунов узган гасырның 60-80нче еллар шигъриятендә нәниләр өчен язылган күпсанлы шигырьләре һәм бигрәк тә җырлары белән таныла. Аның "Туган як" (Мансур Мозаффаров көе), "Әниемнең җылы кочагы" (Әнвәр Бакиров көе), "Югалтмагыз дуслыкны" (Җәүдәт Фәйзи көе), "Язгы хисләр" (Рөстәм Яхин көе) кебек җырлары халык арасында популярлык казанып, үзешчән һәм профессиональ башкаручылар репертуарыннан төшмичә, озак еллар җырланып килде.

*Кешене иленнән, йортыннан аерып*
*Йөрткән күп юллар бар, җирләр бар.*
*Хәтердән җуелып, йөрәктән уелып,*
*Онытылып калган күп җирләр бар.*
*Ә сине, ә сине, ә сине, туган як,*
*Бар микән сагынмый торган чак?!—*

Әлеге юллар хәзер дә яратып җырлана торган "Туган як" җырыннан.

Мөнир Хәсән улы Мазунов 1918 елның 1 апрелендә хәзерге Пенза өлкәсенең Лопатин районы, Иске Карлыган авылында туган. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1935-38 елларда Астрахань педагогия техникумында укый, аннары Ижевск шәһәрендә урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1939 елда армиягә алынып, сугыш елларында Ерак Көнчыгышта хезмәт итә.

1946 елда М. Мазунов Казанга килә һәм 1949 елга кадәр Татарстан радиокомитетында редактор булып эшли, бер үк вакытта читтән торып Казан педагогия институтында укый. 1949-53 елларда ул янадан хәрби хезмәттә: Польшада совет гаскәрләре төркеме өчен чыгарылучы газета редакциясендә эшли.

1953 елдан М. Мазунов янадан Татарстан радиокомитетында эшли башлый, аның җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелә, аннары Татарстан китап нәшриятында өлкән редактор, республика газета-журнал нәшриятында тәрҗемәче, 1967 елдан "Татарстан кооператоры" газетасының җаваплы редакторы. 1971 елдан алып М. Мазунов әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Аның беренче шигырьләре сугышка кадәрге елларда Астрахань һәм Ижевск шәһәрләрендә чыккан татарча газеталарда басыла. Бөек Ватан сугышы чорында фронт газеталарында, аннары Татарстан көндәлек матбугатында, альманах һәм күмәк җыентыкларда Мөнир Мазунов исеме еш күренә.

1948 елда "Елда унике ай" исемле беренче китабы дөнья күрә. Аннары— "Яшьлек җыры" (1954), "Йөрәк җырлый" (1958), "Энесенә ул апа" (1960), "Урал улы" (1962), "Ак күгәрченнәр" (1972), "Ихлас күңелдән" (1980), "Офыклар" (1988) h. б. китаплары басыла. Аларның күбесе балаларга багышланган. Соңрак ул ике дистә китап авторы, шигырьләренә йөздән артык җыр язылган. Шагыйрь иҗади көчен әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә сыный. Ул Дж. Родари, Н. Хикмәт, Н. Некрасов, А. Прокофьев, С. Маршак, П. Хузангай һәм башка язучыларның аерым әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

1982 елда М. Мазунов СССР Язучылар берлегенә кабул ителә.

Ул 1987 елда вафат булды.

Ак җилкән

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

## Рәйсә ЮСУПОВА

# ТЭТЧЕР МАҖАРАЛАРЫ

### Бүре эзләре

...Сентябрь азагының бу иртәсендә дә мин балконыбызга, гадәттәгечә, Тэтчерымның "егетләре"нә: юк шул, кайтып җитмәде бит әле, дип әйтергә чыктым. Һәм шундук балкон култыксасына тотындым: ярабби, берәү! Әйе, әйе, алты "егет"нең берсе—фәкать берсе генә килгән. "Тэтчерым... әллә инде..." дигән уй ток кебек бөтен тәнем буенча йөгерде. Нәкъ шул мизгелдә маэмаем "егете"нең ышаныч һәм өмет тулы күзләрен күреп алдым; һәр көндәгечә, койрыгын болгап, үземне сәламләвенә дә игътибар иттем. "Исән... исән!" дип үз-үземне тынычландыру өчен бу—җитеп ашты. Әйе, әйе, этләр сизә, тоя торган кавем бит; әгәр... әгәр "ул-бу" булган булса—ошбу дусты да килмәс иде дип фараз кылдым. Өстәвенә үзем өчен яңалык та ачтым: карасана, бу кавем "сөйләшеп-киңәшләшеп" яши икән лабаса, юкса бер үк көндә бишесенең берьюлы килмәвен ничек аңлап була, йә?!



Шушы мәлдә иңбашыма иремнең дә җылы кулы орынды:

—Менә күрдеңме инде, теге бишесенең түземе бер генә айга җитте. Ә бусы... Бусы маэмаебызны чын ярату белән ярата, димәк. Игътибар иттеңме, нәкъ теге кәттәләренең, "иң-иңнәре"нең моннан ары да көтәргә сабырлыклары җитмәгән бит, ә?!

Ошбу сүзләргә җавап эзләгәндәй, мин янә аска, маэмаебызның бердәнбер ышанычлы дустына текәлдем. Чыннан да, бу "егет"не теге мәһабәт коллилар, тәкәббер ризеншнауцерлар янәшәсендә "иң-иңе" дип әйтеп булмыйдыр, мөгаен: әнә, бер күзе өстен ак күбәләктәй гаҗәеп тап бизи, коңгырт мехлы гәүдәсе дә ала-коларак, ә муен каешында эт аулаучылардан саклану чарасы—адресы, нәселе язылган калае да бар... Кыскасы, замана стилягасы! Әмма миңа бик тә сөйкемле тоелды ул—Тэтчерыбызны ихлас яратучы, сагынучы, бернигә дә карамыйча көтә белүче акыллы җан.

Гадәттәгечә, аңа башымны чайкадым: юк, кайтмады бит әле, диюем иде инде бу. Маэмай да нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, борынын безгә таба суза төшеп, ике генә тапкыр башын селкеде. Һәм, борылып карый-карый, әкрен генә китеп барды.

— Аңламадыңмы, ни дип әйтте?—диде ирем.

*Дәвамы. Башы журналның 1 санында.*

— Борчылмагыз, кайта ул; һичшиксез кайтачак, диде. Ике көннәнме, ике айданмы, әллә инде ике елданмы—менә монысын төгәл генә аңлый алмадым.

Үз халәтен сиздермәскә тырышса да, күрәм, ирем дә борчыла.

— Таныш машинистыңа шалтырат әле бүген,—дип искәртте ул, заводына китешли дә.

Ярый әле эш урыным, хезмәттәшләрем бар. Менә бу юлы да эшкә күмелеп күпмедер вакыт онытылып тордым. Ашыгыч булганнарын тәмамлагач кына телефоныма ябыштым:

— Хәерле көн, Федор Андреевич! Тавышыгызны бик тә, бик тә ишетәсем килә. Шалтыратмавыгызга да сигезенче көн китте түгелме?! Яңалык юкмы, әллә әйтергә уңайсызы, мине куркыта торганымы?.. Бик борчылам. Бүген әле, җитмәсә, әллә нинди төшләр дә күрдем...

— О-о! Ул төшләрне телефон аша гына түгел, каршыма утырып сөйләргә теләмисезме?

— Телим, әлбәттә! Бик тә телим...

— Көтәм, алайса!..

Хезмәттәш кызларым дәррау купты; беләм, үзләренчә ярдәм итәселәре, мине "айнытасылары" килүдән инде бу:

— Ул төшләреңне безгә сөйләмәсәң дә, Тэтчер турында икәнен чамалыйбыз. Юк бит инде Тэтчер, юк! Урлауларына тулы бер ай үтте ләбаса; исән булса, әллә кайчан кайтыр иде инде,—диде берсе. Икенчесе эләктереп алды:

— Үле бит инде этең, үле! Юкка өметләнәсең...

— Рәхмәт, "юаттыгыз",—дия-дия, мин плащыма үрелдем.

...Машинистым мине:

— Төш вакыты бит; чәй йә кофе эчәргә теләмисезме?—дип каршы алды. Безнең арада булган гәпне кәгазьгә төшерсәң, менә болайрак килеп чыга:

— Юк, рәхмәт! Юл өстендәге кафеда чәйләп алдым инде. Ә менә сезне күрү... үзе үк хушландыра мине. Тавышыгызны гына ишетсәм дә күңелем тынычлана төшә. Әйбәт хәбәрләр дә әйтмисез инде югыйсә. Берсендә, үлепләр башым авыртканда, яңа гына эшли башлаган проводницагызның мәзмәемне күреп алып, вагоныннан төшереп калдыруын әйттегез. Ә мин шундук башым авыртуын оныттым. Икенче бер шалтыратуыгыз вакытында исә, ниндидер бер җәнҗалчының гауга чыгаруын өнәмичә, Тэтчерымның үзе үк вагонны ташлап чыгып китүен хәбәр итүегез булды—тешем сызлаудан туктады... Аның исән икәнлеген ишетү генә дә авыртуны тудыручы нервыларны тынычландыра, күрәсең.

— Ә бүген... Кай җирегез авырта инде бүген?

— Йөрәгем авырта,—Федор Андреевич.

— Төшләрегезне тыңлаудан башлыйк әле алайса...

— Тавык төшенә тары керә дигәндәй, минем ул төшләремнең бөтенесе дә Тэтчерым белән бәйле. Җитмәсә, кино кадрларыдай, төсле дә әле үзләре. Менә бүген күргәннәремнең берсе.

Ике кулына да зур-зур яшькелт сумкалар күтәргән күн костюмлы ханым кызу-кызу атлап урман янәшәсендәге авылына кереп килә, имеш. Сумкасын исни-исни үз артыннан теркелдәүче этенә ул: "Ач икәнеңне бик беләм дә бит, син ашардай ризыклар төптә үк шул, бераз гына түз инде, кайтып җитү белән бирермен", ди, имеш. Көтмәгәндә авылның бер тыкрыгыннан килеп чыккан малайлар төркеменең таяклар-ташлар белән эткә ябырылуын да күрми-абайламый, имеш.Ташлар яңгыры астында калган эт, билгеле инде, урманга таба элдертә... Чү! Ул бит... ул минем Тэтчерым түгелме соң, Ходаем?! Һәм мин аның артыннан йөгерәм дә йөгерәм, имеш...

...Тыным бетеп уяндым да, озак кына уйланып яттым. Янәдән йокыга китү белән төшемнең дәвамы, икенче эпизоды башланды.

Кычкырта-кычкырта поезд үтеп бара, имеш. Мин исә урман кырыенда, төрле-төрле чәчәкләр арасында, мәзмәем янында елап утырам. "Никләр генә син минем апам сүзенә ышандың, никләр ияреп киттең? Шул Ижауларга китмәгән булсаң, сине яшен сукмый иде бит", дия-дия үксим, имеш. Көз аенда мондый яшенле яңгыр яварга тиеш түгел бит инде, диеп табигатькә дә үпкәлим икән әле, янәсе.

Шул мәлдә, йә Ходa(!), маэмаем күзен ача да нәкъ кешечә, чып-чын татар телендә сөйләшә башлый: "Алай ук хәсрәтләнмә инде!—ди.—Апаң үзеңә бер-бер начарлык эшли күрмәсен диеп, Ижауларга ук китәсемне уйламыйча гына ярдем бит мин ул Әлфияләргә. Безнең тормыштан апаңның бик тә-бик тә көнләшүен син үзең сизми идең бит... Ә яшен... Ул мине түгел, мин яңгырдан ышыкланып утырган имәнне сукты. Аякларымның гәүдәмне тота алмавы—куркудан гына ул",—ди, имеш.

"Син—исән?!. Исән!!! Хәзер ветврачны алып киләм. Хәзер... хәзер... Әз генә түз! Зинһарлар, түз!"—диеп, күз яшьләремә буылып уянып киттем.

Күрәм, машинистымның йөзендә кызгану хисенең әсәре дә юк. Елмаеп утыра әле, җитмәсә.

— Ну, төшләрегез!.. Бүреләр турында да күрмәдегезме соң?—ди ул көлеп.

— Күрдем, күрдем. Тик... бу юлы да, Тэтчерым урланасы көнне дә күргән кебек, бүреләрнең үзләрен түгел, фәкать эзләрен генә... Аларны миңа үзем алып килгән ветврач күрсәтте. Шул эзләргә ишарәләп, маэмаегыз ышанычлы "гаиләгә" эләккән, диде. Мондый очракта бүреләрнең ярдәм итә алуы—бәхәссез. Курку тудыручы нервыларны бик тиз таба да һәм "бикләнгән" урыныннан ычкындыра да беләләр алар.Җәрәхәтле урыннарны да ялап дәвалыйлар, төкерекләре шифалы, диде. Этегез бүреләрнең күңеленә, дөресрәге, башлык күңеленә—чөнки аның "сүзе" генә закон көченә ия!—хуш килгәндер, мөгаен, үзләренә ияртканнәр бит әнә. Менә бусы этегезнең эзләре, ә болары—бүреләрнеке. Дүрт бүре җәмгысе; шуларның икесе, көчегегез кебек үк, бала гына әле, - шулай диде ветврач. Һәм... һәм зәп-зәңгәр күзләреннән нурлар чәчеп китеп тә барды.

...Төшемнең бу өлешен таң алдыннан гына күрдем, Федор Андреевич. Инде сезнең хөкемне көтәм.

— Хөкем, дисезме?!. Маэмаегыз белән сезнең арада телепатия бик көчле диюдән капа, нидер өстәрлек яңалыгым юк бугай шул.

— Телепатия?.. Моны мин үзем, мәсәлән, "арадашчы" биотоклар кебегрәк кабул итәм. Бераү турында уйлыйсың гына, ул кеше йә юлыңда очрый, йә телефоннан шалтырата. Ул да, димәк, сине уйлаган, һәм аның биотоклары "алхәбәр" җиткергән. Тэтчерымның исә кешеләрдәге уй-фикерләрне, ни-нәрсә теләүләрен тою, сизү сәләте чыннан да бик көчле. Ул хәтта ни буласын алдан белү сәләтенә дә ия.

Бермәлне шулай Пермьнән шалтыратып, безне туйга чакырдылар. Иремнең заводында комиссия эшли, шунлыктан юлга үземә генә чыгарга туры килә: абыем кызының туе бит—бармыйча һич ярамый... Юлга чыгар алдыннан, хәерле сәфәр теләп, бер-ике минут утырып алдык. Тэтчерыбыз исә тезләремә башын куйды да миңа текәлде. Йа Ходa, зинһар, барма, барма... дип, ялвара иде ул күзләр!.. Ирем шундук сикереп торды да: "Беркая да бармыйсың! Күрмисеңмени Тэтчерны—елый бит, елый..."—диеп билетымны ертып ук ыргытты.

Ә икенче көнне... Икенче көнне ирем—гомер булмаган хәл!—эшемә килде, һәм кулларымны учына алып: "Кичә... Казаннан Пермьгә очучы самолет шартлаган. Әгәр Тэтчерыбыз булмаса... әгәр ул булмаса..."—дия-дия, бик озак тынычлана алмады.

...Минем Тэтчерым менә шундый бит ул.

— Төшегезгә кергән теге имән дә, маэмай да, хәтта яшен дә - чып-чын! Сез теге чакта сөйләшкән проводница Мәрьям маэмайны Ижевскига барышлый нәкъ шунда—без һәрчак сокланып карап үтә торган ялгыз имән төбендә күргән, һәм кайтканда шул урында поездны туктату турында машинист белән дә сөйләшеп куйган. Ә инде кайтканда... Кайтканда исә яшен суккан ул имәннең күмергә әйләнгән кәүсәсен генә күргәннәр.

— Ә бүреләр?

— Болары да чынга охшый. "Москва—Омск" составының машинисты Можга урманын узганда бүреләр гаиләсен күргән.Монысына мин ышанмаган идем. Ник дигәндә, безнең як урманнарын байлар үз милек биләмәләре итеп бүлешергә тотынгач, экологик чистарту сылтавы белән бүреләрне кыру башланды. Исән калганнары Себер тайгаларына качып китте. Бүресез калган бу урманнар хәзер аяныч хәлдә: гектарлап-гектарлап юкка чыгалар, ямь-яшел гүзәллек урынында таштан сәүдә-уен пулатлары калка. Үзем уйнап үскән мари урманнары фаҗигасен

күреп, чәчләрем үрә торды... Минә сезнең төшегезне тыңлагач, теге машинист дөресен сөйләгән, үз урманнарын ташлап китәргә теләмәгән горур бүреләр дә булган икән дим.

— Ә ул ничегрәк сөйләгән иде соң Федор Андреевич?

—Аны мин менә болайрак күз алдына китерәм: поезд белән янәшә генә, куыша-куыша уйнаклап, өч бүре элдертә. Ә арттагы вагоннар яныннан тагын икесе чаба. Әнә шул икәүнең берсе, тач этка охшаган бәләкәйрәге вагонга сикерергә җилкенеп ыргыла-ыргыла чаба икән әле, җитмәсә. Моны абайлап алган машинист тизлекне киметә, ишекләрне ача. Тик... теге бәләкәч вагоннарны берәм-берәм үткәреп бетерә дә, кинәт борылып урманга таба элдертә. Бүреләр дә аның артыннан урманга юнәлә...

Этне чыннан да сезнең маэмай дип фаразласак, аның вагонга сикермәве аңлашыла. Поездның тәгәрмәчләре, вагоннарыннан, үзегез әйтмешли, Казаныбыз исе килми бит.

Җә, бу сөйләшү сезнең җанга ни дә булса өстәдеме?

— Өстәде, Федор Андреевич, өстәде. Мин төшемдә генә түгел, өнемдә дә Тэтчерымның исән-сау булуына ышандым. Ярый әле сез бар бу дөньяда...

## Медальон

...Тэтчерым әйтмешли, "һы!" Бигрәк көтмәгәндә-уйламаганда булды бит әле бу: Болгариядә ял итәргә юллама тәкъдим иттеләр.

Ирем исә башын гына чайкады.

— Тэтчерыбыз кайтышка ишегебез бикле булсынмы?! Мин өйдә калам; ә син дусларыңнан берәрсе белән бар, онытылып ял ит бераз,—диде.

...Һәм менә без, хезмәттәшем Роза Камалетдинова белән икәү, диңгез буена урнашкан Варна дигән халыкара ял йортында вакытны үткәрә алмыйча җәфа чигәбез. Коену, кызынулар сезоны үткән чөнки. Бүген әле, җитмәсә, ачы җилле вак яңгыр сибәли, ә диңгездә... дулкыннар белән шаяра-шаяра давыл уйный. Менә сиңа кояшлы диңгез буе!..

—Киенәсеңме, мин инде әзер; ашарга төшәбез,—дип искәртә Роза.

— Вакыт җиттемени? Чынлапмы?!

Кичке ашауны мин түземсезләнеп көтеп алам. Табынга һәркем алдына кыстыбый хәтле ит куела чөнки. Ә инде ул ит белән... әйе, әйе, ул ит белән мин дусларымны сыйлыйм.

Менә бу юлы да... кәгазь пакетыма ит һәм ботка салуымны күреп, Розаның төсе үзгәрде.

— Аша үзең! Нишләвең инде бу?! Салат белән генә ерак китә алмассың. Этләр туендыра-туендыра ачтан егыласың киләме әллә?—дип чын-чынлап шелтәләп маташа. Аннары, йомшара төшеп, ичмасам, җаның җылыныр иде бераз, тышта да, бүлмәдә дә салкын бит,—дип өсти.

—Дөрес әйтәсең: салкын шул! Урамда яшәүче маэмайларга - бигрәк тә! Дымлы һава, җире дә юеш әле, җитмәсә... Мин бу маэмайларны сыйлаган кебек кемдер берәү минем Тэтчерымны да ашатадыр бит инде.

— И романтик! Дөньяда бөтен кеше дә синең кебек дип уйлыйсыңмы?!.

Ә үзе бу кичтә нигәдер миңа ияреп итте.

Гадәттәгечә, дусларым: әти эт, әни эт һәм дә ике көчек (болары—ике ай ярым-өч айлыклардыр, мөгаен), күзләрен мөлдерәтеп, койрыкларын "җилфердәтеп", мине куаклык төбендә, чирәм өстендә каршы алдылар. Асфальт җәелгән сукмак яны бу. Ә асфальт астына гаилә башлыгы оя ясаган; җил-яңгыр үтмәле түгел, рәхмәт төшкере. Яшереп куйган җамаягымны шул оядан алып, ризык белән тутырам.

— Җә, табын әзер, рәхим итегез,—дигән булам.

Тик болар кымшанмыйлар да. Кыяфәтләрен генә күр: әти маэмай бер ярты метрга алгарак чыгып, уң якта утыра, уртада ике бала, сулда—әниләре. Гаилә башлыгының Розага текәлгән борынында да, миңа текәлгән күзләрендә дә бер үк сорау: "Кем бу?"

— Үз кеше,—дим.—Аның да сезне күрәсе килде.

Мин дүрт-биш адым арткарак китеп, җамаякка ымладым: "Ашагыз!"

Роза да минем янга чигенде. Шуннан соң гына әти маэмай алга узып ашый башлады.

— Ашап бетерә инде бу убыры. Ник дүрткә бүлмәдең ризыкны?—ди Роза.
— Борчылма,—дияем була, гаилә башлыгы борыны белән улына ишарәли: аша, янәсе.

Онытылып китмәсен дигәндәй, үзе дә урынында, җамаяк янында сакта кала. Башын күтәрмичә ашаучы ошбу бәләкәч колагына бераздан борынын тигезеп ала, һәм шундук үз чиратын көтеп тыныч кына утыра биргән әниләренә ымлый. Әниләре туйгач кына кызына "эндәшә".

— Күрдеңме этләр гаиләсендәге тәртипне?—дим Розага.—Ә бит безнең дә бабайларыбыз заманында тәртип шундыйрак булган: табында итне, бәлешне өлешләргә фәкать гаилә башлыгы —ир кеше генә бүлгән; һәм ул ашый башламыйча беркем дә ризыкка үрелмәгән. Хәер, әнкәйләребез безне дә: "Әтиегез кайткач ашарбыз" дия-дия тәрбияләделәр түгелмени?!. Хәзер генә ул... ир-атның абруе, кадере калмады...

Биредәге соңгы көнемне мин маэмай дусларыма багышларга булдым. Иртүк торып җылырак киендем дә алар янына ашыктым.

Тик... ояларында да,бакчада да,диңгез буенда да күренми бит әле үзләре.

Тирә-юньне күзләвемне күреп, яныма бакчачы агай килде:

— Мадам!.. Собак ищет? Сез Руссия? О-о, мин күрдем... күреп тордым: мадам собак любит. 20 день ашаттыгыз собак. Молодец какой! У вас тоже есть?—диде ул гаҗәеп бер акцент белән.

Казаннан булуымны, татар икәнлегемне, үземнең дә этем барлыгын әйтеп, мин танышырга кулымны суздым. Һәм аннары:

— Маэмайларны күрмәдегезме? Алар белән бүген соңгы тапкыр диңгез буйларын урамакчы идем,—дидем.

— О-о!—Ул сәгатенә күрсәтте: иртә бит әле, янәсе.—Собак дома спият.

— Юк бит монда,юк.—Мин дусларымның оя-куышларына ишарәләдем.

— Нет-нет, кипометр два дома,—ди агаем, һәм шундук йөзе яктырып китә: —Күрәсезме, чабыша-чабыша киләләр, әнә...

Аягыма борыннарын төртеп, дусларымның берәм-берәм сәламләүләре, күрәм, бакчачының да күңеленә хуш килгән. Ул гаилә башлыгының муенына ымлый:

— Медальон! Күрдегезме, укыдыгызмы?

Мин укымаганлыгымны белдереп башымны селким. Ул исә чүгә төшеп, медальонны әйләндереп, аның аскы ягындагы язуны күрсәтә. Инглизчәм чамалы булса да, "Сеттер нәселеннән, 5 яшьтә" дигән сүзләрне укый алдым, шөкер.

Агаем медальонны ачып, аның эченнән әллә ничәгә бөкләнгән бер кәгазьне ала. Һәм... һәм ничектер таныш бер аһәң белән кычкырып укый да, урынына салып, медальонны чертләтеп ябып та куя.

— Аңламадыгыз инде, билгеле. Тәрҗемәсе менә болайрак: "Маэмайларыбызны рәнҗетмәвегезне үтенәбез. Ризыкларыннан өлеш чыгара апучыларга чиксез рәхмәтлебез. Балевскийлар гаиләсе".

Тән күзәнәкләремнең чымырдап куюын тойдым. Хуҗалы, "өйле" этләрмени?! Ә язу... Ул ни аңлата алайса?

Ошбу уйларыма бакчачы җавабын ишетәм:

— Инженер Балевский эшләгән предприятие ябылды. Ә укытучы хатынының 4-5 ай инде эш хакы ала алганы юк.

— Нигә маэмайларын сатмыйлар? Бик затлы нәселдән бит алар.

— Балаларыгыз бармы?—ди агай, минем бу соравыма бик тә сәерсенеп.— Сез аларны сата алыр идегезме?!.—Җавап ишетмәгәч, янә өсти:—Менә иртәгәдән, сез китү белән, мин дә эшсез калам.Бу ял йортын да аукционга чыгарачаклар.

...Өйдәге хәлне күршеңнән сора дигәндәй, мин Тэтчерымның урамга чыгарылган дусларын—муеннарына затлы каеш тагылган интеллигент кыяфәтле маэмайларны һәм аларның хуҗаларын—өчәр-дүртәр ай хезмәт хакы алмаучы врачларны, укытучыларны, фән эшлеклеләрен күз алдыма китердем. Эре-эре заводларыбызның эшләүдән туктавын, меңнәрчә, дистә меңнәрчә инженерлар, эшчеләрнең урамга ыргытылуын уйлап алдым.

1991 ел октябренең азагы иде бу...

*Дәвамы киләсе саннарда.*



# Эльзира Габделкаюмова

## СӨЮДӘ БЕЗ—ТИГЕЗ

***

**Мин сагындым сине!
Җанымның һәр күзәнәге
Наз-сулышың тели тоярга.**

**Мин бит көтәм сине!
Күк күзләрең күлләрендә
Күптән йөзәм мин моңнарда.**

**Мин юксынам сине!
Җанның—
Татлы иреннәрең иркендә
Балдай эрисе килә.**

**Мин яратам сине!
Чиксез өмет дәрьясында
Йөзәмен әлегә.**

**Бәлки, мин бер кораб мәңгелектә—
Сөюдә?!**

***

**Күзләремә кара!
Күрәсеңме? Упкын...
Дөрләп ялкын яна...
Ник өстәргә утын?**

**Күңелемә күз сал!
Күрәсеңме? Диңгез...
Шунда кереп чумып
Чыгалсаң син... кер, йөз!**

**Хисләремә тимә:
Алар янартаулар...—
Сөю-утлар атып
Сине яндырсалар?!**

**Синең күздә дәме—упкын?
Күңелеңдә—диңгез?
Хисең—янартаумы?
Мәхәббәтең, димәк,
Минекенә—игез.**

**Сөюдә без—тигез!**

Эльзира ГАБДЕЛКАЮМОВА—*Казан дәүләт университетының татар әдәбияты бүлеге студенты. Көндәлек матбугатта күренеп килә.*

## Илшат Сәйфуллин

# ШАЯН ХИКӘЯЛӘР

### «Батырлык өчен» медале

Озак уйлана торгач, Рафис, нинди дә булса батырлык эшләргә кирәк дигән нәтиҗәгә килде. Их, батырлык эшлисе иде дә, «Батырлык өчен» дигән медальне тагып авылны бер әйләнәсе иде! Олысы-кечесе исе китеп: «Рафис батыр үтеп бара»,—дип калыр иде. Ә классташы Зөлфия, Рафиска карашын төптән үзгәртеп, бердәнбер көнне урамга йөгереп чыгар иде дә, медаль тагып үтеп баручы Рафиска чиккән кульяулык биреп, оялуын яшерә алмыйча, кызарынып, өенә кереп югалыр иде. Зөлфия, юкка гына Рафистан көлеп йөрисең син, үкенерсең әле менә!

Ләкин «Батырлык өчен» дигән медальне алу алай җиңел түгел икән шул. Күпме генә уйласа да, нинди батырлык эшләргә кирәк икәнлеген төшенә алмады Рафис. Аптырагач, җиденче класска җитеп, беренче тапкыр үз теләге белән китап укырга булды. Бәлки, анда батырлык эшләү серләре язылгандыр. Таушалып беткән «Герой пионерлар» дигән китапны кулына алып, йотлыгып укырга кереште ул. Тә-ә-к... Павлик Морозов дигән малай ашлык яшергән әтисен силсәвиткә әләкләгән. Рафис, куанып, әтисе ындыр табагыннан чәлдергән бер капчык арышка күз сирпеп алды. Ләкин әтисенең ике метрлы буен һәм бер потлы гер чамасы йодрыгын искә төшергәч, башына килә башлаган уйдан бик тиз кире кайтты. Т-ә-ә-к, тагын бер герой немесләр утырган поездны Днепр елгасына озаткан. «Жәлке, безнең поездларда немесләр йөрми»,—дип тимер юл ягына карап уфтанып куйды Рафис.

Кәефе төшкән малай икенче китапны кулына алды. Менә болары заманчарак батырлыклар эшләгән. Берсе янгыннан нәни кызны күтәреп алып чыккан, икенчесе суга батучыны коткарган.

Рафис, көне буе авылны әйләнеп йөргәннән соң, су буена килеп утырды. Көннең көн буена авылда бер генә янгын да булмады. Елгада да бала-чага кырыйда гына мәш килә. Хет берсе ярдәм сорасын. Шуна да Рафисның медальдән өмете тәмам өзелде.

Байтак кына утыра торгач, Зөлфиянең чиләк-көянтә күтәреп чишмә буеннан кайтып килүен күреп алды ул. Елга аркылы салынган басмадан үтеп баручы классташына сокланып карап торганда, малайның башында секунд эчендә менә дигән план туды. Иртәгә Зөлфия тагын суга төшәчәк! Әгәр дә басманың ике-өч тактасын урталай сындырып, җинелчә генә беркетеп куйсаң, батырлык эшләргә менә дигән җай чыгачак. Бернечә көннән Рафисны телевизордан күрсәтәчәкләр, аның түшенә медаль таккан рәсеме газета-журнал битләрендә балкып торачак. Журналистлар Рафистан: «Сез ничек тормышыгызны куркыныч астына куеп, иптәшегезне коткарырга булдыгыз?»—дип сораячаклар. Ә ул аларга, китапта язылганча: «Минем урында һәркем шулай эшләр иде»,—дип җавап бирәчәк.

Икенче көнне Рафис кичтән планлаштырылган «басма төзәтү» эшләрен

эшләп куйды да, Зөлфияләр ягыннан килә торган сукмакны караштыргалап, куаклар тирәсендә таптанды. Классташы озак көттермәде. Малай аны күргә эчтән генә үзен батырлык эшләргә әзерли башлады. Ләкин шул вакытта икенче яктан Рафисның дусты Илһам да күренде. Ул кулларын болгый-болгый:

—Рафи-и-с! Рафис дим! Әтиең Казаннан сәпит алып кайткан! Кызыл төстә!—дип кычкыра иде.

Малай дөньясын онытып өенә йөгерде. Елга аркылы салынган басмадан чапканда аның аягы астында җир убылып киткәндәй булды. Басмадан түбән очканда гына ул үз тозагына үзе эләккәнен төшенде. Суга төшкәч, каушаудан, йөзү хәрәкәтләрен дә онытты...

Күзләрен ачып җибәрсә, яр буенда, чирәм өстендә ята, Зөлфия исә аның өстенә менеп атланган да, әле Рафисның йөрәк турысына баскалый, әле аны уңлы-сулы яңаклый иде. Авыртуга түзә алмаган малай сикереп торды да, бөтен ачуын бергә туплап:

—Нигә сугасың?! Минем аркада хәзер медаль алачаксың бит!—дип Зөлфиягә дә, Илһамга да үпкәләп, өенә кайтып китте.

## Килешү

Кара Чыпчык мәктәбе директоры Наил Галиевич кабинеты буйлап арлы-бирле йөренде. Тиздән аның бүлмәсенә Гыйниятуллин үзе киләчәк! Җиңел генә бирелми шул мондый эшләр. Аны мәктәпкә китертү өчен директорга бөтен педагогик талантын, психология өлкәсендәге белемнәрен һәм тәмле телен эшкә җигәргә туры килде. Һәм менә, озакка сузылган сөйләшүләрдән соң, Гыйниятуллин мәктәпкә киләчәген белдерде. Наил Галиевичнең бөтен ышанычы шушы очрашуда. Чөнки бу көннәрдә мәктәптә мәгариф бүлегеннән килгән комиссия эшли. Ә Гыйниятуллиннан күп нәрсә тора. Әгәр дә Наил Галиевич аны җайлый алса, район мәгариф бүлегеннән генәме, министрлыктан килгән комиссияләр дә куркыныч түгел, барысы да ал да гөл булачак.

Директор зур портфеленнән әфлисун, мандарин, банан, ананас һәм башка тәм-томнар чыгарып өстәлгә тезә башлады. Шулчак ишек каккан тавыш ишетелде, кабинет ишегендә җиденче «А»дан Миләүшәнең башы күренде:

—Наил Галиевич, мин Гыйниятуллиннан. Ул сезгә очрашуның ярты сәгатькә кичектереләчәген хәбәр итеп, гафу үтенде. Көтәрсез бит?

Көтмиме соң! Ярты сәгать түгел, ярты тәүлек көтәргә дә риза, очрашу гына нәтиҗәле узсын.

Нәкъ ярты сәгатьтән бүлмәгә Гыйниятуллин килеп керде. Өстәлдәге тәм-томнарга борылып та карамады ул.

—Сез мине нигәдер күрергә теләгәнсез бугай,—диде Гыйниятуллин йомшак кәнәфигә утырып, бер аягын икенчесе өстенә ыргыткач.

—Беләсезме, кем...—дип тотлыга калды директор.

—Рамил Фәритович!

—Әйе, гафу итегез, онытып торам, Рамил Фәритович... Ишеткәнсездер инде, мәктәбебездә комиссия эшли. Ә мондагы хәлләрне сезгә сөйләп торасы юк: бишенчеләр Сания Гатаулловнаны санга сукмый. Алтынчының кызлары ашханәдә борчак боткасын ашаудан баш тарталар, имештер, калориясе күп, фигураны боза. Җиденчеләр дәресләргә салкын карый, сигезенчедән бер төркем малай мәктәп ишегалдында ук тәмәке тарта. Ә сигезнең кызларына тугызынчы класс малайлары көн күрсәтми—гел чинаталар шуларны. Өлкәнрәк классларны сөйләп тә тормыйм... Рамил Фәритович, туктатырга иде бит бу мәхшәрне, вакытлыча гына булса да... Тикшерү бара бит!—директор чүт кенә елап җибәрмәде.

Ун ел мәктәп юлларын таптап, быел, ниһаять, жиденче класска житкән Гыйниятуллин мыегын сыпырып куйды да, хәйләкәр елмайды:

—Сез, Наил Галиевич, бик күп нәрсә сорыйсыз. Менә без—укучыларның да сезгә сораулары, теләкләре бар. Безнең таләпләр үтәлгән очракта гына без сезгә булышачакбыз.

—Нинди таләпләр ул?

—Беренчедән, ашханә мәсьәләсе: коймакны нигәдер тәлинкәгә өчне генә салалар, без шул ук бәягә кимендә бишне таләп итәбез. Вак бәлеш мәктәп ашханәсендә 5 сум тора, ә күрше йортта урнашкан ашханәдә нигәдер 4 сум 50 тиен генә. Укучылар 50 тиен экономия өчен тәнәфестә кышкы суыкларда да шунда чабалар. Салкын тидереп дәрес калдыралар, нәтиҗәдә уку-укыту процессына зур зыян килә. Шуннан чыгып, без вак бәлешнең бәясен 4 сумга кадәр төшерүне сорыйбыз. Аннары, белгәнегезчә, мин мәктәпкә күрше авылдан килеп унышлы гына укып йөрим... Нәни авылдашларым мәктәп интернатында яши һәм кичләрен житмеш дүртенче елгы «Рекорд» телевизорын карап утырырга мәжбүрләр. XXI гасырда нәни балаларга аклы-каралы телевизор каратырга ничек оят түгел сезгә?!—дип, Рамил директорның күзенә туры карады.

Гыйниятуллинның усал карашыннан тегесе егылып китә язды:

—Ярый, бу проблемаларны иртәгә үк хәл итәрбез,—дигән сүзләрен дә, мангай тирен сөртеп, көч-хәл белән әйтә алды.

—Яхшы. Мин дә куйган мәсьәләләрне бүген үк хәл итә башлармын!—дип, Рамил зур гына алманың яртысын «шарт» итеп кабып алды.—Килешүне берәр нәрсә белән ныгытып куймыйбызмы?—дип директорга күз кысты. Директорның йөзе яктырып, яшәреп китте. Шкафларның берсен тиз генә ачып җибәрде:

—Була ул, Рамил Фәритович! Кызылнымы, акнымы?

—Ә сарысы беттемени!

—Сез дигәндә сарысын да табабыз,—дип, директор зур канәгатьлек белән өстәлдәге бокалларны тутырып салды.

Килешүне шулай «фанта» белән беркетеп куйгач, бүлмәдә янадан Миләүшә пәйда булды. Аны күрүгә, классташы үз башына үзе сугып:

—Ә-ә-ә, онытып та җибәргәнмен,—диде.—Наил Галиевич, тагын бер мәсьәлә бар икән. Миләүшә—классташым, эшләремдә ярдәмчем. Ә Фәния Әскәровна аналитик, синтетик җөмләләре белән аның акыллы башын катыра. Берәр төрле хәл кыласы иде бит?

Директор бераз ияген ышкып торгач:

—Нәрсә дә булса уйлап табарбыз,—диярга мәжбүр булды. Миләүшә, моны ишетүгә, Гыйниятуллинның битеннән үбеп алды да, алар кулга-кул тотынышып директор бүлмәсеннән чыгып киттеләр.

Озак кына уйланып торды Наил Галиевич. Аннары тәрәзә янына килеп мәктәп ишегалдына күз салды. Гаҗәп, анда бер генә малай актыгы да тәмәке көйрәтеп йөрми иде. Димәк, Гыйниятуллин эшкә керешкән. Директор да, телефонны алып, укучыларның таләпләрен үтәү өчен тиешле күрсәтмәләр бирә башлады.

# *Хат*

## Тормышка ышанычың сүрелмәсен

***(Фәниягә. № 1, "Аптыраган әле монда".)***

Фәния, "кызым" дип дәшәм, язам инде, хатыңны кайчан язгансыңдыр, язгы депрессия генә түгелме?

Синең кебек уйланучы, "җилкәннәр"не укучы кызлар сирәк бит хәзер. Ашыгып, дөнья пычрагына гына бата күрмә, аннан җилкәннәр белән генә чыгып булмый. Бәлки, карабы, җилкәннәре булмаса да, мәхәббәтеңне очратырсың? Мәхәббәт юк диләр, мин һәрвакыт бар дидем, ул бик зур, көчле хикмәт. Мине авыру диделәр, диләр, әлбәттә.

Йолдызнамәләргә ышанмаска кушсалар да, азрак булса да укыштырып, уйланып кара әле. Синең тормышың алда, ышанычың сүнмәсен.

Мин 50дә, ышанычым бик әкрен яна, сүнәргә азаплана. Безне 18 яшь тулмыйча эшкә алмыйлар иде. Теләсәң, теләмәсәң, училище, аннан матур, чая дип "урын"га тәкъдим иттеләр. Горур идем. Коммунистлык мәҗбүри иде әле "урыннарда". Коммунист чиста һәм намуслы булырга тиеш дип чатнатып әйтеп, эш урыннарымнан киттем. Ә "әйбәт" кызлар путевкалар белән чит илләрдә йөрделәр. Квартирасыз да калдым.

Нервыларым иртә какшады. Яраткан кешем Чечняда вафат булды. 23 ел исән дип көттем, тормышка чыгып, балалар үстерсәм дә "парлы ялгыз" булып яшәдем.

Сиңа тормышта җиңел булмас, кызым. Шулай да уңышлар, мәхәббәт телим сиңа! Бездә медицина училищесы бар. Бәлки, килерсең, укырсың. Бай яшәмибез, тик күңелем киң, торак өчен түләмәссең.

Татар телен хөрмәт итәм, татарча гына сөйләшәбез, милли хәрәкәт оешмасы якын гына.

Балалар аерым тора.

Миндә дә шул хәл, бик яхшы танышым милли хәрәкәткә йөри. Тик анда хатын-кызлар юк. Намаз укуга ныграк тартылалар. Туганнарым, акчасыз син кеше түгел, диләр. Сине бәреп үтерәләр бит, диләр.

Бурычка кулым белән бирәм, аягым белән йөрим ала алмыйча "дусларымнан". Башка кызлар ничек яши икән, дигәнсең. Бай егетләр күзли алар. Үз кызым да шулай итте. Тик мин мәхәббәткә әле дә ышанам.

Бер генә мисал. Мәккәгә кемнәр бара? Үзе эшләмәгән "бизнес" акчасына баралар. Дингә кагыласым, нахак сүз әйтәсем килми, тик бик күп "дини" кешеләрне беләм. Имеш, "ураза тотучыларны" да. Менә боларны уйлап, күзәтеп кара әле.

Хатны язып бетергәч кенә уйлап куйдым, син минем елда тугансың. Аең да минеке микән әллә?

Ашыкма, уйлан, мин ашыктым, шулай да күңелем чиста, оятсыз кешеләр күбрәк. Иң пычрак кызлар дөньяның артына тибеп, дөньясына төкереп, кеше җилкәсендә яшиләр. Тик ул пычрак рәхәткә ашкынма, уйланырга вакытың бар әле. Романнар түгел, шигырьләр укы, алар дөресрәк.

Кабат сиңа уңышлар телим. Якты өметләрең сүнмәсен.

**Әлфирә апаң.**
**Түбән Кама шәһәре.**

***«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:***
***420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».***

## Марс Хафизов

Хафизов Марс Хәмәтюныс улы 1949 елның 17 нче сентябрендә Татарстан Республикасы Тукай районының Биклән авылында туа. Мәктәпне көмеш медаль белән тәмамлагач, шул мәктәптә һәм Чаллы шәһәрендә бер ел чамасы эшләп ала. 1968 елда Казан медицина институтына укырга керә, аны 1974 елда тәмамлый, шул ук елны Түбән Кама шәһәренең Үзәк хастаханәсенә хатын-кыз авыруларын дәвалаучы табиб булып эшкә урнаша. Соңрак Шин заводы поликлиникасында, 1 нче бала табу йортында хезмәт итә. 1990—2005 елларда 2 нче шәһәр хастаханәсенең баш табибе, 2005 елдан Түбән Кама шәһәре наркология диспансерының баш табибы. Хезмәтләре өчен югары квалификацияле хатын-кызлар авыруы дәвалаучы табиб һәм югары квалификацияле медицина оештыручы табиб исемнәренә лаек булды. 1993 елны М. Хафизовка "Татарстан Республикасының атказанган табибы" исеме бирелде. 1990—1995 елларда Татарстан Республикасы Югары Советы депутаты булды.



Марс Хафизов мәктәптә укыган елларда ук яза башлый, кайбер шигырьләре район газетасы битләрендә басыла. Ул шулай ук Чаллыда, шул елларда уңышлы эшләп килгән иҗат яшьләренең "Лира" клубы эшендә дә актив катнаша. "Иң беренче шигырем "Табибларга мәхәббәт" исемле булды" дип язды ул соңрак. Шигърият өлкәсендә житди һәм даими эшләве 90 нчы еллар башына туры килә. 1997 елда М. Хафизовның "Яраларны юа мәхәббәт" дигән беренче китабы дөнья күрде. Соңгы елларда жирле басмаханәләрдә аның "Мин ярата беләм", "Гомерне яңадан башласам...", "Бер елмаюың житә", "Гомерлеккә сайлаган" исемле шигырь китаплары чыкты.

М. Хафизов—лирик шагыйрь. Төп темасы да, асылда, мәхәббәт, тугрылык, балалар язмышы... Шигырьләре традицион калыпта, халыкчан тел белән язылганнар. Шуна күрә дә, аның күп кенә шигырьләренә төрле композиторлар көйләр язган (Луиза Батыр-Болгари, Илһам Байтирәк, Зөфәр Хәйретдинов, Альфред Якшимбетов һ. б.). Алар популяр жырчылар Салават Фәтхетдинов, Илдар Галимов, Алсу Әбелханова һ. б. тарафыннан башкарылып тыңлаучыларга яхшы ук билгеле.

2008 елның январенда М. Хафизов Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.

## Гөлзадә Бәйрәмова

Гөлзадә Әүхәди кызы Бәйрәмова 1963 елның 26 февралендә Татарстан республикасының Саба районы Сабай авылында дөньяга килә. Туган авылында



башлангыч белем алгач, укуын Олы Шынар урта мәктәбендә дәвам итә һәм 1980 елда уңышлы тәмамлый.1980—1985 елларда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый. Шигырьләре, кыска-кыска язмалары белән мәктәптә укыганда ук район һәм республика матбугатында күренә башлый.

Хезмәт юлын 1987—1989 елларда Милли китапханәдән башлый, 1989 елдан бүгенгәчә «Казан утлары» журналы редакциясендә эшли. Шигырьләре, әдәбият-сәнгатькә караган мәкаләләре «Казан утлары», «Идел», «Сөембикә» журналларында, көндәлек матбугатта даими басылып килә. Төрле елларда шагыйрьләр Н. Акмал, Ф. Сафин, С. Сөләйманова, Ф. Тарханова, Ф. Мөслимова, язучы Г. Галиева, драма артисты И. Әхмәтҗанов, җырчы Н. Нигъмәтуллин һәм башкалар иҗаты турындагы әдәби язмалары, рецензияләре республика матбугатында чыктылар.

2006 елда Г. Бәйрәмованың «Идел-Пресс» нәшриятында «Әле кайчан гына...» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Танылган әдәбият әһелләре уңай бәя бирделәр.

Аның иҗатына тирән фикерләү, образлы сурәтләү хас. “Шагыйрәнең шигырьләрендә тормыш тәҗрибәсенә тупланган гамьле дә, моңлы да булган хакыйкать ята. Мәхәббәт лирикасында хис-кичерешләр гаммасы шактый бай. Анда төс-кичерешләрнең бер-берсенә салмак кына кушылып китүен дә, аҗаган уйнаклавы шикелле ярсу балкышлар чагылышын да табигый бердәйлектә күзәтергә мөмкин. Сөю-ярату шигырьләрендәге бизәк-сурәтләр җете булулары белән аерылып торалар”—дип яза китапка кереш сүзендә күренекле шагыйрь Зиннур Мансуров. Г. Бәйрәмова проза өлкәсендә дә каләмен сынап карый. Матбугатта хикәяләре соңгы вакытта еш күренә.

Әдәбият-сәнгать кешеләре турындагы язмаларын һәм хикәяләрен туплаган икенче китабы әзерләнә.

2008 елның январь аенда, кабул итү коллегиясе карары нигезендә, Татарстан Язучыларының идарә утырышында Бәйрәмова Гөлзадә Әүхәди кызы Татарстан Язучылар берлегенә (тәкъдимнамә бирүчеләр—Зиннур Мансуров, Рәдиф Гаташ, Рашат Низамиев) кабул ителде.



*Казан үзәгендә (Татар Дәүләт гуманитар-педагогика университеты янында) композитор Салих Сәйдәшевкә һәйкәл ачылу тантанасында чыгыш ясаучылар—алгы планда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, сулдан уңга: галим Җәмил Нигъмәтов, шагыйрь Равил Фәйзуллин, җырчылар Илһам Шакиров, Азат Аббасов, август, 2005 ел.*



*Гармун ясау остасы Дмитрий Вараксин (сулда) һәм журналист Рәуф Хөснетдинов. 1943 ел.*



*Татар филологиясе үсешенә зур өлеш керткән галим Латыйф Җәләй (1894–1966).*



*Язучы-тәрҗемәче, журналист Абдулла Гомәр (1906–74). 1959–63 елларда "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналының баш мөхәррире.*



*Тукай кабере янында. Апрель, 1986 ел.*



# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ЭШЛЕКЛЕ СӘФӘР

Татарстан президенты Минтимер Шәймиев Согуд Гарәбстанының Эр-Рияд шәһәрендә эшлекле сәфәрдә булып кайтты. Бирегә аны Король Фейсал исемендәге исламны өйрәнү үзәгендә чыгыш ясау һәм Король Фейсал исемендәге халыкара премия лауреатларын бүләкләү тантанасында катнашу өчен чакырдылар. Бер ел элек Россия Президенты В. Путинның Согуд Гарәбстанына сәфәре вакытында М. Шәймиевкә «Исламга хезмәт итүе өчен» номинациясендә Фейсал премиясе тапшырылган иде.

Быел исә премия тапшырыла башлауга 30 ел була. Утыз ел эчендә барлыгы 176 кеше әлеге мәртәбәле бүләккә лаек булган. Юбилей тантанасы вакытында Илбашы Татарстан турында чыгыш ясады. Шулай ук эшлекле очрашулар да үтте. Президент М. Шәймиев Эр-Рияд провинциясе губернаторы принц Салман ибн Абдул-Азиз Эл-Сауд белән очрашты .

Очрашуда ТР Президентының халыкара мәсьәләләр буенча Дәүләт киңәшчесе—ТР Президентының тышкы эшләр департаменты җитәкчесе Тимур Акулов, Россия Федерациясенең Согуд Гарәбстанындагы Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Виктор Кудрявцев, Король Фейсал исемендәге хәйрия фонды тулы вәкаләтле вәкиле Авад Эл-Бади, Король Фейсал исемендәге премия лауреатлары катнашты.

## КАЗАН—КИЛӘЧӘК ШӘҺӘРЕ

Франциянең Канн шәһәрендә Европа күләмендә «MIPIM-2008» иң зур күчемсез милек күргәзмәсендә Казан «киләчәк шәһәре»н күрсәткән. Экспертлар, кунаклар һәм архитекторлар республика стендын әнә шулай дип бәяләгән.

Татарстан башкаласы стендын ачуда РФ төбәкләрне үстерү министры Дмитрий Козак һәм РФ икътисадый үсеш һәм сәүдә министры Эльвира Нәбиуллина катнашкан.

Казан мэры Илсур Метшин кунакларны иң элек халыкара архитекторлар катнашындагы танылган, шулай ук инде тормышка ашырылып килүче проектлар белән таныштырган. Казанның «MIPIM-2008»дә инде өченче тапкыр катнашуы икән. Бирелә ул зур 15 инвестиция проектын күрсәткән.

«Миллениум Зилант-Сити» компаниясенең Казансу елгасының уң як яры буендагы төзелеш проекты белән таныштырып, Татарстан башкаласы мэры елганың сул як ярында шәһәрнең тарихи өлеше каласын, унында XXI гасыр Казаны пәйда буласын ассызыклаган.

Дмитрий Козак Казан зооботаника бакчасын төзү проектын югары бәяләгән. Проект нигезендә «тышкы кыяфәте» белән чикерткәне хәтерләтүче зоопарк территориясендә күп катлы мәдәни-күңел ачу үзәге урнаштырылачак.

Дөньяга атаклы архитектор Эрик ван Эгераат (Голландия) исә Милли китапханә проектын тәкъдим иткән.

## ДӘҺЛИ—КАЗАН АРАСЫ

12 февральдә Һиндстанның Дәһли шәһәремдә Сәүдә һәм инвестицияләр буенча II Россия-Һиндстан форумы ачылды. Анда Россия делегациясе составына ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, ТР сәнәгать һәм сәүдә министры Александр Когогин, «КамАЗ» ААҖ, «Татэнерго» ААҖ җитәкчеләре дә катнашты. Очрашуда ТР Мәдәният министрлыгы һәм Андхра-Прадеш штатының Спорт, мәдәният һәм кинематография министрлыгы арасында мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында фикер алышынды.

## УНИВЕРСИАДА БЕЗДӘ УЗАРМЫ?

2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасы Казанда узарга мөмкин. Брюссельдә Халыкара студентлар спорты федерациясе бинасында башкаланың дәгъва кылу исемлеге тәкъдим ителгәннән соң, Казан рәсми рәвештә кандидат буларак теркәлде. Моннан тыш, кандидатлар исемлегендә Корея, Польшаның—берәр, Канада һәм Испаниянең икешәр шәһәре теркәлгән инде. Универсиаданың башкаласы 31 майда узачак тавыш бирү нәтиҗәсендә билгеле булачак.

## ҖӘЛИЛ РУХЫН ЯД ИТҮ

Инде күп еллар дәвамында 15 февраль халкыбызның каһарман улы Муса Җәлилне искә алу көне буларак билгеләп үтелә. Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов җитәкчелегендә бер төркем каләм әһелләре шагыйрьнең 1 Май мәйданындагы һәйкәленә һәм җәлилчеләр барельефына быел да чәчәкләр салды.

Шул ук көнне Татарстан Милли музеенда Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»н кин җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү тантанасы булды. Биредә шагыйрьгә, аның иҗатташ дусларына һәм көрәштәшләренә багышланган «Батыр үлә, үлмәс ат алып...» исемле күргәзмә дә оештырылган иде. Искә алу көне кысаларында Җәлил укулары да үткәрелде. Аны уздыруда быел үзенең 25 еллыгын билгеләп үткән Муса Җәлил музей-фатиры хезмәткәрләре башлап йөрде.

## ЛАУРЕАТЛЫККА КАНДИДАТЛАР

Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премияләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия, 2008 елның 5 мартында республика министрлыклары, иҗат берлекләре һәм ведомстволары тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң, 2008 елда Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә дәгъва кылуга түбәндәге эшләрне һәм әсәрләрне тәкъдим итү турында карар кабул итте:

1. МАЛИКОВА Мәдинә Габделхак кызы

«Югалган якутлар» («Рухият» нәшрияты, 2004 ел) һәм «Кызыл гөл» (Татарстан китап нәшрияты, 2005 ел) китаплары өчен.

2. ГАТАУЛЛИН Рәдиф Кәшфулла улы (Рәдиф Гаташ)

«Мәңгелек сусау» («Рухият» нәшрияты, Казан, 2005 ел) һәм «Газәлләр» ("Мәгариф" нәшрияты, Казан, 2001 ел) китаплары өчен.

3. ПОВАРИСОВ Суфиян Шәмсетдин улы

Галимҗан Ибраһимов турында «Пәйгамбәрләр таны» трилогиясе (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2004 ел); «Күкнең җиденче катында» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2006 ел); «Оҗмахка бер адым» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2006 ел) китаплары өчен.

4. ГАЛИУЛЛИН Тәлгат Нәби улы

«Сәет Сакманов. Роман-трилогия» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2005 ел) китабы һәм әдәби-педагогик иҗаты (шул исәптән «Шәхесне гасырлар тудырды» китабы, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2003 ел) өчен.

5. ХАНОВ Илдар Мәнси улы

ТР шәһәрләре һәм районнарында (Казан ш., Чаллы, Арча һәм Аксубай районнарында) монументаль һәм декоратив композицияләре өчен.

6. КӘРИМОВ Камил Әдһәм улы «Ком сәгате» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2000 ел); «Сакау күке» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2005 ел) китаплары өчен.

7. ЗӘЙДУЛЛИН Ркаил Рафаил улы

«Мәгарә» шигырьләр китабы (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2005 ел) өчен.

8. АРШИНОВ Виктор Петрович

«Тукайны укыганда» һәм М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» шигырьләре буенча «Соңгы җыр» сериясеннән графика әсәрләре өчен.

9. Авторлар коллективы: А. Г. ЗИЯКАЕВ, Я. Я. НЕЙМАН, С. П. ОДНОВАЛОВ, Г. Л. ШОЛОХОВА

Санкт-Петербургтагы Г.Тукай һәйкәле өчен.

10. ФӘТХЕТДИНОВ Салават Зәки улы

«Мин яратам сине, Татарстан» җыры (Р. Андреев музыкасы, Р. Рәкыйпов сүзләре), соңгы биш елдагы концерт программалары һәм татар халык җырларын популярлаштыруы өчен.

11. М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының иҗат төркеме: РЕЗЕДА ӘХИЯРОВА (композитор), ӘХМӘТ АГАДИ (төп рольне башкаручы), ВИКТОР СОБОЛЕВ (дирижер), МИХАИЛ ПАНДЖАВИДЗЕ (режиссер).

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында «Шагыйрь мәхәббәте» операсы өчен.

***P.S.*** *Укучыларыбыз игътибар иткәндер: Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә дәгъва кылучы кандидатлар арасында алты язучы бар. Аларның һәммәсе "Казан утлары" журналының актив авторлары. Алай гына да түгел, аларның икесе—Рәдиф Гаташ һәм Камил Кәримов редакциябездә бүлек мөхәррирләре булып эшлиләр, Тәлгат Галиуллин—журналыбызның редколлегия әгъзасы. Хезмәттәшләребезгә уңышлар телибез.*

## УРТАК ЭШЛӘР КҮП

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Госман хәзрәт Исхакый Төркиянең Казандагы генераль консулы Әхмәт Эргин белән очрашты.

Очрашу башында Госман хәзрәт Исхакый Төркия консулын Диния нәзарәте эшчәнлеге белән таныштырып, соңгы ун ел дәвамында республикада исламның үсеше турында сөйләде. Җомга намазларында халыкның, бигрәк тә яшьләрнең күп булуына басым ясады; республикада ун дини уку йорты барлыгын билгеләп, халыкның дини үзаңы үсүен ассызыклады.

Әхмәт Эргин исә рухи өлкәдә алып барылган эшчәнлекне югары бәяләде, консуллыкның планнары белән уртаклашты һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән хезмәттәшлек итәргә әзер булуын белдерде.

## АЛТЫН КОРЪӘН—КАЗАНГА КИЛӘ

Быел Казан Кремленә "Алтын Коръән"нең тулы версиясе тапшырылачак. Тиздән аның беренче битен Кремль кунаклары да күрә алачак. Ә Коръәннең үзен 2009 елда Кол Шәриф мәчетендә урнашкан ислам музеенда күрергә мөмкин булачак.

«Алтын Коръән» VIII гасырда язылган «Госман Коръәне»нең күчермәсе. Аны

Мәскәүдә чыгарганнар. 162 биттән торган бу китапны, махсус эретмәдән эшләп, 999 нчы пробалы алтын белән каплаганнар. Китапның авырлыгы 14 килограмм.

Коръәннән 10 күчермә эшләнер дип көтелә, аның икесе Россиядә калачак. Берсе—Россия Президентына, икенчесе Россиянең берәр музеена бүләк ителәчәк. Калган 8-е ислам дәүләтләренең милли музейларына тәкъдим ителәчәк.

## БЫЕЛ—РӘШИТ ВАҺАПОВ ЮБИЛЕЕ

1 мартта Казанның Зур концерт залында Рәшит Ваһапов исемендәге IV Халыкара татар җыры фестивале башланып китте. Фестиваль кысаларында Свердловск, Түбән Новгород, Саратов өлкәләре, Мордовия, Үзбәкстан, Украина, Төркия, Финляндия, Әзәрбәйҗан, Казахстан, Башкортстан, Санкт-Петербург, Мәскәү тамашачылары игътибарына 37 концерт тәкъдим ителәчәк.

Быелгы фестиваль Р. Ваһаповның тууына 100 ел тулуга багышланганлыктан, аеруча зур әзерлек белән үтәчәк. Фестивальне ачу тантанасы да моны раслады. Тамашачылар Р. Ваһапов репертуарындагы җырларны фестивальнең Гран-при иясе Филүс Каһиров, лауреатлар Айгөл Хәйри, Рөстәм Асаев, Айгөл Сагынбаева, Марсель Вәгыйзов, «Хыял» ансамбле башкаруында тыңлап хозурланды. «Таң атканда», «Кәккүк», «Киек казлар», «Шахта», «Урман», «Гөлҗамал» кебек халык җырлары дөньяга сибелгән халкыбыз йөрәгенә барып ирешер өчен Казан сәхнәсеннән старт алды.

## ШАГЫЙРЬ РУХЫ ТАНТАНАСЫ

Җөмһүриятебезнең әдәби-мәдәни җәмәгатьчелеге Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт, М. Җәлил исемендәге республика премияләре лауреаты Фәнис Яруллинның 70 яшьлек юбилеен зурлап билгеләп үтте. Шушы уңайдан М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында «Былбыллар җибәрәм сезгә...» дип исемләнгән иҗат кичәсе булды.

Бәйрәмдарның сәхнә түренә чыгуын тамашачылар аягүрә басып алкышлады. Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиеваның Президентыбыз Указын игълан итүе дә шагыйрь иҗатын яраткан һәркемнең күңеленә хуш килде. Зилә Рәхимҗан кызы үз чыгышында Фәнис Яруллин әсәрләренең нәкъ менә халык тарафыннан югары бәяләнүен, көчле рухлы каләм иясе буларак, аның тормышта да, язучылык хезмәтендә дә фидакярлек кылуын искәртеп үтте, юбилярны республикабыз җитәкчелеге исеменнән котлап, әдипнең күкрәгенә «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен» орденын беркетте.

Шигырь, җыр, музыка белән аралашып барган иҗат кичәсендә бәйрәм хуҗасын Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Татарстан китап нәшриятының нәфис әдәбият редакциясе мөдире, шагыйрь Харрас Әюп, шагыйрь Газинур Морат тәбрикләде. Юбилярны котларга Баулы муниципаль районы башлыгы Альберт Хәбибуллин җитәкчелегендә якташлары да килгән иде.

Иҗат кичәсендә Фәнис Яруллин шигырьләренә язылган җырларны һәм аның шигъри әсәрләрен Татарстанның халык артистлары Зилә Сөнгатуллина, Зөһрә Сәхәбиева, Мингол Галиев, Гөлзадә Сафиуллина, Равил Шәрәфи, Илдус Әхмәтҗан һ. б. сәнгать осталары башкарды.

## ОЛУГ ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

26 февральдә әдәби җәмәгатьчелек олуг язучы, публицист, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Миргазиян Юнысны тәбрикләде. Тантаналы кичә язучының 80 яшьлеге уңаеннан оештырылган иде. Юбилей кичәсе Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры коллективы тарафыннан әзерләнеп, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында үтте. Анда юбилярны мәдәният министры урынбасары А. Җаббаров тәбрикләп, Президентыбыз М. Шәймиевнең Рәхмәт хатын укып ирештерде. Илбаш язучының шәхесен олылый, иҗатын югары бәяли.

—Миргазиян ага—халкыбыз язмышын дингез, океаннар аша чагылдырып, әдәбиятыбызда үзенә бер яңа юл салган әдип ул,—диде үз чыгышында Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов.—Әдәбиятыбыздагы мәңгелек тема—сагыш, җирсү темасы аның бөтен әсәрләрендә дә үзәктә тора. Миргазиян Юныс—гомере буе чит җирләрдә йөреп, гыйбрәт алып, галим, акыл иясе, тирән фәлсәфәче булып ирешкән язучы...

М. Юныс татар язучыларына халыкара оешмага берләшү кирәклеген дәлилләп, Татар ПЭН үзәген оештыруда башлап йөргән кеше дә. Юбилей кичәсендә бәйрәмдарны Татар ПЭН-үзәге исеменнән, күренекле драматург Т. Миңнуллин тәбрикләде.

—Татар язучыларының күбесе авылдан чыккан. Шуңа күрә безнең әсәрләребездә уй-фикерләребез гел авыл тирәсендә бөтерелә,—диде ул.—Миргазиян Юныс исә әдәбиятыбызга дингез темасын алып килде, безне, җирдә нык басып торганда гына үзебезне көчле тойган кешеләрне, очы-кырые күренмәгән дингезләргә, зәңгәр күкләргә әйдәп сокландырды, курыкмаска өйрәтте.

Юбилярны шагыйрьләр Р. Әхмәтҗан, Р. Рахмани, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире Р. Корбан, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары

Ә. Шакиров, Д. Нурлы, якташлары баулылар, авылдашлары, Актаныш районы вәкилләре һәм җырчы, музыкантлар котлады.

## ЛЕГЕНДАР ШӘХЕСКӘ—ХӨРМӘТ

Ульяновск өлкәсендәге Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә «Восход» Мәдәният һәм ял үзәгендә шагыйрь, рәссам, Г. Исхакый, Ш. Маннур, халыкара «Филантроп» премияләре лауреаты, балачактан урын-җир өстендә ятарга, шигырьләрне әйтеп торып рәсемне карандашны авызына кабып ясарга мәҗбүр булган Гакыйль Сәгыйровка 70 яшь тулу уңаеннан иҗат кичәсе үткәрелде. Димитровград шәһәре хакимияте һәм татар милли-мәдәни мөхтәрияте оештырган бу кичәдә Ульяновск өлкәсе губернаторы—хөкүмәт рәисе Сергей Морозов катнашты һәм чыгыш ясады.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев юбилярга Татарстан Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Татарстан Президентының Мәдәниятне үстергә ярдәм фонды, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе котлауларын, бүләкләрен ирештерде. Г. Сәгыйровны Татарстан каләм ияләре исеменнән язучы, тәрҗемәче Лирон Хәмидуллин да котлады. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисенең беренче урынбасары Рәмис Сафин, Норлат муниципаль районы башлыгы урынбасары Фәнис Нәбиуллин, «Ватаным Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе Илдус Диндаров, Ульяновск өлкәсенең һәм Димитровград шәһәренең татар милли мәдәни мөхтәриятләре җитәкчеләре, Самара, Тольятти, Ульяновскидан килгән олы кунаклар, каләмдәшләре һәм башкалар шагыйрьгә иң җылы хисләрен, изге теләкләрен җиткерделәр.

Шундый ук кичә Гакыйль Сәгыйровның туган ягы Нурлатта да үткәрелде.

## ИЖАУДА ӘДӘБИЯТ БӘЙРӘМЕ

Удмуртиянең Ижау шәһәрендәге «Спартак» халык иҗат йортында Татарстан Язучылар берлеге бүлекчәсе ачылды. Әлеге бәйрәм кысаларында бу төбәктә туып-үскән язучы Риза Шәфинең тууына 85 ел тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә дә булып узды. Бүген Удмуртиядә Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары—Ренат Баттал, Ибраһим Биектаулы, Гыйймран Сафин, Гөлфия Исхакова кебек каләм әһелләре яшәп иҗат итә. Ижау шәһәрендә узган тантанада шагыйрь, Татарстан Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов катнашты.

## ХАЛЫК ШАГЫЙРЕН ИСКӘ АЛУ

Күптән түгел Муса Җәлилнең Казандагы музей-фатирында Илдар Юзеевның иҗат кичәсе булып узды. Бирегә шагыйрьнең хатыны Тәфтилә ханым, иҗатташ дуслары, Казанның 7 нче интернат-лицее укучылары килгән иде. Кичәнең М. Җәлилнең музей-йортында узуы очраклы түгел. Шагыйрь бирегә еш булган. Плетцензее төрмәсендә утырган мөселманнарга, шул исәптән, җәлилчеләргә мулла белән очрашу мөмкинлеге тудырылуы турында ишеткәннән соң, «Читләрнең үз бәясе» исемле шигырен дә язган.

Үзе дә янда булган кебек җылы һәм җанлы үтте ул кичә. Аудио-кассетадан булса да, үз тавышы яңгырады, шигырьләре укылды, Татарстанның халык артист Исламия Мәхмүтова, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Мәсгут Имашевлар башкаруында җырлар янгырады. Шулай ук, шагыйрьнең улы Салават Юзеевнең әтисе турында төшергән документаль фильм да күрсәтелде.

## «АЛТЫН МӨНБӘР» КИРЕ КАЙТА

«Алтын мөнбәр» III Халыкара мөселман киносы фестивалендә күрсәтелгән фильмнар янәдән тамашачыларга тәкъдим ителәчәк. «Алтын Мөнбәр кайтавазы» программасы кысаларында 10 документаль һәм нәфис фильм күрсәтү планлаштырыла. Алар арасында дөньяның төрле илләрендә төшерелгән «Доброе утро», «Древо мира», «Нить», «Туземцы» һәм җиңүче—«Баба Азиз» фильмнары бар. Аларны апрель аенда "Мир" кинотеатрында карарга мөмкин.

IV «Алтын мөнбәр» фестивале Казанда август ахырында узачак.

## ФАТИХ ХӨСНИ ОНЫТЫЛМЫЙ

Казанның Актерлар йортында Татарстанның халык язучысы Ф. Хөснинең тууына 100 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булды. Зал классик язучыны яхшы белгән өлкән буын кешеләре һәм яшьләр белән шыгрым тулы иде. Алар арасында язучының туган ягы—Теләчедән килгән вәкилләр дә бар иде. Кичәдә Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, язучы-галимнәр Ф. Галимуллин, Р. Сверигин, Р. Батулла, һ. б. чыгыш ясады. Истәлек сөйләүләр сәнгать осталарының чыгышлары белән үрелеп барды. Сәхнәдән язучының кайбер популяр әсәрләре һәм халык җырлары яңгырады.

## КОМПОЗИТОРНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

29 февральдә Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, композитор Ренат Еникеевка 70 яшь тулу уңаеннан симфоник музыка кичәсе узды. Сәхнәдә "Муса Җәлил истәлегенә" дигән вокал-симфоник поэма, «Төрки җырлар» һәм башка әсәрләр яңгырады.

Кичәдә Россиянең, Казахстанның, Татарстанның халык артисты Фуат Мансуров җитәкчелегендәге ТР симфоник оркестры, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, скрипкачы Шамил Монасыйпов, Татарстанның атказанган артисты Марат Сиразетдинов, Татарстанның халык артисты Мөнир Якупов һәм башкалар катнашты.

Мәшһүр композиторны Республиканың рәсми вәкилләре, хезмәттәшләре, Морзалар мәҗлесе әгъзалары котлады. Алар Р. Еникеев иҗатына соклануларын белдерделәр, уңышлар теләделәр.

### СӘХНӘДӘ—ЯШЬ ТАЛАНТЛАР

«Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Йолдызлык-2008» яшьләр эстрада-җыр фестиваленең Казан этабына йомгак ясалды. Анда 300дән артык яшь сәнгатькәр чыгыш ясады. Алар арасыннан сайлап алынган 175 җырчы, 58 җыр һәм 50 бию төркеме «Пирамида» сәхнәсендә «Йолдызлык» фестиваленең финалында катнашу өчен көч сынашты. Җиңүчеләрне «Вокал-соло», «Вокал ансамбльләре», «Хореография», «Конферанс», «Иң яхшы көй иҗат итүче», «Иң яхшы җыр тексты язучы» кебек номинацияләрдә билгеләделәр. Лауреат исеменә лаек булучы яшь талантлар 26 апрельдә үтәчәк фестивальнең гала-концертында катнашачак.

### «ХӘЗИНӘ»ДӘ ТӨРЕК РӘСЕМНӘРЕ

"Хәзинә" милли сәнгать галереясында төрек рәссамы Мераль Озджанның шәхси күргәзмәсе ачылды. Анда рәссамның "Эбру" техникасы буенча башкарган эшләре тәкъдим ителә. Мераль Озджан—дөньякүләм танылган сәнгатькәр. Төрки мәдәниятне үстерүгә зур өлеш керткән шәхес. Безнең яшь рәссамнар өчен ул Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм "АРТ-ЭКО" галереясында "Эбру" техникасы буенча мастер-класслар да оештырды.

### МИРАСЫБЫЗНЫ БАРЛЫЙБЫЗ

Татарстан китап нәшриятында берьюлы ике китап-альбом дөнья күрде. Аның беренчесе «Бакый Урманче иҗатында Габдулла Тукай» дип атала. Альбом рәвешендәге бу китап рәссамның шагыйрьгә рухи һәм гамәли мөнәсәбәтен чагылдыруда беренче җитди адым дип бәяләнергә хаклы. Китапның төзүчесе—Флора Әхмәтова-Урманче.

Икенче китап-альбом татар графикасының беренче профессиональ осталарыннан булган рәссам Шакир Мөхәммәтҗановның тормыш һәм иҗат юлына багышлана. Китапта Ш. Мөхәммәтҗановның тәрҗемәи хәле, аның матбугатта басылган мәкаләләре, шулай ук Бакый Урманченың рәссам-графикка багышланган мәкаләсе тәкъдим ителә.

### КОРАБ ОБРАЗЫ ГЫЙЛЬМИ ХЕЗМӘТТӘ

Журналыбызның даими авторы, шагыйрә Луиза Янсуар (Шарова Луиза Николаевна) Казан дәүләт университетында «XX йөз татар шигъриятендә «кораб» («көймә») образ-символы» дигән темага (фәнни җитәкчесе—филология фәннәре докторы, профессор Р. К. Ганиева) кандидатлык диссертациясе яклады. Оппонентлары күренекле әдәбият белгече Н. Хисамов һәм галимә Р. Мусабәкова.

Әлеге хезмәт дөнья әдәбиятында киң таралган, универсаль сурәтләрнең берсе булган «кораб» образ-символының генетик тамырларын, мифологиядә, борынгы чыганакларда бирелешен, татар әдәбиятына үтеп керү юлларын барлауга һәм бүгенге татар шигъриятендә, дөнья әдәбияты контекстында аның үсеш-үзгәрешен, трансформацияләрен күзәтүгә багышланган.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар милли әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе, Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен язучы **Яруллин Фәнис Гатаулла улы** «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Тукай алиһәсе». **Рөстәм Килдебәков** картинасы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* драматург **Мансур Гыйләҗев**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татар әдәбияты зур югалтуга дучар булды. 21 февральдә, 75 нче яшендә танылган шагыйрь, язучы һәм әдәби тәрҗемәче **Марс Садри улы Шабаев** дөнья куйды.

Марс Шабаев 1933 елның 14 июлендә Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында укытучы гаиләсендә туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Минзәлә педагогия училищесында белем ала. 1953-58 елларда ул Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Шуннан соң аның журналистика өлкәсендәге күпьеллык эшчәнлеге башланып китә: 1958-60 елларда ул—Татарстан радиокомитетында әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире, 1961-64 елларда—«Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, аннары 1967 елның апреленә кадәр «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналының җаваплы секретаре булып эшли, 1968-70 елларда «Чаян» журналында тәрҗемәче һәм Татарстан Язучылар берлеге химаясендә чыга торган «Идел» альманахының җаваплы мөхәррире булып эшләгәннән соң, М. Шабаев Татарстан китап нәшриятына эшкә күчә, анда баш мөхәррир урынбасары, ә 1972-77 елларда баш мөхәррир һәм 1983 елның октябренә кадәр нәфис әдәбият редакциясендә өлкән мөхәррир хезмәтендә була. 1984-91 елларда М. Шабаев профессиональ язучы сыйфатында әдәби иҗат белән шөгыльләнә. 1991-2004 елларда «Казан утлары» журналында эшли, әүвәл җаваплы секретарь, аннары бүлек мөхәррире була.

Марс Шабаевның шигырьләре көндәлек матбугатта узган гасырның 50 нче елларыннан күренә башлый. «Яңа җыр» дигән беренче китабы 1962 елда басылып чыга. Шул 60 нчы еллар дәвамында гына да шагыйрьнең тагын 7 җыентыгы дөнья күрә. «Җикән камыш», «Онытма» һәм урысча чыккан «Ищу тебя» исемле җыентыклары өчен М. Шабаев 1976 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

М. Шабаев проза һәм тәрҗемә өлкәсендә дә нәтиҗәле эшләде. Ул—«Салда сәяхәт» дигән повесть һәм күп кенә лирик хикәяләр авторы. Америка шагыйре У. Уитменның «Үлән яфраклары» исемле шигъри китабы М. Шабаев тәрҗемәсендә татар телендә чыгуы (1975) татар тәрҗемә әдәбиятында вакыйга буларак кабул ителде. Ул Е. Евтушенконың «Казан университеты», «Әни һәм нейтрон бомба» поэмаларын, Р. Мирхәйдәров романнарын тәрҗемә итеп бастырды.

М. Шабаев—татар әдәбиятының яшь көчләрен үстерүгә күп көч куйган әдипләребезнең берсе иде. 60 елларда поэзиягә килгән шагыйрьләрнең байтагы аны үзләренең остазы дип саный.

1984 елда М. Шабаевка Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде.

Марс Садри улы Шабаев үзенең күпкырлы иҗаты белән татар әдәбиятында якты эз калдырды. Аның истәлеге укучылар күңелендә озак сакланыр.

**З. Вәлиева, Г. Куприянов, Р. Вәлиев, Т. Миңнуллин, Р. Миңнуллин, И. Ибраһимов, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Д. Шакиров.**

# Яңа китаплар




**Рабит Батулла.** Урыннары җәннәттә булсын!: мәрхүм шәхесләребез турында мәрсияләр, хатирәләр.—Казан: "Рухият" нәшр., 2007.—992 бит. Тиражы—1500 данә.

Әкиятче, хикәяче, мәзәкче, драматург, сценарист, тәрҗемәче, тарихи кыйссалар иҗат итүче әдип, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Рабит Батулла олуг шәхесләребез турында нәсер-хатирәләрне тәфсилләп теркәп барган язучы. Бу хатирәләрнең кайсы магнитофонга, кайсысы куен дәфтәренә язылган, кайсысы видеотасмага төшерелгән. Атаклы шәхесләребез турындагы еллар буе тупланган шушы кадерле хатирәләр, ниһаять, бер китап рәвешенә китерелгән. Татар әдәбияты, сәнгате тарихына битараф булмаган һәр кеше өчен кыйммәтле чыганак бу китап.



**Нәҗибә Ихсанова.** Уйнап узган гомер: истәлекләр, уйланулар, әңгәмәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.—344 б. Тиражы—3000 данә.

Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нәҗибә Ихсанова үзенең бу китабында тормышы һәм иҗаты турында уйланулар, истәлекләр белән уртаклаша. "1956 елдан алып бүгенге көнгә кадәр минем җаным театр дөньясында кайнады. Аның һәрбер көне йөрәк аша үтеп, хәтергә сеңеп калган. Газаплы һәм татлы истәлекләрне бүтәннәр белән уртаклашасы килде", дип яза автор китапның кереш сүзендә. Китапта шулай ук әңгәмәләр һәм иҗатташлары хакындагы язмалар, күпсанлы фоторәсемнәр дә урын алган.



Мансур Гыйләҗев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)